Ибраһим САЛАХОВ

Колыма хикәяләре

ТАТАРСТАН
КИТАП
НӘШРИЯТЫ



Ибраһим САЛАХОВ

Колыма хикәяләре

Фаҗига-хроника

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2017

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4
С18

Текст 1989 елгы басмадан алынды.
(Колыма хикәяләре. Фаҗига-хроника.
Аяз Гыйләҗев кереш сүзе. – Казан:
Татар. кит. нәшр., 1989. – 255 б.)

Салахов, И. Н.

С18 Колыма хикәяләре : фаҗига-хроника / Ибраһим Салахов ; [кереш сүз авт. А. Гыйләҗев]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2017. – 279 б.

ISBN 978-5-298-03504-0

Күренекле язучы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Ибраһим Салаховның әлеге китабында «Колыма хикәяләре» роман-хроникасы бирелде. Әсәрдә тоталитар режимның кешелексез сәясәте, зинданнарда, концлагерьларда хаксызга һәлак ителгән миллионлаган репрессия корбаннарының ачы язмышы сурәтләнә.

УДК 821.512.145-3
ББК 84(2Рос=Тат)-4

ISBN 978-5-298-03504-0
© Татарстан китап нәшрияты, 2017
© Салахов И. Н., варислар, 2017

ҖАН АВАЗЫ

«Казан утлары» журналының 1988 елгы 4–6 нчы саннарында Ибраһим Салаховның «Тайгак кичү» исеме белән басылган һәм киң катлау укучылар тарафыннан хуплап каршыланган әлеге әсәре, авторның йөз аклыгы булу белән бергә, татар халкының горурлыгы да, казанышы да. Утыз җиденче, аннан соңгырак елларда Сталинның үлем чалгысы татар мәдәнияте, әдәбияты вәкилләрен дә кыеп үтә. Күпме асыл ирләр, революция солдатлары һәлак була. Культ корбаны булган язучыларны санап бетерерлек түгел, аларның исемнәре, торган саен, яшәгән саен, якты нур белән өртелә бара. Ибраһим Салахов – шул якты төркемнән исән калган бердәнбер олпат аксакалыбыз. Үзе яшәгән заманны аңларга тырышып, үзе күргән вакыйгаларга гадел бәя биреп, үзенең юлдашларына бөек һәйкәл корып, шушы әсәрен иҗат иткән. Эчтәлеге ягыннан гаять үзенчәлекле, документаль төгәллек белән язылган бу әсәр – Сталин чорының роман-хроникасы да, илебез халыкларының тирән фаҗигасе дә. Шуның белән бергә, бик күп миллионнар арасыннан могҗиза белән генә исән калган Ибраһим ага Салаховның җан авазы да.

Бу китап сез моңарчы укыганнарның берсенә дә охшамаган. Ибраһим Салахов шактый гомерен шушы әсәрне язуга багышлаган. Автор үзе бу әсәрен бер сүз белән генә «Фаҗига» дип атау ягында тора. Болай дип атау – гадел, дөрес бәя! Мәгәр бу шомлы сүз генә әсәрнең бөтен тукымасын, бәян ителгән гадәттән тыш вакыйгаларны үзенә сыйдырып бетерә алмый. Әсәр формасы белән дә, эчтәлеге белән дә моңарчы без белгән әдәби калыпларга сыймый, аңа үзгә бәя, яңа үлчәү кирәк.

Белорус язучысы Василь Быков бервакыт: «Рус һәм башка әдәбиятларда моңарчы басыла алмаган, заманабызның каршылыклы чорын реалистик тасвирлаган әсәрләр дөнья күрә башлагач, сөрсегән обывательләре-

бездән бирәү: «Шөкер, безнең әдәбиятта сандыкта качып яткан әсәрләребез юк!» – дип чыгыш ясады», – дип, йөрәк әрнүен уртаклашкан иде. Милләтебезнең кайбер «акыл ияләре» арасыннан да, ашыгып-ашыгып: «Татарда кайчандыр язылып та басылмый калган әсәрләр юк!» – дип белдерүчеләр булмады түгел, булды, әмма татар әдипләренең учагында ут сүнмәгән икән. Кайберәүләр әзер лозунгларга иллюстрацияләр язып, чиндәрәҗәләр, бүләкләр алырга ашкынып, комсызланып, заманның зарарлы кешеләренә ялагайланырга тырышып ал буяуга манылган ялган әсәрләрне бер-бер артлы бастыра торганда, кемдер намус кушканны эшләгән: басылмасын белгән хәлдә, өметсезлеккә бирелмәгән, иҗат иткән, үз сүзен әйтеп калдырырга тырышкан. Шуның иң гыйбрәтле, иң уңышлы мисалы – Ибраһим Салаховның әлеге китабы.

Әсәрдә канлы тиран Сталин үзе күренми. Әсәр дәвамында хаксыз рәвештә җәбер-җәфаларга дучар ителгән бәхетсезләр аның исемен өмет белән яд итәләр. Ул чорның иң тирән каршылыгы да шунда инде әнә! Сталин әсәрдә үзе күренмәсә дә, күзәтүчән, ачык зиһенле Ибраһим Салахов аның портретын төгәл вакыйгалар белән ачып бирә алган.

Сугышка кадәр укылган бер китап хәтеремә үтә нык сеңеп калган. Атаклы немец антифашисты Вилли Бредельның «Сыналу» дигән романы иде ул. Кеше рухын сыту, изү остасы, палач Гитлер үзенә каршы чыккан коммунистлардан үч ала, күп санлы гаепсезләр белән рәттән, асылда, үз дошманнарын җәзалый, кыра. Сталин, үзен Ленинның дәвамчысы дип игълан итеп, иң беренче нәүбәттә Ленин гвардиясен, революциянең тугры солдатларын, совет властеның аңлы, алдынгы вәкилләрен дулкын-дулкын кисеп, таптап үтә, нәсел-токымнарын харап итә, аларның балаларын, туганнарын, танышларын, хезмәттәшләрен тормыштан алып ташлый. Мең һәм миллионлаган көрәшчеләрне эзсез юк итә.

Дөрес, бу фактларны, бу тарихи дөреслекне ул чакта күпләр бөтен тулылыгы белән аңлап бетерә алмаган. Сталин режимының канлы нәтиҗәләрен без партиянең XX съездыннан соң гына күз алдына китерә башладык. Шулай да бу әсәр тарихи дөреслеге, чынлыгы белән шушы

характердагы әсәрләр арасында аерым бер урын тота, чөнки аның авторы үзе күргәннәрне, үзе татыганнарны, үзе кичергәннәрне яза. Бу әсәрдә татар халкының бик күп газиз балалары якты сүз белән телгә алына: Хәсән Туфан, Мохтар Мутин, Сөббух Рәфыйков... Тагын бик күп, бик күп язмышлар, кыска-кыска гына эпизодларда күренеп китсәләр дә, хәтердә уелып калырлык дәрәҗәдә язылганнар. Төрле катлау, төрле милләт вәкилләре иң авыр елларда да, иң читен юлларда да горур башларын түбән имиләр, сатмыйлар, сатылмыйлар, хыянәткә бармыйлар, туганнарча бер-берсен олылап, бер-берсенә рух өстәп, чын патриотларча төрмә-каторга сиратын кичәләр. Әсәрнең һәр сәхифәсеннән, һәр юлыннан батырлык, кыюлык, гаделлек бөркелеп тора.

КПССның XIX Бөтенсоюз конференциясендә Ватаныбыз башкаласы Мәскәүдә хаксызга җәзаланган ил уллары хөрмәтенә һәйкәл салырга дигән карар кабул ителде. Ибраһим ага Салахов үзенең әлеге китабы белән шул мәгърур һәйкәлнең нигез ташын салучыларның берсе булып саналачак.

Аяз Гыйләҗев,
Татарстан Республикасының
халык язучысы

Тыштан солдат,
Ә эченнән җәллад,
Күрәгендә агу һәм мәкер;
Ул йөрәкне күрсә, Нерон чирканыр,
Торквемада кәфенен бөркәнер.

ЮЛ БАШЫ

1

Институтның тулай торагыннан чыкканда, таң атып, кояш инде күтәрелә дә башлаган иде. Гадәттә, мондый көзге иртәләрдә Казан өстенә Иделне каплаган куе томан сарыла, көн җылынып беткәнче, шәһәр шуннан арына алмый – ак чыбылдык астында кала иде.

Бүген ул томан да юк – күк йөзе күм-күк. Көнчыгыштан көлтә-көлтә алтын нурлар сибелә. Көн җылы, матур булыр, ахрысы. Иртәнге салкын һәм дымсулык, мөгаен, кичәге яңгырның сулышы гынадыр. Гаҗәп! Югыйсә инде «әбиләр чуагы» узганга да айдан артык. Бүген октябрьнең егерме бише бит инде. Бәйрәмгә дә ерак калмады – ике атнадан да ким. Быелгы бәйрәм аеруча тантаналы, күңелле булыр – Бөек Октябрьгә егерме яшь тулачак.

Безнең институт колоннасын бәйрәм демонстрациясенә алып чыгуны ректор быел да миңа тапшырды. Ни генә әйтмә, командир кисәге бит мин. Институтка килеп кергәндә, шинель петлицаларымда чия кызыл өчпочмаклар яна иде... Әле дә өстән хәрби мундир төшми. Ләкин студентларның әзерлеге ташка үлчим, инде ике тапкыр җыелдык – саф дигәннең исе дә юк, сыер көтүе кебек, беребез алда, икенчебез артта. Бигрәк тә кызлар шырык-шырык көлеп теңкәгә тия. Кычкыра-кычкыра тамагым карлыгып бетте. Ай-һай, бу хәтле дә йөгәнсез булыр икән хатын-кыз дигән халык!

Дөресен әйткәндә, әле кайсы факультет артыннан кайсы барасы да ачыкланмаган. Беренче җыелуда тарих факультеты алда иде. Икенчесендә, маршировка

вакытында, ректор минем планны бозды да ташлады. «Алдан биофак барсын. Анда кызлар күп, чәчәкләр белән чыгарлар», – дип, бер көтү йөгәнсез кызны колонның алдына бастырды. Ачуымнан шартларга җитештем, чак-чак кына ректорны сүгеп ташламадым – тешләремне кысып калдым.

Ә менә кичә төнлә үзен, ректорны әйтәм, кулга алганнар, халык дошманы булган, ди. Кем белә, булса булгандыр, революциягә хәтле чит илдә укып кайткан зыялы бит. Болай үзе бик Совет яклы булып сөйли иде. Кем әйтмешли, кеше карбыз түгел, эчен ярып карап булмый. Безнекеләр юкка, бер дә тикмәгә кулга алмаслар...

– Борыл, уңга!

Кырыс әмер уйларымны бүлдерде. Мин ялгыз гына түгел, өчәү барабыз икән ләбаса.

Толстой тыкрыгыннан борылып, безнең тулай торак шушында, Карл Маркс урамына чыктык. Монда буп-буш, машиналар да күренми. Әле трамвайлар да шалдыр-шолдыр йөри башламаган. Кала өчен сәер бер тынлык. Асфальт түшәлгән киң урамның ике ягы буйлап тезелгән өчәр, дүртәр катлы ташпулатларның тәрәзәләрендә пәрдәләр. Йоклыйлар. Иртәнге тәмле төшләрен күрә-күрә йоклыйлар булыр бу йортлардагы казанлылар.

– Шарт-шорт!

– Шарт-шорт!

Эңгер-меңгердә йокымсырап торган урам, сискәнеп-сискәнеп, безнең өч пар дагалы итекнең шакылдавын кабатлый:

– Шарт-шорт!

– Шарт-шорт!

Уң ягымдагы опервәкил (ул үзен шулай таныштырды) буйга миннән аз гына калку, гәүдәгә дә тулырак. Күкрәге киерелеп алга чыккан. Башы югары күтәрелгән – парадта Мавзолей янынннан узамыни. Бик тырышып кырынган булуына да карамастан, сакал-мыеклары күгәреп тора. Борыны бөкре. Кашлары кап-кара, бергә кушылып, эчкә баткан ачулы күзләрен каплап торалар. Зәһәр, усал күренә, сөйләшми. Янындагы яшьрәк егеткә боерыкны кашлары белән генә бирә; аларны бер төшерә, бер күтәрә, янәсе, алып кал, алып кит минем кәгазьләрне (хәзер ул яшүсмер-солдат сул ягымнан атлый). Тегесе,

шуны төшенеп, боерыкны үтәп кенә тора – ишарәләр белән фәрман бирүгә өйрәнеп беткән, күрәсең. Бәлки, мондый җаваплы хезмәткәрләр шулай ым белән генә сөйләшергә тиешләрдер. Минем кызым кияү күргәнмени, кодагый, дигәндәй, алар белән кем аралашкан. Тәбәнәк яшүсмер солдат безнең озын-озын итеп атлауга иярә алмый аптырап бетте, гел ялгыша, җәһәт кенә ике-өч адым алга чыгып та карый, тик теге усал кашлар бүселеп күзгә төшкәч, тагын янәшәбезгә баса. Җитмәсә, шинеле дә озын, атлаган саен, ашыккан саен, чабуларына урала...

– Тукта!

Атылып килгән автомашина астына чак кына барып кермәде яшь күршем. Машина безне җиле белән кагып, шофёр тормозга баскан, күрәсең, чинап сискәндерде.

– Киттек!

Тагын асфальт дөпелди башлады:

– Шарт-шорт!

– Шарт-шорт!

Әй, әйтергә онытканмын бит әле, сул яктагы солдат минем бер кочак китапларны, кульязмаларны күтәреп бара. Җәймәгә төреп бәйләнгән хәзинәдә Күкчәтауда вакытта ук язылып, калын-калын дәфтәрләргә күчерелгән шигырьләр, поэмалар, хикәяләр дә бар. «Тау гыйшкы» дигән хикәянең тышлыгына Нури Арсланов кыя-ташлар ясаган иде. Алар арасыннан ике ачулы күз карый. Күзләр арасында – хәнҗәр... Хәнҗәрдән кан тамчылый... Менә хәзер шул «контр кәгазьләр»не солдат күтәреп бара. Әле бер, әле икенче кулына күчерә – кәгазь авыр була бит ул. Үзем булышыйм, дигән идем, опер кашларын җыерды:

– Яр-рамый!

Бигрәк әйбәт, югыйсә мин дә, бу солдат сыман, ул «контр» төенне күтәреп килә-килә, шабыр тиргә төшкән булыр идем.

...Әй, әкәмәт тә булды инде тентүләре! Нәкъ бер яшерен-хәтәр әйбер эзләгән сыман кыландылар. Юкса аркылыга-буйга өчәр метрдан артмаган студент бүлмәсендә ни табасың – карават, өстәл, тумбочка, китаплар да кульязмалар гына инде. Соңгылары – тумбочкада, карават астында, тәрәзә төбендә. Күбесе инде кояшта ята-ята саргаеп беткән. Монда Ленинның утыз томлыгы, Маркс, Энгельс әсәрләре, дәреслекләр һәм әдәби

китаплар – Горацийдан башлап М. Горькийга хәтле. «Тиле таш җыяр, син китап җыясың», – ди торган иде өйдә вакытта әни мәрхүмә. Монда, Казанда, чыннан да, гонорар алган саен, бер кочак китап күтәреп кайта торган булдым. Хәзер инде менә шуларның астын өскә китерәләр. Опер дигәне һәр китапның бит араларын тикшереп-карап утыра. Көләсем килә: ни эзли? Әллә инде, патша төрмәсендә утырган революционерларныкы төсле, китап юллары арасына сөт белән язылган «контр» сүзләр-өндәмәләр бар дип уйлыймы? Кыяфәте! Шундый җитди, бөтен игътибары әлеге саргаеп беткән китап битләрендә – кашлар җыерылып, асылынып төшкән. Актара да актара. Әйдә бер рәхәтләнсен, ни табар икән?!

Бервакыт чират гарәп хәрефләре белән язылган караламаларыма килеп җитте.

– Бу ни бу? – Ачуыннанмы, әллә бик җитди бер гаеп таптым дип куануыннанмы, опер сикереп торды. – Бу нинди кыргаяк эзләре?

– Бу бит безнең элекке алфавит.

– Конспирация! – Опер солдатка текәлде. – Кара, бу конспиратив кәгазьләрнең барысын да бер битен дә калдырмыйча җыеп бәйлә!

Солдат, чын-чынлап каушап, ашыгып, кульязмаларымны җыярга тотынды. Шигырьләр, хикәяләр, әле язылып яткан «Мәхәббәт һәм өмет»[1] романымның караламалары.

– Ә менә монда... Нинди хәнҗәр? Нигә кан? Ә?

Мин чыдый алмадым, көлеп җибәрдем:

– Бу бит «Тау гыйшкы» дигән хикәямнең тышлыгы.

– Ыржайма! – Опер калын дәфтәргә язылган хикәяне кулымнан тартып алды. – Димәк, террорга өндисез! Яле?

Моннан соң опер үзе дә караватастына кереп китте. Бөтен чүп-чарны тартып чыгарып актарырга кереште. Мин тәрәзә төбенә менеп утырдым – әйдә, рәхәтләнеп бер тузанга буялыгыз.

Институтның тулай торагында, нигездә, биш-алты кешегә исәпләнгән бүлмәләр. Ә менә ике кешелеге берничә генә иде.

Деканат, яхшы укыйлар, иҗат эше белән шөгыль-

---

[1] Әсәрнең беренче бүлекләре «Кызылармеец» газетасында басылган да иде инде.

ләнәләр дип, аларның берсен, түбән каттагысын, Хатип Госманов[1] белән миңа биргән иде. Хатип белән бик тиз дуслаштык: сер уртак, бер сынык икмәкне бүлеп ашыйбыз. Кичә, ул бер атнага Васильевога киткәч, бүлмәдә ялгызым гына калган идем.

Әүвәле иртәгәге лекцияләргә әзерләндем – укыдым, конспектлар яздым. Аннан «Мәхәббәт һәм өмет»кә тотындым.

Язучы иҗатында гаҗәп кызык хәлләр була икән. Менә романның кереш өлеше һәм ахыры язылып беткән. Ә уртасы – юк, тотынылмаган да.

Сәбәп? Сәбәп менә нәрсәдә: романның баш герое политрук Гыйльфанов, чик буе бәрелешләренең берсендә яраланып, японнар кулына әсирлеккә төшә. Билгеле инде, аны төрмәгә ябалар, сорау алулар башлана. Чик буе корылмаларының планын, Кызыл Армиянең техник көчләре турында сөйләүне таләп итәләр. Бу сорауларга җавап бирмәгәч, аны газапларга тотыналар.

Менә шушы бүлекләрдә вакыйганы нәкъ япон төрмәләрендәге кебек итеп, бар вәхшилеге белән тасвирларга кирәк бит. Ә ничек? Мин бит үз гомеремдә төрмә, камера, карцер, сорау алу, надзиратель, тикшерүче дигәннәрне күргән кеше түгел. Язучы бары үзе күргән-белгәнне генә язарга тиеш. Укучыларның күңелен җәлеп итәргә тели икән, һичбер уйдырмага урын бирмәскә тиеш. Дөресен генә әйткәндә, мин инде эчемнән, Печән базарына барып, берәр вак-төяк әйбер урлап тотылырга да төрмәгә эләгергә дип план корып йөри идем.

Язып утыра-утыра күзләрем чепелди башлады – арыдым. Сәгатькә карасам, төнге ике икән инде. Чишенә башладым. Ишекне шакыйлар. Мөгаен, Хатип кайткан – ял йорты ошамагандыр, әллә авырып киттеме? Ашыгып ишекне ачсам, менә бу чакырылмаган кунаклар. Башта аптырап киттем.

– Менә ордер, – дип, бер кәгазь суздылар, төшенмәдем, шулай да алдым.

Менә хәзер минем барлык кульязмаларны, гарәп хәрефе белән басылган китапларымны, зур ике төргәк итеп төреп, үзем белән бергә алып киләләр. Кая алып баруларын әйтмиләр – барыбер беләм. Көтмәгәндә Ходай

[1] Соңрак филология фәннәре докторы, профессор булды.

үзе төрмә капкаларын ачты бит әле. Тик менә төрмәгә кертмичә кайтарып җибәрмәсәләр генә ярар иде (бар план җимерелә бит), роман, бетмичә, ярты юлда калачак.

Әй, мәзәк тә булды бит әле чыкканда. Бүлмәне астын өстенә китереп туздырып бетергәч, опер үзе дә арыды, ахрысы:

– Җитәр. Киттек, – диде һәм солдатка төргәкләрне күрсәтеп ымлады: – Ал боларны.

Мин, шинелемне киеп, тумбочкадан бер пачка папирос эләктердем дә ишеккә атладым. Ул ачылгач, ни күзем белән күрим – Зәйтүнә. Чәчләре тузгыган, үзе эчке күлмәктән генә.

– Ибраһим!

Ул, акырып елап, муеныма сарылмакчы иде, опер арабызга кереп басты:

– Яр-рамый!

Башта, үзен сугып егасым килеп, ачуым ташыган иде, аннан суындым. Чын-чынлап кулга алынгандай булсын инде дип, башымны иеп чыгып киттем. Зәйтүнә бер адым артка чигенде дә караватыма егылды. Үзе һаман үксеп-үксеп елый...

– Тукта!

Баскычка абынып егыла яздым. Алдыбызда бихисап зур ишек. Аның ике ягында мылтыклы ике сакчы, сын төсле катып торалар.

– Уз!

Мин, бусаганы атлап, эчкә үттем. Ишекләр шыгырдап ябылды.

2

Бер йомшак кына пышылдап, яшерен сер сөйләп, бер ярсып ярларга сугылып чәчри бу дулкыннар, сихри, илаһи дулкыннар... Менә алар тагын якынлашалар һәм, назлы кочаклап, рәхәтлек диңгезендә тирбәтәләр. Нинди гаҗәп могҗиза бу «Амур дулкыннары».

Гадәттә, тикшерүче Бикчәнтәев, өенә җыенганда, тимер рәшәткәләр белән ныгытылган тәрәзәдәге форточканы шап итеп ябып бикләп куя иде, бу юлы ашыгудан ачык калдырган. Менә шушы кечкенә форточкадан аның кабинетына кичке салкын һава белән бергә илаһи бер моң агыла. Черек күл бакчасында тынлы оркестр «Амур

дулкыннары»н уйный. Танцы мәйданчыгы хәзер яшьләр белән шыгрым тулыдыр. Яратам шул ерак Амур буйларын җанландыручы, хыял дулкыннарында тирбәтүче вальсны. Зәйтүнә бүген килде микән? Юктыр ла, кем белән килсен, мине алып киткәндә ничек үксеп елап калды ич ул.

Ә өченчекөн... Чыннан да, аны без гаҗәп күңелле уздырдык. Гомергә истә калыр ул көн.

Институт комсомол комитеты мине Казанка елгасы буендагы урамнарның берсенә яңа Сталин конституциясен, аның совет халкына биргән хокукларын танытырга, әңгәмәләр оештырырга билгеләгән. Башта факультет секретаре бу хәбәрне әйтүгә, пыр тузып ачуландым. Стена газетасын мин чыгар. Демонстрациягә колоннаны мин алып бар. Инде йорттан йортка йөрергә! Юк, булмый! Мин институтның кендеге түгел. Миннән башкалар да бар. Аларны да җигәргә вакыт.

– Җүләр, син анда ялгыз бармыйсың, – секретарь хәйләле елмаеп күз кысты, – биофакның мадоннасы Зәйтүнә белән...

Эредем дә төштем – балавызмыни.

Инде көзнең соңгы көннәре булуга да карамастан, кояш быел җәйге кебек көләч – кыздырып тора. Якты, матур, һава саф, үтәдән-үтә күренә. Казанка буендагы бакчаларда алма агачлары ут булып яна. Ботаклар алмаларын күтәрә алмый сыгылган. Әчкелтем тәмле алма исе, хуш ис...

Менә шул алма бакчалары буеннан, тар тыкрыклардан Зәйтүнә белән култыклашып, алма ашап барабыз. Юл уңаенда базарга кереп алган антоновкалар. Тәмле дә, ачы да – тешләр камаша. Зәйтүнә бертуктаусыз сөйли, көлә. Бигрәк чая, авызына шайтан төкергән хәерсезнең. Әл гаязе билләһи, әйттем исә кайттым. Ә менә йортларга кереп халыкны җыйганда, Зәйтүнә авызына су алгандай өнсез кала. Монда инде бар авырлык миңа төшә – Конституциянең барлык статьяларын аңлатып чыгарга кирәк!

Ә бүген? Бүген безнең участокка кем барыр икән? Зәйтүнә үзе генә теләмәс. Ни генә әйтмә, каланың чите. Анда әле көндез икәүләп йөргәндә дә куркыныч – атлаган саен исерекләр. Ә кичен! Юк, Зәйтүнә бармас.

Оркестр бераз тынып торган иде, хәзер тагын уйный

башлады. Моң! Гаҗәп гүзәл моң. Тукта, бу бит Салих ага Сәйдәшевнең «Шәрык биюе»! Кеше күңелен тирән дулкынландыра торган гали һәм гүзәл моң бит ул. Әйтерсең лә Ямән чүлләреннән, көмеш кыңгырауларын чыңлатып, кәрван килә – комнарга бата-бата, дөяләр атлый.

Күңел дулкынлана, тулып ташый. Ә музыка, моң, көчәйгәннән-көчәя барып, үзенең тылсымлы канатлары белән мине күтәрә. Мин очам...

– Күтәр башыңны, контра!

Ачулы җикеренү. Кемгә? Чү, мин калгып барам түгелме? Мин кайда? Ниндидер бер кул, җилкәмнән кысып, умырып алып, артка тартты. Гимнастёркам чытырдап китте, мөгаен, ертылды. Аннан теге кул кинәт алга таба этеп куйды. Башым шак итеп таш диварга бәрелде. Күзләремнән утлар чәчелде. Чайкалып барып стенага ябыштым, әмма тотына алмадым. Тез буыннарым чатнап, бар гәүдәм белән идәнгә авып төштем.

– Ах, хәшәрәт, инде алдаша да башладыңмы? – Авыр дагалы солдат итеге аркамны изә, әллә инде умырткаларым чатный, сыным катты, тыным кысылды.

– Мә сиңа! Мә сиңа, халык дошманы! – Тагын типкәләү... – Тор, үләксә! Менә следователь килгәч, тагын өстәмә «паёк» алырсың, бас аягыңа!

Инде икенче тәүлек мине шулай стенага каратып, үрә катырып тоталар. Борылырга да, утырырга да бирмиләр. Җиде-сигез сәгать тикшерүче теңкәгә тия, аннары чиратлашып сакчылар җәзалый. Мин һаман басып торырга тиеш. Балтырларым итек кунычларына сыя алмый, шартларга җитешеп шешкән. Кургаш булып катканнар. Вакыт-вакыт чатнап, пычак белән чәнчегәндәй авыртып, бөтен тәнне калтыраталар.

Сакчы солдатлар тагын күтәреп бастырдылар.

Мин диварга сөялеп көчкә торам. Алдымда известь белән акшарланган стена. Ниндидер таплар. Кан таплары. Очкыннар.

Стена кинәт чайкалды, әле бер, әле икенче якка авышты. Тагын очкыннар чәчрәде, һәм стена әйләнергә тотынды. Баш чатный. Косасы килә. Томан. Тагын стена калкып чыкты да зырылдап әйләнә башлады.

Шул диварга ябышып, мин дә әйләнәм һәм каядыр

упкынга авам.

Ниндидер моң. Оркестр уйный. Утлы ком өемнәре арасыннан кызыл кәрваннар килә...

3

– Сез быел май аенда Ялтада булдыгызмы?

– Булдым.

– Нишләдегез?

– Дәваландым. Сеченов исемендәге санаторийда.

– Нинди авырудан?

– Неврастениядән.

– Сезгә әле егерме алты яшь кенә бугай, шул арада неврастенияме? Димәк, күп эшлисез. Институтта укыйсыз. Шигырьләр язасыз. Молодец. Сез – талантлы егет. Иртәрәк авыргансыз. Үзегезне сакларга, самый главный, минемчә, нервларны туздырмаска иде. Бит сезнең алда зур перспектива. Сез галим, өстәвенә атаклы язучы булачаксыз. Татардан мондый талантлы яшьләр күтәрелүгә мин бик сөенәм.

Бикчәнтәев өстәл өстендәге «Пушка» тартмасыннан бер папирос алып кабызды, тәмләп суырды. Ул үзе буйга миннән тәбәнәгрәк күренә. Әмма гәүдәгә тулы. Йөзе түгәрәк, мөлаем. Куе кара кашлар, тузгып, бөдрәләнеп торган кара чәч. Мөгаен, әле яңа гына парикмахерда булган, бик пөхтә итеп кырынган, хушбуй исе аңкый. Аның өстендә гәүдәсенә сыланып торган хаки төсендәге бик килешле өр-яңа китель.

Ул хәзер аеруча җыйнак, пөхтә, хәтта нәзакәтле елмаеп кына сөйли һәм «сез» дип кенә эндәшә. Ә кичә әнә, килеп керүгә, нинди кабахәт сүзләр белән сүгенде, җикеренде, хәтта сугарга омтылды – кулын тотып калдым.

– Рәхим итегез, – Бикчәнтәев, өстәл аша үрелеп, миңа папирос сузды, – тартыгыз.

Мин, «юк, тартмыйм» дип, башымны чайкадым.

– Менә бик шәп. Сез сәламәтлегегезне саклыйсыз. Умно. Ә безгә менә тартырга туры килә. Гомерне кыскартырга. Берни эшләп булмый, язмышыбыз шундый әшәке. – Бикчәнтәев тагын озак итеп суырды һәм, кинәт нәрсәнедер хәтерләгәндәй, тәмәке тартуын өзеп, бик җитди кыяфәт белән миңа карады. – Гафу итәсез, мөгаен, сезнең ашыйсыгыз киләдер? Мин үзем тук булгач, онытып

та җибәргәнмен.

Дәшмәдем. Инде икенче тәүлек авызга бер валчык ризык төшмәгән. Эчем борып-борып ала.

Өстәл астында кнопка бар, ахрысы. Бикчәнтәев бармагы белән басып торды. Озакламый кырыйдагы ишек ачылды, аннан ак алъяпкыч бәйләгән сары чәчле бер кыз күренде.

– Галя, бу бүлмәгә кичке аш алып килегез.

Галя, «ярый» дип, акрын гына ишекне япты.

– Яхшы, ашны әзерли торсыннар, без өзелгән әңгәмәне ялгыйк әле. – Папиросы сүнгән икән, Бикчәнтәев бик пөхтәлек, тәкәллеф белән шырпы кабызып, папиросын төтәтте, гадәтенчә, ашыкмыйча суырды. – Тәк, тәк... Сез, Ялтада дәваланып кайттым, дисез. Бик әйбәт булган. Ярый. Ә менә Ялтада кемнәр белән очраштыгыз?

– Ялтада халык җитәрлек.

– Анысын мин үзем дә беләм. Мин язучылар турында фикер йөртәм.

– Ә-ә-ә... Галимҗан ага Ибраһимовның хәлен белергә бардым.

– Менә бу – мин көткән җавап. Путёвканы кайдан алдыгыз?

– Кайдан булсын, Язучылар союзыннан, Кави ага бирде.

Бикчәнтәев тагын елмайды. Әле генә Галя ябып чыккан ишеккә дикъкать белән карап торды. «Кичке ашны нигә тоткарлыйлар инде?» мәгънәсендә. Мин дә ихтыярсыз шул ишектән күзләремне ала алмыйм. Өзелеп ашыйсым килә. Кайчан гына китерерләр икән? Кара, бу тикшерүче начар кеше түгел икән, әнә ничек ипле сөйләшә. Ашарга бирергә җыена. Мөгаен, гаебем юклыгын төшенеп, инде кайтарып җибәрергә ниятлидер. Аз-маз тукмадылар тукмавын – ярар, җимерелгән урын юк. Итек кунычларын Бикчәнтәев үзе телеп җибәрде, утырырга урындык бирде. Аякның шешләре бераз кайта да башлады, сызлау кимеде.

– Тәк, тәк... – Бикчәнтәев, урыныннан торып, өстәл артыннан кабинет уртасына чыкты, ишекле-түрле атлый башлады. Яңа хром итекләр шыгыр-шыгыр килә. Борынга тәмәке, хушбуй исе кагыла. Ә мин аш исен эзлим, кайчан гына ул ишек ачылып, ашарга китерүче күренер икән? Ни

алып килерләр? Икмәк белән су булса да бик әйбәт булыр иде.

– Менә сез, Ялтага барыр өчен путёвканы Кави Нәҗми бирде, дидегез, әйеме?

– Әйе.

– Яхшы. Аннан инде сез шул путёвка белән Ялтага барып, Галимҗан Ибраһимов белән очраштыгыз, әйеме?

– Әйе.

– Яхшы. Хәзер сез менә мондый логик нәтиҗә ясагыз. Сезгә путёвка бирүче Кави Нәҗми – халык дошманы. Хәзер ул төрмәдә утыра. Ә сез барып күргән Галимҗан Ибраһимов та халык дошманы, хәзер Пләтән төрмәсендә ята.

– Булмас! – Мин, җан тавышым белән кычкырып җибәреп, аягүрә басарга омтылган идем, тора алмадым – аякларым кузгалмады.

Ул арада ишек ачылып, Галя дигәннәре поднос күтәреп керде, тәмле аш исе борынны ярып китте. Авызымнан сулар килде.

– Менә монда, язучы егет алдына куегыз, – диде Бикчәнтәев, йомшак кына елмаеп. – Җитмәсә, мин тагын кнопкага басармын.

Галя өстәлгә зур таш тәлинкә белән итле токмач шулпасы, кечкенә тәлинкә белән төбәсеннән тулы дөге боткасы, симез иттән гуляш һәм бер стакан ахак булып янып торган кайнар чәй куйды да тиз генә чыгып китте.

– Тәк... – Бикчәнтәев киредән өстәл артына, урындыгына килеп утырды. – Тәк, нинди нәтиҗә: бер халык дошманы сезгә путёвка бирә, икенче халык дошманы сезне каршы ала, нигә?

– Юк, мин ышанмыйм. Алар икесе дә большевиклар. Галимҗан ага, – әле 1905 елдан ук революцион хәрәкәттә катнашып, Киев төрмәсендә утырган, Колчак тылында йөргән разведчик ул.

– Ха-ха-ха! Ха-ха-ха! – Бикчәнтәев буылып-буылып, эчен тотып көлә башлады. Кысла сыман кызарды. Күзләреннән яшь атылып чыкты, һаман туктала алмый: – Ха-ха-ха! Ха-ха-ха!

Әллә инде акылдан шаша дип куркып киттем. Әмма мин гаҗәпләнеп өлгерә алмадым, следователь сикереп торды, йөзе агарып-күгәреп китте. Кашлары салынды,

күзләре акайды. Әйтерсең лә күз алдында күз буып битлек киде. Танымаслык вәхши бер җанга әверелде.

– Син бит, хәшәрәт, алар арасында связной булгансың. Ну-ка, әйт әле, Кави белән Галимҗан сиңа нинди контрреволюцион йомышлар куштылар? Яле! Карталарыңны ач. Кави белән Галимҗан әллә кайчан инде җинаятьләрен өсләренә алдылар и синең элемтәче булуыңны расладылар. Признавайся!

Аптырап калдым: нәрсәне таныргга? Ул арада Бикчәнтәев, йөгерә-атлый, минем янга чыкты.

– Йә, признаваться итәсеңме-юкмы? – Ул сугарга дип кулын күтәргәндә, күзем өстәлдәге мәрмәр пресс-папьега төште, ничек шуңар сузылганымны белмичә дә калдым, Бикчәнтәев сукканчы, мәрмәр пресс-папьены эләктереп алып, аның яңагына бәрдем...

4

Бу елның уникенче мартында Галимҗан Ибраһимовка илле яшь тулды. Без, яшь язучылар, шул уңай белән Казанда, әдәбият дөньясында зур тантана булыр дип өметләнгән идек. Гаҗәпкә, бу көннәр бик «тыныч» үтте. Хәтта газета-журнал битләрендә дә гадәттәге тәбрикләүләр, сәламләүләр күренмәде.

Аптырадык. Бу ни хәл? Галимҗан ага татар әдәбиятына зур хезмәт күрсәткән, тирән хис, фикер тулы әсәрләре белән меңләгән, йөз меңләгән укучының күңелен җәлеп иткән, сөендергән, көендергән әдип, галим, унҗиденче елга хәтле үк революцион хәрәкәттә катнашкан, шуның өчен төрмәләрдә утырган, әмма бу юлыннан тайпылмаган кыю большевик, җәмәгать эшлеклесе бит. Ул – татар әдәбияты, культурасы, фән үсеше өчен бар көчен, гомерен һибә иткән талант иясе. Ничек инде шундый олы, фидакяр затның хезмәте, табышҗимешләре игътибарсыз, ихтирамсыз кала?

Бу хәл мине аеруча борчый иде. Чөнки матур әдәбиятның беренче онытылмас ләззәтен мин аның әсәрләре аша татыдым, сихерләндем. Һәм шул тылсымлы дөньяга атларга, кулыма каләм алырга җөрьәт иттем. Канатландым. Акыл көче белән ныгытылмаган алсу өметләр генә иде әле бу. Әмма ничек кенә булмасын, ул изге өмет-омтылышны Галимҗан аганың гүзәл музыкаль әсәрләре уятты һәм әдәбият мәйданына чыгарга өндәде.

Күкчәтау җидееллык мәктәбен тәмамлау белән тизрәк Казанга китәргә ашкынуымда да, һичшиксез, олы әдипнең тәэсире бар иде. Имеш, Казанга бару белән Галимҗан аганы күреп сөйләшәм, үземнең әсәрләремне – инде ике калын дәфтәргә күчерелгән шигырьләр, хикәяләремне күрсәтәм һәм... Аннан соң ни буласын, билгеле инде, күз алдына китерә алмыйм. Шулай да минем алда Олимп биеклегенә алып баручы салават күпере ачыла сыман иде. Һай ул балачаклар, гүзәл, самими һәм артык беркатлы уйланыла торган гамьсез чаклар!

Казанга килдем. Педагогия техникумына укырга урнаштым. Әмма... Әмма, кызганыч ки, Галимҗан аганы күрү сөенеченә ирешә алмадым. Ул, үпкә чире белән җәфаланып, Ялтага дәваланырга киткән иде.

Минем канатлар шиңде.

Җитмәсә, менә аның илле еллыгын да игътибарсыз калдырдылар.

Билгеле инде, бу хәл мине генә түгел, башкаларны да, бигрәк тә яшь язучыларны бик пошындырды. Нәкъ шушы вакытта мин неврастения авыруына тарып, йокысызлыктан җәфалана башладым. Докторлар санаторийга барып дәваланырга киңәш иттеләр. Ә монда язгы имтиханнар башланды. Баш чатный, күз алларым караңгылана. Дәреслек өстендә калгып китәм... Ләм-мим башка кунмый. Нишләргә? Башны, кран астына куеп, салкын суда тотам да имтиханга керәм.

Менә шулай җәфаланып йөргән көннәрнең берсендә Язучылар союзы идарәсенә чакырдылар. «Бик кирәкле кишер яфрагы инде мин», – дип сукрана-сукрана барсам, сөенеч, бер түгел – ике!

– Ибраһим, сине неврастения белән авырый дип ишеттек. Менә Ялтадагы Сеченов исемендәге санаторийга путёвка. Идарә бу путёвканы сиңа бирергә карар чыгарды, – диде председатель Кави ага Нәҗми, мине бик хөрмәтләп каршы алып. Өнме? Төшме? Путёвка! Ялтага! Ул арада Кави ага мине икенче хәбәре белән җиде кат күккә күтәрде: – Үзең беләсең, быел Октябрьгә егерме яшь тула. Шул уңай белән Татарстан Язучылар союзы һәм Татиздат бәйрәмне бүләк белән каршыларга булдылар.

– Ул нинди бүләк, Кави ага? – дидем, кызыксынып.

– Хәзер, хәзер, – диде Кави ага, гадәтенчә ашыкмый-

ча, хәрбиләрчә ачык-көр тавыш белән. Ул инде күптән Союзда тыныч-гади эштә булуына карамастан, һаман әле хаки төсендәге гимнастёркадан, зәңгәр галифедан. Биле киң каеш белән буылган. Гимнастёрканың чия кызыл петлицаларында икешәр «шпал» яна иде. – Дүрт альманах чыгарырга җыенабыз. Егерме ел эчендә татар прозасы, шигърияте, драматургиясе һәм балалар әдәбияты. Һичшиксез, бу альманахка иң яхшы әсәрләр тупланырга тиеш. Проза альманахын без олы әдибебез Галимҗан ага Ибраһимов әсәре белән ачып җибәрергә уйлыйбыз. Ялтага бару белән аның янына кер – хәлен бел, безнең сәламне тапшыр һәм менә хәзер мин әйткән фикерне җиткер. Яңа әсәре өлгерсә, бигрәк әйбәт булыр иде, әгәр инде юк икән, Галимҗан ага, үзе карап, басылганнардан берсен тәкъдим итсен. Кара, – Кави ага тавышын күтәреп, кисәтеп әйтте: – Кара, Ялтадагы кызларга гашыйк булып, онытып җибәрмә, – Кави ага шук карап көлемсерәде. Мин кызардым. – Бу – бик мөһим һәм ашыгыч эш. Галимҗан агага сәламебезне тапшыр һәм бик нык ихтирам итүебезне белгерт. Без аның тиз арада савыгып, яңадан сафка басуын көтәбез. Ярый, син, Әдәби фондка кереп, путёвканы ала тор. Китәр алдыннан тагын бер кереп чыгарсың.

Мин Галимҗан ага Ибраһимов янына барам! Мин Ялтага китәм! Бу көтелмәгән тау хәтле сөенечне кемгә булса да әйтергә, шатлыкны бүлешергә кирәк. Тизрәк! Тизрәк! Кабинеттан чыгуга, Матбугат йортының өченче катындагы «Кызыл яшьләр» редакциясенә йөгердем. Баскычта таеп егыла яздым, кемдер тотып калды. Ул рәхимле бәндәне күрмәдем дә, рәхмәт тә әйтмәдем – йөгердем. Сөенче! Сөенче!

Беренче очраткан кешем яшь шагыйрь, ахирәт дус Галимҗан Мөхәммәтшин булды. Ул газетаның оттискын укып-тикшереп утыра иде. Мин ишекне ачар-ачмас, кабалана-кабалана, сөенечемне тезеп киттем.

– Менә шәп булган! Менә сөенеч! Әйдә, – Мөхәммәтшин, сөйләп бетерүемне дә көтмичә, җиңемнән өстерәп, әдәби бүлек бүлмәсенә алып кереп китте һәм анда миннән дә көчлерәк ярсып-ташып сөйли башлады: – Ура! Ибраһим Ялтага бара. Әйдәгез, Галимҗан агага тәбрикләү хаты язабыз! Әйдәгез!

Мөхәммәтшин шундук, ишек янындагы озын өстәл

янына утырып, алдына кәгазь салып, хатны яза да башлады. Бүлмәдә Ләбиб Гыйльми, Касыйм Шәйхетдинов, Сөббух Рәфыйков һәм тагын берничә яшь язучы – «Кызыл яшьләр» газетасы хезмәткәрләре бар иде. Алар да бу тәкъдимне хуплап каршыладылар. Мөхәммәтшин, гомумән, бик җиңел, хәрәкәтчән кеше иде. Утырып торырга яратмый – шигырьләрен дә аяк өсте йөреп, тавышланып яза иде. Хатны сырлап бетерүгә сикереп торды да бүлмә буенча арлы-бирле йөреп, кулларын бутап, рухланып укып чыкты.

Машинкада басарга әзерләнгән бу бер бит кәгазьгә язылган сәлам хатта Галимҗан аганың әсәрләрен яшьләрнең бик яратып укулары, өйрәнүләре, әдипне илле еллыгы белән тәбрикләүләре һәм аңа сәламәтлек, озын гомер теләүләре, яңадан-яңа әсәрләрен көтеп калулары, ихтирамнары әйтелгән иде. Бүлмәдәге иптәшләр хатны тулаем хуп күрсәләр дә, һәрбер җөмләсен кат-кат укып, җентекләп тикшерделәр – үзгәрттеләр, нидер алып ташладылар, нидер куштылар. Шундый олы әдипкә чиле-пешле хат язарга буламы!

– Октябрьнең егерме еллык тантанасына Галимҗан аганы кунакка чакырыйк, – диде иң ахырда Сөббух, сүзне очлап.

– Чакырабыз, чакырабыз! – дидек барыбыз да, бу тәкъдимне хуплап.

– Инде килегез, кул куегыз! – диде Мөхәммәтшин, хатны күчереп язып өстәлгә куйгач. – Галимҗан аганы бер сөендерик.

Бүлмәдәгеләр барысы да куана-куана кул куйдылар.

Мин Ялтага килеп төшкән көнне үк, хәтта юл буе сокланып килгән Кара диңгезгә дә бармыйча, Галимҗан Ибраһимов торган йортны эзләп киттем.

1927 елда Г. Ибраһимовның кырык еллыгы уңае белән Күкчәтауда зур тантана оештырылган иде. Без мәктәп сәхнәсендә «Яңа кешеләр» драмасыннан күренешләр куйдык, башка әсәрләреннән өзекләр укыдык. Шул тантаналы җыелышта Күкчәтау халкының теләге белән җидееллык татар мәктәбенә Галимҗан Ибраһимов исеме бирелде. Менә шушы тантана алдыннан Казаннан бик күп яңа китаплар, җөмләдән Г. Ибраһимовның барлык әсәрләре һәм әдипнең зур портреты да алдырыл-

ган иде. Портрет мәктәп залының нәкъ түренә куелды. Мин уку бетеп балалар таралгач, берүзем залга кереп, портрет каршына туктыйм да аңа бик озак сокланып карап тора торган идем. Сокланмаслык та түгел – иңнәренә хәтле төшеп, кабарып торган чәч. Киң маңгай, бер-берсенә кушыла язган калын кара кашлар астында зур, уйчан күзләр. Борын астында гына калдырылган төймә мыек. Иреннәр каты кысылган. Баш аз гына, беленер-беленмәс кенә иелгән, уйга талган. Ниндидер бер зур вакыйганы исенә төшерә – хәтереннән кичерә кебек. Күкрәк калку, иңнәр киң. Мөгаен, мәһабәт сынлы.

Ялтада мин менә шушы мәһабәт кешене, атаклы әдипне эзләп киттем.

Кара диңгез, кояшның алтын нурларында чагылып, чайкалып, җәйрәп, әллә кая аста ята. Ә мин, аулак тыкрыктагы баскыч-баскыч ташларга басып, тауга, Виноград урамына күтәреләм. Урамның ике ягында – төптөз баскан биек, кырыс, тирән уйга талган кипарислар. Алар артында – зөбәрҗәт йөземлекләр һәм күзнең явын алырдай гаҗәеп гүзәл-нәфис талгөлләр, алтын чәчәкләр.

Ниһаять, менә ул мин эзләгән йорт. Урамнан эчтә, бакча уртасында, ике катлы агач бина. Якынлашам. Йорт инде кипарислар арасыннан ачыла төшә. Икенче катка урам яктан биек баскыч күтәрелә икән. Ул веранда ишеге төбендә туктый. Мин менә шушы баскычтан күтәрелергә тиеш.

Баскычтан җитез генә менсәм дә, веранда ишеге төбенә җиткәч, кинәт кенә каушый калдым. Эсселе-суыклы булып киттем. «Нигә бу хәтле иртә авыру кешене борчып йөрим? Ул әле ял итә торгандыр. Мине генә күрәсе килеп торамы аның? Юк, китәргә кирәк. Тагын бер килермен».

– Иптәш, сез кемне эзлисез?

Сискәнеп киттем. Веранданың ишеге ачылып, бусагада җиңел чуар халаттан урта яшьләрдәге бер ханым күренде.

– Гафу итегез, – нигәдер, күтәрелү урынына, бер баскыч түбән төштем. – Мин язучы Ибраһимовны эзләп килгән идем.

– Рәхим итәсез! – Хатын елмайды, аз гына артка чигенеп юл бирде. – Югары үтегез. Без кунакларны яратабыз.

Мин чәчәкләр белән тулы ачык верандага кердем. Туфлиләремне салдым, ашыгып, чак кына егылып кит-

мәдем, роза гөле утыртылган зур мичкәгә таянып калдым. Ярый әле анысы авып китмәде.

– Галимҗан, сөенче, сиңа кунак. – Мине каршылаган хатын яңгыравык тавыш белән кычкырды һәм түр бүлмәнең ишеген ачты. – Узыгыз, менә агагыз торып та килә.

Мин бүлмәгә уздым. Тәрәзә каршына куелган зур язу өстәле янындагы камыш урындык-креслодан Галимҗан ага күтәрелде.

– Хуш килдегез!

Мин аптырап калдым. Тагын каушый башладым. Ул арада Галимҗан ага, миңа якынлашып, үзенең озын, кан тамырлары күгәреп калкып чыккан ябык кулларын сузды.

– Исән-сау килдегезме? Узыгыз. Утырыгыз.

Менә шунда гына исемә килеп, тирләп-пешеп, Галимҗан аганың сөякчел салкын кулларын кыстым. «Җүләр, мин үзем алдан сәлам биреп күрешергә тиеш идем бит».

– Исәнмесез, Галимҗан ага! Хәлегез ничек?

– Әйдүк, әйдүк, энем. Менә бу урындыкка утыр. – Ул миңа да бер камыш кресло тартып куйды. – Хәл? Хәл зарланырлык түгел. Менә бүген сез килүгә, ахры, җиңеләеп, өстәл янына утырган идем. – Галимҗан ага минем кулымны каты гына кысты да, акрын атлап, урындыгын аз гына миңа табанрак тарта төште. Утырды. – Рәхмәт, онытмыйча зыяфәт итүегезгә. Үзегезне кем дип таныйм? Кайсы яктан?

Әллә нәрсәгә телем бәйләнде. Югыйсә, әле поездда килгәндә үк, нәрсәләр әйтәсен, нинди сораулар бирәсен күңелдән ятлап килгән идем бит. Әйтерсең лә, абынып егылып, кулымдагы тәңкәләрне чәчтем.

Аның өстендә – аксыл-сары иркен күлмәк һәм шул ук материалдан тегелгән чалбар. Аякларында да ак йоннан басылган йомшак каталар. Өстендәге киемнәре нигәдер гәүдәгә ятышмый, сәлберәп торалар, йөзе озынча, яңак сөякләре калкып, битен тагын да суза төшәләр. Монда да кан тамырлары бүртеп, күгәреп, йөзен суытып-куыртып торалар. Чәчләр дә кабарып иңнәргә төшмәгән, сыланып ятканнар. Ара-тирә чал кылчыклар да күренә.

Тукта, кайда соң ул теге, мин Күкчәтау җидееллык мәктәбе залында сокланып караган, портрет кысасына сыймыйча тулып, ташып торган мәһабәт ир? Каршымдагы камыш креслога чумып утырган кеше бик кечкенә, бик ябык бит, билләһи!

– Хәдичә, син самавырыңны шаулат. Кунакның авызы кипкәндер. – Менә шушы ягымлы, сабыр тавыш мине тәшвишләнүдән уятты, һәм мин Галимҗан аганың сорауларын хәтерләдем.

Ул башта миңа нигәдер түбәннән йокымсырап карады. Мөгаен, хәбәрләрем аны кызыксындырмыйдыр. Уйларым, фикерләрем чуала башлады. Ул моны сизде, ахрысы, башын күтәрде.

– Гафу итегез, авыруым бераз борчыды. Шулай приступ булып ала. Хәзер менә үтте. – Галимҗан ага ягымлы бер игътибар белән миңа күз сирпеде. Зур соргылт күзләре ачылып, чаткыланып киттеләр, йөзе яктырды. – Тәрәзәне дә ачып җибәрик әле, иртәнге һава шифалы ул.

Талгын гына җил исеп куйды – яфраклар кыштырдады, хуш ис – чәчәкләр исе аңкыды. Пароход кычкырткан тавыш ишетелде. Бухта монда якын гына бит. Күпме кораблар килә, күпме кораблар китә. Кара диңгез кочагы киң...

Галимҗан ага сораулар бирә башлады. Аптырап калдым. Башта ул мине тыңламый, авыруына борчылып, игътибарсыз калдыра дип үпкәләп тә алган идем. Ә хәзер таң калдым – бер кәлимә сүземне дә ычкындырмаган, отып алган. Ул гынамы, Галимҗан ага авыру хәлендә Казанда басылган барлык китаплардан, газета-журналлардан хәбәрдар. Ул минем кебек әдәбиятка әле яңа кереп килгән яшь язучыларның әсәрләрен дә укып бара икән. Менә шул яшь каләмнәр хәзер нинди әсәрләр өстендә эшлиләр, укыйлармы? Кайда, ничек укыйлар – барысын да сорашты. Мин җавап биреп өлгерә алмыйм. Ә кулым костюм кесәсен капшый. Анда – хат. Ничек сүзне-әңгәмәне бүлмичә генә, җайлап, тәкәллеф белән тапшырырга?

– Галимҗан, чәй әзер. – Аш бүлмәсеннән Хәдичә апаның тавышы ишетелде.

Соңыннан белдем, ул язучының хатыны икән.

Әңгәмә бүленде. Галимҗан ага мине чәйгә чакырды. Хәдичә апа бик тәмле вареньелар, хәтта үзебезнең милли ризык чәкчәкне дә әзерләгән икән.

– Кунак белән ризык тәмле була шул, – дип, Галимҗан ага чәйне бик яратып эчте.

– Сез инде, энем, көн дә килегез. Күрәсезме, сезнең белән агагыз ике кәсә чәй эчте, – дип, Хәдичә апа да,

куанып, мине кыстарга кереште.

Чәйдән соң без тагын түр бүлмәгә чыктык. Галимҗан аганың бите алсуланып, рухы күтәрелеп китте. Менә шул уңайдан файдаланып, аңа элек Кави ага Нәҗминең сәламен, теләген тапшырдым, аннан, ниһаять, үзебезнең хатны бирдем.

– Яшь язучылардан?

Галимҗан ага хатны ашыкмыйча, игътибар белән укып чыкты да хөрмәт белән өстәлнең түренә – кульязмалары янына сузып салды.

– Рәхмәт, бик күп рәхмәт яшьләргә, – диде Галимҗан ага, ярыйсы ук дулкынланып, – онытмаганнар. Изге теләкләр белдергәннәр. Бу минем өчен зур сәгадәт. Әмма, – ул, үрелеп, хатны кирәдән кулына алды һәм күз йөртеп кенә эзләнә башлады, – кайда әле... Ә, менә-менә, «бөек әдип», – Галимҗан ага, башын күтәреп, миңа шелтәле карады: – Нигә алай артык мәдех? Ә? Мин бит әле бөек әдип түгел. Язган әсәрләремнең күбесеннән риза түгел, дөресрәге, канәгать түгел. Менә «Татар хатыны ниләр күрми», «Безнең көннәр»не яңадан төзәтеп язып чыктым. Әле дә канәгатьмен дип әйтә алмыйм. Юк, «бөек» сүзе артык.

Ул безнең шул рәвештәге мәдхияләргә ризасызлык белдерде дә ахырында хатны тагын элекке урынына куеп елмайды:

– Яхшылыкка яманлык дип рәнҗи күрмәгез, яшь иптәшләргә ихлас күңелдән рәхмәт һәм сәлам. Мөгаен, сез, илче буларак, – ул тагын бик ягымлы итеп елмайды, – бу тапшыруларымны яшь каләмнәргә җиткерерсез.

– Һичшиксез, Галимҗан ага.

– Менә рәхмәт... Тик минем табигатем артык мәдхияне сөйми. Мин бөек түгел, бары тик эшче каләм – иҗат эшчесе. Авыр хезмәт ул каләм эше.

Октябрьнең егерме еллыгына дүрт альманах чыгарырга әзерләнү хәбәрен Галимҗан ага бик хуплады.

– Һичшиксез, бу зур һәм зарур мөкяфәт. Яхшы эш башланган. Алдыбыздагы егерме еллык – иң олы бәйрәмнәрнең берсе. Аның хөрмәтенә әзерләнә торган бүләк альманахта катнашуны мин үземә мәртәбә дип саныйм. Адаш, – минем исемемне белеп алгач, ул миңа бары шулай «адаш» дип кенә эндәшә башлады, – сез әле

тиз китмисездер?

– Июнь башында путёвкамның срогы тула.

– Бик яхшы. Мин үземнең соңгы язмаларымны карап, берсен сайлап куярмын. Ә сез, адаш, вакытыгыз мөмкинлек бирсә, көнара килеп торыгыз. Мин дә, Хәдичә апаң да кунакны яратабыз. Менә бүген сезнең белән ике кәсә чәй эчтем...

Минем әле тагын утырасым килсә дә, Галимҗан аганың көйсезләнә башлавын (мөгаен, үпкәсе чәнчә) сизеп, саубуллашып чыгып киттем.

Санаулы көн тиз үтә, диләр. Дөрес икән, сизмичә дә калдым, китәр вакыт та җитте. Әмма Ялтада үткән бу егерме дүрт көн һәрьяктан файдалы, шифалы булды миңа. Көн саен Шарко душы, диңгездә коену, яр буенда сәйран чигүләр барлык чирне кырып-юып алды. Рәхәтләнеп йоклыйм, кайвакытта йокым туймыйча да кала – торасы килмичә генә торам. Режим!

«Диңгез кешеләрнең барлык кайгыларын юа!» – дип юкка әйтмәгәннәр икән борынгы юнанлылар. Алай да иң файдалысы һәм гомергә хәтердә кала торганы, һичшиксез, Галимҗан ага белән очрашулар, озак-озак сөйләшеп-әңгәмәләшеп утырулар булды. Бу очрашулар миңа иҗади хезмәтемнең серле ишекләрен ачты, армый-талмый эшләргә, укырга – өйрәнергә, өйрәнергә, өйрәнергә кирәклеген төшендерде. Мин бер үпкә белән генә яшәгән чирле әдипнең, һич аруны белмичә, үзен жәлләми, төннәр-көннәр буена әсәрләре өстендә эшләвен, кабат-кабат күчерүләрен үз күзләрем белән күрдем.

– Менә, адаш, Кызыл Армиядән кайтып, авылда яңа тәртип кору өчен көрәштә һәлак булган Гайфетдин турындагы хикәямне альманахка дип бирәм, – диде Галимҗан ага, соңгы тапкыр хушлашканда кулымны каты кысып.

Кичкырын иде. Ялта өстенә инде күләгә – Ай-Петри күләгәсе төшкән. Салкынча. Босфор ягыннан җил кузгалган. Кара диңгез тынычсызлана – авыр дулкыннар ярга сугыла. Аларның тоныкк тавышы, авыр сулышы монда, без басып торган верандага хәтле ишетелә.

Галимҗан ага өстенә җылы халат бөркәнгән дә диңгез ягына карап уйга талган.

Ә дулкыннар, гүләп, ярсып, ярга сугылалар.

– Менә, адаш, тормыш та шулай. Диңгез шикелле. Бер тыныч була, ә бервакыт, менә хәзерге диңгез төсле, ярсып-дулап, ярларга бәрелә. Ә кеше менә шушы упкын өстендә дә каушамыйча, югалмыйча, үз теләгенә барырга тиеш, – диде Галимҗан ага, акрын гына пышылдап. Әллә миңа, әллә диңгезгә?

Ул тагын да кулымны кысты. Мин баскычтан төшеп киттем. Ул, югарыда баскан килеш, диңгез ягына карап калды. Ә дулкыннар һаман авыр көрсенделәр...

5

– Падла! – Бикчәнтәев, кара көеп, урындыгыннан сикереп торды да төкерекләрен чәчә-чәчә кычкыра башлады. Ул яңагындагы аркылы-торкылы ябыштырылган тасма-пластырь – пресс-папье белән сугуымның тамгасы – бер өскә күтәрелә, бер түбән төшә. – Сволочь! Мин сиңа халык дошманы Ибраһимовның контрреволюцион йомышлары турында язарга куштым. Ә син... – Ул минем төн буенча тырышып, ихлас күңелдән язган биш табак язуны өстәлдән җыеп алды да, ерткалап, почмактагы чүп-чар әрҗәсенә ташлады. – Менә аларның урыны.

– Иптәш следователь!

– Тик тор! Иптәшләрең Брян урманнарында нужа чигә. – Ул, ачуына чыдый алмыйча, тыпырдап, урындыгын аударды да бүлмә уртасына чыкты һәм арлыбирле йөренә башлады. Хром итекләре шыгыр-шыгыр килә. – Тукта, мин сиңа әле күрәчәгеңне күрсәтермен. Бу пластырьлар бушка китмәс, кичә камерада егетләр аз биргәннәрдер... (Бирүен бирделәр, бөтен тәнем күгәргән. Көчкә күтәрелеп чыктым монда.) Бүген тагын өстәрләр! Тагын сугамы?

– Бас!

Мин язуларыма кул куяр өчен генә утырган идем. Аякларымның, тәнемнең сызлавыннан ыңгырашып, чайкалып, көч-хәл белән күтәрелдем.

– Син, падла, халык дошманы Ибраһимовның контрреволюцион эш кушуларын в конце концов ачасыңмы-юкмы, ә?

Төкерекләре битемә чәчрәде.

– Мин бит... Ихлас күңелдән...

– Ха-ха! Ха-ха-ха! – Тагын гасаби иблис көлүе баш-

ланды. Кызарды, бүртенде, пластырьлар кубып төште – кара янган тамга арлы-бирле авышты. – Ха-ха! Мин синең ихласыңны фәлән итәм. Миңа ихласлык түгел, фаш итүең кирәк, фа-аш итүең! Төшендеңме? – Ул минем янымда өермә булып тузынырга-әйләнергә кереште. – Син нәрсә бәбәкләреңне шарландырдың? Следствиене бетерергә күптән вакыт. Эшне туктатып торасың, корткыч! Язасыңмы-юкмы?

– Нәрсәне?..

Әйтеп тә бетерә алмадым, әле генә шыгырдап, үчекләп торган итекләрнең берсе очы белән тез астыма батып китте. Чалкан барып төштем.

– Дежурный!

Ул арада ишек ачылды да, ике солдат йөгереп керде.

– Камерага! Карцер режимына. Кичә аз биргәнсез. Авызы ачылырлык итеп эшләгез. Алыгыз, нәрсә катып калдыгыз?!

Ике солдат ике аягымнан өстерәп алып та киттеләр.

– Ха-ха! – Тагын Бикчәнтәевнең кыргый көлүе кабатланды. – Тукта, мин сиңа пресс-папьены күрсәтермен әле...

6

«Кара козгын», чайкалып, әле бер, әле икенче якка авып-авып китә. Ниндидер чокыр-чакырлы урамнан барабыз. Мөгаен, Казанның кырый бистәсенә чыгабыз. Мин табут кебек кысан урында утырам. Шундый кысынкы – кузгалып та булмый, хәтта терсәкләрне куярга урын юк – кулларны күкрәгемә кушырырга мәҗбүрмен. «Табут» ауган саен, мин дә авам, әмма беркая китеп булмый – ишек бик нык ябылган. Җитмәсә, теге якта – уртада – мылтыклы солдат утыра. Саклап бара – качып китмәсеннәр! Кая алып баралар соң тагын? Нишләтмәкче булалар мине? Ни булса да булсын, тик Бикчәнтәевтән ераккарак алып китсәләр генә ярар иде. Каныкты бит, каһәр суккан. Менә инде тугызынчы тәүлек ни көндез, ни төнлә керфек кактырмый, тутый кош сыман, һаман бер сүзне кабатлый: «Халык дошманы Галимҗан Ибраһимов кушкан контрреволюцион эшләрне сөйләп бир!» Нинди эшләр? Һич төшенә алмыйм. Нинди тозакка төштем? Белмим, әллә инде илдә контрреволюцион болганыш булган? Алай дисәң, ике сүзнең берендә «Иптәш Сталин күрсәтмәләре» диләр. Ай-һай, иптәш

Сталин бер гаепсез кешеләрне газапларга кушар микән? Булмас! Монда ниндидер өер үзләренең явыз ниятләренә юл салмакчы буладыр. Юк, ничек кенә кыйнасалар да, ялган күрсәтмәләр бирмәм, бигрәк тә Галимҗан ага турында. «Табут» тагын кыйшайды – маңгаем белән ишеккә бәрелдем. Шулай кыйшайганда, ичмасам, машинасы авып та китми. Йә үләр идем, йә качар идем... Тук-тук! Тук-тук! Чү, сул як стенадан кемдер чиртә кебек. Әнә тагын, туктук. Колагымны торгызып тыңлыйм.

– Кем чиртә?

– Бу мин, Галимҗан...

Тетрәнеп киттем.

– Галимҗан Ибраһимовмы?

– Юк, Мөхәммәтшин. Син кем?

Мин шашып калдым. Бу ни? Мөхәммәтшин дә мондамы?

– Син... Син дә мондамы?

– Кем, син кем?

– Мин... Ибраһим... Әллә переворот булдымы икән, ә?

– Белмим. Безнең камерада Ләбиб Гыйльми, Сөббух Рәфыйков. Хатка кул куйганнарның барысын да алганнар... Мин инде унбиш тәүлек утырам. Көн дә сорау алырга китерәләр. Галимҗан аганы халык дошманы дип күрсәтергә кушалар. Бикчәнтәев әйтә, Салахов әллә кайчан таныды, ди... Кыйныйлар... – Ул буылып йөткерде. – Син инде кул куйдыңмыни?

– Юк, юк! – Үз-үземне онытып кычкырып җибәргәнмен, – күрсәтмә бирмәдем.

– Пышылдашуны туктатыгыз, – сакчы ишеккә приклад белән сукты. – Еланнар! Хәшәрәтләр! Мин сезне хәзер үк карцерга...

«Кара козгын» тагын кыйшайды, авып китеп, чинап туктады.

Шыгырдап ниндидер капка ачылды. Машина кузгалып китеп бераз барды да тагын туктады. Капка шыгырдап ябылды.

Кемнәрдер арлы-бирле йөгереп үттеләр. «Кара козгын»ның уртасында утырып барган сакчы тимер ишекне ачып сикереп төште. Кемгәдер рапорт бирде:

– Сигез контрны китердек.

Ниһаять, мин, Казанда ун ел торып, Пләтән төрмәсенең өченче катындагы арестантлар белән шыгрым тулы камераларның берсендә мондый төрмә булуын ишетеп тә белми идем. Менә уйламаганда белергә туры килде.

Следователь Бикчәнтәев алдында үрә катып торганда, бу шомлы шобага миңа гына төшкәндер, ниндидер бер аңлашылмаучылык белән бары тик мине генә «или» торганнардыр дип пошына идем. Юк, миннән башкалар да онытылмаган икән. Җитмәсә, камерадагы барлык «фатирчылар» – таныш-белеш яки газета-журналлар аша мәгълүм карт большевиклар, район, шәһәр, өлкә партиясовет оешмаларының җитәкчеләре, профессорлар, укытучылар, студентлар.

Әмма камерага беренче тапкыр атлап кергәндә, бу «танышлар» котымны алды – җаным уч төбенә килде.

Тугыз тәүлек буена камерада япа-ялгыз ятып, бер кешене күрми, һичкем белән сөйләшми, бары тик тикшерүче Бикчәнтәев һәм аның чирүе белән көне-төне тартышу-сугышу мине чыгырдан чыгара язган иде инде. Тагын да берничә тәүлек бу хәл кабатланса, мөгаен, акылдан шашар идем. Менә шуның өчен дә, «кара козгын»ның ишеген ачып, төрмә ишегалдына төшергәч куанып киттем, ичмасам, кешеләр күрермен, сөйләшермен.

Ул арада кара киемле, караңгы чырайлы, телсез надзирательләр, ым белән генә юллап, мине тар тимер баскычлардан төрмәнең югары катына алып менеп киттеләр.

Озыннан-озынга сузылган тар коридор. Бары тик ике очында гына тәрәзә. Алары да тимер челтәр белән киртәләнгән. Түшәмдә кызарып кына өч лампочка яна. Ике якта – тимер белән тышланган ишекләр. Барысына да калын тимер «билбау» каптырылган, һәм ат башы хәтле йозаклар эленгән. Тынчу. Ярым караңгы. Шылт иткән тавыш та юк. Шомлы тынлык.

Алдан барган колга надзиратель кулындагы бер кочак ачкычларны тәсбих төсле тартып барды да бер камера алдына килеп туктады, нигәдер йозакны арлы-бирле тарткалады, аннан, бер ачкычны сайлап алып, йозакны ачты да ишекне тартты. Авыр тимер ишек чинап, акрын гына ачылды.

– Бар!

Мин бу сүзнең мәгънәсенә дә төшенеп җитә алмадым,

надзиратель аркамнан төртеп кертеп җибәрде:

– Бар, бар!

Ишек, шалтырап, шундук ябылды. Әллә төтен, әллә томан. Әллә инде мунча? Аслы-өсле сәкеләрдә бер-берсенә укмашып, тыгызланып утырган шыр ялангач кешеләр. Сакал-мыеклары җиткән, күзләре акайган, үзләре шабыр тирдә. Әллә чынлап та мунча ләүкәсеме бу? Алай дисәң, ләгәннәре, себеркеләре күренми. Бәлкем, акылдан шашкан кешеләрдер? Бу уй мине бөтенләй чыгырымнан чыгарды – бизгәк тоткандагы кебек туңа-дерелди башладым һәм, үзем дә сизмичә, ишекне аркам белән этеп, аякларым белән тибә башладым.

– Ачыгыз! Ачыгыз! Мин... Мин...

Арттан, коридордан, надзиратель, ахры, ишеккә сукты:

– Шыпырт! Карцерга атлыгасыңмы әллә, корчаңгы?!

– Ибраһим, – алдагы сәкедән, томан эченнән кемдер миңа таба үрелде: – Ибраһим... бу син түгелме?

Иманеп киттем. Алдымда – институтның тел-әдәбият факультеты деканы, профессор Галимҗан Нигъмәти. Кафедрага ул һәрвакыт бик шома кырынып, пөхтә киенеп, галстук тагып килә торган иде. Хәзер минем алдымда сапсары сакаллы, чәчләре тузган, бары тик трусиктан гына калган бер тоткын басып тора.

– Сине дә алдылармыни?

Тавышы үзгәрмәгән, нәкъ элеккечә йомшак, басынкы, бик ягымлы. Кинәт тынычлана калдым. Ишеккә тибүдән туктап, хәлсезләнеп, шуып төшеп, идәнгә утырдым.

– Кайчан алдылар?

– Допроста булдыңмы?

– Газеталарда ни язалар?

– Амнистия турында сөйләмиләрме?

– Менә амнистия, – кемдер югары сәндерәдән калын тавыш белән кычкырып көлде. – Менә амнистия: ректор янына студентлар килә башлады.

– Ташла әле, Шәйхи, иблислегеңне. Син бит райком секретаре.

– Төшерелгән! – диде каһкаһәле тавыш.

– Тсс...

Ишектәге «күз» ачылды. Бүренекедәй кан баскан бер яман бәбәк карады.

– Тагын бер тавыш ишетсәм, камераны карцер режи-

мына куям.

– Ибраһим, – Галимҗан ага Нигъмәти, минем яныма идәнгә утырып, аркамнан какты. – Йә, тавышланмыйча гына сөйлә әле... Институтта ни хәл? Тагын кемнәрне кулга алдылар?

Мин, ниһаять, аңыма килеп, белгәннәремне сөйләргә керештем.

Бу камерада дүрт тоткын утыра торган бүлмә булган. Менә быел, «урып-җыю» артык «уңышлы» баргач, төрмәләрдәге комфортка – караватта ятуга чик куелган. Алар чыгарып ташланган, караватлар урынына камераның буеннан-буена ике катлы сәке-сәндерә эшләнгән. Хәзер инде монда дүрт түгел, егерме дүрт тоткын утыра. Ятканда ян белән генә яталар икән. Сәке башкача сыйдырмый, һава җитми. Шуның өчен мәхбүсләр үзләре тәрәзә өлгеләрен ватып бетергәннәр. Тимер рәшәткәле тәрәзә белән «калфак»[1] арасында – кар. Хәзер аннан ишелеп суык керә. Ә камерада егерме дүрт җан. Алар сулый. Менә ни өчен монда тынчу һәм мунчадагы кебек парлы икән.

Сөйләшә торгач, камерага да, мәхбүсләргә дә иярләштем. Мин китергән «соңгы хәбәрләр» тәмамлангач, Галимҗан ага Нигъмәти мине култыклап торгызды да сәке кырыена утыртты. Кемдер торып, параша янына китеп, миңа урын бирде.

– Утыр, энем, бераз ял ит, бигрәк йончыгансың.

Өске сәкедән кемдер бер сынык икмәк сузды:

– Сез допростан бит... Бераз тамак ялгап алыгыз.

Мин, чыннан да, ачыккан идем. Өченчекөнге насыйп булмаган ризыктан соң, мине карцер режимына куеп, тәүлеккә дүрт йөз грамм паёк бирә башлаганнар иде. Бары тик куркуымнан гына онытып җибәргәнмен икән. Хәзер икмәк күргәч, йолкып диярлек алып, авызыма каптым – чәчәдем. Кемдер кружка төбендә калган чәен бирде. Бары ашап бетергәч кенә, рәхмәт әйтү исемә төште.

– Аптырама, Ибраһим, монда тәкәллефкә урын юк. Бераз хәл җый, ичмасам.

Миңа үз сыныгын сындырып биргән теге кеше югары сәкедән идәнгә сикереп төште. Түм-түгәрәк, кара сакал-

[1] Сталин үзенең бер чыгышында: «Төрмә төрмә булырга тиеш», – дигән иде. Шуннан соң төрмәләрнең тәрәзәләренә «калфак» кидергәннәр: тышкы дөньяны карый да алмасыннар, күрмәсеннәр дә.

лы. Чандыр. Буйга миннән бик аз гына озынрак булыр, ахрысы. Ничектер таныш сыман. Бигрәк тә яңгырау, ачык тавышы һәм бик якты саргылт күзләре. Кайда күрдем соң бу кешене?

– Таныйсыңмы? – диде Галимҗан ага Нигъмәти, теге кешегә карап. – Бу бит иптәш Алкин, ВКП(б)ның Казан шәһәре Бауман район комитетының беренче секретаре.

Хәтерем ачылып китте. Әйе, әйе! Әле яз башында гына Академия театрында язучылар һәм артистларның берләшкән җыелышында ул Октябрьнең егерме еллыгына әзерләнү, яңа әсәрләр язу, сәхнәгә кую турында бик дәртле, ялкынлы доклад сөйләгән иде бит. Бу чыгыш барлык тыңлаучыларда тирән эз – рухлану калдырган иде.

– Габдулла, син «бүре күзе»н каплап тор әле. Соңгы хәбәрне, – ул миңа карап елмайды, – шагыйрьнең килүен иптәшләргә белдерергә кирәк.

Мин хәйран калдым. Кемгә, ничек белдерергә? Ул арада Габдулла, бөтен камерада бердәнбер сакалмыексыз яшь егет, тиз генә ишеккә таба атлап, аркасы белән «күз»не каплады. Ә Алкин, җәһәт кенә идәнгә чүгеп, су йөри торган җылыткыч торбага сак кына берике тапкыр чиртте һәм шундук иелеп колагын куйды – тыңлады. Аннан тагын катырак чиртте. Камерадагы халык нигәдер арлы-бирле кузгала, сөйләшә, тавышлана башлады. Ә Габдулла кузгалмый, аркасы белән һаман «бүре күзе»н томалап тора.

Алкин идәнгә җайлабрак утырды да торбага янә чиртә башлады. Бер чиртә – пауза, ике чиртә – пауза. Әйтерсең лә Морзе аппаратында телеграмма бирә.

Ә камерадагылар, тынычсызланып, күзләрен ишектән алмый.

Алкин аеруча бер дикъкать белән йодрык буыннарына карап чиртә.

– Тык, тык-тык, тык-тык, тык...

Ләкин мин аларны бүтән күзәтеп тора алмадым, сәкедә урын табылуга, изрәп йоклап киттем.

Камерада берничә көн торгач кына, мин бу серле чиртүнең Бестужев алфавиты дип аталуын, декабристлардан бирле төрмәләрдә бердәнбер сөйләшү-хәбәрләшү ысулы икәнен белдем. Нигездә, Морзе ысулы. Рус алфавиты авазлары йодрык буыннары исәбеннән, бишәрләп

юлларга бүленә. Артык күпкә китмәсен өчен, егерме дүрт аваз файдаланыла икән.

Баштагы чиртү – юл саны. Беренче, икенче, өченче юл. Икенче чиртү шул юлдагы авазның урынын белдерә. Мәсәлән, «А» хәрефе болай бирелә: башта бер чиртү – беренче юл, тагын бер чиртү – беренче юлдан беренче хәреф.

Шулай сүзләр, җөмләләр, исем-фамилияләр барлыкка килә икән.

Алкин шулхәтле маһирланган бу сөйләшүгә. Аерым хәбәрләрне тапшыру белән генә канәгатьләнми, хәтта йөрергә яки параша түгәргә чыкканда, кулга төшкән газета хәбәрләрен дә тапшыра һәм торба буенча бирелгән җавапларны бер ялгышусыз «укый».

Бу һөнәргә ул мине дә өйрәтә башлады. Әмма аны туктаусыз сорау алырга йөртүләр, аннан кыйналып килүләр бу «сабак»ны тәртипле рәвештә дәвам итәргә мөмкинлек бирмәде. Шулай да Алкин юк вакытта «соңгы хәбәрләр»не мин тапшыра башладым.

8

Алкин, әле яңа гына укырга өйрәнә башлаган бала сыман, иҗеклəп «укый»:

– Га-лим-җан И-бра-һи-мов ка-ты а-вы-рый. Би-шен-че ка-ме-ра-га Әб-җә-ли-мов-ны[1], Рес-пуб-ли-ка-нец-ны[2] ки-тер-де-ләр... То-лым-бай-ский[3] дүр-тен-че тәү-лек с-той-ка-да. Тин-чу-рин[4]...

– Тсс! – Ишек төбендә дежурда торган Габдулла баш бармагын авызына куйды. – Тсс...

Коридорда ыгы-зыгы, йөгергән, ыңгырашкан тавышлар ишетелде.

Алкин, сикереп торып, сәке кырыена утырды. Ул арада ишектәге йозак шалтырап ачылды. Кемнедер сөйрәп камерага керттеләр. Ишек шыгырдап ябылды. Габдулла белән Алкин идәнгә егылган кешене күтәреп алдылар.

– Урын!

Сәкедән ике кеше сикереп төште. Шул бушаган урынга – түбәндәгесенә – теге сорау алудан килгән кешене

---

[1] Әбҗәлимов – ВЛКСМның Сталин райкомы секретаре.

[2] Республиканец – өлкә культура идарәсе башлыгы.

[3] Толымбайский – Гомәр Толымбай, язучы, әдәбият галиме.

[4] Тинчурин – Кәрим Тинчурин, драматург.

яткыздылар.

– Бу бит Мәхмүт Баһаутдинов, – диде Алкин, яныма килеп. – Комсомолның өлкә комитеты секретаре. Мескен, аңын югалткан. Шулкадәр кыйнаганнар.

Тагын йозак шалтырады. Камера тып-тын калды. Кемнең чираты? Ишек ачылыр-ачылмас, надзиратель башын сузды:

– Алкин, допроска!

Камера калтыранып киткәндәй булды – сулыш өзелде. Ә Алкин, сәйранга гына җыенгандай, пальтосын киеп, эшләпәсен кулына алды, елмайды.

– Йә... пока!

Өстән бер йөк төшкәндәй җиңеләеп киттек.

– Булдыра алсаң, тикшерүчедән карандаш урларга тырыш...

– Тырышырмын, – Алкин тагын ягымлы елмайды да тышка чыгып китте.

Камерадагылар, авыр сулап, үз урыннарына тарала башлаганнар гына иде, тагын йозак шалтырады. Әйтерсең лә электр тогы сукты, калтырап туктап калдык. Ишек ачылды, әмма нигәдер берәү дә кермәде. Бары тик пышылдап кына сөйләшкән тавыш ишетелде, һәм шунда гаҗәеп бер хәл булды. Камерадагылар барысы да, урыннарыннан торып, ишеккә таба үрелделәр – йотылып иснәделәр.

Хуш ис! Шундый тәмле, тәнгә рәхәт бирүче хушбуй исе борынны кытыклый. Камера яктырып киткәндәй булды. Төрмә артында терәлеп торган, элек кадере беленмәгән гади тормыш, ә хәзер уй җитмәс ерак-гүзәл ирек үзе ишелеп монда керде, дөресрәге, төрмә ишеге ачылып китте сыман. Туя алмый, үрелеп-үрелеп сулыйбыз. Рәхәт тә, күңелле дә, артык газаплы да булды бу көтелмәгән очрашу.

– Барлау! – Ачулы калын тавыш рәхәт калгудан уятты.

Барыбыз да параша янына тыгызландык. Сыймаганнар өске сәндерәгә утырдылар.

Ишек киңрәк ачылды.

Камерага, ашыгып атлап, төрмә башлыгының ярдәмчесе килеп керде. Озын буйлы, атлет гәүдәле яшь егет. Өстендә өр-яңа, үзенә ятышып-сыланып торган форма – кыек сырлы кара тукымадан тегелгән френч, галифе чалбар, ялт-йолт итеп торган хром итекләр. Аның

йөзе түгәрәк, бит алмалары тулы, кызарып тора... Бар гәүдәсеннән хушбуй исе аңкып тора.

– Исәнмесез! – Аз гына елмая төшеп, тавышын күтәрмичә генә эндәште. – Ничек, жалобалар юкмы?

– Гражданин начальник, – Габдулла кысыла-кысыла алга чыкты, – камерада бик тыгыз, ятарга урын юк.

– Борчылмагыз. – Башлык ярдәмчесе, тагын көлемсерәп, камерага күз йөртеп алды. – Чыннан да, тыгызрак икән. Борчылмагыз. Бүген бушатырга тырышырбыз. – Ул бармагы белән төртеп саный башлады: – Бер, ике, өч, яле, атакай, син өскәрәк күтәрел... (миңа эндәшүе), дүрт, биш... егерме бер.

– Өч арестант допроста, – диде надзиратель, кабаланып.

– Арестант түгел, – диде санаучы, каты кисәтеп, – подслед-ствен-ный.

Надзиратель кашларын җыерды, каралып китте.

– Хушыгыз!

Башлык ярдәмчесе тикшерү нәтиҗәсен блокнотына язды да кергәндәге кебек ашыгып атлап чыгып китте. Ә камерада хушбуй исе катыш ниндидер билгесез күтәренкелек калды.

– «Бушатырбыз» диде бит, ә? – диде Габдулла.

– Кем белә. Берсекөнгә бәйрәм. Бәлки, егерме еллыкка амнистия булыр, – диде өске сәкедән карлыккан тавыш.

– Тот капчыгыңны!

– Юк, егетләр, – диде аскы сәкедән берәү, өметләнеп, – иптәш Сталин безне бу хәлдә калдырмас.

Камерада шау-шу, бәхәс башланды.

9

Пләтән төрмәсендәге иң газаплы һәм куркынычлы төннәрнең берсе, һичшиксез, җиденче ноябрьгә каршы төн булды. Арестантлар арасындагы тынычсызлык инде ай башыннан ук кузгалган иде. Бәйрәм якынлашкан саен, ул көчәя барды.

Бәйрәм алды һәрбер кешенең күңелен дулкынландыра, җилкендерә бит ул. Бәйрәм көнне ниндидер сөенечле бер үзгәреш булыр төсле тоела. Көтелмәгән яңалык-шатлык өмет итәсең. Яңа көн туган саен, әнә шул сөенечкә якынлашкан кебек сабырсызланасың. Тизрәк-тизрәк бәйрәм җитсә иде, дисең. Зарыгып көтәсең ул өметле көнне.

Ә төрмәдә? Бер гаепсез тоткынлыкка дучар булган кеше нишләргә тиеш бәйрәм алдыннан? Бигрәк тә Октябрь бәйрәме алдыннан? Октябрь революциясенә егерме яшь тулу көннәрендә, иң демократик Конституция – Сталин конституциясе кабул ителгән чорда?!

Нинди уйлар, нинди хисләр, нинди өметләр аны яктыртырга, хәл бирергә яки җәрәхәтләргә тиеш соң? Бу соңгы, хәл итүче төндә. Йә? Йә?!

Гаҗәп икән ул тоткындагы кеше. Хәйран калдым. Элек әйтсәләр һич ышанмас идем. Ә хәзер...

Тоткын ул бар гәүдәсе белән күрә, бар гәүдәсе белән ишетә, бар гәүдәсе белән тоя-сизә икән. Тәрәзәләре тимер рәшәткәләр белән ныгытылган, тимер ишекләре зур йозаклар белән бикләнгән, тышкы дөньядан биек, таш диварлар, чәнечкеле тимерчыбыклар, көне-төне йокысыз күзәтеп торучы уяу сакчылар, этләр, мылтыклар, пулемётлар белән аерылган, бүленеп алынган кап-караңгы төрмә камералары яңадан-яңа хәбәрләр белән тулып кына тора. Кайдан гына, ничек кенә килмиләр алар. Су йөри торган җылыткыч торбалар буйлап, калын таш стеналар аша, югары каттан түбәнгесенә тегәрҗеп белән төшерелгән ширпы капларында, юынырга чыкканда бәдрәф диварларына беленер-беленмәс кенә сызгаланган «тавык тәпиләре» эзендә. Параша чыгарганда игътибарга алынган надзирательләрнең күз карашында, эндәшүләренең тонында, ниһаять, әле сөйләрлек хәле калган булса, сорау алудан кайтучылар аша һәм башка бик күп, иректә бөтенләй игътибар бирелми торган, беренче карашка бөтенләй әһәмиятсез күренешләрдә, билгеләрдә.

Алкин сорау алудан көч-хәл белән кайтып керде. Битавызы күгәргән, сул күз кабагы канаган иде. Инде ул да Баһаутдинов сыман сәкегә егылыр да камера тормышыннан ваз кичәр дип уйлаган идем. Юк! Ул сәкегә утырып аз гына хәл җыйды да елмайды. Тезелеп торган ап-ак тешләре камераны яктыртып җибәрде. Тирә-яктагыларның йөзләре ачылды. Мин дә җиңеләеп киттем.

– Йә, дуслар, – диде дә, елмая биреп, түбән иелде. Ахрысы, итеген салмакчы булды, әмма кире турайды, йөзе чытылды. – Булмый икән. Сул итекне салдырыгыз әле.

Мин, йөгереп килеп, итекне салдырырга омтылган идем, кая. Балтырлары шешеп, итегенең кунычын

киергәннәр. Тәнем тетрәнеп китте. Аны да тәнозын бастырып тотканнар, ахры, кансызлар.

– Булмаса, кунычын җөеннән сүтеп җибәрегез. Габдулла, теге пыяла кыйпылчыгы кайда? – диде Алкин, тирәякка каранып.

Габдулла йоклый икән, уяттылар. Ул параша астына кыстырылган кыйпылчыкны алды. Көч-хәл белән кунычны сүттек.

– Менә, иптәшләр, гозерегезне үтәдем, – диде Алкин, итекләрен салдыргач, сул аягының чолгавы арасыннан чәнти бармак хәтле генә карандаш чыгарып. – Галимҗан ага, озынрагын алырга кулым җитмәде.

– Монысына да...

Ул арада «күз» чайкалды. Алкин юри, ахры, аякларын сузып җибәреп сүгенә башлады. «Күз» ябылды – надзиратель китте. Алар нигәдер мәхбүсләрнең сүгенүләренә игътибар итмиләр генә түгел, кул селтиләр иде. Сүгенә бирсеннәр, янәсе.

Галимҗан ага Нигъмәти карандаш төпчеген ыштан бөрмәсенә яшерергә өлгермәде, күрше дивардан чакыру сигналы чирттеләр. Алкин шундук, идәнгә шуып төшеп, стенага колагын куйды. Камера тып-тын булып калды.

– Кружка!

Кружка бирделәр. Алкин кружканы стенага каплап тыңлый, теге яктан биргән хәбәрне ятлый башлады.

– Октябрьнең егерме еллыгы хөрмәтенә моңа кадәр һич күрелмәгән зур амнистия әзерләнә. Барлык сәяси тоткыннар азат ителәчәк. Указ җиденче ноябрьдә игълан ителәчәк.

– Ура!

– Әйттем бит була дип.

– Тавы-ыш! – «Күз» ачылды – кан сарган ачулы бәбәк күренде. – Бу нинди шау-шу?

Надзиратель, кисәтүен ныгытыр өчен, ахрысы, ишеккә итеге белән бер-ике типте дә, авыр атлап, башка камераларга таба китте. Күрәсең, аларда да тынычлык юк.

Ә бездә – тантана. Камерадагыларның барысы да сөйли, һәр тоткын бу гадәттән тыш хәбәр турында нигезле фикерен ишеттереп калырга тырыша.

Дөресен әйткәндә, әле генә Алкин кружка аша күрше камерадан алган хәбәр яңа түгел, ул инде ай буенча ка-

батлана. Әмма хәзер, бәйрәм алды төнендә! Октябрьнең егерме еллыгы тантанасы алдында! Бусы инде, һичшиксез, нигезле өметләнү.

Бөек Октябрьгә егерме ел тулганда, ничек инде шул революцияне үз куллары белән барлыкка китергән, аны саклап калу өчен кан түккән ветераннар, аларның эзбасарлары – яшьләр, комсомоллар төрмәдә утырсын? Акылга сыймый.

Бу хәбәр – амнистия турындагы сүзләр – ничә генә тапкыр кабатланмасын, һәрвакыт, беренче тапкыр ишеткән сыман, тын алуны өзеп, онытылып тыңлыйбыз. Күңел яктыра, күзләр нурланып китә, хәтта сулган-саргайган йөзләргә алсулык сирпелә. Сулыш иркенәя.

Ирек! Азатлык! Синнән дә татлырак, синнән дә кадерлерәк, кыйммәтлерәк тагын нәрсә бар дөньяда? Әмма синең иксез-чиксез киң, җылы, мәрхәмәтле кочагыңда вакытта без кадереңне генә белмибез икән, бөек бәхет!

Инде күп калмады. Аз гына, бик аз гына түзәргә, сабыр итәргә кирәк. Озакламас, бу авыр ишекләр ачылып китәр. Без тагын да кешелекнең бөек куанычы – азатлык кочагына ташланырбыз һәм туйганчы иркәләнербез.

Барыбыз да ул көннең тууына ышана идек, иманыбыз камил иде. Без бит ят түгел, үги түгел. Барыбыз да Совет иленең тугрылыклы, фидакяр балалары. Шулай булгач...

Тиздән! Тиздән!

Бөтен камера шушы изге уйлар белән дулкынланды!

– Даң-доң! Даң-доң!

Тоткыннарның йөрәген өшетә торган, нервларын өзелердәй итеп какшата, акылны томалый торган чаң! Шомлы, кара каргышлы чаң! Бу ни бу? Гадәттә, бу чаң кичке чәйдән соң – тикшерү алдыннан сугыла иде. Хәзер бит әле сәгать, күп булса, биш-алты чамасында гынадыр.

– Даң-доң! Даң-доң!

Коридорда ыгы-зыгы. Әллә янгынмы? Әллә инде берәрсе качарга маташканмы? Хәер, тимер рәшәткә, калын тактадан эшләнгән «калфак», таш стена, чәнечкеле тимерчыбык, этләр, сакчылар, мылтык, пулемётлар киртәсе аша мөмкинмени бу?!

Әллә? Әллә берәрсе бу хурлыкка чыдый алмый асылынганмы? Бу хәлнең булуы бик мөмкин. Әмма бер тоткын асылынган өчен бу хәтле ыгы-зыгы тумас. Даңгыл-

дау туктар-туктамас, камераның ишеге ачылып китте.

Надзиратель бар тавышына акырды:

– Торыгыз! Басыгыз! Тикшерү! Тизрәк!

Упыр-тупыр бер-беребезне кысып, параша янына өереледек.

Камерага, атылып, ике хәрби кеше керде. Өсләрендә – озын соры шинель, яка очларында – янып торган берәр шпал, димәк, майорлар. Башларында – өр-яңа колакчын бүрекләр. Икесе дә урта яшьләрдә, тулы гәүдәле. Йөзләре суык. Күзләре, бораулап, ачу белән карый. Әле күптән түгел генә барлау ясаган төрмә башлыгы урынбасары бусага төбендә «смирно» баскан, өлкән түрәләрнең боерыкларын көтә.

– Тикшерү, – диде майорларның берсе, камераны сөзеп карап, ачулы тавыш белән. – Тизрәк! Берәм-берәм минем алга басыгыз да исем-фамилиягезне, кулга алынганчы кайда, кем булып эшләвегезне әйтеп, сәкеләргә менеп капланып ятыгыз. Кара, монда бүтән карыйсы булмагыз. Йә-йә, башладык. Син?

– Алкин, ВКП(б)ның Казан шәһәре Бауман район комитетының беренче секретаре.

– Марш! Син?

– Галимҗан Нигъмәти, профессор.

– Марш! Син?

– Сөббух Рәфыйков, шагыйрь.

– Син?

– Имәнкулов Зариф, беренче татар полкы комиссары.

– Син?

Түбәнге сәкедән озын буйлы, таза гәүдәле кеше күтәрелде. Майор сискәнеп артка чигенде, күрәсең, сугып җибәрер дип курыкты һәм икенче тапкыр, бу юлы инде акрын гына эндәште:

– Сез?

– Камай Гыйлем, профессор, Владимир Ильич Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты ректоры.

Майор тагын артка чигенде.

– Стенага карап басыгыз. Следующий?

– Сәләх Атнагулов, профессор.

– Өскә! Син?

– Баһаутдинов Мәхмүт, комсомолның Татарстан өлкә комитеты секретаре.

– Өскә!
– Менә алмыйм. Аякларым шешкән.
– Ярар, алайса, – дип, майор нәфрәтле караш ташлады. – Ярар, түбәнгә ят. Син?
– Акимов Николай Васильевич, Татпросвет секретаре.
– Син?
– Нижегородцев Ардалион Михайлович, өлкә комсомол комитетының бүлек мөдире.
– Ә син нәрсә анда менеп кунакладың? Төш!
Өске сәкедән, җиңел генә сикереп, атлет гәүдәле берәү төште.
– Чанышев.
Әле һаман артта басып торып, килүчеләрне блокнотына язып торган майор, кинәт блокнотын төшереп җибәрә язып, кабаланып алга атлады.
– Якуп?
– Юк. Ул – минем абыем. Ул – комдив. Мин – җайдаклар эскадроны командиры.
– Өскә! – Алда торган майор кашларын җыерды, йөзен чытты: – Барыгыз да елан Тухачевскийның койрыклары.
Чанышев нәрсәдер әйтергә дип авызын ачкан иде, бусагада басып торган төрмә башлыгы ярдәмчесе бармак янады:
– Тсс! Молчать!
Чанышев башын чайкады да, бер сикереп, иң өске сәндерәгә менеп китте.
– Син?
– Гомәр Гали, әдәбиятчы, редактор.
– Ә син, чулак?
– Мыскылламагыз, – дип, Николай чулак кулын селкеп алды. – Тумыштан.
– Безгә барыбер. Фамилияң? Тизрәк.
– Борциковский Николай, Казан педагогия институты студенты.
– Син?
– Шәйхетдинов Касыйм, «Кызыл яшьләр» газетасы редакторы.
– Ильясов Гали, Татар академия театры режиссёры.
– Син нәрсә аптырап торасың?
Параша янында басып торган Габдулла сискәнеп китте:
– Мин? Мин бит комсомол райкомы секретаре. Мин...

– Ярар. – Майор әйтеп бетерергә бирмәде, бүлде: – Фамилияң?

– Әхмәдуллин Габдулла...

Аннан соң ике укытучы, бер прокурор, бер ВКП(б)аның авыл райкомы секретаре аваз бирде. Сәкедә урын булмагач, аларны стенага каратып бастырдылар. Мин дә шулар рәтенә эләктем. Башкалар әле сорау алудан кайтмаган иде.

Гадәттә, барлауда саныйлар да чыгалар иде, болай мәсхәрәләп яткырмыйлар, стенага терәмиләр иде бит. Бу ни бу? Бәйрәм алдыннан тагын нинди «яңа тәртип» күрсәтәләр монда?

– Отбой. Ятыгыз. Тавышланмагыз, – диде алдагы майор, тикшерүне төгәлләп, тагын бер тапкыр камераны сөзеп карап.

– Ә кичке аш? – Кемдер югары сәкедән кычкырды.

– Бүген анысы юк, – диде дә башлык ярдәмчесе ишекне япты. Йозакны юри, ахрысы, шалтыр-шолтыр китереп бикләде.

Уйны уйга сузып, очларын бәйли алмыйча җәфаланганда, тагын ишек ачылды, ашыгып надзиратель керде, елан төсле пышылдады:

– Ыш-ш-ш, «А» хәрефенә кем бар?

Бусага төбенә өч тоткын килеп, фамилияләрен әйттеләр.

– Алкин.

– Кирәкми.

– Акимов.

– Кирәкми.

– Атнагулов.

Сәләх ага, болай да ябык, озын, әз генә шадра кеше, хәзер бөтенләй караңгыланып, хәлсезләнеп китте. Ул әле иртән генә сорау алудан ватылып, көч-хәл белән кайткан иде.

– «Б» хәрефенә?

Надзиратель әйтеп тә бетермәде, өске сәндерәдән Николай сикереп тә төште. Надзиратель чак тайпылып калды.

– Хәшәрәт! Баса яздың бит, чулак җен.

– Мин бит Борциковский, – диде Николай, бер дә борчылмыйча. Ул әле сорау алуда булмаган, беренче чакы-

рылуы иде.

– «Б»га тагын кем?

Югарыдан кемдер җавап бирде:

– Баһаутдинов тора алмый. Яңа гына...

– Молчать! – Надзиратель ачуыннан сикереп китте. – Анысы миңа кагылмый. Торгызыгыз!

Тынлык. Беркем кузгалмый.

– Торгызыгыз, – дип, надзиратель акырып җибәрде, – кабахәт контрлар! Кемгә әйтәм мин? Өстерәп төшерегез.

Тагын тынлык.

– Мин сезне акылга утыртырмын, анагызны... – Надзиратель, кабахәт сүзләр белән сүгенеп, коридорга таба борылды. – Керегез әле!

Ишек артында көтеп кенә торганнар, ахры, ике дәүдәү надзиратель атылып керде. Өлкән надзиратель түбәнге сәкедә ыңгырашып яткан Мәхмүткә ишарәләде:

– Әнә теге контрны алып чыгыгыз.

Бераздан Камайны, Галимҗан Нигъмәтине, Гомәр Галине, рәссам Зәбихне алдылар. Сәкедә урыннар бушады. Әмма бер генә тоткын да, аягүрә торудан хәлсезләнүләренә карамастан, ул урыннарны алырга ашыкмады.

Тынлык. Авыр кара тынлык.

Ә коридорда һаман ыгы-зыгы. Нинди тынгысыз бу бәйрәм алды төне?

– Син, энем, минем якка борылып ят әле, бер эчемне бушатыйм. Юкса болай уйлый-уйлый акылдан да шашарсың... Очы очка җитми, – диде сул ягымда яткан күршем. «Өч күнлек секретарь».

Белмим, аны нигәдер шулай атыйлар. Үзе шул кушаматка өйрәнгән, рәнҗеми дә. Әмма хәзер мин аның кушаматы белән кызыксынудан яки сөйләшергә теләүдән ерак идем. Үз уйларым үземә җиткән – очы-кырые юк. Теге вакытта ялгыш кына кулга алуларыдыр, төрмәне күрсәтмичә генә чыгарып җибәрмәгәйләре дип борчылган идем. Инде менә төрмәне дә, андагы мәхбүсләрне дә күрдем. Моннан чыгу мөмкинлеге исә көннән-көн ерагая бара. Бөтен ышаныч амнистиядә... Анысы булыр да, булмас та төсле – су өстендәге калкавыч кебек, бер күренеп күңелне ярсыта да тагын суга бата... Шуңа күрә әлеге иптәшкә:

– Эчне пошырма әле, – дидем дә борылып яттым.

– Юк, син тыңла әле, энем, – дип каныкты бу, –

тыңласаң, кайгың таралыр. Күреп торам бит, син әле өйләнмәгән дә егет. Институтта сөйгәнең дә калгандыр. Ни өчен мине «өч көнлек секретарь» дип атыйлар, шуны сөйлим әле. Син шагыйрь бит. Теге «Кырык вәзир»дәге «Бер сәгатьлек хәлиф»не укыгансыңдыр, нәкъ шуның сыман.

– Алай бик кызык булгач сөйлә инде. – Мин күршемә таба борылып яттым.

– Менә, энем, мин көч-хәл белән ТКУны тәмамладым. Аннан Казан артындагы авылларның берсендә райком инструкторы булып эшли башладым. Дөресен әйткәндә, миндә әллә ни оештыру таланты да кәпрәеп күренмәде. Кушканны эшлим дә йөрим. Кушмаганга тыкшынмыйм. Үзем болай, энем, тумыштан барга канәгать. Күктән йолдызлар үрелеп алу өметем булмады. Дәрәҗә баскычларыннан күтәрелү турында да уйламыйм, чамамны беләм дә мыштым гына йөрим. Ул арада уртакул бер авыл кызына өйләнеп тә алдым. Җаныем да әллә кая үрелмәде, колхозда сыер сава башлады. Ә менә ел башыннан эшләр үзгәрде дә китте.

– Әйе, шуннан?

– Кызыгы әле алда, энем. Менә бит, язгы чәчү алдыннан гына, безнең беренче секретарьны һәм минем турыдан-туры башлык агитпроп мөдирен бер төндә алдылар да куйдылар. Обкомнан килгән вәкил: «Алар халык дошманнары», – дигәч ышанасы да килмәде. Ләкин, Казаннан килеп әйткәч, ышанмый кая барасың? Икенче секретарьны – беренче, мине мөдир итеп сайладылар да куйдылар. Җаваплы эшне кабул итәргә дә өлгермәдем, бер төндә теге икенче секретарьны да алдылар. Аны да: «Дошман булган, астыртын корткычлык эшләгән», – диделәр. Өченче секретарь авырып больницада ята иде... Обком вәкиле тотты да мине беренче секретарь итеп тәкъдим итте. Ис китте. Сайламаслар дигән идем. Бюро членнарының берсе дә каршы кул күтәрмәде. Дөресен әйткәндә, былтыр конференциядә сайланган бюро членнарының яртысы юк – төрмәдә утыралар иде.

Менә мин беренче секретарь кабинетында. Ул арада Казаннан тагын вәкилләр килеп тулды. «Район оешмаларында корткычлар утыра, хәзер үк аппаратны алардан тазартырга кирәк, менә исемлек», – диделәр.

Аптырадым. Үзем белән бергә эшләгән иптәшләр. Һич тә корткычка охшамыйлар иде. Нишлисең, югарыдан кушкач тыңларга кирәк. Бюро җыйдым. Өч көн район аппаратын корткычлардан тазарттым. Инде дүртенче көн, уф Алла, үз эшемә тотыныйм дип җыенсам, райком ишеге төбендә ике адәм:

– Иптәш секретарь, безгә кереп чыгыгыз әле, – диделәр.

Киттем. Менә инде утыз тугызынчы тәүлек монда ятам. Әле һаман...

Шалтыр-шолтыр ишек ачылды. Барыбыз да сикереп тордык – кемдер сорау алудан кайтты, ахры. Юк икән. Надзиратель, пышылдап:

– «Р» хәрефенә кем бар? – дип сорады.

Янымдагы «өч көнлек секретарь» идәнгә сикереп төште.

– Рамазанов Миңлегали.

– Киен.

Миңлегали пальтосын, фуражкасын таба алмый кабалана. Мин аларны баш очыннан суырып алып бирдем. Ул ашык-пошык киенеп чыгып китте. Әллә ничек йөрәгем сызылып калды. Беркатлы, риясыз шул кешене жәлләде күңелем.

Камерада тагын тынлык урнашты. Түшәмдәге корымланып беткән лампочка кызарып кына яна. Шуның өчен монда ярым караңгы. Кемдер буылып йөткерде. Кемдер авыр көрсенде һәм тавышланып рәнҗеде, газапланды:

– Йа Алла, бу нинди хаксызлык?!

Чыннан да, нигә мондый гаделсезлек, ә? Иртәгә бит олы бәйрәм. Октябрь революциясенә егерме ел тула. Ә без менә монда, тынчу төрмәдә, бет, борча, кандала оясында ятарга урын таба алмый нахакка газапланабыз. Зәйтүнә хәзер нишли икән, ә? Җүләр, нишләсен, рәхәтләнеп караватында сузылып ятып йоклыйдыр. Иртәгә демонстрациягә барасы бар бит. Ә хәзер инде төн уртасы... Күңелем тулып китте – күзләремнән яшь тамды. Эре-эре тамчылар битемне пешерә. Капланып үкси башладым.

– Ибраһим, Ибраһим, сиңа ни булды, елама, – диде ниндидер йомшак тавыш. – Ярамый.

Ә мин тыела алмыйм, аның саен буылып-буылып үксим.

– Нигә мондый хаксызлык?..

– Ибраһим...

Артык йомшак, якын, ягымлы тавыш. Кем соң ул минем өчен болай борчыла? Торып утырдым.

– Елаудан файда юк, – диде Алкин, миңа якынрак шуышып утырып. – Ялгыз син генә түгел бит.

– Алай да... Мин нинди халык дошманы булыйм ди, Алкин абый? Мин бит балтачы малае. Совет хөкүмәте мине институтка кадәр китерде.

– Ә менә Гыйлем Камай? Ул кем? Фабрикант баласымы? Аның әтисе гомер-гомеренә бурлак булган, Идел буенча баржалар тартып йөргән. Гыйлем үзе пристаньнарда йөк бушатып йөргән. Совет хөкүмәте аркасында гына укып, утыз яшендә профессор дәрәҗәсенә күтәрелгән. Аның ачышлары фәнгә зур казаныш китерде һәм илебезне дөнья күләмендә югары дәрәҗәгә күтәрде. Ул...

– Шундый галимне нигә соң төрмәгә япканнар?

– Бу сорау мине дә борчый, – диде Алкин, көрсенеп, сүздән язып. Аннары өстәде: – Иптәш Сталин бу баш-баштаклыкка юл куймас, тикшерер. – Алкин сакалын тарап, уйланып торды да тагын кабатлады: – Тикшерер. Башкача һич мөмкин түгел. Менә татар әдәбиятының ерак тарихын җанландыручы, бүгенгесен үстерү өчен армый-талмый эшләүче галимнәр – Галимҗан Нигъмәти, Сәләх Атнагулов та ярлы крестьян гаиләсеннән.

– Ә сез?

– Минем әти дә ярлы крестьян булган. Үзем Казанда бер олаучы абыйда ат карап, «барабыз» булып эшләп үстем. Аннан рабфакта укыдым.

– Ә шулай да, абый... Нигә болай чып-чын коммунистларны, Совет хөкүмәте өчен сугышкан кешеләрне төрмәләргә тутыралар, ә? Әллә инде фетнә кузгалып, хөкүмәт эсерлар кулына күчкәнме? Бәлкем, иптәш Сталин да хәзер төрмәдә утыра торгандыр, ә?

– Юк, анысы ук булмас, булмас, – диде күршем сагышлы тавыш белән.

Тагын ишек шалтырап ачылды. Ниндидер шинельле бер кешене төртеп керттеләр.

Без түбән төштек. Таныш түгел, яңа кеше иде ул.

– Иптәш, сезне әллә яңа гына кулга алдыларммы? Тукта, сез... сез Беренче татар полкы командиры Тупиков түгелме?

– Алкин!

Кочаклаштылар. Бер-берсеннән аерыла алмыйлар. «Күз» ачылды. Ачулы ялгыз бәбәк карады. Ябылды. Ә Алкин белән Тупиков һаман әле кочаклашып, аптырап, куанып, борчылып, бер-берсенә сораулар яудыралар.

– Йә, ярар, – диде Алкин, ниһаять, үзеннән байтак озын, таза командирның кочагыннан чыгып. – Әйдә, утыр. Син кайдан килеп төштең?

– Эх, әйтмә инде! – Тупиков сәке кырыена утырды. – Өч көн инде сорау алалар. «Имәнкулов белән бергә контрреволюцион оешмада торгансыз. Ул инде гаебен таныды», – ди тикшерүче.

– Ялганлый, – Алкин утырган урыныннан сикереп торды. – Ялган. Зарифны әле бүген генә сорау алырга чакырдылар. Ул һичбер документка кул куймый, шуның өчен барган саен кыйныйлар.

– Ә мин инде, тикшерүчегә ышанып, Имәнкуловны яла ягуда гаепли башлаган идем.

– Юк-юк, ышанма. Зарифны инде бер атна илиләр. Сорау алудан кайтып егылырга өлгерми, тагын күтәрәләр. Кыйныйлар. Коры сөяккә генә калып бара. Тагын нинди яңалык?

– Менжинский клубында хәрби трибунал. Өченчекөнне «Буа эше»н караганнар.

– Әйе-әйе, ишеткән идем. Нәрсәдә гаеплиләр, кемнәрне?

– Кемнәрне булсын, Буа районының барлык җитәкчеләрен. Райком секретарьларын, башкарма комитет председателен һәм башкаларны. Барысы уналты кешене[1]. Имеш, корткычлык оештырганнар. Кичә хөкем карары укылган.

– Аклаганнармы?

– Аклаганнар: унбишен атарга, бары редактор Яушевка гына унбиш ел төрмә.

– Булмас! – Алкин кычкырып җибәрде. – Булмас!

– Кызганыч, ләкин бу дөрес, – диде Тупиков, авыр сулап. – Дөрес.

---

[1] «Социалистик Татарстан» газетасының 1988 елгы 26 май санында «Буа эше» дигән мәкаләдә хөкемгә тартылучылар саны – егерме бер, атарга хөкем ителгәннәре ундүрт дип бирелә. – Ред. искәр.

Алкин камера буенча арлы-бирле йөрде дә килеп туктады.

– Тагын?

– Бүген шунда ук бер төркем хәрбиләргә суд башланды. Анда дивизия командиры Дзент та бар, ахрысы. Шулай ук корткычлыкта, фетнә әзерләүдә гаеплиләр, ди. Безне дә шул төркемгә тыгарга тырышалар. Анда кушсалар бетәбез!

– Шулай уйлыйсыңмы?

– Башкача мөмкин түгел. Кара әле, Алкин, – Тупиков тавышын баса төште, – исемдә вакытта әйтеп калыйм. Зариф кайтса, болай диген...

Кинәт камераның ишеге ачылып китте, алҗыган, мышнаган надзиратель башын тыкты:

– Тупиков мондамы?

– Монда.

– Уф Алла! – Надзиратель, гыжылдап сулап, ишекне ачып җибәрде: – Син сволочьны коридор бетереп эзләп йөрим, үз камераңны белмисеңмени?

– Үзең керттең ләбаса.

– «Үзең, үзең»! Сез монда төрмә тулы, ә мин – берьялгызым. Әйдә тор, чык!

– Йә, хушыгыз! – Тупиков кулларыбызны каты итеп кысты да чыгып китте.

Тимер ишек шап итеп ябылды.

Алкин түбәндәге сәкегә сузылып ятты. Мин икенче катка менеп киттем. Күзләремне йомдым, әмма йокы юк. Уйлар, уйлар. Бал корты төсле мыжылдыйлар. Бу ни хәл, ә? Армиядән кайтуыма әле дүрт ел да юк. Мин өч ел Казанда Беренче татар полкында хезмәт иттем. Полкның командиры – Тупиков, комиссары Имәнкулов иде. Мин аларга сокланып карый идем. Алар икесе дә Гражданнар сугышында катнашкан, каннарын, җаннарын аямыйча Совет хөкүмәте өчен сугышкан кешеләр. Имәнкулов Зарифның күкрәгендә Кызыл Байрак ордены. Аны Реввоенсовет председателе иптәш Фрунзе үзе бүләкләгән – Төркестанда басмачылар белән сугышта күрсәткән батырлыклары өчен. Ә хәзер? Алар икесе дә төрмәдә. Нигә? Нигә? Артык арылган, ахрысы, күзләрем йомылып китте...

Зәйтүнә белән көймәдә Кабан күлендә йөзә идек. Мин мандолина уйныйм, Зәйтүнә җырлый, «Агыйдел» көенә, минем шигырьне җырлый:

Агыйдел алкын икән,
Сулары салкын икән;
Агыйделкәй кызларының
Йөрәге ялкын икән.

Зәйтүнә кинәт җырны бүлә дә миңа карый – бармак яный.

– Ә син каян беләсең?

– Нәрсәне? – Аптырап, ишүемнән туктыйм, төшенмим.

Зәйтүнә бик җитди.

– Ник, үзең язгансың бит, Агыйдел кызларының йөрәге ялкын икән, дип. Кем әйтте? Йә, җавап бир әле?

Мин көләм.

– Кем булсын. Синең йөрәк. Бөре кызының йөрәге. – Үзем, ишкәкләремне ташлап, аның иреннәренә үреләм.

Шулчак көймәбез чайкалып китте.

...Ниндидер шау-шудан сискәнеп, күзләремне ачтым. Камерадагылар барысы да торып утырганнар – үрелеп тыңлыйлар. Алкин ишек төбендә колагын ишек ярыгына куйган. Мин дә торып утырдым.

Коридорда тагын ниндидер ыгы-зыгы. Ашыгып атлап, коридорны дер селкетеп, әле бер, әле икенче якка узалар. Берәү, икәү генә түгел, күбәүләр. Пышылдап сөйләшкән, сүгенгән тавышлар. Инде бит таң алдыдыр? Бу нинди вакытсыз ыгы-зыгы? Барыбыз да сулыш алуны кисеп тыңлыйбыз: нәрсәгә бу хәтле йөгерешәләр анда – коридорда?

Кинәт безнең камераның ишегендәге йозак та шалтырады. Алкин парашага таба авышты. Әллә инде сорау алудан китерделәр, йөрәк сызлана, сыкрый, сыгылып-сыгылып китә.

– Дөп-дөп! Дөп-дөп!

Бу нинди тавыш? Дөп-дөп... Чү, бу бит минем үз йөрәгем шулай тавышланып суга – тынычсызлана. Ярсый. Әйтерсең лә менә-менә ниндидер коточкыч фаҗига булырга тиеш. Йозак тагын шалтырады. Ишек тартылды. Берничә дагалы итек допылдап килеп туктады. Китерделәр. Мөгаен, сорау алуда изгәннәр, култыклап китерделәр...

Пышылдау. Ишек каты итеп этелде. Дагалы итекләр дөп-дөп итеп алдагы камераларга таба уздылар. Алкин тагын ишек төбенә чүгәләде.

– Каршыдагы камера ачылды, – ди ул. – Бер, ике өч... Өч кешене алып чыктылар.

Ишек шыгырдап ябылды. Йозак шалтырады. Алты аяк адымы түбәнге катка төшә торган баскычка таба кузгалды. Дөп-дөп. Пышылдау. Кинәт «күз» ачылып китте. Акайган бәбәк кадалып карады да акырып җибәрде:

– Ятыгыз, контрлар!

Ишеккә ике тапкыр типтеләр. Тагын теге карлыккан тавыш колакны тондырды:

– Ятыгыз, дим, этләр, ятыгыз!

Барыбыз дә сәкегә сузылдык. Аяк тавышлары ераклашты. Коридор тып-тын булып калды.

Без дә тынычлана башладык. Әмма игътибарыбыз әле һаман ишектә. «Күз» ачылды да ябылды. Алкин әле һаман бусагага чүккән килеш тыңлый. Тынлык. Инде ул да арып, китәргә дип кузгала башлаган иде, баскыч ягыннан ашыгып атлаган дагалы итекләр тавышы ишетелде. Якынлашты. Узды. Туктады.

– Сизәсезме, – диде Алкин, – үлем камерасына килделәр.

Барыбыз да сикереп торып утырдык. Сулыш киселде, йөрәк тибүдән туктады. Ни була? Нинди җинаять эшләргә җыеналар анда, бәйрәм алды таңында?

Шыгырдап, каршыдагы үлем камерасының ишеге ачылды. Корыч тавыш чыңлап китте. Мөгаен, ашыгып кергәндә штыклар бер-берсенә сугылдылар. Ишек шыгырдап ябылды. Тынлык. Үлемгә хөкем ителгәннәрне киендерәләр иде, ахры. Ишек ачылды. Ыгы-зыгы. Баскыч ягыннан тагын берничә пар дагалы итек бу камерага таба ашыгып атлады. Ыңгырашу. Нindидер кагылу-сугылу. Өстериләр иде, ахры. Кемдер гөп итеп идәнгә егылды. Тагын ыгы-зыгы.

– Ип-тәш-ләр... Буа-лар...

Җан тетрәткеч ачы тавыш бөтен төрмәне телгәләде. Әйтерсең лә ток сукты. Барыбыз да сәкедән сикереп төштек. Ишеккә өелдек. Коридордагы ыгы-зыгы көчәйгәннән-көчәя бара. Сугылу, гөрселдәү, ыңгырашу, чырылдау. Тынлык. Аяк адымнары. Кузгалдылар.

– ...Ип-тәш-ләр, – тагын гырылдап, буылып чыккан тавыш. – А... атар-га а-лып ба-ра-лар... Без га-еп-сез... Сталин... Сталинга...

Тавыш гырылдап киселде.

Нижегородцев ике кулы белән ишекне кыйный башлады:

– Сез нишлисез, палачлар?!

Күрше камераларның да ишекләренә типкәли, кычкыра башладылар.

– Палачлар!

– Сталинга язабыз!

– Бүген Октябрьгә егерме ел тула, ә сез большевикларны атасыз!

Шау-шу. Дөбердәү. Акыру. Бөтен коридор, бөтен Пләтән төрмәсе дөрләп кабынды-кузгалды, гөр килде.

Ул арада тагын коридордан ыңгырашу, буылып, гырылдап чыккан тавыш:

– Яшә-сен... Ста-лин!..

– Сук авызына!

– А-а... – Коточкыч ыңгырашу.

– Авызына чүпрәк тыгыгыз.

Тагын ыгы-зыгы. Берничә кеше, тартышып барып, идәнгә егылды, күрәсең. Коридор селкенеп киткәндәй булды.

Төрмә артында мылтык аткан тавыш ишетелде.

Этләр буылып-буылып өрә башладылар.

Без барыбыз да ишеккә барып ябырылдык.

10

Ниһаять, зарыгып, сабырсызланып, өметләнеп көткән бәйрәм көне, Октябрь революциясенең егерме еллык тантанасы көне – җиденче ноябрь.

Бу иртәдә беренче сюрприз – безнең камераны иртәнге баландадан мәхрүм итү булды. Үткән кичке баланданы бирмәүне дә онытa алмый идек әле. Менә сиңа кирәк булса «бәйрәм бүләге».

Болай да буш корсаклар тагын кысылды һәм быкырдап-кычкырып ашарга сорады. Ә баланда мичкәсе бүген безнең камера янына тукталмады.

Сәбәп?

Сәбәбе дә аның әллә ничек, ак күңеллелектән, беркат-

лылыктан килеп чыкты.

Гадәттәгечә, бүген иртә белән дә йокыдан торырга (кем йоклады икән бу фаҗигале төндә!) чаң суктылар.

– Даң-доң! Даң-доң!

Без әле урыннардан сикереп торырга өлгермәдек, ишек ачылды, ашыгып, төрмә башлыгының ярдәмчесе килеп керде.

Ул көндәгечә бик пөхтә киенгән – киеменең бер җирендә җыерчык юк. Җиңел, шат, күркәм, рәхимле, мөгаен, бәйрәм тәэсирендәдер. Без дә җиңеләеп киттек. Камера яктыргандай булды. Мин үземнең беркатлылыгым белән ул әле безне бүгенге олы бәйрәм, Октябрьнең егерме еллыгы белән тәбрик итәр дип тә өметләнгән идем. Анысы ук булмады. Алай да ул бүген башка вакыттагы кебек ачулы кычкырмады, елмаеп кына эндәште:

– Әйдәгез, барлашып алыйк.

Без өйрәнгән гадәт белән параша янына кысылдык. Көяз түрә бармагы белән һәрберебезнең күкрәгенә төртеп санады – сәкегә чыгарды.

– Бер, ике, өч... уналты.

– Башкалар сорау алуда, гражданин начальник, – дип рапорт бирде камера старостасы Алкин.

– Бик яхшы, – диде ул, елмаеп, кесәсеннән блокнотын алды, язарга омтылды – карандашы юк. Әле бер, әле икенче кесәсен актарды, борчылды.

– Ах, шайтан алгыры, кабинетта онытып калдырганмын, – ул үтенү белән безгә карады. – Бәлки, берәрегездә карандаш кисәге бардыр?

Әле генә сорау алудан кайткан Галимҗан ага Нигъмәти аның янында тора иде. Ул карашны үзенә кабул итте. Уңайсыз хәлдә калган түрәгә ярдәм күрсәтергә ашыкты:

– Миндә бер бик кечкенә генә карандаш кисәге бар иде...

Бу сүзләрне ишетүгә, Алкин калтыранып китте, күзләре белән Нигъмәтигә ниндидер ишарәләр ясады. Әмма Нигъмәти аңа игътибар итмәде.

– Менә, менә, – көяз түрә хәтта иелә төште, елмаюдан бите балкып китте. Без дә елмайдык: нинди әйбәт, үз кеше. – Миңа кечкенә булса да ярый.

Галимҗан ага Нигъмәти, чалбарын ычкындырып, ыштан бөрмәсеннән кичә Алкин алып кайтып биргән каран-

даш сыныгын алып бирде.

– Рәхмәт, коткардыгыз, – түрә блокнотына барлау санын язды да теге карандаш сыныгын кесәсенә салып куйды.

– Гражданин начальник, – Галимҗан ага хәтта кулын сузды. – Сез ялгыштыгыз...

– Юк, – диде түрә рәсми һәм коры гына. Шундук йөзе дә агарып, суынып китте: – Бу карандаш монда урлап алып киленгән. Аны миңа тапшыруыгыз өчен, профессор әфәнде, сезгә күп рәхмәт. Ә камера, тәртипне бозган өчен, карцер режимына куела. Надзиратель, әмерне алырсыз. Пока иртәнге ашны бу камерага бирмәгез.

Ул кергәндәге кебек үк ашыгып атлап чыгып китте. Ишек ябылды. Камерада хушбуй исе һәм тирән ачыну калды.

– Сволочь! – Сорау алудан кайтуга, аскы сәкедә керпе төсле бөгәрләнеп ятып, камерадагылар белән ләм-мим сөйләшми торган тәбәнәк юан кеше – район прокуроры – кемдер үзен тибеп җибәргәндәй чәчрәп сикереп торды да Галимҗан агага сугарга кизәнде: – Синең аркаңда ач калдым!

– Акрын, – якында гына торган Сөббух Рәфыйков тегенең кулын тотып калды, этеп җибәрде. – Син генә түгел, барыбыз да ач. Галимҗан ага әнә үзе дә нишләргә белми...

Чыннан да, Галимҗан ага битен ике кулы белән каплап, бөгелеп төшкән иде.

– Син, малай, миңа кул сузма. – Прокурор тагын әтәчләнә башлады.

– Кул сузу түгел, – Сөббух, кызарынып-бүртенеп, аңа таба үрелде, – буып ук ташлармын.

– Каравыл! – Прокурор акырып ишеккә ташланды. – Каравыл, ишекне ачыгыз!

«Күз» чайкалды, аннан акайган сыңар бәбәк карады. Ишек ачылды.

– Нигә акырасың?

– Үтерәләр.

– Ха-ха... – надзиратель кычкырып көлә башлады. – Юк, үтергәндә болай кычкырмыйлар, прокурор әфәнде...

– Мин... мин... честный. Мондагылар барысы да дошманнар, халык дошманнары.

– Утыр яхшы гына, – дип, надзиратель, чыннан да, керпе сыман тырпайган, коридорга чыгарга омтылып, төкерекләрен чәчә-чәчә пышылдаган прокурорны этеп җибәрде. – Кем честный, кем юк – аны тикшерү ачыклар. Кит!

Прокурор идәнгә тәгәрәде. Кемдер арттан аяк чалды, ахрысы. Ишек ябылды. Прокурор киредән урынына менеп ятмакчы иде, шау-шуга уянган Камай (ул әле таң алдыннан гына сорау алудан кайткан иде) прокурорны җилкәсеннән алып күтәрде дә, арт ягына тибеп, сәке астына кертеп җибәрде.

– Ят шунда, чыксаң, инде чынлап үтерәм, – диде тыныч кына.

Бераздан ишек ачылып, таныш булмаган берәүне керттеләр. Күн тужурка, шундый ук күн фуражка кигән. Аякларында балтырларын кысып торган, күннән эшләнгән куныч – крагилар һәм сары ботинкалар. Яшь егет. Йөзендә ару, борчылу. Аңа прокурорның урынын бирделәр. Егет, берәүгә дә карамыйча, эндәшмичә, күрсәтелгән урынга утырды. Бераздан Алкин, аның янына килеп:

– Син кайдан, иптәш? Нинди яңалык? – дип сүз башлады.

– Яңалык чамалы, – диде егет, теләр-теләмәс кенә башын күтәреп. – Бүген төнлә мин бер укытучы белән утырдым. Әлмәттән. Аны Атласов төркемендә судлыйлар икән.

– Нәрсә, инде суд та башланганмы?

– Инде икенче көн. Менжинский клубында трибунал хөкем итә, ди. Ябык суд. Берәүне дә кертмиләр. Клуб солдатлар, этләр белән саклана. Менә шул укытучы гаҗәпләнеп, хәвефләнеп сөйләде.

Мин дә, башкалар да, югары сәкеләрдән төшеп, крагилы егет янына өерелдек. Сөббух «күз»не капларга басты.

– Һади Атласов, – инде алтмышның аръягында булуына карамастан, таза, нык, җиңел сөякле, хәрәкәтчән кеше. Ул инде бер срок утырып кайткан. Соңгы елларда Бөгелмәдә укытучы булып эшли иде, ди. Үзе бик нәзакәтле, тәрбияле, югары белемле галим. Француз, немец, инглиз телләрендә яхшы сөйләшә, китаплар тәрҗемә итә иде, ди.

– Әйе-әйе, беләбез, – диде Камай ага, – талантлы кеше. Шуннан...

– Трибунал аны, Бөгелмәдә контрреволюцион оеш-

ма төзеп, Совет хөкүмәтен җимерүгә әзерләнүдә гаепли. Бу оешманың актив членнары дип, Бөгелмәдән, аның тирәсендәге авыллардан алтмыштан артык мулла, мәзин, укытучыларны кулга алганнар. Минем янымда утырган укытучы да шул исәптән икән. «Дөресен әйткәндә, Һади аганы судта гына күрдем», – ди үзе. Атласов судта менә ничек сөйләде, ди: «Бөек Ленин вафат булганнан соң, бигрәк тә соңгы елларда, Сталин милли сәясәтне Маркс-Энгельс тәгълиматларыннан ераклаштыра бара. Милли кадрларның үсүенә, аларның мөстәкыйль фикер йөртүләренә киртә куя. Совет илендәге Көнчыгыш халыкларының гарәп алфавитыннан латинга күчүләрен алкышлап, Владимир Ильич: «Бу тарихи вакыйга – Көнчыгыш халыкларын бөтен дөнья культурасына алып чыгуда күпер», – дигән иде. Ләкин ул бу бөек борылышны үз күзләре белән күрә алмыйча калды. Әмма Көнчыгыш халыклары, аның васыятьләрен истә тотып, аңа рәхмәт укыйлар һәм латин хәрефен киң җәмәгатьчелеккә җиткерергә – укытырга көч салалар. Ә Сталин һичбер нигезсез рәвештә тагын алфавит алыштыру мәсьәләсен күтәрде һәм инде мәҗбүри рәвештә тормышка ашыра. Бер кеше гомерендә совет Көнчыгыш милләтләре инде өченче алфавитка күчәләр. Безнең халыкның күбесе болай тиктомалдан надан калачак. Шулай ук телләрнең тууы, үсеше турындагы Сталинның соңгы тезислары Маркс тәгълиматына капма-каршы», – дигән. Бу урында Атласов, немец һәм инглиз телләрендә Маркс хезмәтләреннән цитаталар китереп, үз фикерләрен дәлилләгән.

– Молодец, – диде кемдер урта сәкедән.

Сөйләүче аңа игътибар бирмичә дәвам итте:

– Ахырда ул сүзен болай тәмамлаган: «Әгәр иптәш Сталинның кайбер фикерләре белән килешә алмау җинаять икән, мин сезнең хөкемдә. Әмма мин Совет дәүләтен җимерергә әзерләнмәдем һәм контрреволюцион оешма булдыру нияте белән мавыгу җүләрлегенә барып җитмәдем. Чөнки мин үзем хәл кадәре бу хөкүмәтне урынлаштыру өчен көрәштем, корал белән чехларга каршы сугыштым. Тарих – шаһит».

– Дөрес. Атласов Колчак тылында безнең өчен эшләде һәм бик кирәкле данныйлар бирде, – диде комиссар Имәнкулов.

– Бүлмәгез әле! Шуннан?

– «Әгәр дә, – дигән Һади ага, өстәл артындагы трибунал членнарына карап, – әгәр дә уйдырма гаепләү актыгызда күрсәтелгәнчә, мин контрреволюцион оешма торгызырга, Совет хөкүмәтен җимерергә уйлаган булсам, тагын кабатлыйм, андый ният миндә булганы юк, кемнәргә, нинди көчләргә таянган булыр идем? Гафу итегез, ярты ел нахакка төрмәдә утыруыма да карамастан, мин әле үз акылымда. Әгәр ул кара юлга бассам, сез алдыма китереп бастырган мулла-мунтагайларга түгел, яшь көчләргә таянган булыр идем. Шуның өчен бу акылга-аңга сыймый торган уйдырма төркемне миңа бәйләмәгез. Мин аларны белмим, белергә дә теләмим». Ул укытучыны бүген тагын судка алып киттеләр. Мине...

Кинәт каерып ишек ачылды. Әңгәмәгә мавыгып, вакытның узганын да сизми калганбыз, йозак шалтыраганын да ишетмәгәнбез.

– Төшке аш.

Исебез китте. Ишек төбендә – ризык кисмәге. Пар чыгып тора – чумар. Аның исе дә борынны кытыклый. Инде тәүлеккә якын корсак буп-буш – «корыга» эшли бит. Кызыл балчык чүлмәкләр берәр чүмеч баланда белән кулдан кулга күчә башладылар. Миңа да чират җитте. Чүлмәк кулга тиюгә чөмерә башладым. Төбендә кашык белән бутарлык бер чумар да юк иде. Әллә чөмергәндә йотып куйганмын, тоймаганмын, әллә инде чумарның җиседме түгел, исеме генә булган. Иң соңгы чүлмәккә прокурорны тартып чыгардылар. Әмма ул, чүлмәкне алуга, тагын мүкәләп сәке астына кереп китте.

Тамак ялгаганнан соң, теге крагилы егетне дә алып чыгып киттеләр. Ул Татпрофсоветта физкультура-спорт бүлеге мөдире булып эшләгән, ди. Аңа да «корткычлык» ямаганнар. Әллә көләргә, әллә еларга?

Кичке аш алдыннан торбаны шакыдылар. Алкин «Бестужев әлифбасы»на күчте, идәнгә чүгеп, торбага колагын куйды һәм аннан килгән хәбәрне иҗекли башлады. Сулышны өзеп, Алкинга төбәлдек:

– Три-бу-нал Ат-ла-сов-лар төр-ке-мен... – Хәбәрне тапшыручы, бу җиргә җиткәч, пауза эшләде... Әллә инде «күз» комачауладымы. – Атласовның үзен дә а-тар-га хөкем ит-кән...

Алкин, хәбәрне әйтеп бетерер-бетермәс, идәнгә утырды. Электр тогы суккандай катып калдык. «Күз» чайкалды. Ачылды. Кан баскан ачулы бәбәк карый.

Йөрәк тибүдән туктады сыман. Күзләремә яшь килеп тыгылды.

– Йа Алла, бу нинди бәйрәм бу?

Сабырсызланып, өметләнеп, соңгы ышанычларны бәйләп, дүрт күз белән көткән бөек бәйрәм – Октябрьнең егерме еллык тантанасы үтте дә китте. Ашыгыч процесслар, атулар, көне-төне туктаусыз сорау алулар, кыйнаулар, гарипләндерүләр, мәсхәрәләүләр белән узды. Ә без көткән, ышанып көткән амнистия телгә дә алынмады. Киресенчә, бәйрәм көннәрендә камерага яңадан-яңа арестантларны тыгызлап тутыра башладылар. Болар инде «өченче дулкын» кагылганнар. Өченче секретарь, өченче председатель, өченче зав, өченче ректор, өченче директорлар. Алар әле үзләре башкарасы эшнең эчтәлеге-юнәлеше белән танышу түгел, яңа кабинетларының нинди булуын хәтерләп калырга да өлгермәгәннәр.

Тукта, юкка зарланам бит, бәйрәмнең очы – ризыгы, соңга калып булса да, безнең камерага да җитте ич.

Бу сөенечле хәл унынчы ноябрь көнне кичкә таба булды.

Камерада аеруча авыр бер тынлык иде – кайсы ятып, кайсы утырып-калгып уйга чумган. Пыяла күзләре ватылган рәшәткәле тәрәзәдән суык җил өрә, калфакка кар өя. Хәзер инде камерада ялангач берәү дә юк. Кемнең нинди киеме – чүпрәге бар, шуңа уранган. Төшке баланда инде корсакка кергән булуга карамастан, ул һаман буш. Төшенеп бетә алмыйсың, шундый вакытта тоткынның уенда әллә ирек, әллә ризык күбрәк урын ала. Менә шуның өчен сөйләшәсе килми – рәнҗүле тынлык.

Йозак шалтырады.

Төрмәдә утыра торгач, үзенең язмышына күнегә башлый тоткын, шулай булырга тиеш сыман. Ә менә чаң тавышына, йозак шалтырауга һич күнекми. Нәкъ беренче ишеткәндәге кебек, бар гәүдәсе белән чирканып, калтыранып китә һәм сулышы киселә – ни була? Хәзер дә шулай сискәнеп, калтырап торып утырдык.

Ишек ачылды.

Гаҗәп! Ишектән кеше түгел, зур бер капчык керә башлады. Гомердә күрмәгән хәл – төрмә, камерага иләмсез зур капчык керә. Аптырап калдык – ни булыр? Берәр хәтәр булмаса ярый инде. Төрмәдә һәрнәрсәгә шикләнеп карыйсың бит.

Менә капчык шыгырдап камерага керде, шап итеп идәнгә утырды. Аның артыннан капчыкның хуҗасы күренде. Әллә инде Кыш бабай? Менә сиңа кирәк булса, берсеннән-берсе гаҗәбрәк. Бөрмәле ак тун, озын колаклы куян бүрек. Ак йоннан басылган киез итекләр... Ишек ябылды.

– Исәнмесез, иптәшләр, – диде көр тавыш, һәм куян бүрек селкенеп куйды, тирә-якка кар чәчрәде, – бәйрәм котлы булсын.

Камера аптыраудан телсез калды.

Ниһаять, куян бүрек баштан кулга күчте. Урта яшьләрдәге түгәрәк йөзле ир. Сары чәч. Зур яшькелт күзләр. Үзе бик тыныч күренә. Тагын көр тавыш:

– Нигә сәламне алмыйсыз? Менә сезгә бәйрәм күчтәнәче алып килдем. – Кунак, иелеп, капчыкның авызын бәйләгән җепне ычкындырып җибәрде, бүлмәгә тәмле икмәк исе таралды. – Староста бардыр сездә? Мә, бар иптәшләргә дә бүлеп бир. Бәйрәм ашы тигез булсын. Мәгез.

Алкин, алгарак чыгып, кул бирде.

– Таныш булыйк, бу – камераның старостасы Алкин.

– Тукта, тукта әле, – дип, кунак Алкинның кулын җибәрмичә селеккәләде, – кара әле, син теге Казан шәһәр комитеты секретаре түгелме, күрермен дип уйламаган идем, – көлеп тә җибәрде. – Ә бит «Кызыл Татарстан»да үзеңне бик селеккәләгәннәр иде, корткыч дип. Үзең болай... – ул җентекләп, игътибар белән Алкинны баштанаяк карап чыкты, – үзең болай корткычка охшамыйсың... Хаха! Ха-ха!

Камера бердәм шаркылдап көлеп җибәрде.

– Ярар, егетләр, башта тамак ялгап алыгыз, кая, менә бу сәкегә аударыйк. Берәр нәрсә җәегез әле...

Сөббухның одеялы яңарак, тазарак икән, ул шуны сәке буена җәеп җибәрде. Хуҗа капчыкны шунда аударды. Күзләр дүрт булды: киптерелгән сохари, түгәрәк күмәчләр, гәрәбәдәй сары бавырсаклар тау булып өелделәр.

– Рәхим итегез. Хәзинәдә бары.

Менә бит көтмәгәндә...

Авыз сулары корып, күчтәнәчне «кортлап» торган без тоткыннарга Алкин староста әүвәл берәм-берәм сохарины, бавырсакны өләшеп чыкты, аннары шуны сорау алудан тагын урлап кайткан карандаш үзәге белән учына язды. Һәрбер ризыкны егерме дүрткә бүлде, сорау алырга чакырылган иптәшләрнекен аерым алып куйды.

Ниһаять, корсаклар чын-чынлап тулды. Үзебез дә туендык. Әмма «нәфес – шайтан» диләр бит, туюын туйсак та, күңел туймый, кесәләргә – алдагы көннәргә дип яшереп куйган сохариларны да анда-санда «урлап» алып кетердәтәбез.

«Кыш бабай», колакчын бүреген, тунын салып ташлап, сәкегә утырды да, безнең сөенә-сөенә кетер-кетер китерүгә куанып, сорашканны да көтмәстән, көр тавыш белән сөйләп китте:

– Мин Мөхәммәтгали Мөхәммәтзариф улы булам. Район башкарма комитеты председателе идем. Гөнаһ шомлыгы, июль аенда «Кызыл Татарстан» газетасында «Кортычлар» дигән мәкалә чыкмасынмы. Шунда менә мине дә телгә алганнар. Бу газета районга килеп җитүнең икенче көнендә абзагызны райкомга чакырдылар да әүвәле партбилетны алдылар, аннан эштән «азат» иттеләр. Өйгә кайттым да: «Гөлҗиһан, җаным, мин әйтәм, әйдә, әзерлән. Сохари киптер. Анда әллә ни сыйламыйлардыр. Андагы дус-иш тә йөрәк ялгар, мулрак булсын», – дим. Инде Казанда безнең ике райком секретаре, ике башкарма комитет председателе һәм аларның урынбасарлары, шулай ук районның башка җитәкчеләре утыралар иде. Әлхасыйль, шулай булгач, мине алуларына шик-шөбһә юк иде.

– Авылдашларыгызны очратмадыгызмы әле? – диде Сөббух, авызындагы сохарины кетердәтеп.

– Юк әле, энем, – дип бик рәхәтләнеп елмайды кунак. – Иншалла, очратырмын.

– Бүлдермәгез инде, кешегә сөйләргә ирек бирегез. Шуннан?

– Карчык минем зиһенле җан. Укытучы. Аларны да «чүпләделәр» бит. Артык тавыш-тын чыгармыйча гына пешеренә башлады. Ул пешерә, мин турап мичкә куям. Төн җиттеме – көтәбез. Әнә киләләр, менә киләләр. Йокыдан

калдык. Менә шулай көтә торгач, дүрт ай үтте. «Карчык, мин әйтәм, әллә, капчыкны күтәреп, үзем барыйммы икән, бик зарыктырдылар», – дип омтылып та куйгаладым. «Кит, җүләр, өйдә утыру туйдырдымы? Бәлки, синең бәхеткә, безнең бәхеткә, кулга алулар туктар», – ди. Шулай итеп тынычландык. Бәйрәм җитте. Бәйрәм, инде кузгатмаслар, дибез.

– Бәйрәм ничек узды, Мөхәммәтгали абзый? – диде Сөббух.

– Ничек диим, дус-иш безгә керергә шүрли. Газетада исемем аталгач, билгеле инде, халык дошманы булабыз. Без аларга керергә базмыйбыз. Кәсафәтебез тиеп-нитеп калмасын дип. Карчык белән берәр йөзне төшереп, кочаклашып кына яткан идек, ишекне шакыйлар бит хәерсезләр...

Без көлешеп алдык.

Ул арада стенага чиртә башладылар. Мөхәммәтзариф улы Мөхәммәтгалинең әңгәмәсе өзелде. Алкин, кружкасын алып, «телефон»га күчте.

– ...Га-лим-җан Иб-ра-һи-мов ка-ты а-вы-рый. Төр-мә боль-ни-ца-сына сал-ды-лар... Воль-фо-вич ял-ган по-каза-ние-ләр би-рә... То-лым-бай-ский доп-рос-та а-кыл-дан яз-ган... Кы-ям Аб-ра-мов[1] доп-рос-тан чык-кан-да бас-кычтан таш-лан-ган... Га-лим Мө-хәм-мәт-җа-нов про-во-катор... Бү-ген ун ке-ше-не ат-ты-лар...

Тек-тек, тек-тек... «Бестужев» тәүлек буенча тынмый – берсеннән-берсе авыр, шомлы, хәвефле хәбәрләр биреп кенә тора.

Камера ишекләре ачыла да ябыла.

Сорау алырга. Сорау алудан.

---

[1] Кыям Абрамов – ТАССР Халык Комиссарлары Советы председателе.

11

Яңа ел алды төне.

Ниндидер серле, тылсымлы ул. Кем генә булмасын, ирме, хатын-кызмы, яшьме-картмы, һичшиксез, бу төндә ул кинәт тукталып кала – уйлана, хыяллана, өметләнә. Алдагы туасы унике айда, алай гына да түгел, нәкъ менә шушы төн уртасында, Яңа ел туган минутларда, ниндидер бер могҗиза пәйда булыр – «күк капусы» ачылыр да, барлык теләкләр кабул булыр төсле. Бер кешегә генә түгел, күп кешегә, бар адәм баласына, бөтен җиһанга, галәмгә. Шуның өчен һәрбер кеше бу төндә, бигрәк тә сәгать уклары уникегә якынлашканда, дулкынлана, каушый һәм... әле булмаган, әмма булачак, һичшиксез булачак сөенеч өчен елмая!

Тиздән 1938 ел туачак.

Бөтен камералар, бөтен төрмә хәзер шушы тантаналы, тылсымлы мизгел алдында.

Тиздән... Утыз җиденче ел капкалары ябылып, яңа елга аяк басачакбыз. Тиздән...

Утыз җиденче ел бөтен ниятләрне туздырып ташлады. Барлык якты өметләрне туплап, ашкынып, ашыгып көткән бәйрәм – Октябрьнең егерме еллыгы тантанасы да узып китте.

Өмет өзелде.

Юк, өзелми икән ул тоткын өмете. Аның бүгенге көне нинди генә авыр, фаҗигале булмасын, ул әле иртәгә якты сибеләсенә ышана.

Нигә?

Бу сорауга һичбер тоткын җавап бирә алмый. Чөнки аның ышандырып-инандырып әйтерлек дәлилләре юк. Әмма ул ышана, күңеле белән, җаны-тәне белән инана, өметләнә.

Ул көн килер.

Ирек-азатлык килер, һичшиксез, менә бу туасы елда. Яңа елда!..

Тиздән Кремль куранты даң-доң итеп унике тапкыр сугар да, Советлар Союзы Гимны яңгырар. Иректәге кешеләр бу мизгелдә, шатланып, шәраб тулы бокалларын күтәрерләр һәм бер-берсенә бәхет теләрләр.

Йозак шалтырады. Шыгырдап-чинап ишек ачылды, һәм кемнедер камера эченә этеп кертеп җибәрделәр. Ул

идәнгә капланып төште. Мин, үзем дә сизмичә сикереп төшеп, идәндәге кешене күтәреп сәкегә утырттым.

– Мәхмүт... Мәхмүт, бу синме?

Нижегородцев йөгереп килде. Икәүләп күтәреп, аны урынга салдык.

Мәхмүт Баһаутдинов нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан иде – авызыннан кара кан атылды.

Бераздан тагын ишек ачылды, көчкә-көчкә атлап, Алкин керде.

Бу камерага килгәннән бирле, мин аны беренче тапкыр шундый хәлсез, ватылган хәлдә күрәм. Күз төпләре кара янган.

– Мөхәммәтҗанов белән йөзгә-йөз китереп сорау алдылар, – диде Алкин, бераз утырып исен җыйгач. – Ул, күзен дә йоммыйча: «Ни язсалар, шуңа кул куй. Оешма исемлегенә кешеләрне күбрәк язарга тырыш. Нихәтле күп кешене бутасак, шулхәтле тизрәк тикшерерләр», – ди хаин. Үзем утырган урындыкны алып, башына суктым. Шуның өчен мине изделәр. Су... су... бирегез әле...

Камерада нинди су?

Мин ишекне кыйный башладым. Рәхимле бер надзиратель икән, бер кружка су бирде. Алкин бер-ике йотты. Калган су белән Мәхмүтнең битен юып, аның беразын авызына тамыздык.

Ә тәрәзә артыннан ерактан Кремль сәгатенең сукканы ишетелде.

Бераздан Лебедев-Кумачның «Нинди иркен минем туган илем» җыры яңгырады:

> Я другой такой страны не знаю,
> Где так вольно дышит человек...

12

Башта, бу камерага кергәннең беренче көннәрендә, мондагы тоткыннар барысы да бертөсле, авыр язмышларын бердәй кичерәләр, хафаланалар дип уйлаган идем.

Алай түгел икән.

Әйтик, менә Алкин. Ул ничектер бу язмышына һич бирешми, алай гына да түгел, камерадагы башка мәхбүсләрне дә моңа игътибар итмәскә, күңел төшенкелегенә бирелмәскә өнди. Кайчан гына булмасын, хәтта сорау алудан кыйналып-ватылып хәлдән таеп кайтканда да, аһ-ваһ килеп, камераның рухын төшерми, эченнән

кичерә. Хәл алу белән, «җәмәгать» эшенә тотына. Йә хәбәр ала, йә үзе башка камераларга яңа ишеткән хәбәрләрен тапшыра. Йә «балык ауларга» тотына. Папирос кәгазенә берәр хәбәр яки берәр сорау язып, шырпы кабына сала да җеп белән тәрәзәдән түбән камера калфагына төшерә яки шундый ук почтаны ала. Ул эш тә бетсә, мәзәк сөйли башлый – грузин, әрмән, яһүд, украин акцентлары белән. Көлә-көлә эчең ката.

– Ибраһим, ашыкма, сабыр ит. «Сабыр төбе – саф алтын» дип, борынгылар белмичә әйтмәгән... – ди Галимҗан ага Нигъмәти, бик акрын пышылдап кына. Нәкъ кафедрадагы кебек тыныч һәм ягымлы итеп. Ул, урыныннан тормыйча, ятып, күзләрен йомып уйланырга ярата. Нәрсә уйлый торгандыр инде ул көне-төне.

Тәбәнәк, чандыр, әмма хәрәкәтчән Гомәр Гали:

– Юк, бу һич мөмкин түгел. Монда бер корткычлык бар. Моны иптәш Сталинга җиткерергә кирәк, – дип, көннәр буе ишек төбендә надзирательләрдән кәгазь-карандаш сорый.

– Миңа иптәш Сталинга язарга кирәк, – ди ул, ишек ачылуга.

Аны кире этәләр.

– Кәгазь-карандашны следовательдән сора.

Гыйлем Камай:

– Егетләр, вакыт әрәм үтмәсен, мин фән дөньясыннан бер-ике кызыклы мисал китерим, – дип, химия яңалыклары белән мавыктыра, онытылып тыңлыйбыз.

Мәхмүт Баһаутдинов капланып ята да үз-үзе белән сөйләшә:

– Кайда ялгыштым? Кайда?

Ә теге прокурор бер кешегә дә кушылмый, сөйләшми, сәке астында посып утыра да, берәр төрмә хезмәткәре керсә:

– Гражданин начальник, монда барысы да халык дошманнары. Мине монда ялгыш утыртканнар. Башка камерага күчерегез, – ди. Елый, сүгенә, ишек кага. Аны инде ике тапкыр ризыктан мәхрүм иттеләр. Тик ул һаман үз «эшендә».

Ардалион Михайлович Нижегородцев туктаусыз елый һәм зарлана:

– Сез төшенмисез. Төрмәгә алыныр алдыннан гына

өйләнгән идем. Минем инде балам булырга тиеш. Ә мин аны күрмим. Нигә? Юк, мин бит үз баламны күрергә хаклы! Нинди гаделсезлек бу?

Әхмәт авыз эченнән генә җырлый, сызгыра. Инде берничә тапкыр карцер белән куркыттылар, ә ул һаман җырлый:

Карурманнан чыккан чакта
Кисеп алдым пар каен...

Яңа ел үтте. Җил-давыллы февраль килде. Сорау алулар көчәйде. Киткәннәрнең күбесе кайтмый. Әллә шулай озак бастырып тоталар, әллә башка камераларга күчерәләр, әллә?..

Менә инде Мәхмүт Баһаутдинов та юк, Гыйлем Камай өченче тәүлек күренми. Безне бәйрәм күчтәнәче белән сыйлаган теге «Кыш бабай»ны шул ук төнне алганнар иде – әле күренми. Әллә инде безне сөендерер өчен генә килгән Хозыр булды микән ул?

Ә «чыбыксыз телефон» һаман тек-тек итеп берсеннән-берсе хәвефле хәбәрләр бирә:

– Га-лим-җан Иб-ра-һи-мов төр-мә боль-ни-ца-сын-да үл-де... Кә-рим Тин-чу-рин ач-лык игъ-лан ит-те. Би-шен-че көн па-ёк-тан баш тар-та... Мәх-мүт Ба-һа-ут-ди-нов а-кыл-дан шаш-кан... Үт-кән төн-дә е-гер-ме җи-де ке-ше-не ат-кан-нар. Ба-ры-сы да хәр-би-ләр... Га-зе-та-лар-да «и-рек-ле, и-рек-сез дош-ман-нар» ди-гән я-ңа фра-за-лар оч-рый баш-ла-ды...

Яз килде. Зәңгәр күзле күлләр, елгалар белән, аллы-гөлле чәчәкләр, хуш исле болыннар белән, зөбәрҗәт урманнар, сандугачлы таңнар белән яз килде – 1938 елның язы.

Ә төрмәләр? Камералар? Ә мәхбүсләр? Тимер рәшәткәләр, биек, калын таш стеналар, чәнечкеле тимерчыбыклар, мылтыгын тотып, бертуктаусыз әйләнеп йөргән сакчылар, туктаусыз улап өргән этләр белән уратылып алынган төрмәнең бет, борча, кандала тулы тынчу, сасы камераларда тилмереп утырган гаепсездән гаепле мәхбүсләр өчен дә язмы? Алар да яз хисләре белән дулкынланалар микән?

Ерактан, Идел-Ослан ягыннан, пароходларның берберсе белән очрашып сәламләшү-хушлашу гудоклары, анда-санда ишетелеп, озак яңгырап, күңелләргә сагыш,

моң өсти. Очынып, шаярып очкан чыпчыклар тәрәзә калфагына килеп куналар да, «чык-чык» дип, тоткыннарны үчекләп китәләр.

Кай көннәрдә җылы яңгыр – ләйсән яңгыр явып үтә. Камерадагы тынчу һава алышынып, күкрәкләр-үпкәләр җиңеләя.

Күңел ярсый, тыпырчына, канатлана һәм оча. Иреккә, Иделгә, өзелеп сагынган изге мәхәббәт кочагына!

Бүген инде унберенче май. Былтыргы бишенче ноябрьдән бирле мин менә шушы Пләтән төрмәсендә. Өченче каттагы тар камерада. Ә бер тапкыр да төрмә ишегалдына атлап чыкканым юк. Әллә оныттылар инде, сорау алырга да чакырмыйлар. Камерадагы мәхбүсләр дә алышынды. Мин кергән вакытта утырган тоткыннарның берсе дә юк. Китәләр. Кайтмыйлар. Алар урынына башкаларны, яшьрәкләрне – «1938 елгы набор»ны китерәләр. Камерада мин инде карт арестант – староста.

Ә шулай да нигә мине сорау алырга чакырмыйлар икән, нигә?

Йозак шалтырады. Ишек ачылды.

– «С» хәрефенә кем?

– Салахов Ибраһим Низамович.

– Әйберләреңне ала чык.

Әйбер дигәннәре – итек кунычыма кыстырылган китек агач кашык.

– Хушыгыз, иптәшләр!

Камерадагылар, ашыгып, кулымны кысалар.

– Хәере белән.

– Бәлки, иреккәдер.

Мин ишеккә атлыйм. Йа Хода, нинди язмыш көтә мине алда – яктылыкмы, әллә дөм караңгылыкмы?..

КОЯШЛЫ БҮЛМӘ

Билгеле инде, мине, түбәнге катка төшү белән, коридорның эченә үк кереп торган ябык машинага – «кара козгын»га төртеп керттеләр. Тоткыннарны көне-төне сорау алырга ташучы бу түләүсез таксиның эчке төзелеше миңа бик таныш. Анда кара-каршы өчәр-өчәрдән алты кеше көчкә сыеп утыра торган, бастырып куелган табут төсле тап-тар бүлмә. Тоткыннар керер-кермәс ишек шап итеп ябыла да бикләнә – тын да ала алмыйсың.

Бүлмәләр арасында уртада – сакчы. Мине соңгы, алтынчы «табут»ка тыктылар. Димәк, калган биш бүлмә инде тулган.

Гаҗәеп бер хәл. Әгәр дә адәм баласы маңгай күзләре белән күрү мөмкинлегеннән мәхрүм ителсә, күңел күзләре белән тоеп күрә башлый икән. Менә мин хәзер дөм караңгыда. Ә шулай да машинаның кайсы җирдән, кайсы якка, хәтта кайсы урамнан баруын беләм, тоям. Менә аз гына барды да туктады. Капка. Шалдыр-шолдыр тимер чыңы – йозакларны ачалар.

Машина капка төбендәге чокырга уң тәгәрмәче белән төшеп китте. Көчкә генә уңга борылды – Печән базарына таба юл тотты. Шулчак күрше «табут»тан чирткәләп аваз бирә башладылар. Стенага авызымны куеп эндәштем:

– Син кем?

– Галимҗан Мөхәммәтшин.

– Син... син исәнмени?

– Эһе-эһе... – Буылып йөткерү.

Күршем буылып йөткергәндә, машина чаттан борылды – Болак күперенә таба барабыз.

– Бездән Ләбибне, Сөббухны алдылар. Галимҗан Ибраһимов инде Яңа ел башында ук төрмә больницасында үлгән. Толымбайский сорау алганда акылдан шашкан. Кыям Абрамов баскычтан ташланган. Галимҗан Нигъмәти...

– Шыш, контрлар! – Ишеккә приклад белән суктылар. Башым чыңлап китте. – Еланнар, монда да пышылдаша башладыгызмы?

Күрше «табут» ишегенә дә приклад төште.

«Козгын» чинап-улап күтәрелә башлады. Бауман урамын үтеп, тауга – Чернышевский урамына күтәре-

ләбез. Аннары кинәт ашыгып җилдерде – түбән төшәбез. Хәзер машина туктарга тиеш. Шыгыр-шыгыр капка ачылды. Уздык.

– Чык, җәфа! – Конвой «табут»ның ишеген ачты: – Төш, контрик!

Озынлыгы өч, киңлеге ике метр чамасындагы камера. Тәрәзәсе юк, җир астында ул. Түшәмдә челтәр эчендә кечкенә бер лампочка яна. Цемент идәнгә беркетелгән карават. Аның өстендә – киез. Сары одеял, ап-ак җәймә. Ак тышлы мендәр. Аптырап калдым. Сигез ай буе Пләтән төрмәсендә тыгыз камераның идәнендә ятарга урын таба алмый, күп төннәрне ишек төбендә яки параша өстендә калгып үткәргән тоткынга бу урын-җир оҗмах көрсие булып күренде. Караватка утырдым. Тордым. Тагын утырдым, сузылып ятып карадым – нинди рәхәт. Бер кеше кысмый-этми, сүгенми, теләгәнчә сузыл...

Йозак шалтырады. Ишек ачылды. Надзиратель белән бергә камерага ак халат кигән берәү керде. Врач! Ялгыштым, халатлының кулында чәч алу машинкасы. Сигез ай буена бритва күрмәгән сакал-мыек, гәрчә үзем күрмәсәм дә, бер ел мәгарәдә ятып чыккан Әбүгалисинаныкыннан калышырлык түгел иде, мөгаен.

Сакал-мыекны алдырып, җиңеләеп, кәефләнеп утыра гына идем, тагын ишек ачылды.

– Чык! – дип ымлады надзиратель, матур гына яшь егет. Мөгаен, әле күптән түгел генә эчке гаскәр сафына алынган солдат.

Ярым караңгы коридор буенча барып сулга борылдым – ачык ишектән кердем. Душ. Тагын рәхәт: сигез айда беренче тапкыр җылы су белән сабынлап юындым. Бер кат тирем кубып төште, ахрысы. Камерага кайтсам, тумбочкада ике җамаяк. Берсендә – итле токмач, икенчесендә – бәрәңге боламыгы белән ике зур котлет йомарламы. Ул гынамы?! Күзләремә ышанмыйм, бармакларым белән капшап карадым – өч папирос! Ну нинди җәннәт!

Ниһаять, сигез ай дигәндә кырынып, юынып, этешмичә-төртешмичә, сүгенмичә, таза урын-җир өстенә утырып, чиста эмаль савыттан ашый башладым. Токмачлы шулпа шундый тәмле, телеңне йотарсың. Әни мәрхүмә шулай тәмле итеп пешерә иде токмачлы ашны. Аштан соң бер папиросны кабыздым. Билгеле инде, монда утырган

тоткынга шырпы хәтле шырпыны ышанып бирә алмыйлар. Тимер ишекнең форточкасын шакыдым, коридордагы надзиратель «күз»не ачып карады да, кулымдагы папиросны күргәч, ни гаҗәп, бер дә ачуланмыйча, йозакны, ишекне ачты һәм шырпы сызды. Бу да беренче тапкыр. Әче тәмле зәңгәр төтенне суырган саен, җаным рәхәтләнә, башым әйләнә. Нинди рәхәт! Кайгы дигәннең әсәре дә калмады. Мөгаен, мине иреккә чыгарырга әзерлиләрдер.

Тәмәкене тартып бетереп, төпчеген парашага ташладым да, чишенеп, караватка яттым – бер рәхәтләнеп йоклыйм әле. Мондый йомшак, иркен урынга да ятасы бар икән!

Күзләрем эленеп кенә бара иде, шалтыр-шолтыр ишек ачылды, һәм шунда ук надзирательнең ачулы тавышы колакны кисте:

– Тор!

Аптырап аягүрә басарга өлгермәдем, камерага хәрби киемдә ике кеше атлады. Алдагысы ишеккә көчкә сыеп, кысылып, бөкрәеп керде. Мәһабәт. Камера тап-тар булып калды. Шинеленең петлицаларында икешәр ромб. Арттагысы аның култык астыннан гына. Петлицаларында шакмаклар.

– Мин – хәрби прокурор, – диде ромблы ир, калын тавыш белән миңа ачулы төбәлеп. – Жалоба бармы?

– Мин үземнең нигә монда булуымны төшенмим, – дидем, исемне җыеп.

– Капитан, сез аңа гаепләү кәгазен бирегез, – диде прокурор, артта папка күтәреп торган ябык кешегә кырын карап. Теге, папкадан бер бит кәгазь алып, миңа сузды. Прокурор ишеккә атлады һәм инде миңа бөтенләй карамыйча гөрелдәде: – Укы! Нигә утыруыңны төшенерсең.

Ишек шыгырдап-чинап ябылды.

Мин бер генә табак кәгазь дип уйлаган идем – монда машинкада интервалсыз басылган өч битле гаепләү акты. Укый башлауга, чәчләрем үрә торды.

«...Контрреволюцион милләтче оешманың актив члены. Оешма Совет хөкүмәтен җимереп, Бөек Туран дәүләте төзергә әзерлек алып барган. Мәкерле максатларына ирешү өчен, бу явыз милләтчеләр партия җитәкчеләрен, беренче чиратта иптәш Сталинны физик юк итәргә план корганнар. Шушы явыз ниятне тормыш-

ка ашыру юлында оешманың актив әгъзасы Салахов Ибраһим Низамович яшь язучылар, студентлар арасында контрреволюцион үгет җәелдергән...» һәм башкалар.

Ахырда – статья, пунктлар.

«Явыз ниятләрен, контрреволюцион эшләрен өстенә алмаса да, студент Алмакаевның күрсәтүләре белән аның җинаятьләре исбат ителә, һәм ул РСФСР Җинаять кодексының илле сигезенче статьясы нигезендә гаепләнә».

Бу ни бу? Һич төшенә алмыйм. Куркыныч төшме, әллә?..

Төн буена камерада арлы-бирле йөреп чыктым. Йоклау түгел, утырып тора алмыйм. Йөрәк ярсый, сызлый, сыгыла.

Бу нинди хаксызлык?

Кайда, кайда син, дөреслек?!

Камера караңгылана. Соры таш стеналар чайкалып, өстемә авып килгәндәй була. Мин, сикереп торып, тимер ишеккә ябышам. «Күз» ачыла, кан сауган бәбәк карый һәм ачулы тавыш:

– Ишектән кит! – дип боера.

Әлсерәп, хәлсезләнеп, караватка килеп егылам.

Мин нигә бу тынчу камерада? Хәзер бит май уртасы, табигатьнең иң гүзәл чагы. Күкчәтау даласы хәзер шау чәчәктәдер. Ә мин? Кинәт бит алмаларым көеп китте, кайнар яшь коела.

«Син – хыянәтче! Халык дошманы! Син туган илеңә хыянәт кылган өчен каты җәзаланырга тиеш! Сине үлем җәзасы көтә...»

Бу коточкыч авазлардан колагым тона, йөрәгем сулкылдый. Соңгы көчемне җыеп күтәреләм һәм акылдан шашкан кебек кычкырам:

– Ялган! Ял-ган! Мин һичбер вакытта да, һичбер вакытта да туган илемә хыянәт итмәдем! Хыянәт итмәдем, ишетә-сез-ме...

Хәлсезләнеп, цемент идәнгә егылдым.

Шалтырап, камера ишеге ачылды. Бары тик озак вакыт төрмәдә утырган арестантларга гына хас бер сизенү-куркыну белән сикереп тордым. Күзләрем әле ачылмаган.

– Чык!

Уянып киттем. Күзләремдәге томан таралды. Надзира-

тель – камерада. Ишек төбендә – тагын ике яшь солдат.

– Нәрсә катып калдың, атла!

Ниһаять, исемә килеп, камерадан коридорга чыктым.

Бер конвоир алга чыкты, икенчесе артта.

– Атла!

Атлыйм. Тар гына коридор. Бер якта – тимер ишекләр, икенче якта – таш стена.

– Уңга борыл!

Борылдым. Тар гына таш баскыч өскә күтәрелә.

– Алга, марш!

Тагын борылдык, тагын күтәрелдек.

– Туры алга!

– Тирә-якка каранмаска! Тавышланмаска!

Нәрсәгәдер сөртендем. Шундук мәсхәрәле тавыш:

– Корсаклы хатын, тизрәк!

Бер-ике борылып күтәрелгәч, озыннан-озынга сузылган коридорга чыктык. Идәндә – йомшак палас.

Коридорның ике ягында ниндидер кечкенә-кечкенә ишекләр, мөгаен, кием шкафлары. Алдан барган конвоир, кинәт туктап, шул ишекләрнең берсен ачты.

– Кер!

Мин бу сүзгә төшенеп тә җитмәдем, артымнан килгән конвоир кулындагы мылтыгының прикладлы белән этеп җибәрде. Мин, сөртенеп, шкаф эченә кердем. Ишек ябылды.

Бу ни бу? Табутмы? Ләхетме?

Нигә әле мине монда яптылар? Нишләтмәкче булалар? Чү! Янымдагы икенче әрҗәнең ишеге ачылды. «Чык!», – диделәр. Димәк, анда да минем төсле бер мәхбүс камалган булган. Ишек ябылды. «Атла!» Берничә дагалы итек дык-дык китеп барды. Ниһаять, ярты елга якын төрмәдә әүмәкләнгән тоткынның зиһене ачылды, бу «тыз-быз»ның хикмәтенә төшенә башладым, ахрысы. Коридорның ике ягы буйлап тезелеп киткән бу ишекләр кием шкафларыныкы түгел – яшерен тукталгычлар. Коридорның ике башыннан арлы-бирле йөртелә торган тоткыннар үзара очрашмасын, күрешмәсен өчен, берсе узып киткәнче, икенчесен шушы әрҗә-табутка ябып торалар икән. Үзенә күрә «мини камера».

– Чык! Алга атла!

Ярым караңгы коридор буенча дүрт-биш адым үтәргә

өлгермәдем, тагын әмер:

– Тукта!

Каршыда ике кеше биеклегендәге өлгеләп эшләнгән, ак буяуга буялган куш ишек. Алдан барган конвоир аларны ачып җибәрде:

– Кер!

Бусагадан атлауга, күзләрем чагылып, чайкалып киттем – егыла яздым. Ишек яңагына тотынып калдым.

– Тизрәк!

Бик зур бүлмә. Ике якта өчәрдән – дәү-дәү алты тәрәзә. Күтәрелеп килгән язгы кояш әнә шул тәрәзәләрдән бүлмәгә үрелгән.

– Нәрсә катып калдың, атла! Атла!

Күзләремне кулларым белән уа-уа атладым.

– Тукта!

Алдымда – кызыл постау ябылган өстәл. Кояш нурларында ул янып-ялкынланып торган учак булып чагылды. Аның артында өч кеше утыра. Өчесе дә хәрби киемнән. Әле «энәдән генә төшкән» хаки төсендәге постау гимнастёркалар. Яка кыекларындагы петлицаларда – очкынланып торган ромблар. Димәк, иң югары чиннар. Уртадагысы юан, гимнастёркасына көчкә сыеп тора. Кара сакал. Пеләш баш. Ике яктагылары гәүдәгә кечерәк, ябыграк. Сакал-мыек пөхтәләп кырылган. Уң яктагысы җирән чәчле. Сул яктагысының чәче сүс сыман – дулкынланып тора. Өчесе дә алларында өелеп торган папкаларны актаралар. Күз кабаклары төшкән, йөзләре суык.

– Конвой, коридорга! – диде кинәт калын бас белән уртада утыручы пеләш башлы юаны, алдындагы бер папканы ачып-ябып.

Мине камерадан бу якты бүлмәгә алып килгән конвоирлар ялт борылып чыгып та киттеләр. Ишек ябылды.

– Гаепләү кәгазен алдыгызмы?

Төксе эндәшү. Кайсысы сорады, аптыраудан абайламый да калдым. Алай да җавап бирергә ашыктым.

– Мин халык дошманы түгел, бервакытта да...

– Җитәр!

Әйтерсең лә кылыч белән чаптылар, иңге-миңге булып киттем.

– Кара, кара, – уртада утырган хәрбинең кара сакалы сикереп китте, тавышы гасабиланды, – син әле суд алдын-

да да җинаятьче булуыңны танырга теләмисең!

– Мин...

– Молчать!

Өстәлдәге кыңгырау чыңлап китте. Күз алларым караңгыланды.

– Судка нинди үтенечегез бар?

Тагын ачулы бас. Уянып киттем. Суд! Язмышымның соңгы күпере. Йә ирек. Йә зиндан. Хәзер менә шушында, шушы мизгелдә бөтен киләчәгем хәл ителәчәк. Димәк, ашыгырга! Акылны, зиһенне җыярга. Һәм үземнең гөнаһсыз булуымны, ялгышлык белән генә кулга алынуымны сөйләргә. Яла белән чын җинаятьне аерырлар һәм гадел хөкем чыгарырлар. Шулай булгач, барысын да, барысын да яшермичә әйтергә – тикшерүченең кыйнауларын, уйдырма документларга кул куйдырырга тырышуларын, ялган шаһитлар китерүләрен... Үземнең балта остасы малае булуымны. Пионерда, комсомолда, партия сафларында тәрбияләнүемне, барлык иҗатымны Совет иленә багышлавымны...

– Соңгы тапкыр сорыйм: судка үтенечегез бармы?

– Мин... мин... – нигәдер калтыранам. Тешем тешкә сугыла. – Мин... гаеп... гаепле түгел... Мин... Совет...

– Җитәр! – Калын бас башыма тукмак белән ордымыни, тагын күз алларым караңгыланды. – Соңгы тапкыр сорыйм: җинаятегезне таныйсызмы?

– Мин... мин... гаеп-сез...

– Конвой! – Бүлмә калтыранып китте. Ишек ачылды. Аяк адымнары. – Алып китегез.

Уртадагы юан хәрби кеше кулындагы папканы – минем «гамәл дәфтәре»н – сулга ташлады.

Ике конвоир ике кулымнан алып, борып-кысып, ишеккә таба эттеләр.

– Тиз! Тиз!

Мине, коридорга алып чыгып, тагын теге табутка яптылар. Әллә нәрсә булды – хәлем китте. Ярый әле ишек ябык, кысып тора. Зиһенем таралды. Уйның очын очка бәйли алмыйм. Бу ни? Чыннан да, шул суд дигәннәре... Хәрби коллегия дигәннәре шушымы? Мин бит судта сорашырлар, аз булса да сүзләремә дә колак салырлар, хакыйкатьне ачарга тырышырлар дип өметләнгән идем ләбаса.

– Чык!

Ишек ачылып китте.

Мине тагын теге якты бүлмәгә – суд залына китереп, кызыл постау ябылган зур өстәл алдына – салкын, чытык йөзле хәрбиләр каршына бастырдылар. Конвоирлар ашыгып чыгып киттеләр. Шундук өстәл артындагылар аягүрә басып кадалып калдылар. Уртадагы хәрби кеше алдында яткан кәгазьне үрелеп алды да боз төсле салкын бас белән, сүзне сүзгә бәреп, ашыгып укый башлады: «СССР Югары Суды Хәрби коллегиясенең күчмә сессиясе председатель ..., әгъзалар ... (исем-фамилияләре хәтеремдә калмаган – башта алар кайгысы идемени!) составында Совет Социалистик Республикалар Союзы исеменнән...»

Тезеп китте – аяз көндә боз явамыни?! Ә ачык форточкадан тынлы оркестр тавышы ишетелә. Танго. Салмак. Тыныч. Әйтерсең лә кичке йомшак җилдә назлы чайкалучы диңгез йомшак кына ярларга сугыла. Күңелне, хәтта бөтен тәнне иркәләүче сихри музыка. Мин бу тылсымлы моң астында Зәйтүнә белән онытылып-сөенеп әйләнергә бик ярата идем бит.

Каршыда – бакча. Бу сихри музыка шуннан агыла. Мөгаен, бүген ял көне – кордашлар, илаһи моң астында, берсен берсе кочып, гамьсез тирбәләләрдер. Гүзәл танго! Иркәләүче назлы ритмнар! Анда минем кордашларым. Нигә мин алар белән бергә рәхәт диңгезендә тирбәлмим? Нигә?!

Музыка тынды.

Мин айнып киттем. Ә суд рәисе һаман борынын тарта-тарта укый: «...илле сигезенче статьяның беренче, җиденче, сигезенче, унынчы, унберенче, унҗиденче пунктлары буенча гаепләнеп, ун ел аерым режимдагы төрмәгә ябылу һәм, төрмә срогын тутырганнан соң, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм калдыруга хөкем ителә».

АЛЛА ЙОРТЫНДА

1

Судтан соң мине икенче төрмә каршындагы кызыл чиркәүгә күчерделәр. Ни өчен чиркәүгә диярсез. Шәһәрнең барлык төрмәләре тоткыннар белән шыгрым тулган.

Тоткыннарның шактыен атарга хөкем итәләр. Төрмә ишегалдындагы баганага беркетелгән «кара табак» – радио – бертуктаусыз сәфәр юнәлешләрен игълан итә:

– Котласка! Ак диңгез каналына! Норильскига!

– Соловкига! Тайшет – Абакан юлына!.. Колымага!

Шул тарафларга Казаннан эшелоннар, баржалар, Столыпин вагоннары агыла.

Шулай да шәһәр төрмәләрендә халык дошманнарына урын җитешми. Ә Кремль астындагы икенче төрмәнең нәкъ каршында, урам аркылы гына чиркәү бар. Стеналары колач җитмәс калын, идәннәре, ишекләре тимердән, тәрәзәләре шулай ук тимер рәшәткәле. Әйтерсең лә Ходай үзе әзерләп куйган!

Тоткыннарның бер бригадасы атна-ун көн эчендә бу чиркәүне такта киртә белән әйләндереп, койма өстеннән чәнечкеле тимерчыбыклар сузып, чат-чатка биек манаралар утыртып бирә.

Төрмә башлыгы, надзирательләр, бер взвод конвой – яңа төрмә әзер. Рәхим итегез!

Менә шушы өр-яңа төрмәнең – кызыл чиркәүнең – авыр тимер ишекләре шыгырдап-чинап ачылгач, «Алла йорты»на беренче атлап кергәндә хәйран калдым.

Йа Хода, бу нинди мәхшәр?!

Ыгы-зыгы, шау-шу. Камера түгел, ниндидер зур ярминкә! Кайдан бу хәтле халык?!

– Кара әле, Ибраһим, бу синме?

Кемдер җилкәмә төртте. Таныш тавыш. Борылдым. Кочаклаштык. Бик озак бер-беребездән аерыла алмый торабыз.

– Кара, бу синме, Сөббухмы?

– Ә мин сине атканнардыр дип уйлаган идем.

Сөякләр чытырдый...

– Әлегә без исән! Исән!!!

– Әйдә, аулаграк җиргә барыйк әле, мин сиңа бер нәрсә сөйлим, – дип, Сөббух мине алтарьга таба алып китте.

Кайда монда аулаграк урын – һәр җирдә кырмыска оясы. Шулай да түрдәге бер почмакка чүктек.

– Судтан соң мине подвалга алып төштеләр дә зур гына бер камерага керттеләр, – дип, Сөббух пышылдап кына сөйли башлады. – Исем китте. Безнең обком секретарьлары, наркомнар барысы да шунда...

– Беренче секретарь да бармы?

– Ул да, Лепа да, Разумов та. Безнең Ләбиб, Фатих ага Казанлы, Шамил Усманов, тагын әллә кемнәр. Мин каушап калдым. Кайсы елый, кайсы: «Бу нинди хаксызлык, Сталинга, Сталинга язам», – дип кычкыра. Ләбиб, йөгереп килеп, мине кочаклап, балавыз сыга башлады: «Сөббух, җанкисәгем, сине дә атарга хөкем иттеләрме?» – ди. Ул арада камераның ишеге ачылды да, мине киредән тартып алдылар...

– Даң-доң! Даң-доң!

Кызыл чиркәүнең бу чаңы бүген инде гыйбадәткә түгел, тоткыннар качмаганнармы, асылынып үлмәгәннәрме икәнен белер өчен кичке барлауга – сафка тезелергә куша. Кыямәт көнемени, чиркәү эченең өсте астына килде. Ыгы-зыгы, шау-шу, сүгенү, акыру, елау. Ул арада шалдыр-шолдыр ишекләр ачылды – унлап надзиратель һәм бозау хәтле өч эт ишелеп керде. Тоткыннарны күргәч, этләр тагын да ярсып-үрсәләнеп өрә башладылар. Якыннанрак узган берничә мәхбүснең җиңнәрен-балакларын да талап алдылар.

– Җитәр, шау-шуны бетерегез! – Конвой башлыгы, бар тавышына кычкырып җикеренү өстенә, үтемлерәк булсын өчен, ахры, нәкъ блатнойларча, өч-дүрт катлы итеп сүгенеп тә куйды.

Йөзәр-йөзәрдән биш сафка тезелдек. Надзирательләр һәр сафны икешәр-өчәр тапкыр санап чыктылар, аннары сәндерәләргә менеп, барлык хәзинәләрне туздырдылар – берничә капчыктан карта, энә, биш тиенлек бакыр акчадан кисеп, шомартып эшләнгән бритва, көзге кебек чүп-чарны казып чыгардылар. Конвой башлыгы:

– Төрмә тәртибен бозган өчен иртәгә барыгызны да прогулкадан мәхрүм итәм. Әгәр дә кәгазь-карандаш табылса, карцер режимына куям! – дип каты гына кисәтте һәм тагын бер кат сүгенде дә командасын алып чыгып китте. Этләр, өрүне онытып, алдан атылдылар, күрәсең, камерадагы һава аларга ошамады. Чиркәү кинәт чайкалып киткәндәй булды – биш йөз мәхбүс берьюлы кузгалып, һәркайсы алданрак урын алып калырга тырышып, сәкеләргә үрмәләде. Тагын ыгы-зыгы, сүгенү, этү-төртү китте. Ул арада берәүне бишенче кат сәндерәдән атып та бәрделәр. Тимер идәнгә кан җәелде.

Ишек ачылды. Тагын этләр, надзирательләр... Теге мәетне алып чыгып, бераз шау-шу тынгач, Сөббух, минем янга килеп:

– Ә без кая ятарбыз икән? – диде.

Чиркәүне йөреп чыктык, бер буш урын юк.

– Әйдә, булмаса, сәке астына – идәнгә ятыйк! Салкынчарак та булыр.

Сөббухның биштәрендә бер җәймә кисәге дә бар икән. Мүкәләп сәке астына кердек тә, җәймәне җәеп, икәү янәшә яттык. Инде ике-өч көн рәтләп йокламаганлыктан, ятуга, күзләр-керфекләр бәйләнә башлады. Әмма Сөббух та, мин дә йоклап китә алмыйбыз, арлы-бирле әйләнәбез. Өстәге сәкедән нәрсәдер ком төсле шыбыр-шыбыр коела. Бөтен тән кызышып кычыта.

– Син йоклыйсыңмы?

– Кайда йоклау, әллә нәрсә чеметә.

– Мин дә чыдый алмыйм. Кашысаң, нәрсәдер сытыла. Кулдан сасы ис килә.

– Юк, булмас, әйдә, ишек төбенә барып бераз утырыйк.

– Синдә тартырга юкмы?

– Мин суд алдыннан бирелгән папиросның берсен кесәгә төреп салган идем.

– Булдыргансың!

Сәке астыннан үрмәләп чыгып, җәймәбезне тартып алсак – исебез китте. Ул кып-кызыл төскә кергән! Сәкедән ком түгел, кандала коелган икән. Менә кем безне йоклатмаган.

Камера гырылдый, мышный, сүгенә, саташа. Ә без Сөббух белән икәү, параша төбендә утырып, икебезгә бер папиросны төтәтәбез. Шулай да монда япа-ялгыз камерада ятуга караганда күңеллерәк.

Кемнәр генә юк,ниләр генә эшләмиләр бу гыйбадәтханәдә.

Алтарь почмагындагы сәке-сәндерәләрнең иң түбәнгесенә җирән чәчләре иңнәренә хәтле төшеп торган бер поп тезләнгән дә, Гайсә пәйгамбәрнең тәрегә кадакланган сурәтенә карап, бертуктаусыз чукына, ял-чәчләре әле бер, әле икенче якка чайкала. Сөйләүләренә караганда, поп, ял-чәчләрен кырдырмас өчен, әллә никадәр җәфа чиккән – кыйналган, атнадан артык карцерда утырган. Әмма чәчен алдырырга бирмәгән. Иртәгә ул этапка оза-

тылачак, ди. Хәзер менә ихлас чукынып, Гайсәдән озын-озак юлга көч-мәдәд ялвара, күрәсең.

Язмышның мыскыллап көлүеме, нәкъ менә шул поп чукынып яткан сәке өстендәге сәндерәдә ап-ак сакаллы бер татар карты тастымалын намазлык итеп җәеп утырган да, кулларын күкрәгенә кушырып, күзләрен йома төшеп – бу дөнья шау-шуыннан китеп – пышылдап кына дога укый, ара-тирә сәҗдәгә китә. Ә алар өстендәге сәкедә бер төркем күлмәк-ыштансыз тоткын акырып-бакырып карта суга. Киемнәр оттырылган инде, чиратта – ун, унбиш көн алда биреләчәк паёк, баландалар... Ә каршыдагы бер сәкедә карт партизан үзенең Гражданнар сугышындагы маҗараларын сөйли. Берәүләр йоклый, икенчеләр елый, өченчеләр тыела алмый көлә. Кайсы акылдан язган – һич төшенерлек түгел.

Алтарь каршындагы мәйданда алыш-биреш, сәүдә. Ни генә сатмыйлар! Тәүлеккә бирелә торган биш йөз граммлы паёк икмәк – «кибән башы» дисеңме, суынган арыш чумары – баланда дисеңме. Каяндыр шикәр, конфет, хәлвә кебек ләззәтле нигъмәтләр дә тапканнар. Тәмәке, папирос – берәмләп, учлап, төремләп – җаның ниндиен тели. Монда күлмәк, ыштан-гимнастёрка, итек-ботинка, оек, тәмәке янчыгы кебек кирәк-яраклар да алырга була. Бу базарның бәһа нигезе доллар да түгел, фунт-стерлинг та түгел, сум да түгел. Төп үлчәү – паёк. Бер паёк, ярты паёк, чирек паёк... Менә шулай сатулашалар һәм шушы бәягә алыш-биреш ясыйлар.

Тәрәзәгә якынрак төштә – көнкүреш хезмәте күрсәтүчеләр: ямаучылар, тегүчеләр, итекчеләр. Хәтта монда бер төрем тәмәкегә сакал-мыегыңны кырып, яшәртеп җибәрәләр.

Монда үтенеч язып бирүче адвокатлар да, законны яттан белүче прокурорлар да бар.

Җырчылар, биючеләр, таракта уйнаучы музыкантлар...

Соңгылары – һәвәскәр артистлар – күбрәк түрдәге иң киң, иң якты сәке тирәсендә әйләнә. Чөнки монда камераның патшасы – староста ята. Урта буйлы, тыгыз бәдәнле, кап-кара сакаллы, тузган бөдрә чәчле чегән – ат карагы. Унбиш елны алган. Төрмә түрәләренең таянычы. Ул монда хуҗа – теләсә, хөкем итә: яткызып суктыра яки туйганчы икмәк, баланда белән сыйлый ала. Староста-

га аш-суны ашханәдән аерым савытта, капкачлы кечерәк җамаякта китерәләр.

2

Сагыну!

Татлы да, ачы да син, сагышлы сагыну. Синнән качам, сине онытырга тырышам. Әмма... Әмма үзем тагын-тагын кочагыңа – кайнар, назлы, гөләп куагы төсле гүзәл, чәнечкеле кочагыңа омтылам. Көнбагыш чәчәге төсле сокландыргыч син, сары сагыну. Синдә кояш чаткылары һәм әрем тәме. Сәкедән берәр арестант төшеп, урыны бушады исә, мин тиз генә аның урынына менеп ятам да, пальтом белән томаланып, уранып, күзләремне йомам. Биш йөз тоткынлы камерада болай да тынчу. Чиркәүнең гыйбадәт үзәгендә. Уранып яткач, тын кысыла, сулыш ала алмый башлыйм, шабыр тиргә батам. Алай да битемне ачмыйм. Уранып яткач тыныч: камера, андагы ыгы-зыгы ераклаша, югала, үземне кеше юк аулак бер җирдә хис итәм. Рәхәт, тылсымлы бер дөньяга күчәм һәм сине күз алдыма китерәм.

...Исәнме, Зәйтүнә! Йә, сөйлә әле, зачётлар ничек бара? «Койрыклар» юкмы? Хәзер бит институтта «урак өсте», курстан курска күчүне хәл итә торган язгы зачётлар. Менә бит, борынгы тарихтан, истматтан, диаматтан былтыргы шикелле үзем генә булышкан булыр идем дә, жәл, көтмәгәндә хәлләрем болай булып китте. Ә шулай да, өметсез – шайтан, диләр бит, бу караңгы төн мәңгелек булмас әле.

Хәтерлисеңме, Зәйтүн гөлем, былтыр язгы зачётларга ничек әзерләнгән идек икебез? Һаман әле минем күз алдымда.

...Ботакларын киң җәйгән нәфис алма агачлары, мәһабәт юкәләр шау чәчәктә. Хуш ис! Ә без шул агачлар күләгәсендә – йомшак чирәмдә – бер кочак китапларны, конспектларны чәчеп ташлап, аунап укыйбыз, укыйбыз. Башлар томалана башлый – сугышып китәбез. Кыйнашабыз. «Җитәр! Әнә кулым кара көеп чыкты!» – дип үпкәләп, елаган булып китә башлыйсың. Мин йөгереп барып кочаклыйм һәм кайнар иренеңә үрелә. Әле менә хәзер дә аның сихерле-дәртләндерүче тәме иреннәремдә... Аннан, култыклашып, көлешә-көлешә, аллеяда йөрибез.

Яр астында куаклыкта яшеренеп утырган энҗе таҗлы миләүшә чәчәге табып бирәм – күкрәгеңә кадыйм. Хуш ис – әйтерсең лә иң нәфис, иң кыйммәтле Париж хушбуе ягынгансың.

Төшкене ашап кайткач, тагын юкәләр астына киләбез. Кояш инде бая без яткан җирне кыздыра башлаган, төньякка, яр астына күчеп, сузылып ятабыз да иртәнчәк укыган китаплар буенча бер-беребезгә сораулар бирә башлыйбыз. Алай күңелле, китап-конспект укыгандагы сыман ялыкмыйсың – хәтердә дә озаграк саклана. Зачётны да алдан бирәбез. Билгеләр дә югары. Башка студентлар безгә соклана, кайберәүләре хәтта көнләшә дә иде бит, әйеме? Бигрәк тә Фазыл. Ул гел безнең тирәдә чуала, әйтерсең паркның башка җирендә аңа урын юк. Берәр сәбәп табып яныбызга килә – «ашка таракан булып төшә». Йә китабы юк, имеш, йә конспекты югалган. Үзе һаман турсайган була. Ышанасыңмы, Зәйтүнә, менә шул дус булып йөргән Фазыл турсаеп кына калмаган, өстемнән донослар да язып торган. Чын, чын! Кулъязмаларын, әләк хатларын үз күзләрем белән күрдем. Аның кулын әллә кайдан таныйм – кәкре-бөкре шайтан таяклары. Тикшерүче күрсәтте. Нәрсәләр язган бит әле, имеш, мин контрреволюцион оешмада член булганмын. Имеш, аны да шул оешмага керергә өндәгәнмен! Менә бит нинди җаһил!

Ничек инде дөньяда юкны язарга, үзеңнең иптәшеңә яла ягарга кирәк? Оятсыз. Вөҗдансыз! Мөгаен, анда вөҗдан булмаган да. Менә ул ни өчен турсайган, кара көеп йөргән. Син, Зәйтүнә, аның белән сөйләшмә. Ул – хаин! Ышанма! Их, җәл, син бит хәзер бу сүзләремне ишетә алмыйсың. Ә шулай да... Шулай да тоярсың, сизәрсең. Бер-берсен бик-бик яраткан кешеләрнең йөрәкләре бер ритмда тибә, бер-берсенең күңел авазларын ерактан да ишетәләр икән, ди бөек Фирдәүси үзенең робагыйларында. Мөгаен, син дә ишетерсең бу кисәтүче, сине бәла-казадан сакларга тырышучы авазымны. Ишетерсең бит?!

Их, белсәң иде, шундый-шундый сагындым үзеңне, бәгырьләрем өзелә.

> Сызла, сызла, сызла, күңелем!
> Сызла бертуктамыйча,

Сызла айлар, сызла еллар,
Сызла төн йокламыйча! –

дип, Сәгыйть Рәмиевнең сагышлы юлларын кабатлыйм.

Ә син, Зәйтүнә? Син дә сагынасыңмы мине? Әллә? Юк-юк! Әйттем исә кайттым – әлгаязе билләһи. Без бит ахирәт дуслар, ахирәт җаннар...

– Даң-доң! Даң-доң!

Чиркәү диварлары барлык аллалары, фәрештәләре, изгеләре белән чайкалып китте. Минем дә иң кыйммәтле, иң изге уйларым челпәрәмә килде. Ыгы-зыгы, шау-шу.

Биш йөз мәхбүс берьюлы сәке, сәндерәләреннән чуен плитә идәнгә сикерделәр. Мин дә.

Барлаудан соң түрдәге сәкеләрнең берсе астына чүктем дә (монда ишек төбе – параша янындагы кебек мәхшәр түгел, тынычрак) тагын уйланып бетмәгән уйларымны очларга тотындым.

– Бәй, син монда качкансың ич, эт белән эзләп тә таба алмассың. Чык әле, бер шигырь яздым, – дип, Сөббух мине, тартып-йолкып, үзе янына чыгарды. (Әрәм калды уйларым, кайдан тапты, хәерсез.) – Менә тыңла.

Исем китте: дүртьюллык кына шигырь укыды – тирә-як яктырып китте. Идел, аккош кебек ак пароходлар һәм җыр. Маяк яндыручы кызның көймәдәге җыры.

– Син, кара әле, миннән нигә качасың? – диде Сөббух, шигырен укып бетергәч, миңа үпкәләп карап. Ялганлый алмыйм, серемне ачтым, Зәйтүнәне сагынуымны әйттем.

– Әйдә, бүген икәү параша чыгарыйк. Бүгенге баш дежурный – безнең авыл егете. Мин аннан Зәйтүнәне институттан телефон аша чакыртып, иртәгә күрешү оештыруын үтенермен, – диде Сөббух, бер дә көтмәгәндә мине канатландырып.

– Май кап! – дип сикереп тордым. – Әйдә, тизрәк старостага барыйк. Парашаны башкаларга биреп куймасын тагын!

3

Әйтерсең лә чиркәүнең барлык эреле-ваклы кыңгырауларын кактылар. Казан Кремле астындагы зур чиркәү – биш йөз тоткын утырган төрмә жу итте. Хәбәр яшен тизлеге белән телдән телгә, сәкедән сәндерәгә күчте.

– Күрешү!

– Очрашу рөхсәт иткәннәр.

Хәйран калмаслык та түгел бит, бу чиркәү төрмәгә әйләнгәннән бирле, мондый хәлнең һич булганы юк. Булуы да мөмкин түгел, чөнки бу камерада аеруча куркынычлы – илле сигезенче, илле тугызынчы статьялы арестантлар. Аларга нинди күрешү? Ә менә көтмәгәндә – хәбәр! Илле сигезенче статьялы мәхбүскә күрешү биргәннәр.

Бу сөенечле хәбәрне ишетүгә, бөтен камера, чират торып, мине тәбрикләргә, үземне ничек тотарга, ничек сөйләшергә – очрашу вакытында нинди хәбәрләр алып калу кирәклеген өйрәтергә кереште! Хәтта берсе папирос кәгазе китереп бирде: «Бу кәгазьгә үзеңә кирәкле сүзләрне-үтенечеңне яз да бармак арасына кыстыр. Күрешкәндә кызның кулын гадәттәгедән озаграк кыс, чәнчә бармагың белән учын кытыкла һәм кәгазеңне аның кулында калдыр». Алдым. Яздым. Ятып калганчы – атып кал. «Зәйтүнә, минем нахак гаепләнүем турында Сталин иптәшкә хат яз». Кем белә, Сталинга барып җитсә, бәлки, «Азат итәргә!» дигән фәрман килер. Тик менә, каушап, идәнгә – надзирательләр күзенә төшереп җибәрмәсәм генә ярар иде инде. Кәгазьне төкерекләп бармак арасына кыстырып йөри башладым – күнегергә кирәк.

– Беренче эшлисе эш, – диде камерадагы блатнойларның атаманы Папа Пий II, үзенең аеруча булдыклы, ышанычлы «мөрит»ләрен җыеп алып, – көзге һәм каләм[1]. Егетебезне тулысынча тәртипкә китерү хаҗәт.

Шундук бер төркем шыр ялангач «мөрит»ләр, идәнгә утырып, ике биш тиенлек бакырны эшкәртә башладылар. Бер бакыр тәңкәне чуен идәнгә ышкыйлар – ул көзге булачак. Икенче бакыр тәңкәне, кисеп, шул ук идәнгә кайрый башладылар. Ул каләм («бритва») булачак. Ул арада әле кичә генә монда килеп эләккән бер «медвежатник» (фатир карагы) килеп, өстендәге өр-яңа күк сатин күлмәген салып бирде.

– Кыз алдында мескен күренмә!

Инде чалбар һәм итекләр кирәк иде. Армиядән киеп кайткан кыек сырлы күк тукымадан тегелгән галифе буйбуйга таралды да төште – бигрәк хәтәр туза икән. Ә

---

[1] Каләм – жаргон сүз, биредә «пәке» мәгънәсендә.

итекләр кәвеш булып кына калганнар иде инде. Үрә басты-рып куйганда балтырлар шешеп, сала алмагач, кунычла-рын телгәләгән идек. Бу якны да кайгыртучылар табылды.

– Карчыгам, бер дә кайгырма, – диде камера старостасы, кап-кара сакаллы, кара бөдрә чәчле чегән Роман (ат карагы!). Һәм шундук сәкегә утырып, аягындагы хром итекләрен салып миңа тоттырды. – Ки, минем төсле биеп китәрсең... Чалбар да җәл түгел, ләкин, үзең күрәсең, бу чалбарга син башың белән кереп чумасың. Әй, Петушок, – дип, ул яныбыздан узып барган ярдәмчесен, минем чамалы блатной егетне туктатты һәм аны, ярминкәдә ат сайлаган сыман әйләндереп-тулгандырып карады да: – Күгәрченем, яле, сал чалбарыңны, – диде.

– Ә мин?.. – диде Петушок, аптырап. – Минем трусик та юк ич.

– Ярамаган тагын, монда кызлар юк, бераз җилләрсең.

Ул минем трусикны аңа бирде дә, кара постау чалбарны миңа кидерде һәм сакалын дерелдәтә-дерелдәтә көлде:

– Менә, карчыгам, бөтенләй бүтән кошка охшадың.

– Даң-доң!

– Барлау!

Камерага һау-һаулап этләр, алар артыннан сакчы солдатлар керде.

Барлаудан соң Папа Пий II нең шәхси чәчтарашы Чикерткә мине тулы тәртипкә китерә – сакал-мыекны кыра, чәчне кырка башлады.

Эш байтак озакка сузылды: бер-ике сыздырып алган саен, «каләм»не идәнгә кайрарга туры килде, юкса битнең тиресен каезлый башлый. Чикерткә, дөресен әйтергә кирәк, хәленнән килгәнчә, авырттырмыйча, шома итеп, төкләрне калдырмый кырырга тырышты һәм, нигездә, бу теләгенә иреште дә бугай. Биттә, борын астында әллә ни күзгә чекерәеп торган кылчыклар күренми. Минем кулда әле генә барлыкка килгән «көзге» – шоп-шома, ялтырап торган биш тиенлек бакыр тәңкә. Аны, эш барышын күреп, тикшереп торыр өчен, Чикерткә үзе бирде. Билгеле, биттә, ияк астында, муенда кәгазь өстенә кәгазь ябыштырылган «ямау»лар барлыкка килде. Әчетә, сызлый. Шулай да кыяфәт яхшы якка үзгәрде. «Ямау»лар иртәгәгә хәтле бөтәеп рәтләнер. Папа Пий II, үзе килеп тикшереп,

Чикерткәнең эшен яхшы дип тапты. Аннан соң староста, баш надзиратель белән сөйләшеп, бер чиләк су алдырды – ул кичләрен аяк-кулларын юып ята торган иде. Бу юлы да шул максат беләндер дип уйласам, мине чакырды:

– Карчыгам, кызың янына хуш исле булып бар, мә бер чиләк су: яхшылап юын.

Кемдер сабын белән мунчала да китерде. Суд алдыннан бер юындырганнар иде, шуннан бирле тән су күрмәгән. Юыну түгел, эчәргә җитми бит су.

Ә монда – мөлдерәмә тулы бер чиләк!

Кичке аш вакытында староста миңа үз «хәзинә»сеннән (аерым җамаяктан) өстәмә рәвештә бер өлеш баланда, бер өлеш галушки бирде. Ашап бетерүгә, тагын бер сюрприз.

– Кил, карчыгам, монда, – дип, ул үзе янында гына йоклата торган Петушокны куып төшерде дә миңа шул урынны күрсәтте, – ят рәхәтләнеп, аяк сузып йокла, кыз белән күрешер алдыннан сине идәндә аунатып булмас.

Мин, чиркәү түрендәге изге такта түшәккә менеп, аягымны сузып яттым...

4

Иртәнге баландадан соң киенү байтак вакытны алды. Старостага берсе дә ошамый. Имеш, итек кунычлары күзгә кебек ялтырамый, чалбарда җыерчыклар. Күлмәкнең ике төймәсе юк икән... Мөритләр ярдәмендә барысын да рәткә китерергә туры килде. Староста мине әйләндерептулгандырып карады да, ниһаять: «Кунак кызы кебексең, – диде. – Бар, бар, кит, ишек янында бөтерел, сакчы чакыруга әзер тор! Юкса алар бер кычкырыр да, чыкмый дип, ишекне ябып та куяр. Бар, бөгелмә, төз тор. Төрмәгә эләгүгә җебегән димәсен! Бар инде!»

Ишек янында әйләнәм, хәзер үк чакырмасалар гына ярар иде. Уйларым белән җыенып беткәнем юк. Юкса төн буена да гел шул турыда уйлап чыктым бит. Ә шулай да әйтеп каласы сүзләр уйлаган саен өстәлә бара. Күрешүгә бары ун минут вакыт бирәләр. Менә шул ун минутта сигез ай буе җыелган бөтен уйларны, сагынуымны, сагышымны – барысын-барысын да әйтеп бетерергә кирәк. Юк, алай ярамый. Хисләр соңыннан. Иң элек менә бу бармак арасындагыны озатырга. Тукта, төшеп калмаганмы үзе?

Юк, төшмәгән әле, бар. Кая, төкерекләп ябыштырыйм, ашыкканда шуып төшеп кала күрмәсен, тфү, тфү. Аннан өс-башны кайгырту кирәк бит. Радиодан, «Кызыл яшьләр», «Яшь ленинчы» газеталарыннан аласы гонорарлар бар иде, шуларны алырга дежурный алдында Зәйтүнә исеменә доверенность язармын. Бәлки, менә шушы доверенность язган арада язуны да бирергә? Алай уңайлырак булмасмы? Менә шул гонорарга Зәйтүнә Печән базарыннан ботинка, костюм-чалбар, эчке киемнәр алсын. Тагын нәрсә? Ә-ә, башка фуражка да кирәк бит әле... Тагын нәрсә? Әйе, бер-ике передача да китерсен – ашамлыклар һәм тәмәке. Тәмәке күбрәк кирәк. Камерадагы иптәшләрне аз булса да сыйларга. Менә бит алар мине ничек ялт итеп киендерделәр. Бәйрәм ашы – кара-каршы. Аннары әле бит институт хәлләрен сорашмадым. Хатип Госмановның хәле ничек? Аны кулга алмадылар микән? Тагын нәрсә турында? Күкчәтаудан, әтиләрдән хат юк микән?

Йозакны шалтыраталар – ачалар!

Тукта, иң алдан нәрсәне әйтергә булдым әле? Әй, шайтан алгыры, онытып та өлгердем бит, ә! Хат! Хат!

Ишек ачылуга, дежурный йөгереп керде дә мине этеп җибәрде:

– Кит моннан. Тыңлагыз, фамилиясе аталганнар, әйберләрен алып, ишегалдына! Староста! Монда кил, билге ясап тор.

– Иванов Иван Петрович!

– Мин!

– Рамазанов Сабир!

– Мин. – Уртадагы сәкедән сары сакаллы бер карт төште, капчыгы балкага кысылып калды, ала алмый.

– Чык! Нәрсә корсаклы хатын төсле тулганасың?

Мин капчыкны ычкындырып җибәрдем. Карт ишеккә йөгерде.

– Базарбаев Аманбай.

Моны ишетүгә, башым әйләнеп китте, Аманбайдан – тагын бер якын дустан аерылдым бит. Кая алып китәрләр инде аны? Янә очрашырбыз микән?

– Джапаридзе...

– Хәсәнов...

Камерадан ике йөз иллеләп тоткынны этапка алдылар. Әйтүләренә караганда, Норильскига. Аннан каршы-

дагы – Кремль астындагы икенче төрмәдән тагын ике йөз иллеләп мәхбүсне безнең камерага китерделәр. Китте ыгы-зыгы, урын өчен талашу-сугышу. Ярый әле староста мине онытмады. Түрдәге икенче кат сәкедән урын бирде.

Ә күрешү?

Мондый мәхшәрдә нинди күрешү булсын ди. Юкка гына җилкендем. Инде менә нишләргә дә белмим. Киемнәрне, салып, хуҗаларына тапшырырга кирәк.

– Ба-лан-да!

Кизү торучы унбашылар ишек төбенә җыелды. Ишек ачылды. Ике колагыннан ике мәхбүс күтәргән кисмәкләр камерага керә башлады. Әче кәбестә исе борынны ярып китте. Безнең унлыкка да миски килде. Мин дә, консерв банкамны алып, чиратка бастым.

– Салахов, – ишеккә!

Банкам кулымнан төшеп китте.

– Күрешү вакыты биш минут. Очрашуга килгән кешеләргә якынлашырга, кул бирергә ярамый. Һичбер нәрсә алырга, бирергә рөхсәт юк. Бары минем аркылы. Политика турында сөйләшергә ярамый. Төшендеңме?

– Төшендем.

– Атла!

Кузгалдым – тез буыннарым калтырый. Йа Алла, өнемме, төшемме? Чыннан да, хәзер мин аны... күрерменме? Зәйтүнә! Нихәтле әйтелмәгән сүзләр, хисләр... Йөрәктә. Шуңа, ахры, ул дөп-дөп итә. Юк-юк, каушамыйм. Каушама, күңелем! Син, син бәхетле. Ул, ул саф мәхәббәт, керсез-изге мәхәббәт бу ишек артында бит. Ул, мөгаен, минем кочагыма ташланыр. Аңа аны эшләмә, моны эшлә дип кисәтүче дежур надзиратель юк бит...

Ишек ачылып китте.

Мин бусагадан атладым да сын булып катып калдым.

Бу ни бу? Әллә инде күзләрем буыла? Нинди оятсызлык бу, нинди мәсхәрә?

– Нигә ул монда? – дип кычкырып җибәрдем, ачуымнан-әрнүемнән калтыранып.

– Зәйтүнә – минем хатыным, – диде Фазыл, күзләрен тозландырып. Ә аның янында басып торган Зәйтүнә башын иде.

– Булмас, булмас! – Бер-ике адым алга атладым да

бизгәк тоткандагы кебек туңып, чирканып дерелди башладым. – Ул – хаин! Ул минем өстән ялган әләк язган.

– Хатыным алдында хурлама! – диде Фазыл, кара көеп.

– Ә-ә, хурламамы? – Бүлмә уртасында миңа утырырга куелган табуретканы күтәреп алып, Фазылның башына сугарга омтылган идем, надзиратель, йөгереп килеп, кулымнан тотып калды.

Зәйтүнә кычкырып елап җибәрде.

– Күрешү тәмамланды! – диде дежур надзиратель, табуретканы идәнгә куеп.

Очрашу бүлмәсеннән мине туп-туры карцерга алып киттеләр.

5

...Зәйтүнә белән вафасыз күрешүдән соң биш тәүлекне карцерда уздырдым, аннан чыгаргач, тагын шушы йортка китерделәр.

Бердән – ачлык, икенчедән, сөйгән кызымның хыянәте мине ярыйсы ук йончыткан иде. Ашыйсым килә. Уйдангарьләнүдән баш чатный. Кайда, кемгә зарны түгәргә? Аптырагач, бердәнбер дус Сөббухны эзләп киттем, этапка кумаган булсалар гына ярый инде үзен. Алтарь тирәсендә каранып йөргәндә, өстән берәү кычкырды:

– Әй, күзлекле!

Туктадым. Баксам, өске сәндерәдә аякларын салындырып утырган кара сакал – староста, бармагы белән ишарәләп, мине үзе янына чакыра икән.

– Кил әле монда, карчыгам. Хәлләр ничек?

– Ярый шунда.

– Яраса, кил, утыр.

Мин теләр-теләмәс кенә аның янына күтәрелдем. Ул бөтен йөзен каплап алган кара, куе сакал-мыегын ике куллап тарап-купшыланып алды да, сул күзен кысып, хәйләле бер караш белән сорау бирде:

– Сине китап яза диләр, дөресме?

– Элек дөрес иде, хәзер юк!

– Ничего, хәзер дә була, батя... Мин сиңа бер эш таптым, үзе ашлы, үзе тузансыз, кичен яныма кил, туйганчы ботка ашарсың. Килештекме?

– Килештек.

Нинди эш тапты икән миңа бу ат карагы?

Менә бит, уйламаганда эшләр җайланды да китте.

Көн дә өстәмә бер паёк икмәк. Аш та баланда түгел – ит шулпасы, ботка, кайвакытта котлет, староста казаныннан. Үземә генә түгел, Сөббухка да өлеш чыгар...

Ә эше? Эше, староста үзе әйтмешли, тузансыз да, өреле дә. Нәрсә эшлим дисезме? Сөйлим. Көн дә кичке баландадан соң, йокы алдындагы тикшерү-барлауга хәтле, хикәят сөйлим. Кече яшьтән үк «Әлфе ләйлә вә ләйлә», «Кырык вәзир», «Шаһнамә», «Әбүгалисина», «Тутыйнамә», «Салсал» кебек гарәп әкиятләрен укып үскәнгә, запас җитәрлек. Менә хәзер ул ярап куйды. Көн дә бер яңа әкият сөйлим – тоткында утырган халык гарәп әкиятләренең гүзәллегенә, андагы батыр шаһзадәләргә, сылу кызларга, бигрәк тә тәмледән-тәмле «әнваг-әнваг нигъмәтләргә», шәрабларга хәйран калып, хыял дөньясында йөзеп, үзенең бүгенге кызганыч хәлен бик азга гына булса да онытып тора, шуның өчен минем әкият сөйләр вакытны көтеп җиткерә алмыйлар. Бу әкиятләрем бигрәк тә камераның хуҗасы – ат карагы чегәнгә ошый: йотылып тыңлый...

– Алтын кеше бит син, бөркетем. Авызыңнан энҗе-мәрҗәннәр коела. Синең урын монда түгел, җәннәттә бит, җаным, – дип, аркамнан кагып, үсендереп куя.

Камерадагы биш йөз мәхбүс мине белә, килә башласам, торып, сәкесеннән урын бирә. Мин хәзер сәке астында – кандала оясында түгел, алтарьда, староста янында – якты, киң урында ятам.

Менә бит, бәхет, киләм дисә, күктән төшә.

Сигез ай Пләтән төрмәсендә көне-төне сорау алуга йөреп, карцер паёгында торып, коры сөяккә калган идем. Хәзер чиркәүдәге бер ай эчендә тазарып, тулып киттем.

– Сөбханалла, – ди Сөббух, әллә көлеп, әллә инде чынлап. – Син көннән-көн матураясың.

Ахрысы, Сөббух күз тидерде. Бер төнне мине уяттылар да ашыгыч рәвештә каршыдагы икенче төрмәгә алып киттеләр. Нәрсәгә? Билгесез.

6

– Сез җинаятьчеләрне төрмәдән качарга өндәгәнсез һәм, шул явыз ниятегезне тормышка ашырыр өчен, төркем туплагансыз, чиркәү идәне астыннан Казанка елгасына таба подкоп ясарга әзерләнгәнсез. Бу җинаятегезне танмыйсызмы?

– Гражданин тикшерүче... – Өстәл артында ниндидер бер папка ачып кәгазьләр актарган күзлекле кешегә аптырап карадым. Әллә инде башка берәү белән бутый?
– Гафу итәсез, мин бернәрсә дә белмим. Нинди подкоп?

– Молчать! – Тикшерүче, берәү энә чәнчеп алгандай, кинәт чәчрәп торып кычкырып җибәрде, папкадан бер табак язылган кәгазь алды. – Менә гаебең! Сез берәү дә сизми дип уйлагансыздыр. Безнең күз җир астыннан да күрә. Номерыгыз барып чыкмады! Яндыгыз. Соңгы тапкыр сорыйм: җинаятегезне танныйсызмыюкмы?

– Гражданин...

– Җитәр! Конвой! – Ишек ачылып, мине монда алып килгән солдатларның берсе атылып керде. – Менә бу адәм актыгын карцерга! Гаебен өстенә алганчы чыгармаска. Марш!

– Бар, бар!

Надзиратель этеп-төртеп карцерга тыкты да тимер ишекне шалтыратып ябып бикләде. Мин бусагада басып калдым – узарга урын юк. Озынлыгы биш, киңлеге өч метр чамасындагы таш капчык – тәрәзәсез дүрт цемент стена. Түшәмдә тузанга, пычракка катып беткән бер лампочка кызарып тора. Тынчу. Ярым караңгы. Бала-чага тавышы. Башта мин үземнең күзләремә дә, колакларыма да ышанмадым – саташам, ахры. Тора торгач, бераз күз ияләште. Анадан тума ундүрт-унбиш яшьлек үсмер малайлар берсе өстенә берсе атланып тартышалар, сикерәләр, егылалар, сугышалар.

– Әфәнделәр! – Почмактан нечкә бер тавыш колакны кыеп китте, һәм шуннан ук җирән сакаллы берәү күтәрелде. Бусы трусиктан. Күкрәгендә ялангач кыз сурәте һәм язу: «Мәхәббәт өчен җан фида!» Шау-шу акрынлап тынды. Теге җирән сакал алга чыкты: – Әфәнделәр, безгә яңа барон килгән, баш иегез.

Җирән сакал алдымда яртылай сыгылып төште.

– Барон, – диде теге җирән сакал, иелгән килеш, – безне гафу итегез, киләсегезне белмәгән идек!..

Арттан берсе кычкырып җибәрде:

– Баронга көзге кирәк, үзен күрәсе килә.

Ул арада минем алда басып торган бер пумала башлы малай, ялт борылып, нәкъ минем борын төбендә

туңкайды.

– Музыка!

Теге туңкайган малай шатыр-шотыр җил чыгара башлады.

– Ха-ха-ха!

Акылдан шашкан кебек акыру, хихылдау, кычкыру. Мин нишләргә белми аптырап торганда, теге җирән сакал тагын команда бирде:

– Парад!

Ул әйтеп тә бетермәде, әле генә минем алда туңкаеп торган малай сикереп җилкәмә менеп утырды, башкалар аның артыннан тезелделәр.

– Шагом а-арш!

Әмер ишетелүгә, җилкәмдәге бала, аяклары белән күкрәгемә тибеп, кузгалырга боерды.

– Бер-ике, бер-ике.

Мин теге пумала башны күтәргән килеш – алдан, калганнар – арттан...

– Ходаем, падишаһны сакла...

Җилкәмә атланган малай нечкә кызлар тавышы белән патша дәүләте гимнын башлады, башкалар күтәреп алдылар. Алар улый, ә минем тыным кысыла. Җилкәдәге пумала баш үзе албасты сыман авыр, җитмәсә, ботлары белән муенны кысып, үкчәләре белән күкрәгемә тибеп куя: «Тизрәк!»

Кайда тизрәк, мин, абына-сөртенә, камераны ике тапкыр әйләндемме-юкмы, әлсерәп егылдым. Арттагылар барысы да минем өскә ауды. Шаркылдап, хихылдап көлү, акыру. Ә мин изелеп-ватылып, инде һуштан язам дигәндә генә, тагын әмер яңгырады:

– Җитәр, баронны өйләндерергә вакыт!

Өстемдәгеләр этешә-төртешә тордылар.

Ә мин кузгала алмыйм.

– Кияү егет, – теге җирән сакал, алдыма тезләнеп, мыскыллап көлә башлады, – поп сине кем дип чукындырган иде?

Минем телем дә әйләнми.

– Күсе, тукта әле, – җилкәмә атланып йөргән пумала баш миңа карап-карап торды да кычкырып җибәрде: – Бу бит чиркәүдәге әкиятче!

– Син каян беләсең? – Күсе, чыннан да күсе сыман су-

зылып, пыяла күзләре белән карады. – Бәлки, ул түгелдер?

– Үткән атнада мин үзем тыңладым. Менә дигән әкиятләр белә, – ул баш бармагын күтәреп телен шартлатты. – Да, ул – язучы, яңа таныдым.

– Писарьмы?

– Юк ла, китаплар язган.

– Ә-ә-ә! – Җирән сакал миңа аптырап, икеләнеп карады да кинәт кычкырып җибәрде: – Тамаша бетте. Әкиятчегә урын бирергә!

Пумала баш, йөгереп килеп, мине күтәреп торгызды да «Король» утырган җиргә – түргә алып барып утыртты.

– Гафу итегез, язучы абый, мин башта сезне танымыйча калдым.

Ул арада тагын ишек шалтырады. Ачылды. Тагын ике кешене этеп-төртеп керттеләр. Берсе ишектән көчкә сыеп керде – дәү, юан; икенчесе – тәбәнәк, ябык.

Ишектән керүчеләр башларын да күтәрергә өлгермәделәр, шәрә үсмерләр алар өстенә ташланды. Алдарак торганы, дәү җилкәләрен күтәреп, өстенә ташланганнарны атып бәргән иде, бөтен карцер аның өстенә ябырылды. Ектылар да таптый-изә башладылар.

Артта калган тәбәнәк буйлы, моны күреп, куркуыннан, ахры, үзе егылды. Теге дәү озак көрәште, әле бер, әле икенче малайны алып атып карады, әмма җиңелде. Җирән сакал үзе аның өстенә менеп кунды. Калганнар параша капкачы белән суга-суга йөдәттеләр.

Дәү ахырда егылды.

Шуннан соң аны «өйләндерә» башладылар – поп кушкан исемен әйттерделәр, кайда, кем булып эшләвен ачыкладылар. Ул бер районда прокурор булып эшләгән, имеш, – җирән сакал үзе таныды. Менә ни өчен аңа каныгалар икән. Авыз-борыны кан булуга карамастан, прокурорны әүвәле утырттылар. Аннары чалбарын салдырдылар, һәм һәр малай тимер кашык белән өч тапкыр аның «йомшак» җиренә сугып үтте.

Прокурор тәмам хәлдән таеп егылды. Шуннан соң гына «өйләндерү» тукталды. Тәбәнәк тоткын ирекТә укытучы булып эшләгән икән, аңа тимәделәр.

– Менә сиңа кадак, прокурор әфәнде, – дип, Король параша өстендә көчкә утырган дәүгә зур бер кадак сузды. Пумала баш кадакны алып прокурорның борынына

төртте, теге башын күтәрмичә генә алды. Карышырга җөрьәт итмәде, ахрысы. Король, күзләре белән бораулап, сүзен ялгады: – Подъёмга хәтле ишекнең ике тупсасын казып чыгар. Ә син, Пумала баш, карап тор. Казымый башласа, параша капкачы белән җилләтеп ал.

Отбойдан соң кем кайда торса, шунда утырып, чүгәләп йоклап китте. Камера-карцерда бары Король, Пумала баш һәм мин – «оста әкиятче» генә сузылып яттык. Бары хәзер генә мин үсмер малайларның нигә шыр ялангач булуына төшендем. Бөтен киемне бет сарып алды. Күлмәк үзеннән-үзе кыймылдый. Шундый үзәккә үткәзеп тешлиләр, чыдап булмый. Аптырагач, мин дә чишенеп ташладым.

Ә ишек бусагасында кытыр-кытыр штукатур, кирпеч вагы коела. Прокурор карцер ишегенең тупсаларын чокый...

Җәй. Көмеш толымнары белән чайкалып-дулкынланып яткан дала. Еракта ап-ак киез өйләр күренә. Әчкелтем кымыз исе борынны кытыклый. Ә мин кылган эчендә сузылып ятып хәл җыям. Талгын гына җил исә. Нинди рәхәт... Менә кул астында гына кып-кызыл булып пешкән җир җиләге. Авыз итим әле дип кулымны сузган гына идем, ниндидер тавышка сискәнеп уяндым.

Карцер буп-буш, бер кеше калмаган. Ишек каерылып ташланган. Коридорда яткан тимер ишек өстендә надзиратель басып тора: күзләре акайган, әле бер, әле икенче якка карый.

– Әй, мондагы тоткыннар кайда?

Мин аптырап сикереп тордым да, ялангач икәнемне тоеп, яңадан чүктем.

– Белмим.

– Ничек белмисең? Ишекне кем җимерде?!

Ул арада тагын берничә надзиратель йөгереп килде дә, сүгенә-сүгенә, кире борылды.

Алдан килгән надзиратель аптыраудан, ахры, идәндә яткан ишекне бераз күтәреп торды да ташлады һәм мине кисәтте:

– Әй, син, кара, беркая да китмә!

Мин киенә башладым.

Төрмә ишеге алдында шау-шу. Этләр өрә. Ике тапкыр мылтыктан аттылар.

Бераздан төрмәнең столяр цехында эшләүчеләр ки-

леп, каерылып ташланган ишекне киредән урынына куя, цементлап ныгыта башладылар. Алар миңа надзиратель күрмәгәндә бер паёк икмәк, өч-дүрт төремлек махорка бирделәр.

Озакламый карцердан качкан яшүсмерләрне берәм-берәм өстерәп-кыйнап китерә башладылар. Прокурор белән укытучыны бәйләп бәдрәфкә ташлаган булганнар икән, аларны да китерделәр. Ишек, урынына куелып, тагын ябылды, аркылы тимер билбау-болт белән кысылып бикләнде. Карцер тагын тулды. Бары тик Король белән Пумала баш кына күренмәде. Әллә инде алар, төрмәдән качып өлгерделәр, әллә инде аларны башка җиргә яптылар. Кире китерелгән үсмерләрнең барысының да диярлек кул-аяклары яраланган, тәннәре кара көйгән иде. Әмма берсе дә еламый, бары тик сүгенәләр, ишекне кагалар. Ул арада карцерның түшәмендәге люк ачылды да, шлангтан су сиптерә башладылар. Озакламый су билдән булды.

Тәнозын бил тиңентен суда тоттылар. Каты кыйналудан җәрәхәтләнгән, хәлсезләнгән өч малай басып та тора алмыйлар. Аларны иптәшләре алмаш-тилмәш стенага сөяп, күтәреп тордылар. Тора-бара минем аякларны да көзән җыера башлады. Тагын бераз су эчендә калсам егыла идем.

Ниһаять, подъёмга чаң какканнан соң, карцерның ишеген ачтылар – су, буа ерылгандай, коридорга җәелде. Җиңеләеп киттек.

Надзирательләр мине алырга килгәннәр икән. Шул юеш, өстән су саркып торган килеш, төрмә кәнсәсенә алып киттеләр. Өч тимер капка ачылып ябылды. Ниһаять, тәрәзә рәшәткәсе күгәреп беткән озынча бүлмә. Ярым караңгы. Өстәл. Кәгазьгә төртелгән күзлекле тикшерүче, башын да күтәрми, миңа:

– Ничек, җинаятегезне таныйсызмы? – дип эндәште.

– Нинди җинаять?

Күзлекле урыныннан сикереп торды да акырды:

– Конвой, алып китегез, карцерда чересен!

Хәзер җәйнең иң матур чагы – июль уртасы. Мондый чакта кемнең генә күңеле табигатькә талпынмый! Тәнгә сихәт, күңелгә рәхәт бирүче яшел урманнарда, хуш исле чәчәкләр белән балкыган болыннарда кемнең буласы килмәс?

Ә мин менә инде сигезенче тәүлек тынчу карцерда җәфаланам. Көн дә тикшерүче чакырта. Хәзер инде төн уртасында, йокы басканда, төрмә шомлы тынлыкка батканда алдыра башлады. Һаман бер сорау:

– Төрмәдән качу чараларын кемнәр белән, ничек әзерләдең син, халык дошманы? Әллә кайчан инде сине атарга кирәк иде. Әгәр бу җинаятеңне дә өстеңә алмасаң, сиңа котылу юк! Әйт, төркемеңдә кемнәр бар иде?

Ә минем башым әйләнә, күз алдым караңгылана – нинди качу? Нинди төркем? Нинди җинаять?

Кинәт ишек ачылып китә. Ике таза егет – конвоирлар – мине кыйнарга тотыналар. Ә тикшерүче һаман бер сүзне кабатлый:

– Әйт, төркемеңдә кемнәр бар? Кемнәр?

Менә бу карцерның калын таш стенасы артында өчдүрт адымда гына урам. Кремль астындагы бу урамнан Казанкага коенырга йөри идек без. Их, хәзер менә, ичмасам, бер генә тапкыр шул суга чумып чыксаң. Бөтен кер, бар кайгы юылыр иде...

Шалтырап ишек ачылды.

– Следовательгә!

Әүвәле ике тәүлек, бигрәк тә иртән паёк һәм баланда алганда, ашказаным борып-авыртып теңкәгә тиде. Башкалар ашаганны күрмим дип, күзләремне йомып ятам. Староста: «Утыз тугызынчының паёгын, баландасын кире алыгыз. Ул ачлык игълан итте», – ди. Һәр иртәдә. Бүген инде дүртенче тәүлек. Инде ашыйсы килүдән бигрәк эчәсе килү җәфалый. Иреннәрем ярылды. Температурам күтәрелде. «Бер генә тамчы су...» Әмма мин бирсәләр дә эчмим, үземне үзем газаплыйм. Үлемгә дучар итәм. Авызда инде төкерек тә юк, ахрысы. Тел кабарган, эчәсе килә. Бер генә йотым...

Соңгы сорау алуда, аңымны югалтканчы кыйнап, мине карцерга китереп ташладылар. Бөтен тәнем кара янган, сул кулымны күтәрә дә алмыйм – сызлый. Әллә сынган, әллә чатнаган. Бары соңгы сорау алуда гына «подкоп»ның кайдан килеп чыгуын төшендем. Чиркәүдә әкият сөйләгәндә мин, тыңлаучыларны мавыктырыр өчен, пиратлар турында, аларның замоклардан, ныгытмалардан качуларын да тасвирлый идем. Кемдер «чирткән». Менә шуны инде «подкоп»ка хәтле күперткәннәр. Ә мин хәзер

шул юк «подкоп»ны, «төркем»не табып бирергә тиеш.

Табалмыйсың, яшерәсең икән – яңа срок!

Ун ел төрмә. Биш елга хокуктан мәхрүм булу! Инде өстәмә җинаять – төркем белән төрмәдән качуны җитәкләү... Караклар, кеше үтерүчеләрне генә түгел, ә хөкүмәтнең, халыкның кан дошманнарын төрмәдән алып чыгарга «җыенган» кеше бит мин... Ә бу җинаять тагын кимендә ун ел төрмә өстәячәк миңа. Булмаса – ату!

Менә ни өчен мин аңлы рәвештә ашау-эчүдән ваз кичтем. Бу – соңгы таянычым. Мин инде икенче яланы – нахак гаепне җентекләп тикшереп, аклауны таләп итәм.

Карцерда инде берничә тапкыр тоткыннар алышты. Әмма, дөресен әйтергә кирәк, мине бер генә карак та, бер генә рецидивист та рәнҗетмәде, киресенчә, миңа ятарга урын бирделәр. Паёкларымны, ач булуларына карамастан, гадел рәвештә кире кайтаралар һәм хәзер чиратлашып ишекне кагалар:

– Кеше үлә, врач килсен!

– Доктор!

Иреннәремдә – кан. Авызымда – тоз тәме. Их, бер генә йотым су...

– Мәгез, эчеп җибәрегез.

Бер стакан су, саф салкын су! Чайкалып, түгелеп миңа килә.

– Башын күтәрегез.

Кемдер башымны күтәрде. Стакандагы салкын шифалы суның дымы инде иреннәремдә тоела, уф Алла! Моны да күрер көн бар икән! Бар хәлемне җыеп үреләм. Өстәл! Өстәл янында – күзлекле кеше.

– Эчеп җибәрегез!

Сылык итеп кире егылдым. Стакандагы су чайкалып түгелеп китте. Мин аңымны югалттым...

– Ибраһим, ач күзеңне. Менә бераз су йот. Курыкма, мин, мин бу. Имәнкулов Зариф. Хәтерлисеңме, Беренче татар полкы комиссары, Имәнкулов. Йотып җибәр.

Су тамгач, иреннәрем җәелеп киткәндәй булды.

– Ибраһим, тагын, тагын бер йот.

Имәнкулов... Имәнкулов... Бу фамилия каядыр күктә әйләнеп йөрде дә сүнде. Мин тирән бер упкынга төшеп киттем.

Бу камерада әле Имәнкуловтан башка Татиздат буен-

ча таныш журналистым Кәримов Хәмзә дә бар икән. Ул да, рәхмәт яугыры, ярдәмгә килгән – атнага якын миңа кашыктан аз гына шикәрле суда изелгән икмәк ашатып, булышып торган.

7

– Безнең камерага алып килгән надзирательнең әйтүенә караганда, сине ике тапкыр следовательгә күтәреп алып барганнар. Ул сиңа су тәкъдим иткән. Син эчәргә дип омтылгансың да, аңыңа килеп, стаканны этеп җибәргәнсең. Тугызынчы тәүлектә температураң кырыкка күтәрелгән. Төрмә врачы сине, карцердан алып, больницага салырга кушкан. Әмма тикшерүче, ул гаебен өстенә алмады дип, рөхсәт бирмәгән... Менә ни өчен безнең камерада син, Ибраһим, – диде Имәнкулов.

Мин әле ваба авыруыннан арына башлаган кеше кебек хәлсез, калтыранам. Ә шулай да аңым эшли – Имәнкулов! Чыннан да, бу минем янда яткан тоткын – шул Беренче татар полкының комиссары, Гражданнар сугышы батыры, күкрәгендә Кызыл Байрак ордены балкыган мәшһүр комиссармы?

– Ташла, ул турыда сорашма инде. Әнә ишек ачыла. Акрынлап саф һавага чыгып керик, хәл өстәлер үзеңә.

Имәнкулов, култыклап, мине ишегалдына алып чыкты. Камера ишегеннән атлауга, күзләрем чагылды, башым әйләнә башлады.

– Булмаса, утыр монда.

Имәнкулов мине йөрү мәйданына чыга торган ишек төбенә утыртты да баш надзирательгә нидер әйтте. Тегесе кулын селкеде. «Утырсын» мәгънәсендә.

Ул арада икенче яктан һава алырга чыккан хатын-кызлар күренде. Гадәттә, бер камераныкылар кергәнче, икенчесендәгеләрне тышка чыгармыйлар иде. Бу юлы надзирательләр вакытны бутаганнар, ахрысы.

Минем яннан, башларын иеп, кулларын артка куйган хатын-кыз тоткыннар уза. Йөзләре сулган, карашлары сүрән. Арада яшьләр дә, чал чәчле карт аналар да күренә.

– Чү, Ибраһим, бу синме? – Кемдер үтеп барышлый пышылдап кына эндәште. – Исәнме!

– Сәрвәр апа[1]?!

– Шаулама! Хәлең ничек?

– Әле генә карцердан.

– Ишеттем. Барысын да ишеттем. Тугыз тәүлек! Егет икәнсең! Инде бирешмә!

– Җыланнар, тагын пышылдаша башладыгызмы? Туктагыз! Иртәгә тагын сезнең камераны прогулкадан мәхрүм итәм, – надзиратель хатын ирләрчә өч-дүрт катлы итеп сүгенә, арттагыларны этә-төртә башлады.

Әле былтыр гына Сәрвәр апа язучылар җыелышында балалар әдәбиятының үсеше турында доклад белән чыккан иде. Тулы күркәм гәүдәле, шат чырайлы, кызлар кебек җыйнак, матур иде ул вакытта. Ә хәзер? Хәзер әнә танымаслык булып ябыккан, йөзе саргайган, әмма тавышы көр. Ул, надзиратель хатынның сүгенүенә, куалавына да карамастан, миңа таба борылды һәм инде ачык тавыш белән кычкырды:

– Ибраһим, өметеңне өзмә! Бу караңгы төн мәңге булмас.

Ул тагын да нәрсәдер әйтмәкче иде, надзиратель хатын Сәрвәр апаны этеп җибәрде. Сәрвәр апа камера бусагасына абынып егылды.

Авыр тимер ишек шалтыр-шолтыр килеп ябылды.

---

[1] Сәрвәр апа – Сәрвәр Әдһәмова, язучы, тәрҗемәче Кави Нәҗминең хатыны.

АНА ТАВЫШЫ

Бу фаҗигале вакыйгадан соң инде кырык елга якын вакыт үтте. Әмма ул йөрәк өзгеч тавыш, чегән хатынының баласын эзләп, зарлап елавы әле хәзер дә колагымда чыңлый. Кайвакыт баласын кочаклап перронда аунаган шул чегән хатыны төшемә керә. Кара тиргә батып, куркып уянам.

1938 елның июне. Уфа. Тимер юл вокзалы. Перрон. Ул шомлы кичтә безне, бер төркем «халык дошманнары»н, күп газаплар күреп, ниһаять, Уфа төрмәсенә килеп эләккән тоткыннарны, тагын каядыр озатырга дип вокзалга китерделәр. Билгеле инде, «кара козгын» читлекләрендә. Шуның өчен юлда кем белән килүебезне белмәдек. Безне перронда, каядыр китәргә торган ниндидер поезд янына китереп төшерделәр һәм шундук бер Столыпин вагоны алдында тезләндерделәр. Бу юлы төркем кечкенә, егермеләп кенә мәхбүс иде. Яңа гына яңгыр явып үткән, перрон пычрак. Җитмәсә, безне нәкъ пычракның күзенә тезләндерделәр. Чалбарлар шундук лычма су булды. Әмма аңа бер тоткын да игътибар итми. Уфаның тоткыннар белән шыгрым тулы тынчу төрмәсеннән соң мондый саф һавада булу, иркенләп сулыш алу кәтелмәгән рәхәт бит. Дөрес, вокзал-перрон һавасында төтен аралаш күмер, май исе сизелә. Әмма инде бу һаваны камераныкы белән чагыштырып булмый. Белмәгәнбез генә икән иректә вакытта: вокзалның һавасы да, тынгысыз ыгы-зыгысы да күңелгә ятышлы. Әнә ничек кайнап тора ул. Берәүләр, чемоданнарын, капчыкларын, әрҗәләрен күтәреп, водокачка ягына таба абына-сөртенә йөгерә, икенчеләре, нәкъ шулай тирләп-пешеп, аларга каршы чаба. Барысы да ашыга. Тик без генә – тоткыннар гына сүлпән. Әйтерсең лә теге дөнья кешеләре – пычрак суга тезләнеп, тынсыз утырабыз. Юк, бу тыштан гына шулай. Ә эчтә, менә бу пычрак суга тезләнгән ертык-керле киемле, ябык-сары, тутлы йөзле тоткыннар күңелендә – өермә. Алар үзләренең, нәкъ шушы пассажирлар төсле, теләсә кай якка бара алган чакларын хәтерли, туганнарын күз алдына китерә. Алай гына да түгел, күзләре белән интегеп якыннарын эзли, бәлкем... Бәлкем, менә шушы шашып йөгергән юлаучылар арасында атасы, хатыны, баласы бардыр... Бәлкем?

Аһ, хәзер алар килеп чыкса...

Мин дә, тирә-ягымдагы иптәшләрем төсле үк өзелеп, вокзал ыгы-зыгысына карыйм. Көтәм. Кемне? Үзем дә белмим. Әмма ашыгып, ашкынып көтәм...

– Ә-ә, әү-әү...

Дерт итеп киттем. Якында гына бер яшь бала кычкырып елап җибәрде. Нинди нарасый? Кайда? Без инде һәрберебез елдан артык тоткында – гаиләдән аерылган. Шуның өчен бу тавыш, сабый бала тавышы, сәер дә, якын да, газаплы да.

Бала елый.

– Ә-әү... Ә-әү...

Кайда? Кем баласы? Мин башымны артка бордым. Гәүдә белән борылырга ярамый. Конвой һәр хәрәкәтне качарга әзерләнү дип исәпли һәм шундук ата. Артта, кырыйда, безнең кебек үк тезләнеп, бер чегән хатыны утыра – яланбаш, чәчләре тузгыган, яланаяк. Өстендә керле, ертылып беткән кат-кат күлмәк һәм инде төсе уңган зур шәл. Ул шәлен иңенә салып уранган. Шул шәл эчендә кечкенә сабый күзләр – шомырт күзләр елтырый. Хатын шәлен бераз бушатты да, якасын ачып җибәреп, сабыйга имчәген каптырды. Елау басылды. Сабый чуп-чуп итеп тәмләп имә башлады. Күзләр йомылды.

Паровоз кычкыртты. Буферлар бер-берсенә сугылып чыңладылар.

– Торыгыз! – Конвой башлыгының ачулы тавышы колакны ертып китте. Ул үзе кечкенә, чандыр. Борыныннан кыссаң, җаны чыгар. Мондый ачы тавыш кай җиреннән чыгадыр. – Басыгыз! Тезелегез! Тикшерү!

Безне төрмә конвоеннан юлныкына тапшыру башланды. Төрмә конвое башлыгы – озын буйлы, тулы гәүдәле, җәенке битле, кысык күзле башкорт егете – янәшәсендәге солдатка күтәреп килгән зур күн сумкасын җиргә куярга боерды. Куйдылар. Ачтылар. Аннан зур-зур папкалар чыгара башладылар. Тоткынның формулярын, гамәл дәфтәренә язылган хөкем карары һәм башка кәгазьләрен.

– Иванов, бер адымга алга чыгып бас!

Уң яктагы ак сакаллы карт профессор әмерне үтәде һәм исемен, туган елын, ничә елга, нинди статья белән хөкем ителгәнен әйтте.

Юл конвое башлыгы, формулярны алып, тоткынның

әйткәннәрен тикшереп, формулярдагы язмалар белән чагыштырып тора.

Без барыбыз да бу гадәти, инде ел буена бер төрмәдән икенчесенә йөри-йөри күнегеп беткән «сират күпере»ннән үтеп, Столыпин вагоны алдына бастык. Иң соңгы булып чегән хатыны калды. Бая борылып караганда абайламаганмын икән. Беренчедән, анда мин күбрәк игътибарны сабый балага биргән идем. Икенчедән, хатын бөгелеп баласын имезә иде. Менә ул хәзер торып баскан. Имәнеп киттем. Әллә инде Проспер Мерименың мәшһүр Кармены басып тора? Төз, зифа буй. Матур, килешле гәүдә. Чем-кара, озын калын толымнар тузып җилкәгә төшкән. Калын кыйгач кара кашлар. Карчыга борын. Хәзер каты кысылган юка иреннәр һәм аз гына алга омтылган ияк. Дөрес, бит алмалары янып тормый, аксыл, суырылган. Бу инде аңлашыла, ул да, безнең кебек, тынчу камерадан чыккан, туяр-туймас паёкта торган, җитмәсә, бала имезә. Әгәр хәзер аны иркен таборга җибәрсәң, туйганчы ашарга бирсәң?.. Мине аеруча сокландырганы – зур шомырт кара күзләр. Алар ниндидер бер көч, ярсу белән бораулап карыйлар. Ә торышы – нәкъ таборда биергә чыгарга әзерләнгән төсле иркен, хәтта аз гына куштан да. «Карагыз, сокланыгыз, мин нинди чибәр!»

Ул бер адым алга атлады да, горур бер караш белән, башын аз гына артка чөеп, шәлгә урап күкрәгенә бәйләгән бәбиен тирбәтә-тирбәтә, аз гына чайкала, борын астыннан гына ниндидер бер көй шыңшый. Күрәсең, беренче баласы – сөенеп туя алмый.

– Әй, син нәрсә, Земфира?! – Юл конвое башлыгы аңа мыскыллап карап акырып җибәрде. – Нәрсә чайкаласың? Әллә камерада чәкеп алдыңмы? Сиңа аерым чакыру кирәкме, атла. – Ул төрмә конвое башлыгына борылды. – Кайда аның формуляры?

– Чегән хатынының формуляры юк. Ул әле тикшерелә генә. Озату кәгазе генә бар.

– Бир монда, – диде дә теге түрә чегән хатынына кадалды. – Ә нәрсә ул шәлгә уралган? Әллә багарга да өлгердеңме? Нәрсә ул?

– Ул – минем кошчыгым.

– Җүләр, нинди кош тагын?

– Иптәш начальник, – диде башкорт егете, – ул – балалы хатын.

– Нинди бала?! – Конвой башлыгы ачуыннан елан чаккандай сикереп китте. – Шул гына җитмәгән, юлга бала белән. Бир әле конвоирга, балалар бүлмәсенә тапшырсын.

– Миндә көчек юк!

– Молчать! – Түрә кеше акырып җибәрде. – Мин сиңа күрсәтермен тешләреңне. Иптәш Иващенко! – Ул чылбыр булып безне урап торган конвоирларның чегән хатынына якынрак торганына эндәште: – Ал баланы, вокзалдагы дежур милиционерга бир!

– Тыңлыйм! – Иващенко мылтыгын янындагы иптәшенә бирде дә чегән хатынына ташланды.

Хатын, ялт, аркасы белән борылды. Солдат, алга чыгып, хатынның күкрәгенә кул сузган иде, кинәт аның битенә шап итеп хатынның кулы төште.

– Аһ, сөйрәлчек, син әле конвоирга сугасыңмы?!

Гайрәтле түрә, чыпчык кебек сикерә-сикерә килеп, балалы чегәннең аркасына төртте. Хатын перронга барып капланды, бәбие акырып елап җибәрде. Конвой башлыгы хатынны тагын бер тибеп әйләндерде дә баланы тартып алырга иелде һәм шундук «А!..» дип яман тавыш белән акырып артка чигенде. Аның уң кулыннан кан тамчылый иде.

Ике тапкыр кыңгырау чыңлады. Начальник кесәсеннән яулык алып, уң кулын урады да вагонга йөгерде, тамбурда басып торган проводницаны чакырып, колагына нидер пышылдады. Проводница ризалык белдереп башын иде.

– Әйдә, үләксә, йөгер теге вагонга! – Түрә кеше чегән хатынын куа, ашыктыра башлады. – Тиз, тиз, падла!

Хатын, баласын кочаклаган килеш мүкәләп, егылган җиреннән торды. Үзе һаман «ә-ә-ә» дип баласын тынычландыра. Аның әле бала имезеп утырган җирендә зур гына капчыгы да бар икән. Бер кулы белән баласын күкрәгенә кысып, икенчесе белән биштәрен өстерәп, яшел вагонга, конвой күрсәткән, проводница басып торган ишеккә таба ашыгып атлады. Начальник арттан аның саен кызулады.

– Тизрәк, тизрәк, үләксә! Поезд кузгала. Синең аркада әнә составны тотып торам, адәм актыгы!

Чегән хатыны, абына-сөртенә капчыгын өстерәп, бас-

кыч төбенә килеп җитте. Үзе мышный, баласы елый.

– Әйдә, әйдә, мен вагонга.

Хатын бер кулы белән баласын кысып, икенчесе белән капчыгын өстерәп вагонга күтәрелмәкче иде, баскыч биек, аягы җитми. Ул арада өстә басып торган проводница, елмаеп:

– Бирегез балагызны, мин тотып торыйм, – диде.

– Рәхмәт.

Чегән хатыны баласын проводницага биреп, үзе ике куллап капчыгын күтәрде – вагонга менәргә азапланды. Шундук шап итеп эчке ишек ябылды.

Хатын акырып җибәрде:

– Мишут-ка-а!..

Ул арада күрше вагонның ишеге ачылды, һәм аннан теге проводница кызыл чүпрәккә төрелгән баланы конвой башлыгына суздым.

– Иващенко! – Начальник конвоир солдатны чакырып алды да акырып елаган баланы суздым: – Мә, тизрәк вокзалга детприёмникка илт.

Иващенко бик шыксыз-уңайсыз рәвештә төргәкне алып култык астына кыстырды да вокзалга таба йөгерде. Бала буылып, үксеп елый иде:

– Ә-әү... Әү...

Паровоз соңгы гудогын бирде.

Безне, тиз генә этеп-төртеп, вагонга керттеләр. Поезд кузгалды.

Столыпин вагонында тоткыннар өчен дә комфорт җитәрлек – купелы вагоннардагы кебек, аерым-аерым бүлмәләр. Бары тик тәрәзәләре, көзгеләре, радиосы, вентиляциясе генә юк. Аның каравы ашау-эчү өчен ресторанга барып йөрисе юк – китереп торалар. Бу купе-камераның истәлекле, күзгә ташланып торган җиһазы – ишек. Ул тимер белән тышланган. Югары өлешендә ачыла-ябыла торган тимер рәшәткәле форточкасы бар. Ә форточкада сәгать телендәге сыман түгәрәк тимер кисәге – «медаль» асылынып тора. Бу – «күз». Коридорда кизүдә торучы конвоир һәрвакыт «күз» янында. Ул аны түргә үткәндә дә, ишеккә атлаганда да ачып карый – сыңар күз белән, әмма җентекләп. Башкача мөмкин дә түгел – устав куша. Купе-камерага бикләнгән җинаятьчеләрдән теләсә нинди «баш китәрлек» эшләр

көтәргә була. Мәсәлән, идәнне, түшәмне, стенаны тишеп качу йә хат-мазар төшереп калдыру, яки асылыну... Шуның өчен «күз» һәр минут ачылып-ябылып тора.

Менә шушындый купе-камераның берсендә без сигезәү. Яныбыздагы кырый камерага теге чегән хатынын япкан булганнар икән. Ул бертуктаусыз ишеккә суга, тибә, кычкыра.

– Ачыгыз! Ачыгыз, дим, җен-пәриләр. Кайда минем улым?! Кайда минем Мишуткам! Ачы-гыз! А-чы-гыз! Ишетәсезме, ерткычлар, ишетәсезме?!

– Җүләр, кычкырма! Уфа инде әллә кайда калды, – ди кизүдәге Иващенко, форточканы шарт-шорт ачып-ябып.

– Улымны... Улымны кая куйдыгыз?! – Йөрәк өзгеч тавыш һәм акырып елау.

Бөтен вагон бу зардан, елау-каргаудан тетрәнә. Йөрәк әрни, ташый, түгелә. Ә чегән хатыны һаман ишекне шакый, тырный, суга, тибә һәм яман тавыш белән кычкыра:

– Улымны... Мишуткамны... Кошчыгымны кая куйдыгыз?! Бирегез, бирегез...

Берәр сәгатьтән соң күрше вагонда баручы конвой башлыгының тавышы ишетелде. Нindидер боерыклар бирде һәм кизү торучы солдатның чегән хатыны турындагы рапортына тыныч кына:

– Еласын, тамагы карлыккач туктар әле, – диде.

Түрә чыгып китте. Форточка ачылды. Безгә берәр селёдка, өч йөз грамм ипи бирделәр – кичке аш. Тамак ялгарга утырдык. Әмма нихәтле ач булмыйк, ризык бугаздан үтми, тыгыла. Чөнки колакта чегән хатынының зарлы тавышы, ләгънәте, ялваруы. Өч-дүрт сәгатьтән ишеккә сугу, тибү тукталды, тавыш та акрынланды. Хәзер шыңшып елау, үксү һәм зар...

– Мишутка, бәгърем... җаным... кошчыгым. Инде карының ачкандыр, имәсең киләдер. Менә имиләремә сөт төште, сызлый. Ми...шут...ка... Аһ...

Буферлар бер-берсенә сугылып шыңшый. Тәгәрмәчләр, рельслар башына сугылып, бертуктаусыз шак-шок, шак-шок итә. Анда-санда паровоз кычкыртып куя. Туктый. Перронда шау-шу, кыңгырау. Буферлар сугыла. Тагын шак-шок, шак-шок. Поезд каядыр ашыга. Кая? Безгә билгесез. Нинди язмыш, нинди яңа михнәтләр, газаплар көтә безне?

– Шак-шок, шак-шок.

Керфекләр эленә.

Яман бер тавышка сискәнеп уяндым.

– Мишутка, у-лым, син кай-да-а?

Әйтерсең лә йөрәкне телгәләп тоз сибәләр, ул әрни, сызлый, сыгыла.

– Ми-шут-ка-а-а-а!..

Карлыккан тавыш тагын тозлы күз яшенә тыгылып ялварды.

Төн. Шак-шок, шак-шок һәм кизүдәге конвойчының аяк адымнары. Аннан тагын күрше купеның ишегендә акыру, елау, шаку, тибү, теш шыгырдату һәм ләгънәтләү. Паровоз бөтен даланы яңгыратып кычкырта-кычкырта да чаба бирә.

– Җеннәр, пәриләр, кая куйдыгыз минем газиз улымны, бирегез! – Инде тавыш акрын, гырылдап чыга.

Ниһаять, таң алдыннан күрше камерадагы тавыш тынды.

– Бичара хатын. Йоклап китте, ахрысы, – диде авыр сулап күршем Мәхмүт Әбҗәлимов.

– Арыгандыр инде мескен. Әйдә, без дә йоклап алыйк ул уянганчы, – дидем дә борылып яттым, күзләремне йомдым.

Коридорда пыш-пыш сөйләшү, арлы-бирле йөгерүгә уянып торып утырдык. Бар игътибарыбыз коридорда. Нәрсә? Менә вагонның тышкы ишеге шарт итеп ябылды. Конвой башлыгының ачулы тавышы яңгырады:

– Ни булды?

– Иптәш... начальник... үлгән.

– Кем үлгән?

Тагын кизүдәге конвоирның хәвефле пышылдау тавышы:

– Чегән хатыны, иптәш начальник. Асылынган...

ТАНЫШ ТҮГЕЛ ДУС

1

Мин кабат-кабат 1938 елның май аена әйләнеп кайтам. Унбиш-егерме көн эчендә ашык-пошык, аеруча бер салкын канлылык, игътибарсызлык, хәтта җирәнүле караш белән, халыкның 1905–1917 еллар революцияләре дулкы-

нында күтәрелеп чыгып, шул революция җиңүе өчен фидакяр көрәшкән, кан койган, әмма бөгелмәгән, һаман бөек көрәш сафында калган газиз уллары һәм кызлары бер гаепсез, нигезсез «халык дошманы» дип гаепләнделәр. Өлкә партия комитеты һәм пленумы әгъзалары, шулай ук Верховный Совет депутатлары, халык комиссарлары, галимнәр, язучылар, артистлар, карт большевиклар, башка совет оешмалары җитәкчеләре, күз дә йоммыйча, үлем җәзасына хөкем ителде. Азларына гына «шәфкать» күрсәтеп, аларны ун-унбиш елга төрмәгә, әгәр дә инде аннан үлмичә алай-болай чыга калса, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм итәргә дигән хөкем чыгардылар.

Мин, мөгаен, яшь булуым аркасында, бәхетлеләр төркеменә – төрмә җәзасына тартылганнар арасына эләктем. Казаннан соң Бөгелмә, Уфа, Свердловск, Чиләбе, Төмән төрмәләрен кичтем.

Бу юл бик авыр узылды, һәрбер төрмә йөрәктә кан саркып торган төзәлмәс ачы яра булып калды. Әле хәзер, кырык елдан соң да ул төрмәләр, камералар, карцерлар төшемә керсә, мин куркып, саташып, шабыр тиргә батып, тетрәнеп уянам.

Эссе җәй айлары. Тоткыннар белән шыгрым тулы камералар – ятарга түгел, басып торырга да урын җитми. Парашалар тулып ага. Сасы ис бугазны буа. Ашарга коры паёк. Су юк. Төрмәдән төрмәгә Столыпин вагоннарының кысрык камера-бүлмәләрендә күчерәләр. Анда да бар ризык – балык. Анда да тәүлегенә бер кружка су.

Казан төрмәсеннән бу юлны без, «аеруча куркыныч биш җинаятьче», бергә башладык.

Беренчебез – яңак сөякләре калкып торган, зур кара күзле, калын кара чәчле Мәхмүт Әбҗәлимов. Һич борын төшерми, кайгырмый, нинди дә булса бер кызык уен, сүз табып кына тора.

Икенчебез – Мәхмүткә капма-каршы, тәбәнәк, юан, әмма гаҗәеп матур сынлы Гений Измайлович Республиканец – Казанда В. И. Ленин музеен оештыручы, аның беренче директоры.

Өченчебез – атлет гәүдәле Николай Васильевич Акимов.

Дүртенчебез – Ардалион Михайлович Нижегородцев,

киптерелгән балык төсле ябык. Сары чәчле. Зур пыялалы күзлектән. Гел хәвефләнеп, тынычсызланып тора.

Бишенчебез – үзем.

Алда бер әйткән идем инде: Мәхмүт тә, Николай да, Ардалион да – бу хәлләр килеп чыкканчы комсомол җитәкчеләре булып эшләгән егетләр.

Без беренче тапкыр 1938 елның көзендә Казан вокзалындагы Столыпин вагонының бер караңгы, тар камерасында очраштык. Менә шуннан башлап бик күп еллар бергә булдык – уртак камерада утырдык, бер кашыктан ашадык. Ахырында Колыма приискаларына кадәр барып җиттек.

2

Поезд Төмән станциясенә килеп туктады.

– Мөгаен, безне монда төшерерләр. Иртәгә Октябрьнең егерме бер еллыгы бит, – диде Мәхмүт, тимер рәшәткәгә колагын куеп тыңлап. – Әнә овчарка чиный, алырга килүләре анык.

Әйтеп тә өлгермәде, конвой башлыгы, йөгереп килеп, безнең камера-купеның йозагын ача башлады:

– Чыгыгыз! Әйберләрегез белән! Тизрәк!

Атылып-бәрелеп тамбурга чыгуыбыз булды, күзләребез чагылды: перрон ап-ак, беренче күбек кар төшкән. Хуш ис, кар исе. Тынчу камерадан соң сулап туя алмыйбыз.

– Төшегез!

Ап-ак кар түшәлгән перронга төшәргә өлгермәдек, тагын боерык:

– Тизләнегез! Кыбырсымагыз!

Мондый әмерләргә без инде күнегеп беткән – вагоннан төшкәндә, вагонга менәргә әзерләнгәндә, тоткын җиргә тизләнергә тиеш. Яңгыр явып, перрон измә пычракка әйләнгәнме, хәзерге кебек тездән кармы, конвойның эше юк – тизлән!

Бу юлы да карга чумып тезләндек. Бер генә кат чалбардан, суык балтырны чеметеп алды – дерелди башладык. Паровоз сузып кычкырды да пошкырды, поезд китте.

– Басыгыз! Берәм-берәм, марш!

Без – биш тоткын. Ә безне каравыллап төрмәгә алып барырга алты конвоир һәм бозау хәтле бер эт килгән. Бигрәк зур «илтифат»!

Төрмә капкасы янына җиткәч, конвой башлыгы безне туктатты да, конвоирларга пышылдап кына ниндидер бер боерык биргәч, вахтага керде. Без стенага таба елыштык.

– Алло, алло! – Карлыккан тавышлы конвой башлыгының телефоннан сөйләшкәне ишетелде. – Иптәш начальник, аеруча хәтәрләрне алып килдек. Кая олактырырга?

Без кычкырып көлеп җибәрдек. Конвой шашып калды.

– Сез нәрсә? Сез? Акылдан шаштыгызмы әллә?

Аннан гадәти әмерләрен бирделәр:

– Тезләнегез, контр кисәкләре!

Тагын карга батып, көрткә тезләндек. Ә үзебез елмаябыз.

Инде икенче ел төрмәдә утырабыз. Һәрберебезгә зинданны шәп чәпәгәннәр. Ләкин һаман әле үзебезнең бу хәлгә – арестант булуыбызга, бигрәк тә «аеруча куркынычлы җинаятьче», «халык дошманы» булуыбызга иялəшеп бетә алмыйбыз. Менә ни өчен конвой башлыгы «аеруча хәтәр» дигәч, без пырх итеп көлеп җибәрдек.

Әмма бу көлүебез хәерлегә булмады – кар эчендә тезләнеп, сәгатьтән артык көтәргә туры килде. Тешләр тешкә сугылып, шакылдап, калтырап, туңып, күгәреп беттек. Тагын бераз болай кар эчендә утырсак, бөтенләй катып кала идек.

Ниһаять, безне торгызып, иң әшәке сүзләр белән сүгәсүгә, төрмә ишегалдына керттеләр, аннан приклад белән суга-төртә, карцер бинасына әйдәделәр. Төрмә капкасы алдында болай озак утыруыбызның сәбәбен соңыннан гына белдек. «Аеруча хәтәрләр»не урнаштырыр өчен, төрмәнең карцерын ашыгыч рәвештә бушатырга туры килгән икән.

«Кара козгын» чайкалып кузгалды. Без тагын киттек. Кая? Билгесез. Уйла, борчыл. Газаплан. Вакыт җитәрлек сиңа, арестант. Унъеллык юлың башланды гына бит әле.

Әүвәл ярыйсы гына иде төсле монда. Әмма, бара торгач, тын кысыла, баш чатный башлады. Өстә форточка булган. Ләкин хәзер ул бозланып каткан, тыштан һава керә алмый. Озакламый сару кайнарга тотынды.

– Ачыгыз, һава җитми!

– Һава! Һава! – дип кычкыра башлаган идек, ишекләргә

шарт-шорт приклад белән сугарга тотындылар.

– Өнегез чыкмасын! Дөмекмәссез!

«Козгын» каядыр түбән төшеп китте. Чайкалды. Үпкәм бугазыма тыгылгандай булды – чыдый алмадым, укшып, косып җибәрдем. Дерелдәп туңып күзләремне ачсам, кар өстендә ятам. Тирә-якта, минем кебек үк сузылып, иптәшләрем ята.

Кемдер арт яктан килеп башыма типте.

– Тере!

Карасам, конвой башлыгы. Бәрән тиресеннән тегелгән колакчын бүректән. Тездән түбән төшеп торган бөрмә билле туннан, ак пималардан – арлы-бирле атлап, кар өстендә аунап яткан тоткыннарның «хәлен» тикшерә – типкәләп уза.

Ул тагын бер әйләнде дә авызындагы папиросын төкереп ташлап әмер бирде:

– Юләр сатуны туктатыгыз! Торыгыз!

Конвоирлар йөгереп килеп тарта-йолыккалый башлады:

– Әйдә, әйдә, кыланма!

Мин торырга дип кузгалган идем, икенче якка авып киттем, аяклар җансыз. Конвой башлыгы, ашыгып килеп, билемә типте:

– Кара син контрның назлануын!

...Бер төн, бер көн сугылып-авырып, үлә язып, икенче тәүлек иртәсендә генә Тубыл төрмәсенә килеп егылдык. «Кара козгын» төрмәнең эчке ишегалдына – коридорына ук килеп туктаган. Шуның өчен без шәһәрне дә, хәтта үзебез утырачак төрмәне дә тышкы яктан күрә алмадык. «Кара козгын»нан аңгы-миңге, көч-хәл белән чыгуга, беренче әмер «Чишенегез!» булды.

Суык ишегалдында шыр ялангач калып чишендек тә бозланып каткан цемент идәнгә бастык.

Алып килүче конвой башлыгы, кулындагы папкадан безнең гамәл дәфтәрен чыгарып, фамилияне әйтә башлады:

– Әбҗәлимов!

Инде бу барлауга күнегеп беткән тоткын бер адым алга атлый һәм тын да алмыйча тезеп китә:

– Әбҗәлимов Мәхмүт. 1913 елда Казанда туган, ун ел төрмә, биш ел мәхрүмлек, илле сигезенче статья (фәлән-

фәлән пунктлар).

– Кулларыңны күтәр!

Култык астын карыйлар.

– Колаклар?

Колак тишекләрен карыйлар.

– Бөгел...

Шулай берәм-берәм һәрберебезнең бар җирен тикшереп карыйлар. Катып, туңып беттек. Тикшерү, тентү тәмамланганчы киенергә ярамый.

Ниһаять, алу-бирү, тентү бетте, безнең формулярлар конвойдан төрмә администрациясенә күчте.

Коридорның аргы башындагы бер ишекне ачтылар. Надзиратель әмер бирде:

– Алга, марш!

Йа Алла, бу көнне дә күрәсебез бар икән – мунча! Ләүкә. Краннар. Ләгәннәр. Сабын кисәкләре – барысы да бишәрдән.

Төрмәгә эләккәннән бирле мондый иркен мунчаны күргәнебез юк иде. Бигрәк тә хәзерге кебек, катып туңганнан соң...

Салкын су, кайнар су. Пар. Җәннәт. Ләүкәдән төшмибез. Барыбызның да тәне кабыкланып каткан. Кайнар су, пар белән җебеткәч, кабык салына башлады. Берберебезне тырнакларыбыз белән кырып юабыз. Бер кат тиребез салынды, ахрысы.

Юынып бетеп коенгач, икенче бүлмәгә чыктык. Сөлге, күлмәк-ыштан – һәрберебезгә аерым-аерым.

– Кирәк-ярак алыгыз, – диде надзиратель, ишекне ачып.

– Выты, багыгыз әле, душаларым, – ди Мәхмүт, юри мишәрчәләп. Үзе, арлы-бирле атлап, өр-яңа формасын күрсәтә. – Выты, нинди кураж булдым, ә?

– Петлицаларында алтын йолдызлар гына юк, маршал булыр идең, – ди Акимов, көлеп.

Мин дә яңа формага төрендем. Үзеңдәге күренми, кеше өстендәге чекерәеп тора.

Безгә өр-яңа төрмә киемнәре: бушлат, гимнастёрка, чалбар, колаклы бүрек бирделәр. Алар барысы да күксел калын киндердән тегелгән һәм барысында да канәфер төсендәге «ямаулар». Чалбарның тезләрендә, гимнастёрканың якаларында, бушлатның да шулай ук яка-

сында, җиң очларында, бүрекнең колакларында. Бу «ямаулар», билгеле инде, киндер җитмәүдән түгел, алай-болай качып китсәләр, әллә кайдан аның кемлеге кычкырып торсын өчен. Ботинкалар да бирделәр, тик шнуры гына бер тотым. Озын ярамый, асылынуыбыз ихтимал бит.

3

Сез Фёдор Михайлович Достоевскийның «Үле йорт язмалары» исемле китабын, һичшиксез, укыгансыздыр. Нинди фаҗигале күренешләр, нинди газаплар, вәхшәтләр күз алдыннан үтми аны укыганда. Йөрәк тетри, әрни. Коточкыч ул Тубыл төрмәсенә багышланган бу китап. Икенче тапкыр кулга алырга да куркасың аны – җаның өши. Менә шул китапта тасвирланган, Ф. М. Достоевский җәфаланган төрмәдә – Тубыл зинданында – миңа да 1938 елның ноябреннән 1940 елның маена хәтле ел ярымга якын утырырга туры килде.

Башта Фёдор Михайлович михнәт чиккән иске төрмәдә әсир булдык. Аннан 1939 елның мартында безне, «җәмгыять өчен аеруча куркыныч политик җинаятьчеләрне», әле яңа гына салынган махсус корпуска күчерделәр. Кеше, бигрәк тә тоткындагы кеше, һәрбер үзгәрешкә, хәтта бер камерадан икенчесенә күчүгә дә сөенә. Яңалык! Надзирательдән башка камерага күчәчәгебезне ишеткәч, без дә сөендек – кабындык. Кем белә, яңа төрмәдә, бәлки, тормышыбыз яңача – җайлырак китәр.

Әмма... Әмма кышын ашыгыч салынган яңа корпусның тар тимер баскычларыннан күтәрелеп, әле цементы да кибеп җитмәгән, тар, ярым караңгы коридорыннан узгач, ике яктан тезелеп киткән камераларның авыр тимер ишеген ачып бусагасыннан атлауга, бар өметләр челпәрәмә килде.

– Әйе... Фёдор Михайлович утырган борынгы төрмә оҗмах булган икән, – дидем мин, ачынып, шыңшыпчинап камера ишеге ябылгач. Җаным өшеп-тетрәнеп китте. Әйтерсең лә тере килеш ләхеткә куйдылар мине.

Хәер, болары әле алдарак... Әлегә безнең бу төрмәгә яңа аяк басу...

– Бу минуттан башлап исем-фамилиягез формулярда гына кала. Всё! Бу минуттан башлап сез бары үзегез утыра торган камера саны һәм ятак саны белән генә аталасыз. Всё! Аңлашыламы?

– Аңладык!

– Всё!

– Бер сорау бирергә мөмкинме?

– Тондыр!

– Безгә туганнарыбыз белән хат-хәбәр алышырга мөмкинме?

– Мин сезгә төшендердем, Тубыл төрмәсе гади төрмә түгел. Ул – полит-и-зо-ля-тор! Төшендегезме?

– Юк.

– Менә юләр. Барысын да монда мин хәл итәм. Инде төшенденме?

– Әйе.

Төрмә башлыгының безне – «аеруча куркынычлы биш сәяси җинаятьчене» – беренче кабул кылуы шуның белән тәмамланды. Баш надзиратель безне төп торакларга алып китте. Коридорның урта бер җирендәге таныш камера алдына килеп туктадык. Туксан алтынчы номерлы камера.

Әүвәле йозак, аннан камераның авыр ишеге ачылды.

– Керегез.

Монда атлауга, күзләребез чагылып китте – каршы стенада зур-зур өч тәрәзә. Рәшәткәләр дә башка төрмәләрдәге төсле бөтен тәрәзәне томалап тормый, шпага рәвешендәге уклар рамнарның урта күзләренә генә җитеп туктый. Өске як рәшәткәсез, ачык. Бу камераның озынлыгы сигез, киңлеге биш метр чамасында. Биеклеге дә әйбәт, өч метр ярым булыр кимендә. Түшәм һәм стеналар бик яхшылап известь белән акшарланган. Бу бүлмә һич төрмә камерасына охшамаган. Әйтерсең мәктәпнең класс бүлмәсе. Бигрәк тә хәзер иртәнге кояш нурларында бүлмә ялт итеп тора.

Ул гынамы? Тагын бер сюрприз. Менә шушы киң, биек, якты бүлмәдә унике карават. Шуларның бишесе бик пөхтәләп урын-җир: яңа одеял, ике җәймә, киез, мендәр белән җыелган, һәр карават башында ап-ак сөлгеләр.

Исебез китте. Әллә инде безне иреккә чыгарырга җыеналармы?

Ул гынамы? Форточка ачылды:

– Төшке аш алыгыз.

Сөенечтән әле әйтергә дә онытканмын: бүлмә уртасында озын өстәл, өстәл тирәли – ике эскәмия. Билгеле инде, караватларның, өстәл-урындыкларның аяклары

идәнгә болт белән ныгытылган. Менә шушы өстәлгә ризык килде – зур җамаяк тулы уха. Кечерәгендә солы боткасы. Бер чәйнек чәй, берәр шакмак шикәр. Паёкка исә алты йөзәр граммлы бодай күмәче!

Мондый тәмле уханы, мондый тәмле ботканы, мондый тәмле күмәчне, мондый тәмле чәй-шикәрне минем моннан соң төрмәдә дә, төрмәдән чыккач та һичбер җирдә ашаганым, эчкәнем булмады.

Гаҗәп тантаналы бер сый булды бу Тубылдагы беренче ашыбыз. Сыйланып туйгач, өс-башыбызны салып, апак җәймәләр ябынып ял итәргә яттык. Өнме бу? Төшме?

Изрәп йоклап киттек.

– Торыгыз! Кичке аш!

Сикерешеп тордык. Бу ни бу?! Төн. Кояш сүнгән. Лампочкалар кабынган. Нинди рәхәт йоклаганбыз.

Кичке ашка зур гына җамаяк туп-тулы солы боткасы. Изелеп пешкән, сөтләнеп тора. Бер чәйнек чәй, биш шакмак шикәр. Төшкедән калган яртышар паёк күмәч тә бар иде. Туйганчы ботка ашадык, аннан тәмләп-шикәрләп чәй эчтек. Кайдан килде бу рәхәт?

Кичке аштан соң озакламый тикшерү булды:

– Туксан алты-беренче, туксан алты-икенче...

– Урынында.

Менә шунда гына инде без, үзебезнең исем-фамилияләребезне югалтып, бары тик санга калуыбызны төшендек.

Тикшерүдән соң түшәмдәге лампочка өч тапкыр «күзен кысты».

Отбой.

Без тагын йокларга яттык. Караватта одеял ябынып, башны мендәргә салып йоклавы нинди рәхәт.

4

Гений Измайлович икенче көнне иртәнге чәйдән соң, чират буенча кружкаларны юып, өстәлне сөрткәч, бик җитди кыяфәт белән:

– Беләсезме, егетләр, – диде, – минем башта бер даһи план туып килә. Көне буе монда бот күтәреп яту эш түгел.

– Әйдәгез, егетләр, – дип, яткан урыныннан Николай сикереп торды, – хәзер начальниктан чаңгылар сорап алыйк та Иртеш артына походка китик.

Кемдер көлә башлаган иде, Гений, «күз»гә күрсәтеп,

бармак янады.

– Тсс... Тик тормаган телдә бәла бар, ди. Көләбез дип, карцер режимына эләкмик.

– Үзең башладың. – Ардалион кызарып-бүртенеп ачуланырга кереште: – Синең даһи планыңнан башка да сару кайный.

– Поход – киләчәк эше, – диде Гений, Николайга карап, Ардалионны ишетмәгәнгә салышып. – Анысы да булыр. Ә хәзергә мондый план – расписание тәкъдим итәм. Тыңлагыз...

– Әйдә инде, сузмыйча гына сөйлә.

– Ә сез бүлдермәгез. План мондый: һәр иртәдә – физзарядка. Аштан соң – дәрес.

– Менә бусы даһиларча, инде мәктәпкә йөри башлыйбыз, – диде Ардалион, мыскыллы көлеп.

– Йөрмәскә дә була. Менә шушы бүлмәдә.

– Укытучылар?! – диде Ардалион, һаман каныгып.

– Беренче укытучы – син, физикадан. Ибраһим – шагыйрь, әдәбияттан, Николай – математикадан, Мәхмүт – тарихтан. Ә мин культура тарихыннан лекцияләр укый алам.

– Чыннан да, план гениальный, тик мөмкинлекләребез... чамалырак, – диде Николай, мыек астыннан гына көлеп (ул инде мыек җибәргән иде).

Дөресен әйткәндә, башта мин үзем дә, Генийның бу «даһи планы» эшкә ашуына шикләнеп, башкалар төсле көлеп караган идем. Ләкин көйләнде бит.

«Дөнья культурасы тарихы» буенча беренче лекцияне Гений Измайлович үзе башлады. Буйга кечкенә, гәүдәгә тулы, йөзе нурлы, борынгы грек скульптураларына охшаш матур сынлы (ярыйсы ук зур «тубал» баш). Ул, өстәл янына килеп басып, бик җитди кыяфәт белән:

– Иптәшләр, без тыңлаячак лекцияләрнең кереш темасы... – дип, профессорларча вәкарь белән сөйли башлагач, колакларыбыз торды.

– Кара әле, тубалбаш, сине юкка гына Гений дип атамаганнар икән, – аркасыннан кагып, Мәхмүт аны мактап та алды.

Беренче лекция тирән эчтәлеге белән барыбызга да ошады.

Икенче көнне «кафедра»га Ардалион чыкты. Матема-

тика тарихыннан башлады. Аннан Мәхмүт, Николай, мин...

Шулай итеп, безнең биш факультеттан торган университет эшли башлады.

Уянгач ук – физзарядка. Аннан барлау. Иртәнге аш. Аннан соң барыбыз да өстәл янына тезелеп утырабыз. Бары тик конспект язар өчен кәгазь, карандаш кына юк. Лекция – төшке ашкача. Аннан соң ирекле уеннар. Мәхмүт ипидән бик матур итеп шахмат сыннары эшләде.

Уеннан соң уку. Төрмә китапханәсе бик бай икән – барлык классиклар да бар. Кичке ашка хәтле һәр кеше үзе яздырып алган китапны укый. Аштан соң – әңгәмә.

Башта һәркем чират белән үзе укыган китабының кыскача эчтәлеген сөйләп чыга.

Ә аннан соң – «Истәлекләр кичәсе». Кем нәрсә сөйли. Монда инде беренче мәхәббәт тә, беренче өметләр дә, мәзәкләр дә. Җаның ни тели – барысы да... Ассортимент киң...

– Сезнең җәйге таңда сандугач сайраганын тыңлаганыгыз бармы? Гаҗәп бит ул. Никадәр моң! Никадәр виртуоз маһирлык. Йөрәк эри... Күңел дулкынлана, ташый. Онытыласың, илаһи бер диңгездә йөзәсең. Барлык кайгыларың онытыла. Шатлык били сине. Менә шундый сихерле моң ул таң алдындагы сандугач сайравы. Минем Зифам да шулай җырлый, сандугач булып сайрый. Менә нинди җырчы ул минем Гөлзифам.

– Бераз арттырмыйсыңмы?

Ардалион әйтеп тә бетермәде, Гений – аның колак төбенә шап бар көченә... Селёдка Ардалион шундук авып китте. Без ни әйтергә, нәрсә эшләргә дә белмичә калдык – кайсын әрләп, кайсын якларга?

Гений кызарып, еларга җитешеп урыныннан торды да тәрәзә янына барып басты.

– Генка, гафу ит, мин бит шаярып кына... Зифа Басыйрованың чыгышларында мин булдым, яхшы җырлый. Ә син шундук колакка. Әле дә авырта. – Ардалион, кыпкызыл булган колагын сул кулы белән каплап, уң кулын Республиканецка сузды: – Әйдә, килешик. Бигрәк кызу канлы икәнсең.

Республиканец кулын бирмәде, кискен бер хәрәкәт белән борылып, ашыгып атлап, камераның икенче башына китте. Үзе мыш-мыш килә.

Могҗиза булмый диләр. Юк, була икән. Үзем күрдем, ышандым. Менә үзегез чамалап карагыз әле: бу хәл могҗиза түгелме? Нәкъ менә шул төнне изрәп йоклап киткән генә идем, кемдер тарткалый:

– Тор әле, тор тизрәк! Әнә, ишетәсеңме, ул җырлый.

– Кем? Кайда? Җылый?

– Юләр! Еламый, җырлый... Тор инде.

Торып утырдым. Иптәшләр дә торып караватларында утыралар. Каяндыр ерактан җыр тавышы ишетелә – татарча моңлы җыр. Бик-бик ягымлы хатын-кыз тавышы:

Төнгә каршы берәү моңлы итеп, Рамай,
Аерылышу көен җырлады.
Тынга калды урман буйлары да, Рамай,
Чишмәләр дә акмый тыңлады...

– Уф Алла, – Гений тавышланып көрсенде, – Зифа... Зифа җанкисәгем җырлый бит.

Төрмә ныгытмасы аръягындагы шәһәр мәйданына куелган репродуктордан искиткеч моң-зар түгелде.

– Акрын... Тавышланма инде... – Мәхмүт, үрелеп, Генийның күлмәгеннән тартты, – дежурныйны китерерсең.

Ә җыр аз гына тынып-өзелеп торды да, мөгаен, Зифа анда, ерак Казанда, радиостудиядә күкрәгенә күбрәк сулыш алуга, тагын канат какты:

Сахраларга чыгып бер сызгырдым, Рамай,
Чапкан печәннәрем кипсен дип.
Безне генә кемнәр каргады икән, Рамай,
Гомерләре аерым үтсен дип.

Гений бер торды, бер ятты – иңрәде. Ә җыр – моңлы көр тавыш аның саен үсте:

Агыйделкәйләрнең яры биек, Рамай,
Күренеп тора Казан каласы.
Шушы аерылудан күрешә алмасак, Рамай,
Гомерлеккә йөрәк ярасы.

Камера эче моң белән, нур белән тулды. Генийның гына түгел, минем дә, билгеле инде, камерадагы башка иптәшләрнең дә күзләренә яшь тулды. Кайнар яшь. Сагыш. Үзем уйлыйм: Гений бәхетле. Бәхетле! Аның сөйгән яры бар. Ул аны онытмый, сагына. Өметләнә. Чакыра. Көтә. Сөйгәненең илаһи тавышы Себергә, Тубылга, безнең камерага хәтле килеп җитте... Ә минем кемем бар? Бердәнбер ышанычым Зәйтүнә хәзер мине чаккан елан

кочагында.

Гений иңрәп идәнгә төште.

Җыр өзелде.

Йозак шалтырады. Чинап, камераның авыр тимер ишеге ачылды. Бусагада – баш надзиратель һәм дежурный. Йөзләрендә кан әсәре юк, иреннәре дерелди.

– Бу нинди фетнә?

– Гражданин надзиратель, – Гений ишек төбенә килеп басты, тотлыкты. – Гражданин... на...чальник... минем хатыным җырчы... Ишеттегезме?

– Камера өч тәүлеккә карцер режимына утыртыла! – диде баш надзиратель, бар тавышына акырып. – Иртәгә иртәнге ашны бирмәгез.

Ишек шалтырап ябылды. Гений, иңрәп-үксеп, урынына егылды.

5

Башта, кизү торучы надзиратель әйткәндә, бу хәбәргә ышанырга да, ышанмаска да белми аптыраган идек.

Хәзер менә бишебез дә өстәл янында утырабыз. Һәрберебезнең алдында бер табак ап-ак кәгазь һәм карандаш. Инде елдан артык кулларыбызга тотканыбыз юк иде төрмә өчен куркыныч бу коралны.

Камера эче тып-тын. Хәтта бер-беребезнең сулыш алуын да ишетәбез. Кул дерелди. Башта уйлар, уйлар, уйлар! Ничек башлап китәргә, нәрсә язарга, нәрсәне калдырып торырга? Рәхәтләнеп күңелне бер ачып җибәрәсе, анда җыелган барлык аһ-зарны түгәсе иде. Ярамый! Ярамый! Ә нәрсә турында гына язарга соң алай булгач?

Әнием әле мин бала чакта ук үлде. Шуның өчен хатны әтигә язам. Менә инде ике ел дигәндә беренче хат. Бу хатны алуга ничек куаныр әткәем. Барлык туганнарга йөгереп йөреп, хатны күрсәтер. Бер көн эчендә бөтен Күкчәтау исән булуымны ишетеп сөенер.

– Ибраһим, кара әле, – Мәхмүт, хатын язып бетереп, миңа борылды. – Син ничек уйлыйсың, бу хат Казанга ничә көндә барып җитәр икән, ә? Апама яздым, әнкәем күптән үлде бит.

– Ничек әйтергә, минемчә, берәр атна үтәр.

– Нигә бер атна? – Ардалион, хатын борын төбенә китереп (ул начар күрә, калын пыялалы күзлек киеп йөри), кабат укый-укый сүзгә катышты: – Нигә атна? Атна озак.

Әйтик, Тубылдан Төмәнгә бер көн. Аннан поезд белән...

– Җүләр. – Николай, язудан туктап, башын күтәрде: – Син әле һаман иректәге сыман уйлыйсың. Бу төрмәдә бер генә камера түгел... безнең камера гына туксан алтынчы, исәпләп кара.

– Син, Николай, артык пессимист. – Ардалион, хатын өстәлгә куеп, кызып бәхәскә ташланды, үз фикерен өскә чыгарыр өчен кычкыра башлады: – Һәрнәрсәгә кара күзлек аша карыйсың!

– Ә син ал күзлектән, әйеме?

– Мин... мин, – Ардалион тотлыга башлады, чак кына күзлеге төшеп китмәде, тотып калды. – Мин бик реальный карыйм. Бу хатлар биш-алты көндә адресатлар кулында булачак. Нигә дисезме? Бу төрмәдә хатны камералар чират буенча язалар. Без, мөгаен, иң соңгылардан.

Форточка ачылды:

– Йә, хатларны, карандашларны бирегез.

Николай хатының читенә бер-ике сүз язды да надзирательгә сузды.

Мин дә хатны, карандашны бирдем. Республиканец, алпан-тилпән килеп, дежурныйга хатын сузды да кире тартып алды:

– Гафу итегез, улыма сәлам язарга онытканмын.

– Җитәр! Вакытыгыз тулды, сәламне киләсе айда әйтерсез.

Надзиратель карандашларны санап, кисеп алып кыскартмаганнармы дип тикшереп, бер-берсенә куеп үлчәп алды да форточканы шап иттереп япты.

– Беләсезме, егетләр, мин Гөлзифага үткән төндә радиодан аның тавышын, моңлы җырын ишетүемне яздым. Барыбыздан да рәхмәт, дидем.

– Булдыргансың! – Ардалион Генийның кулын кысты. – Шәп иткәнсең! Зифа, чыннан да, сандугач икән. Аның гүзәл тавышы әле дә колагымда...

6

Белмим нигәдер, Яңа ел якынлашкан саен, күңел иләсмиләс килә. Әллә ниләр уйлыйсың, әллә никадәр өметләр өясең аңа. 1938 ел туар алдыннан Пләтән төрмәсендә дә күңел шулай җилкенгән иде бит... Нигә начарга юрарга? Кем белә, 1939 ел кинәт өр-яңа, якты, сөенечле ел булыр. Бәлкем, иптәш Сталин Яңа ел котлавында: «Безнең илдә

нахакка төрмәдә утыручылар булырга тиеш түгел! Тикшерегез!» – дияр, һәм 1939 елда барча гаепсез мәхбүсләр иреккә чыгарлар. Ниһаять, хакыйкать өстенлек алыр, явызлык, ялган ялалар җимерелер.

Өметләнәбез. Укыйбыз. Яңа ел кичәсенә номерлар әзерлибез. Мәхмүт – җыр, Гений – шигырь, Ардалион – мәзәк, Николай – чуваш җыры. Ә мин яңа бер шигырь чыгарырга тиешмен. Күңелле булырга тиеш ул Яңа ел алды кичәсе.

Нәкъ утыз бере көнне иртәнге чәйдән соң камераның ишеге ачылып, өч надзиратель килеп керде дә:

– Туксан алты-беренче, тиз киен, коридорга чык, – дип боерды.

Аптырап калдык.

– Йоклыйсыңмы әллә, тизрәк!

Мәхмүт, киенеп, һәрберебезнең кулын кысты. Ишеккә атлады:

– Хушыгыз, иптәшләр.

Мәхмүт артыннан, караваг саннары буенча, бер-бер артлы Ардалион Нижегородцев, Гений Республиканец, Николай Акимов күрешеп чыгып киттеләр. Кая? Билгесез. Төрмәдәге иң газаплы җәза, – мөгаен, менә шушы билгесезлек. Алып чыгалар, алып китәләр, кая икәнен әйтмиләр. Мәхбүс телгәләнә – нинди язмыш алда?

Менә бу юлы да елдан артык бергә булган, үзләренә бертуган сыман ияләшкән дүрт дустымны кинәт каядыр алып киттеләр. Тагын күрешербезме-юкмы? Күрешсәк – кайда?

Нинди авыр газап бу – билгесезлек. Шалтырап, чинап ишек ачылды:

– Туксан алты-бишенче, чык!

Соңгы тапкыр зур, якты камерада бушап, үксезләнеп калган биш караватка карадым да, күзләремә яшь тулды.

7

Озынлыгы өч, киңлеге ике метр чамасындагы камера. Тәрәзә юк. Тәрәзә урынына югары почмакта түшәм кырыенда форточка хәтле генә бер «күз» – эченә тимерчыбык челтәр калдырып коелган соргылт пыяла. Аннан кояш нурлары да үтеп төшә алмый, бары тик соргылт бер шәүлә генә төсмерләнә. Камераның сул почмагында

цементтан катырылган берсе биек, берсе тәбәнәк тумба. Биеге – өстәл, тәбәнәге – урындык. Ишек төбендә параша. Ә ятагы кайда соң бу хөҗрәнең? Каранам. Уң як стенаның түбәнге өлешендә ниндидер уем һәм тимер ятьмәләр. Кинәт түшәмдәге электр лампасы өч тапкыр күзен кысты, теге уем эчендәге ятьмәләр сикереп идәнгә төште – ятак пәйда булды. Өстендә – киез, мендәр, одеял. Шундук ишектәге форточка ачылды.

Надзиратель:

– Йокла! Башыңны ачык калдырып, чалкан ят. Кагыйдәне бозучы карцерга ябыла. Өч яктылык сигналы бирелгәч, тор. Тиз тор. Карават автомат рәвештә җыела! Ят! – дип акырды.

Мин, тиз генә чишенеп, яңа урынга яттым. Арылган. Көне буе әле бер камерага, әле икенчесенә кертеп, озак-озак тотып тинтерәткәннәр иде. Әмма күзләремне чытырдатып йомсам да йоклый алмыйм.

Әле иртән генә без бишәү идек. Бергәләп Яңа елны каршыларга, «концерт» бирергә әзерләнә идек бит. Сез кайда, дуслар? Сез дә хәзер, минем кебек, бу цемент ләхеттә йоклый алмый газапланасызмы?

Ә Яңа ел? Ул кайда? Уздымы? Килеп җитмәдеме? Одеялны башымнан уранып, камераны күрмәскә тырышып уйга чумдым.

Нинди булырсың икән соң син, яңа 1939 ел?

– Шак-шок.

Сикереп тордым. Форточкада надзирательнең ачулы чытык йөзе:

– Нигә тәртипне бозасың? Нигә башыңны урап яттың? Тәртипне тагын бер бозсаң, карцер! Ят!

Шак-шок, шак-шок.

Коридорда йөргән дежурныйның дагалы итеге. Бер ераклаша, бер якынлаша. «Күз» ачыла. Ябыла. Тагын шак-шок. Шак-шок.

8

Дүрт якта да сары таш стена. Кояш нурлары төшми. Иптәшләр дә юк. Таш капчык. Мин япа-ялгыз. Нишләргә? Аптырагач, авыз эчемнән генә җырлыйм:

Уйлый күңелем, уйлый күңелем,
Уйлый күңелем барсын да;
Уйлама, күңелем, барсын да,

Син уйлап шашарсың да.

Чыннан да, болай беркемне күрми, беркем белән сөйләшми, көне-төне япа-ялгыз утыра, уйлана торгач, акылдан язу да ерак түгел. Нишләргә? Аптырагач, ишекле-түрле йөри башлыйм. Дүрт адым алга, дүрт адым артка – шулай баш әйләнгәнче. Күз аллары караңгылана башлый. Тумбочкага утырам. Карават стенадагы уем эчендә. Ул үзенең расписаниесен бозмый – кичен төшә, иртән күтәрелә дә стена эченә кереп ябыла – көн буена. Унсигез сәгать тумбочкада утырырга кирәк. Утырасың – әллә көн, әллә төн. Түшәмдәге лампочка гел чекерәеп тора. Каршыда – тимер ишек. Анда форточка һәм «күз». Форточка тәүлегенә өч тапкыр – иртәнге, төшке, кичке ашны – баланданы биргәндә ачыла. Тагын арлы-бирле атлый башлыйм. Хат барып җиттеме икән, ә? Куанганнардыр. Куанмыйча, мин бит әтинең бердәнбер улы. «Улым, инде син укы. Тырыш. Кеше бул!» – дигән иде ул, мин Күкчәтаудан Казанга укырга киткәндә.

Тырыштым. Казан педтехникумына кердем, иске-москы киеп, ачлы-туклы йөрсәм дә, лекцияләрне калдырмадым. Мине әле техникум комсомол комитетының (меңнән артык комсомол) секретаре итеп тә сайладылар. Ул эшне дә кулдан килгән кадәр тырышып алып бардым. Алдынгы, тырыш комсомол дип, партия сафларына алдылар. Әүвәлгедән дә җәһәтрәк йөгерә-эшли, укый башладым. Техникум бетерүгә, өлкә комсомол комитеты мине (беренче секретаре бичара Мәхмүт Баһаутдинов иде) Акташ районына, иптәш Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» мәкаләсе чыкканнан соң, ялгышларны төзәтергә, колхоз оештырырга җибәрде. Илтән-Бута авылында балалар укыттым һәм колхоз оештырдым. Кулаклар мәктәпне яндырдылар. Төнлә тәрәзәдән аттылар – чак кына үлемнән калдым.

Тагын Казан. «Яшь ленинчы», «Кызыл яшьләр», «Пионер каләме» редакцияләре. Шигырьләр. Хикәяләр. Беренче китап, икенче китап басылып чыкты. Кызыл Армия. Пединститут. Әти җаным, мин, нәкъ син әйткәнчә, кеше булырга тырыштым. Көннән-көн күтәрелә, үсә бара идем бит...

– Әй, балыкчы! – Форточка ачылгач, сискәнеп, ая-

гүрә бастым. – Ха-ха! Балык тота идеңме? Туры утыр!

Форточка шап итеп ябылды. Уйларым таралды. Тагын утырдым. Стенадагы уемга ябылган урын-җирдән бер җеп асылынып тора. Аптырагач, шул җепне тарта башладым. Сузыла. Тагын тартам – сузыла. Кызык. Теге җепне бармакка урый башладым. «Күз» ачылды да ябылды. Мин һаман теге җепне тартып бармакка урыйм. Бераздан «күз» тагын тиз генә ачылып ябылды. Ә бераздан форточка ачылды. Надзиратель, бармагы белән ишарәләп, мине үзенә чакырды. Пышылдады:

– Нишлисең?

– Бернәрсә дә эшләмим.

– Ничек «бернәрсә дә»? Яле, бармакларыңны күрсәт әле!

Ике кулымны да суздым – җеп тартып, бармакка урап утырганымны онытканмын да. Надзиратель кинәт бал корты чаккандай сикереп китте, тавышланып кычкырды:

– Ә бу? Бу нәрсә?

Форточка шап итеп ябылды.

Бер унбиш минуттан, шыгырдап, чинап тимер ишек ачылды. Гаҗәп! Ул иртә-кичен генә ачыла иде.

– Киен!

Бушлатны, бүрекне кидем.

– Чык! Кулларыңны артка куй, марш!

Караңгы коридор буенча бераз атлагач, яңа әмер:

– Тукта!

Туктадым. Алда – баскыч. Бер надзиратель минем алга төште. Бу – саклык чарасы. Мин баскычтан ташланмасын өчен.

– Марш, аска!

9

Күзләремне озак-озак итеп йомып-ачып, йомып-ачып карадым – берәр нәрсә күренмәс микән? Юк, тычкан күзе хәтле дә яктылык шәйләнми. Дөм караңгы. Шулай да тикшереп карарга кирәк – мин нинди капчыкта? Стена буйлап капшанып, аякларны акрын гына шудырып-шудырып, алга таба үреләм. Үзем куркам – алда су тулы баз булып төшеп китмим! Кем белә нинди мәкерле карцерга китереп тыгуларын. Уйлап та өлгермәдем, сул аягым каядыр төшеп китә язды, тартып алдым. Йөрәк дөп-дөп итә. Тез буыннарым калтырый

башлады. Бераз артка чигенеп хәл җыйдым. Аннан тагын «сәяхәт»не башладым. Бая төшеп китә язганым бер чокыр гына икән. Аны уздым – каршы стена! Ниһаять, монда бераз торып тынычлангач, идәнгә бөгелдем – берәр утыргыч юк микән, йөри-йөри арылган. Өстәвенә күңел тынычсызлыгы. Идән – боз. Карцер идәнен тезләнеп йөреп чыктым – урындык юк. Бастым. Нишләргә? Утырасы иде. Тагын капшана башладым. Чү! Бу нәрсә?! Ике кулым белән капшап тикшерә башладым – карцерның түр почмагында, түбәндә – уентык. Утыргыч. Ниһаять, утырдым. Инде бер тынычлап ял итим. Каяндыр җил өрә сыман. Өшетә башлады. Бер дә кеше утырмаганга суыктыр – цемент бит. Утырам. Утыргыч бер дә җылынырга уйламый – өшеткәннән-өшетә генә бара. Өрә, җил өрә. Кайдан? Тирә-якны капшыйм – берәр ярык-тишек юкмы? Юк. Ә җил өрә. Аптырагач, торып, урындыкны капшый башладым. Тишек. Стенада нәкъ утыргыч турысында торба сыман тишек. Менә кайдан җил өрә икән. Әйе. Яңа төшендем бу хикмәткә. Бик акыллы эшләнгән. Урындык бар – утыра алмыйсың. Җил. Суык. Бу тишек тә төрмә хезмәткәрләренең бер яңалыгыдыр. Артык арыган, йончыган булсам да, суык җил утыргычтан куып торгызды. Дер-дер киләм. Торып, карцер буенча арлы-бирле әйләнә башладым.

Башта өер-өер уйлар. Очы да, кырые да юк. Саташып авыргандагы кебек куркыныч уйлар. Хәтта күз алдында ниндидер хәшәрәт күләгәләр авыша кебек. Юк! Юк! Ничек тә бу уйлардан арынырга кирәк.

Әллә күпкә,
Әллә бик озакка,
Ахры, мәңге оныта алмамын
Тамбов урманнары уртасында
Усак яфраклары шаулавын...

Күңелдән, әз генә пышылдап, Такташның «Мокамай» шигырен сөйли башладым. Тынычланып киттем. Уйлар таралды. Тагын-тагын Такташны исемә төшерәм.

Белмим, күпме вакыт үткәндер, телем әйләнми башлады, аякларның хәле китте – стенага тотына-тотына, теге тишек урындыкка барып лык итеп утырдым. Карцерның ишеге ачылды. Дежурный:

– Чык! – дип боерды.

Чыктым. Надзиратель мине коридор буенча ишегалдына алып чыгып китте. Әллә инде камерага кайтара?

Юк, ләгънәт төшкере, икенче якка борды. Эңгер-меңгер. Әле генә кар явып үткән. Хуш ис! Яңа кар исе. Рәхәтләнеп сулыйм...

– Тукта!

Туктадым. Каршыда карцер корпусының бер як стенасына бастырып-төреп куйган табутлар. Болай да өшеп торган тән чымырдап китте – нигә дип бу табутлар янына китерде соң мине дежурный? Боерык:

– Менә шуларның берсен күтәр дә камерага!

Читтәге бер табутка килеп тотындым. Ярыйсы ук авыр – калын, чи тактадан эшләнгән. Каһәр төшкерене көч-хәл белән карцерга өстерәп кергәч, ишек ябылды. Отбой. Йокларга! Аска да, өскә дә, баш астына да – бер бушлат. Шулай булгач, аны салып тормадым, киенгән килеш кенә, табут эченә кереп сузылдым. Ичмасам, монда тере килеш ятып хәл җыйыйм. Йокы ястык теләмәс, диләр бит. Күзләремне йомдым. Дер-дер киләм. Баягыдан да көчлерәк туңа-калтырый башладым. Астан суык килә. Ята торгач, такта җылыныр дигән идем. Юк, һаман өрә. Аптырагач торып утырдым. Табутның төбен капшый башладым – бу ни бу? Исем китте. Табутның төбендәге такта тишек-тишек. Гаҗәпләнеп тишеккә бармак тыгып карыйм – йомычка. Яңа төшендем суыкның кайдан килүен. Барысы да бик акыллы эшләнгән. Бу ястык ике төпле икән. Арасына йомычка тутырылган. Ул, көнозын тышта торып, суык җыя, ә монда керткәч, шул суыкны чыгара... Менә шундый ястыкта йоклап кара.

Өченче тәүлек дигәндә, мине төрмә башлыгы кабинетына китерделәр.

– Сез – йөз алтмыш сигезенче тоткын, – диде өстәл артындагы тирән креслога утырган түрә, ниндидер кәгазьләргә кул куя-куя, башын күтәрми генә, – төрмәнең эчке кагыйдәсен бозган өчен өч тәүлеккә карцерга ябылган идегез, срок тулды. Мин сезне чыгарам. Ләкин карагыз аны, тагын да тәртипне бозсагыз, моннан да катырак җәза кулланырмын. Төшендегезме?

– Төшендем.

– Алып китегез.

Үземнең йөз алтмыш сигезенче икәнемне белеп, камерама кайттым. Кара, нинди якты, нинди иркен икән минем бу куышым.

10

Иртәнге чәйдән соң шәфкать туташы күренә башлады. Билгеле инде, ул ялгыз гына түгел, йөзен чыткан надзиратель янында күләгә булып басып тора.

Форточка нибары ике-өч минутка гына ачыла. Менә шушы минутлар – хәзер минем өчен иң кадерле, иң сөенечле минутлар. Бу минутларда мин барлык кайгы-хәсрәтемне, хәтта үземнең төрмәдә икәнемне дә онытам, камерам кинәт яктырып, балкып китә. Изге минутлар! Форточка ачыла да ябыла. Шатлык сүнә. Камера караңгылана. Мин тагын егерме дүрт сәгать шул изге могҗизаны көтеп, өметләнеп яшим. Нинди бөек көч икән ул сагыну, көтү, өметләнү!

Бары тик ике-өч минут. Әмма аларда никадәр илаһи көч һәм тылсымлы канатлар...

Һәр иртәдә паёкны икегә сындырып, яртысы белән бер кружка чәйне эчәм дә ишек янына басып көтә башлыйм – җаным, тәнем белән көтәм. Тыңлыйм. Менә коридор башындагы ишек ачылып ябылды. Керделәр. Ике кеше. Берсе дөп-дөп итеп тупас атлый. Икенчесе – нәфис. Тык-тык итеп җырлап килә. Алар бераз киләләр дә туктыйлар, киләләр дә туктыйлар – күрше камераларга. Тагын дөп-дөп. Тагын тык-тык. Менә алар тынып калдылар.

Надзиратель форточканы ачты.

Менә ул зур соргылт күзләр. Бик нәфис, бит алмалары алсуланып торган түгәрәк йөз. Алсу иреннәр һәм гаҗәеп бер елмаю. Ул якты да, татлы да, тылсымлы да.

– Хәерле иртә!

Нинди ягымлы, иркәләүче саф тавыш. Әйтерсең лә көмеш кыңгырау чыңлады.

Мин рәхмәтемне әйтеп бетерергә өлгерә алмыйм, тагын тылсымлы чың:

– Берәр җирегез авыртмыймы?

Менә шушы мөкатдәс минутларны бик азга гына булса да сузарга тырышып, мин тәүлек буе әзерләгән «авыруларым»ның берсен – көн дә бер үк чирне атап булмый ич – әйтергә ашыгам:

– Тамагым авырта... төн буенча йөткереп чыктым. Әһе-әһе.

Ул, аптечка сумкасын форточка капкачы-өстәленә куеп, даруларны эзли. Мин аның йөзенә карап туя алмыйм

– сокланам. Ул буйга артык озын түгел, башы нәкъ форточка биеклегенә туры килә. Шуның өчен һәрвакыт туп-тулы бөтен йөзе белән күренә. Ә аның белән беррәттән торган дежурный озын буйлы. Камераны күрер өчен, аңа бөгелергә туры килә. Бөгелү –эш, шуның өчен дежурный үзен артык «мәшәкатьләми» – бөгелми. Миңа бит шул гына кирәк.

– Мәгез, – нәфис бармаклар миңа ачык пакетта порошок суза, – эчеп җибәрегез.

Мин, пакетны алып, порошокны авызга салам да кәгазьне кире дежурныйга бирәм. Менә шуның өчен дә шәфкать туташы янында дежурный йөри – мәхбүс кулында кош теле хәтле дә кәгазь калдырырга ярамый. Шарт итеп форточка ябыла.

Ә камерада никадәр хушбуй исе, яктылык, нур кала... Мин, сихерләнгән кеше кебек, ишек яныннан китә алмыйча торам.

Иртәгә тагын килер микән?

Минем өчен иң авыр, газаплы көн – якшәмбе. Якшәмбе – ял көн. Иртәнге чәйдән соң инде гадәттәгечә форточка ачылмый. Мине караңгы уйлар баса. Үземне кая куярга белми өзгәләнәм. Акылдан шашармын дип куркам ул дәһшәтле якшәмбеләрдә. Дөньяда иң авыр газап сөйләшмәү икән. Бу камерага кучүнең беренче көннәрендә мин әле бу дәһшәтне сизеп бетермәгән идем. Ә хәзер көннән-көн баса. Ялгызлык. Бер кешене күрмәү, беравыз сүз алышмау. Ичмаса, надзирательләр дә сөйләшмиләр.

Бу кабер тынлыгы, ялгызлык кайчанга хәтле сузылыр? Бер ай? Өч ай? Бер ел? Ун ел?

Юк! Юк! Ун ел бу ләхеттә түзә алмам, акылдан шашармын! Шашармын!

Менә шушы фаҗигале язмышта зур соргылт күзле кыз! Ул – фәрештә! Ул – мине дөньяда яшәргә өндәүче бердәнбер изге көч! Мин аны көтәм һәм аның күренүенә юанып кына яшим... Ул килер. Ул елмаер. Ул миңа «хәерле иртә» дияр. Һәм кәсә тулы женьшень шәрабы – әбелхәят суын бирер. Мин йотылып эчәрмен бу күзгә күренми торган илаһи шәрабны!

Ниһаять, китап укырга рөхсәт иттеләр. Көне-төне укыйм.

Тормышымда тагын бер яңалык – шигырь ятлау. Пушкинның «Евгений Онегин» поэмасын күңелгә биклим. Иртә белән чәйгә хәтле бер бүлеген әкрен генә сөйлим. Төштән соң тагын бер бүлеген. Шулай һәр көн. Поэманы сөйләп бетергәч, яңадан башлыйм. Дөрес, берничә тапкыр надзиратель:

– Йөз алтмыш сигезенче! Кисәтәм, тавышланмагыз! Карцер! – дип бармак янады.

Нишлим. Карцер булса карцер. Анда да укырмын.

– Хәерле иртә!

Менә шушы шәфкать туташы күренә башлаган көннән башлап үземдә гаҗәп бер үзгәреш сиздем. Иртә белән автоятактан сикереп төшүгә, элеккедәй йокымсырап утырмыйм – гимнастика белән шөгыльләнәм. Юынырга чыккач та, элекке кебек, битне арлы-бирле чылату белән канәгатьләнмим, чын-чынлап сабынлап юынам, тешләремне дә чистартам. Гимнастёрка белән чалбарымны да киез астына җәеп үтүкли башладым...

11

Көтмәгәндә тагын бер бәхетсезлек. Бар таянычым, юанычым китап иде. Аннан да аерылдым.

Бүген, бәхетсезлегемә, катырак йоклап киткәнмен – лампочка күз кысканны сизмичә калганмын.

– Нигә ятасың?! – дип, надзирательнең акыруына атылып-бәрелеп тордым да, тумбочка өстендәге чалбарны алмакчы булып, күзлегемне цемент идәнгә төшереп җибәрдем. Челпәрәмә!

Хәзер күзләрем кызарып китте. Уку түгел, күтәрелеп тә карый алмыйм – яшь ага.

– Хәерле иртә.

– Рәхмәт.

– Сезгә ни булды, һаман түбән карыйсыз?

– Ялгыш күзлегемне ваттым. Хәзер күзлексез карый алмыйм.

– Алайса, мин сезне күз врачына язам.

Форточка ябылды.

Тумбочкага утырдым. Күзләрем кырып, чәнчеп авырта, яшь ага. Йа Алла, бу нинди газап тагын...

Шул ук көнне төшке аштан соң надзиратель мине икенче корпустагы күз врачына алып барды. Врач, күзләрем-

не карап, күзлек алырга рецепт язды да кырыс кына:

– Счётыгызда акчагыз бармы? – диде.

– Юк, – дидем, аптырап һәм борчылып.

– Һәрбер арестантка күзлек алып бирергә төрмә приют түгел. – Врач, маңгаенда янып торган ялгыз «күзен» салып, ачу белән эндәште: – Төшендеңме?

– Әйе.

– Алып китегез!

Мин Александр Марлинскийның (Бестужев) Себер төрмәләрендә, Кавказда язган хикәя, романнарын, бигрәк тә «Амалотбек» романын кызыксынып укый идем. Бу әсәрләр миңа ничектер якын, сердәш. Бәлки, аны язучының да минем төсле мәхбүс булуы тәэсирне көчәйткәндер. Пләтән төрмәсендә Алкиннан өйрәнеп калган «Бестужев әлифбасы» әле дә миңа ара-тирә күрше камералар белән бәйләнешергә ярдәм итә бит...

Менә шул бердәнбер сердәш тә хәзер әнә укылмыйча ята. Укыйсы килә, китапны алып, күзләремә китерәм – томан. Яшь ага, кыра. Сызлый.

12

Форточка ачылды. Теге йомшак, нәфис тавыш:

– Сез күзлек алдыгызмы?

Күзләремнең авыртуына чыдый алмый, сөлге белән башымны урап утыра идем, сикереп тордым – сөлгем төшеп китте.

– Юк. Счётымда акча юк бит.

Зур соргылт күзләр миңа текәлде. Нәрсәдер әйтергә теләгәндәй, бик серле итеп, яратып, пошынып карады алар миңа.

Форточка ябылды. Күзләремнән мөлдер-мөлдер яшь ага башлады. Әллә авыртканга, әллә...

Әтигә хат язганга инде бүген сиксән алтынчы көн, һаман җавап юк. Нигә икән? Әллә адресны дөрес язмадыммы? Алай булса, мин бит Күкчәтауга Сафа абзыйлар адресына яздым. Ул өйдә туганнарның берсе булмыйча булмас. Әллә? Әллә инде... Юк! Юк! Нигә алай начарга юрыйм. Бәлки, инде хат килгәндер, төрмә өстәлендә алганны көтеп ята торгандыр. Хат белән, бәлки, аз-маз акча да җибәргәннәрдер. Күзлек алырга. Менә әйбәт булыр иде.

Шулай беркөнне төшке аштан соң форточка ачылды да, баш надзиратель миңа ниндидер кәгазь сузды. Мөгаен, хат! Сөенечемнән егылып китә яздым.

– Сезнең лицевой счётка илле сум акча килде. Әгәр эчке тәртипне бозмасагыз, аена ун сумлык ашамлык, тәмәке алдыра аласыз. Менә карандаш. Кирәк әйберләрегезне бу бланкка языгыз.

Форточка шап итеп ябылды. Кәгазь, карандашны тоткан килеш катып калдым – өнемме, төшемме? Тагын форточка ачылды:

– Нәрсә карачкы сыман басып торасың? Бир бланкны, карандашны.

Шунда гына исемә килеп, бер генә сүз яздым да бланкны, карандашны надзирательгә кайтарып бирдем. Йа Алла, теләгем кабул булган. Хатым барып җиткән! Камера буенча әйләнәм, йөгерәм, сикерәм.

– Йөз алтмыш сигезенче! Тәртипне бозмагыз.

– Юк-юк! Зинһар, мине заказымнан мәхрүм итмәгез. Мин шатлыгымнан.

– Утыр!

Утырдым. Тын да алмыйм.

13

Күзлекне бер киям, бер салам. Әле ишеккә, әле түшәмгә – лампочкага карыйм... «Амалотбек»ка күз салам. Күрәм, күзләрем авыртмый. Укыйм! «Әти җаным, сиңа мең-мең рәхмәт. Мине иң авыр газаптан коткардың. Рәхмәт! Тик менә нигәдер хатыңны бирмәделәр. Бәлкем? Тукта, син бит бары гарәп хәрефләре белән генә язасың. Шуңа күрә аны, конспирация дип, утка якканнардыр. Алай да син инде исән икәнлегемне беләсең. Мин дә тере икәнеңне беләм һәм бәһасез бүләгең өчен сөенәм – башым күккә тия. Яшә, әти җаным!»

Форточка ачылды.

– Ничек күзләрегез, авыртмыймы?

Көлеп җибәрдем. Бу камерага күчкәннән бирле беренче тапкыр форточкадагы гүзәл кыз да елмайды. Апак энҗе тешләрен күрсәтеп, ягтырып елмайды. Йа Алла, мондый да гүзәл җан булыр икән дөньяда!

– Җитәр! – диде безнең елмаю-көлүне күреп тырпайган надзиратель. – Утыр!

Форточка ябылды. Камерада яктылык, көләч елмаю калды.

Нинди илаһи кыз бу шәфкать туташы. Үзе сылу, күзләре сылу, иреннәре сылу. Күңеле сылу. Әнә күз врачы. Ул да медицина әһеле. Ә үзе аю кебек акырып тора. Сүзләре – ук. Ә бу кызның һәр сүзе, һәрбер авазы – кәсә тулы терек суы. Аның «хәерле иртә» дигән бер генә сүзе дә тәүлек буена көч, егәр, өмет өсти.

Исеме кем икән? Вера? Надежда? Любовь? Ничек кенә булса да, аның исеме җисеменә хас матур, яңгырашлы булырга тиеш. Һичшиксез шулай!

Яшә, Вера! Яшә, Надежда! Яшә, Любовь!

Мин сиңа бәхет-сәгадәт телим. Язмышың якты, бик якты булсын. Бәхет кошы сине бервакытта да, бервакытта да ташламасын!

Нигә, нигә синең соргылт күзләр
Күзләремә болай багалар?
Нинди көчләр, сөйлә, әй, аппагым,
Керфек очларыңнан тамалар?

Хөрмәтле Һади абый, син инде мине гафу ит, шигыреңне аз гына үзгәрттем. Синең урман кызың – Әминәң – кара күзле булган. Минем өметем соргылт күзле. Шуның өчен мин кара күзләрне соргылт иттем. Бар юанычым да шул гына бит, ачуланма инде, Такташ абый.

14

– Хәерле иртә! Үзегезне ничек хис итәсез?!

Тагын сагынып көтелгән көмеш кыңгырау чыңлады. Якты, изге күзләр. Чү, алар нигәдер йомылып алдылар төсле. Сул каш нәрсәгәдер ишарәләп сикереп алды түгелме? Кайчандыр кызлар шулай кашлар, керфекләр белән сөйләшә иделәр түгелме? Бәлкем, хәзер дә!.. Шәфкать туташы – өметем – форточканың нәкъ каршына баскан. Ул үзенең нурлы-мөлаем йөзе белән миңа карый. Ә надзиратель – кырыйда, аның усал күзләре бары тик миндә, күршесенә игътибар итми.

Шәфкать туташы форточка өстәле өстенә аптека сумкасын куеп актара башлады һәм, миңа карап, сул күзен кысты:

– Әле дә башыгыз авыртамы?

– Инде өченче төн йоклый алмыйм...

– Яхшы, хәзер мин сезгә анальгин бирәм. – Нәфис

бармаклар сумкадан кәгазь пакетка төрелгән порошок алдылар: – Мәгез. – Сул күз тагын кысылып, баш әз генә иелеп тә алды: – Тиз генә йотып җибәрегез.

Гадәттә, кагыйдә буларак, порошок кабы ачык килеш бирелә. Мәхбүс порошокны шундук эчеп-йотып, кәгазен дежурныйга кайтарырга тиеш. Бу юлы да порошок миңа ачык килеш бирелде. Тоткын сизгер була бит ул, порошок пакетын алуга, бармакларым тойды: кәгазь ике кат!

Кыз юри, ахры, дежурныйга нидер әйтте – игътибарын миннән алды. Шулвакыт мин порошокның аскы кәгазен төшереп җибәрдем, порошокны авызыма салдым, калган капны дежурныйга бирдем.

Форточка шап итеп ябылды.

Аяк тавышлары ераклашуга, идәнгә иелдем, порошок кәгазен алдым – язу! Ишекнең төбенә үк утырып – «күз» ачыла калса, кулымдагы кәгазь күренмәсен дип,– дулкынланып укый башладым. Вак кына хәрефләр: «Боекмагыз. Үз-үзегезне саклагыз. Хаклык килер».

Адымнар! Кәгазьгә тагын бер кат күз йөртеп чыктым да авызыма каптым.

– Нишләп торасың?

– Парашага чыгам.

Күз ябылды. Мин «изге» кәгазьне чәйнәп йотып җибәрдем. «Боекмагыз! Үз-үзегезне саклагыз! Хаклык килер!»

– Килер! Килер! Килер!

– Нәрсә, акылдан шашасыңмы?!

Мин елмайдым, бөтен тәнем җиңеләеп китте.

15

Яшьлек, күксел таулар төсле,
Киткән саен матур, ягымлы;
Томаннарга төренер яшьлегемне
Мин онытмам – кайнар чагымны...

Әллә кайчан инде, Күкчәтауда вакытта язган шигыремнән бу бер куплетны соңгы көннәрдә кат-кат кабатлый башладым. Сагынам. Ярсыйм. Дулкынланам. Миңа инде егерме сигез яшь. Иптәшләрем инде укуларын тәмамлап, өйләнеп, балалар тәрбиялидер. Ә мин?..

– Киен дә чык!

Ишек ачылып, дежурныйның камерага керүен дә сизмичә калганмын.

Зур, якты бүлмә. Дүрт өстәл, һәр өстәл артында ап-ак халат кигән кешеләр утыра. Барысы да ирләр.

Мине кырыйдагы өстәл янына китереп бастырдылар. Өстәлдә бик күп папка-формулярлар. Күзлек кигән урта яшьләрдәге кеше, бер папканы ачып, миңа карамыйча гына сораулар бирә башлады:

– Исем, фамилия, әтиең исеме? Туган ел? Статья, пунктлар, срок?

Барысын әйткәч, папка ябылды. Мине күрше өстәлләргә күчерә башладылар. Нәкъ армиягә алгандагы кебек, анадан тума калдырып тикшерә башладылар. Үпкәне, йөрәкне, күзләрне, колакларны...

Берсе-бер сөйләшми, әйтерсең лә чукраклар. Карыйлар да язалар – ниндидер карточка-бланк тутыралар.

Тагын камерага китерделәр.

Әллә инде армиягә алырга җыеналармы? Мин бит инде өч ел хезмәт иткән кеше. Политрук. Әллә? Тумбочкадан сикереп торып, арлы-бирле йөри башладым. Бәлкем? Бәлкем... безнең болай нахакка төрмәдә утыруыбыз иптәш Сталинга барып җиткәндер дә...

16

Бу ни бу?

Коридорда шыгырдап, чинап камера ишекләре ачыла башлады. Ыгы-зыгы, шау-шу. Кычкырып сөйләшкән тавышлар. Хәтта көлүләр. Ул арада минем камераның да ишеге ачылып китте. Надзиратель, камерага кермичә, бусагадан тыныч кына:

– Чык! – диде һәм тукталмыйча узып китте.

Камерадан чыгуга, зур-зур сакаллы өч кеше мине кочаклап алды, сөякләрне чытырдатып кысалар, үбәләр.

– Сез кем? Сез кем?

– Ә син кем?

– Кара, син нәкъ Карл Маркс шикелле булгансың ич, Ибраһим, сакалың биленә җиткән.

Тагын кочаклаштык. Көчкә таныдым үзләрен. Мәхмүт, Ардалион, Николай.

– Ә Гений кайда? Нигә ул күренми?

Әйтеп өлгермәдем, туп төсле тәгәрәп, Республиканец килеп чыкты, уртабызга ташланды. Күтәреп алдык, чөя башладык.

– Ирек!

– Ирек!

Бу төрмә, аның ярым караңгы коридорлары бервакытта да мондый күңелле шау-шуны ишетмәгәндер, мөгаен. Нинди генә тавышлар юк монда. Көлү, кычкыру, акыру, үкереп елау һәм шатлыклы җыр, ирек турында җыр.

Читтән карасаң, мөгаен, исең китәр иде – барысының да чәчләре җиткән, сакаллары үскән, йөзләре агарган, үзләре акылдан шашкан төсле тавышланалар, коридорның әле бер, әле икенче ягына чабалар, егылалар, кочаклашалар.

Беренче ташкын! Сөенү ташкыны! Монда әле акыл баш була алмый. Монда әле йөгәнсез, тезгенсез хисләр! Хисләр! Хисләр! Башкача мөмкин дә түгел бит. Ярты елга якын кешене күрми, бер кеше белән сөйләшми ләхеттә яткан кешеләр алдында кинәт ишекләр ачылсын да, кинәт бу хәтле халык белән очраш. Бу могҗиза түгелме? Монда инде үлчәү юк, кем күпме һәм ничек кычкыра ала – кычкыра, кочаклый, үбә һәм тыела алмый елый.

Ә менә без, биш дус, бер-беребезне кочаклаганбыз да һич аерыла алмыйбыз. Тәннәребезне капшыйбыз – бу безме? Без түгелме?

Гений, тамагын кырып, көр тавыш белән җырлап җибәрде:

Кузгал, уян, ләгънәт ителгән
Коллар һәм ачлар дөньясы...

Шау-шу тынды. Бөтен коридор бары бер җыр – «Интернационал»ны җырлый башлады.

17

Төрмә ишегалдына чыгуга, башыбызга таш төшкәндәй булды. Тавыш-тын бетте. Йөзләр караңгыланды. Башлар иелде. Әле бер генә минут элек балкыган, канатланган өмет сүнде. Кара болыт каплады безнең күкне. Арестант! Мескен арестант. Син нинди беркатлы сабый! Вакытсыз ачылган камера ишеге дә синең өчен ирек капкасы булып тоелды, ашыгып-ярсып, ирек җырлары җырлый башладың. Канатланып оча да башлаган идең... Ә хәзер? Хәзер алдыңда – ачы хакыйкать: калын таш стеналар. Чәнечкеле тимерчыбыклар. Манаралар. Мылтыгын кулыннан төшерми, туктаусыз әйләнеп-карап торучы сакчылар. Һәм һау-һаулап өрүче этләр.

– Утырыгыз!

Баскан җиребезгә утырдык.

Мәйдан уртасында берничә өстәл. Өстәл өстендә өем-өем папка-формулярлар. Өстәл артында урындыкларга утырган, басып торган, арлы-бирле йөгергән түрәләр.

– Өченче кат, каптёркага!

Бер төркем тоткын, торып, төп корпус янындагы кечерәк бер таш йортка таба атладык. Зур таш келәтнең бер почмагында тау булып эреле-ваклы капчыклар ята. Һәрберсендә бирка. Биркага камера һәм мәхбүснең шифры – хуҗаның «исеме» язылган.

– Бишәр-бишәр кереп, биштәрләрегезне алыгыз, – диде келәт башлыгы.

Чират белән актара башладык. Үткән көзне төрмәгә килеп төшкәч, үзебезнең сәләмәләрне салып, капчыкларга тутырган идек. Аларны монда өйгәннәр икән. Чират миңа да җитте: әллә ничә йөзләгән капчыкны арлы-бирле ташлый торгач, йөз алтмыш сигез саны сугылган кечерәк кенә биштәр дә килеп чыкты. Кирәге чамалы. Алыгыз дигәч кенә алам. Анда рәтле бернәрсә дә юк.

Шулай да, иске булса да, моннан бер ел элек өстеңдә булган әйберләрне күрү кызык бит. Ул киемнәрнең яңа чагы, киеп куанган чак искә төшә. Мин дә, келәтнең икенче бер почмагына китеп, башкалар белән бергә биштәремне актара башладым. Менә күн тужурка. Мин аны Печән базарыннан «Дуэль» повесте гонорарына биш йөз сумга алган идем. Ул сап-сары, ялт-йолт итеп тора иде. Аны беренче тапкыр күргәч, Зәйтүнә: «Бу тужурка сиңа бик килешә», – дигән иде.

Нигә әле аны искә алам, хәерсез? Гимнастёрка, чалбар сатып алынмаган – гаскәрдә узган еллар истәлеге. Ә итек? Нинди әйбәт хром кунычлы иде. Солдат итеген сүттереп, яңадан тектергән идем. Үзе аякларга таман – кысмый да, буш та түгел, галифе чалбар белән бик килешә иде. Зәйтүнә белән танцыга йөргәндә бигрәк тә. Фу, тагын Зәйтүнә! Хәзер итекнең кунычлары җәелеп ята – үрә бастырып тотканда, балтырлар шешкәч, телеп алганнар иде бит...

Чү, шул итекләр эчендә ниндидер кәгазьләр. Берсен күтәреп селкедем – теге кәгазьләр коелды. Хатлар. Мөгаен, өйдән килгәннәрдер! Бирергә өлгермәгән булганнардыр. Куанып, ашыгып беренче хатны кулга

алып, адресын карауга, хәлсезләнеп идәнгә чүктем. Үземнең хат! Әтигә язган хат. Ашыгып икенче итекне селеккәләдем. Аннан да хатлар төште. Минем хатлар! Кыш буенча язылган, җавап китерергә тиешле хатлар!

– Ибраһим, кара әле, синең биштәрдә хатлар бармы? – диде артымда капчыгын актарып маташкан Гений. – Мин... мин... Зифадан хат көтәм...

Ул арада башка иптәшләр дә биштәрләрен күтәреп килделәр – чырайлары сытылган.

– Ичмасам, яндырсалар белмәс идек, көтәр идек... Ә монда, иң әшәке рәвештә мыскыл итеп, үз хатыңны бер елдан соң кулыңа тоттыралар! – диде Мәхмүт, ярсып.

18

Башта гомуми камераларга ябылган мәхбүсләрне егермешәр-егермешәр кешедән машиналарга утыртып озата башладылар. Кая? Билгесез. Әмма тоткын тоя: монда, төрмә мәйданында, барысы да диярлек яшь-таза халык. Димәк, каядыр эшкә җибәрәләр.

– Бер кешелек таш капчыкта утырганнан җир казыганым артык, – диде Мәхмүт, этап икәнен сизгәч.

Мин дә, башкалар да бу фикергә кушылдык. Чыннан да, дүрт стена арасында тилмерүгә караганда, саф һавада, кешеләр белән бергә эшләүгә ни җитә. Әйдә, җәһәннәм чокырына җибәрсәләр дә җибәрсеннәр, тик кире ялгызак камерасына гына бикләмәсеннәр.

Төшке баландадан соң «одиночник»ларны төйи башладылар. Безгә аеруча хөрмәт – «кара козгын» машинасы. Ичмасам, киткәндә Тубыл шәһәрен күреп калырбыз дигән идек, ул өмет тә өзелде...

Июнь башы иде. Сибәләп кенә яңгыр явып үтте. Бераз чыландык. Әмма яңгырдан соң кояш чыкты, һава юылып, яктырып китте. Саф һава. Бигрәк тә тынчу камерадан соң ул безгә җофар исле. Ә шәһәр өстендә аллы-гөлле тасма булып сузылган салават күпере. Аны күрмәгәнгә инде ике елдан артыктыр. Нинди гүзәл син, нинди тылсымлы син, бөек сөенеч күпере! Менә шушы күпер буйлап Күкчәтау далаларына хәтле китәсе дә китәсе иде.

– Тиз! Тизрәк машиналарга!

Иң соңгы булып килгән унбиш «одиночник»ны йөк машиналарына утырта башладылар. Мөгаен, безгә «кара козгын» җитмәгән. Аңа үпкәләмәдек.

Менә нинди икән син Тубыл – Русия арестантларының пайтәхете – декабристлар, Петрашевичлар интеккән шәһәр.

Без утырган зиндан артта кала бара. Ул тау өстендә икән, Казан Кремленә охшаган – биек таш стена белән уратылган. Эчтә – зур-зур корпуслар, хәтта гөмбәзле, алтын тәреле чиркәү! Машинабыз, таудан төшеп, Тубылның зур урамыннан бара. Берәр, икешәр катлы агач өйләр. Нәкъ Күкчәтау шикелле. Тик минем туган шәһәрем тау итәгендә утыра, ә Тубыл – Иртеш буенда. Иртеш хәзер биектән караганда ука тасма булып ялтырый.

Урамның ике ягында, капка төпләрендә халык – картлар, яшьләр, бала-чага. Күрәсең, бөтен Тубыл халкы тоткыннарны озатырга чыккан. Шау-шу юк. Тынлык. Халык зур бер дикъкать белән, сөзеп, безнең машиналарга, йөзләргә карый, кемнедер эзләгән кебек, күреп калырга тырышкан кебек карыйлар, озаталар алар безне... Безнең күзләр дә аларда. Әнә алда – чаттагы өйнең ишеге төбендә, баскычта – бер кыз басып тора. Зәңгәр күлмәктән, зәңгәр яулык-кыекчадан. Йөрәгем дерт итеп китте. Ул да... ул да... Нәкъ шушындый күлмәктән күренә иде бит. Менә ул уң кулын маңгаена, каш өстенә канатландырды – карый. Җентекләп, текәлеп карый сыман...

Машина якынлашканнан-якынлаша бара. Минем бар игътибарым шушы сынга бирелде. Ул түгелме?! Ул! Ул! Йа Алла, чак кына кычкырып җибәрмәдем «хуш, хуш!» дип. Менә безнең карашлар очрашты. Кыз башындагы зәңгәр кыекчасын йолкып алып селкеде. Машина аны тузан белән күмеп узды...

Пристаньга килеп туктадык. Безне нindидер бер иске, кара майга буялып беткән баржаның трюмына төшерделәр. Озакламый, чайкалып, баржа кузгалды, безне каядыр алып киттеләр. Трюм эче тып-тын булып калды. Без дә уйга чумдык.

– Син безне кая, нинди язмышка алып барасың, Себернең бөек чал елгасы Иртеш? Кая?

КОЯШ БАЕГАНДА

Кайвакыт анда челпәрәмә килеп кыйралган салават күперенең хәрабәләре балкый. Кайвакыт ниндидер бихисап зур тылсымлы кала ялкынланып ала. Ә кайвакыт...

Ничек кенә булмасын, һәр көнне кояш үзенә хас бер тантана белән байый. Әмма бу тантанада һәрвакыт ниндидер олы бер сагышның шәүләсе ята. Нинди сагыш икән ул? Мөгаен, аерылышудыр. Һичшиксез, шулайдыр. Чыннан да, аерылышудан да газаплырак сагыш бармы икән бу дөньяда? Бармы икән?

Кояш, көнозын иркен күктә йөзеп, Җир шарын яктырта, җылыта, аны зөбәрҗәт яшел үсемлекләр белән, аллыгөлле чәчәкләр белән бизи. Ә аннары? Аннары ул, Җир шарын ташлап, каядыр еракка – офык артындагы мохиткә китә. Бата. Югала. Менә шуның өчен, ахрысы, кояш, офыкка якынлашкан саен, аерылышу минутлары җитә барган саен сүрәнләнә, моңаеп кызара башлый. «Шәфәкъ елый, хәерлегә генә булсын инде», – ди торган иде мәрхүмә әнкәм, кояш баеган якка карап дога укый-укый.

Мин үзем дә балачактан ук кояшны озатып калырга яратам. Озак, бик озак торам мин ул сагышлы тантананы карап. Уйга чумам. Бигрәк тә нахак рәвештә тоткынга эләккәч, кояш белән бергә баеган, еракта калган гомер искә төшә. Һәм эчтән генә «Зәңгәр шәл» көен шыңшыйм. Кычкырып җырларга тавышым юк.

Ал яулык, зәңгәр шәл,
Үтә гомерем бигрәк җәл...

Менә хәзер дә нәкъ шундый шәфәкъ баеган сагышлы чак иде. Әмма, кояш сүрелсә дә, вагон эчендәге эсселек сүрелми. Киресенчә, көнозын кояш күзендә кызып барган вагон хәзер үзенең бар кызуын эчкә өрә һәм шуның өчен монда чамасыз ягылган кара мунчадагы төсле эссе, тынчу. Вагонның ике ягына корылган аслыөсле сәкеләрдә билдән ялангач кырык мәхбүс лычма тир эчендә. Җитмәсә, вагон ярыкларыннан тузан тула. Сулыш алып булмый. Тоткыннарның күбесе – урын тапканнары, сәкеләрен ташлап, идәндә ауный. Мин дә идәндә, ишек кырыенда, бозга ташланган балык төсле чәбәләнәм.

Шулай җәфаланып ятканда, өске сәндерәдән кемдер кычкырып җибәрде:

– Байкал! Байкал!

Салкынча, дымсу җил кагылды. Вагон эче җиләсләнеп китте. Барыбыз да сикереп торып, тимер рәшәткә белән челтәрләнгән форточкаларга өерелдек. Бу ни бу? Башта үз күзләребезгә үзебез ышанмыйча, имәнеп калдык –

могҗиза. Чыннан да могҗиза – алсу дулкыннар. Биек таш кыя таулар итәгеннән бормаланып барган эшелон алдында – офыкта – алсу дулкыннар чайкала. Алар, вакыт-вакыт күтәрелеп, ишелеп, офыкның үзен күмеп китәләр, алтын хәрабәләрне юалар. Аннан кире чигенәләр, тагын янып яткан тылсымлы кала өстенә үреләләр...

Без, сихерләнгән кебек, тәрәзә рәшәткәсенә ябышканбыз, бу гаҗәп күренештән күзләребезне ала алмыйбыз. Алдан тау итәге буйлап борылып барган паровоз да, хәтта аның өстендәге бөркелеп барган төтен-толымнар да алсу, янып, һаман-һаман кызара бара... Паровоз ашыга, көнчыгышка – бөек Тын океанга ашыга. Йөге авыр. Алтмышлап вагон, диләр. Бары алда һәм койрыкта гына яшел пассажир вагоннары. Анда эшелон сакчылары. Уртада – ишекләре зур-зур йозаклар белән бикләнгән, тәрәзәләре чәнечкеле тимерчыбыклар белән капланган, мал-туар ташый торган кызыл вагоннар. Ул вагоннарның һәрберсендә кырыклап тоткын. Менә шушы җанлы йөкне паровоз, ашыгып, Владивостокка таба тарта һәм канлы офыкка керә бара.

Паровоз сузып кычкыртты. Байкал өсте шыңлап китте. Бераздан гудок тавышы кире кайтты.

– Ту-ту-ту-у...

Мөгаен, Байкал ярындагы таш кыяларга сугылып кире чигенде бу тавыш. Ә паровоз һаман ашыга, Көнчыгышка ашыга. Вагон тәгәрмәчләре тык-тык, тык-тык итә. Буферлар чыңлап китә. Вагон чайкала. Без бер-беребезгә сугылабыз.

Менә инде унҗиде тәүлек без бу күчмә төрмәдә чайкалабыз, какланабыз һәм каядыр ашыгабыз. Кая? Безнең өчен билгесез. Мөгаен, Владивостокка. Ә аннан? Ходай белсен.

Безне, Тубылдан сайлап алынган яшьләрне, тазаларны, иске бер баржа трюмына тутырдылар да Иртеш буйлап Омскига китерделәр. Андагы озату төрмәсендә бер атна тоткач, бик ашыгыч рәвештә шушы эшелонга төяп алып киттеләр.

Июнь ае, яңгыр юк. Вагоннар иртә таңнан кичке шәфәкъка хәтле кояш астында. Юлда коры паёк – илле грамм икмәк һәм бер порция – ике йөз грамм чамасы горбуша кисәге бирәләр. Бу балык үзе чи тоз. Ашыйсы

килүгә түзә алмыйча, алуга кимереп куясың, аннан соң ул су сорый башлый. Эшелон зур станцияләрдә генә туктый. Конвой башлыгының кәефе яхшы булса, һәр вагоннан ике кеше төшереп, икешәр чиләк су алдыра. Ә инде аның кәефе кырылган булса, вагон ишекләре ачылмый. Сусау түгел – җаның чыксын. Менә шуның өчен, суга эләксәң аерыла алмыйсың – кайнаганмы- кайнамаганмы – аны уйларга вакыт юк. Соңыннан дизентерия башлана. Бикле вагонда дизентерияне күз алдына китереп карагыз...

По диким степям Забайкалья,
Где золото роют в горах,
Бродяга, судьбу проклиная,
Тащился с сумой на плечах.

Йомшак баритон тавыш, йөрәк тавышы. Ул акрын, бик акрын башланды. Бер урыннан икенче урынга күчү, тәрәзә кырые өчен тавышлану-сүгенү кинәт тукталды. Вагон эче тып-тын булып калды. Анда бар моң, йөрәктән тулып ташыган сагыну моңы, сагыш дулкынланды:

Бежал из тюрьмы тёмной ночью,
В тюрьме он за правду страдал.
Идти дальше нет уже мочи.
Пред ним расстилался Байкал...

Бу Василь Шевченко җырлый. Гаҗәп киң, көр таышлы егет ул. Баеп барган шәфәкъка – Байкал күленең алсу дулкыннарына тәрәзә кырыеннан караган да моңлана... Мин аның белән баржада – Тубылдан Омскига күчкәндә таныштым. Карар күзгә дә бик килешле, баһадир бәдәнле егет – киң җилкәле, тулы гәүдәле. Ашыкмыйча, акрын, ышанычлы адымнар белән атлап йөри. Холкы да кыяфәтенә тиң, тыныч-салмак – бервакытта да кызып китми, үлчәп кенә сөйләшә. Ачуланмый да. Үзе миңа кордаш. Срогы да минеке төсле «бер катушка, биш тагылма» – ун ел төрмә, биш ел мәхрүмлек.

– Арестка хәтле Украинада комсомол өлкә комитеты секретаре булып эшләгән идем, – ди, күңеле ташыганда ачылып китеп. – Үзем инде ничек тә түзәм, күпчелек белән бергә. Ә менә әнкәй... Ул бу кайгыга, бу мәсхәрәгә түзә алмас. Бердәнбер улы – халык дошманы... – Василь авыр сулый. – Ул үзе – Постышев белән бергә подпольеда эшләгән революционерка. Әти Гражданнар сугышында һәлак булды... Ярар! – Кинәт ул, уянып киткәндәй, башын

чайкый, авыр уйларны чәчеп ташларга тырыша, ахрысы, җырга күчә: – Әйдә, булмаса, комсомол көннәрне искә төшереп алыйк!

Бүген дә «Наталка-Полтавка» ариясеннән үзенең иң яраткан комсомол җыры «Саубуллашу»га күчте. Аны башкалар да күтәреп алды. Бу вагонда барыбыз да диярлек яшьләр, комсомолецлар:

Уходили, расставались,
Покидая тихий край.
«Ты мне что-нибудь, родная,
На прощанье пожелай».

Җыр үсте, күтәрелде, канатланды. Бу җыр тәэсирендә үзебезнең арестант икәнебезне дә, бикләнгән тимерчыбыклар белән уратылган вагонда билгесез җиргә баруыбызны да оныттык. Яңадан үзебезнең дәртле комсомол чагыбызга кайттык – бертавыштан җырны гөрләттек:

И родная отвечала:
«Я желаю всей душой, –
Если смерти, то – мгновенной,
Если раны – небольшой».

Без күп булсак та, барыбызның тавышын күмеп, Васильнең көчле баритоны яңгырый – ул канатланып күтәрелә, үсә һәм, йөрәкләрне дерелдәтеп, еракка-еракка сузыла, сүнеп барган шәфәкъка, Байкалның алсу дулкыннарына үрелә. Бу җыр яңгыраган минутлар – Василь өчен дә, башкалар өчен дә иң изге минутлар. Барлык кайгы-хәсрәтләр онытыла. Бары тик җыр, бары тик аның тылсымлы канатлары. Алар безне еракта калган яшьлеккә – комсомол учакларына алып очалар.

– Так-ток!

– Так-ток!

Ике яклап ике каен чукмар белән вагон стеналарына суга башладылар. Без, җырга мавыгып, поездның станциягә килеп туктаганын да сизмәгәнбез. Беренче чукмар сугуына, җыр очланмыйча өзелде. Шундук ишек ачылып китте, вагонга Чыпчык сикереп менде. Ул – бу эшелонны озата баручы конвой башлыгы – тәбәнәк, ябык. Әмма шундый җитез – чыпчык кебек очып-кунып кына йөри. Хәзер ул очып түгел, атылып менде. Нечкә иреннәре каты кысылган, күгәргән. Чырае сытылган, күзләре ялтйолт итә.

– Уңга!

Без уң як сәкегә өерелдек.

– Сулга!

Без, ашыгып, бер-беребезне таптый-изә, сул сәкегә тыгызландык.

– Тиз-тиз!

Чыпчык кулындагы резина таяк белән кырыйда калганнарны яра башлады.

– Өскә! Өскә!

Өстә инде урын юк. Менгән берсе авып төшә. Ә резина камчы һаман чож-чож килә.

– Күзлегем... – Ардалион елап, кычкырып, идәнгә ташланды.

– Мә сиңа күзлек! – Чыпчык, сикереп, күзлек өстенә басты, пыяла челпәрәмә килде. – Контр! – Камчы Ардалионның аркасына төште. Ул сыгылып идәнгә ауды.

– Уңга!

– Сулга!

– Тиз-тиз, контр-еланнар!

Чыпчык безне, шулай бер уңга, бер сулга куып, бик озак азаплады. Үзе кызарды, карлыкты, тиргә батты. Ахырда күгәреп, сөйли алмас хәлгә килде. Ә без инде бөтенләй хәлдән тайдык, кузгалырлык чама калмады, тагын арлыбирле кумаса гына ярар иде.

– Шәп җырлыйсыз, Байкал шыңлап торды. Ха-ха! Без аптырап калдык, әллә мактый, әллә сүгенә. Нигә бу иблисчә көлү?

– Җырны башлаучы кем? Тавышы бик әйбәт икән. Вагон шып тынды. Бу инде хәтәр сорау иде. Мондый мактауга җавап бирмәү хәерлерәк булыр.

– Гражданин начальник, – безнең арада Иркутск төрмәсеннән генә кушылган бер бурят егете бар иде, ул, елмаеп, алга басты: – О, безнең староста булдыра, опера артистыннан һич тә ким түгел.

– Мин үзем дә шулай уйлыйм, – диде Чыпчык, чак кына авызын кыйшайтып һәм шундук елан булып ысылдады: – Яле, опера артисты, монда кил әле.

– Мине әйтәсезме, гражданин начальник?

– Сине, сине! Ишеккә якынрак кил әле.

Һау-һаулап эт өргән тавыш ишетелде. Ул арада эт җитәкләгән ике солдат-конвоир безнең вагон каршысына

килеп туктады. Ике тапкыр кыңгырау чыңлады.

– Тиз бул, староста!

Василь ишеккә якынлаша килеп, каршысына басарга да өлгермәде, Чыпчык, сикереп, ике куллап аның яңагына сукты:

– Россияне агитировать итү җитмәгән, инде тайгага тотындыңмы?

Василь чайкалды, әмма егылмады. Моны күргән Чыпчык аны башыннан этеп җибәрде. Кемдер кул сузды, тотып калырга омтылды – булмады. Василь бар салмаклыгы белән ишектән перронга барып төште.

Этләр, ярсып өреп, аның өстенә ташланды. Ул арада Чыпчык та сикереп төште. Вагонның ишеген тартып яптылар.

– Ту-туу!

Паровоз сузып кычкыртты. Поезд кузгалды. Кояш кызарып баеган иде инде.

БЕР ЙОТЫМ СУ

1

– Даң-доң! Даң-доң!

Вахта каршындагы баганага элеп куелган рельс кисәгенә сугалар.

– Даң-доң! Даң-доң!

Уяныргa.

Сикереп тордым – ник кенә күзләремне ачыйм. Аңгыминге киләм, башым сыгылып-сыгылып китә. Керфекләрне кузгатып булмый, әйтерсең җилем белән ябыштырганнар.

– Әйдә инде, ник мыштырдыйсың? – Мәхмүт кулымны тотып өстерәп китте. – Әнә безнең рота тезелеп тә ята.

Бер-ике генә атладым, ниндидер ташка абынып егылдым, күзләремнән утлар чәчрәде. Ниһаять, йокым ачылды. Сикереп торып йөгердем – сафка килеп бастым.

Эңгер-меңгер. Таң алды караңгысы. Шуның өчен арлыбирле йөгергән кешеләр шәүлә булып кына уза. Салкынча. Тора торгач телгә килдем.

– Мәхмүт, нигә бу хәтле иртә торгыздылар?

– Монда күпме ятарга була? Юлга.

– Кая?

– Кая булсын, алтын казырга.

– Димәк, Колымага. Шәп.

Мәхмүт тамагын кырып куйды – тынычсызлана. Мин төшенмәдем – нигә бу җәһәннәм оясыннан ычкынуга куанмый? Владивосток шәһәренең Икенче елга районындагы Озату лагерена килүебезгә инде өч ай тула бит.

– Лагерьда ашау да яхшырак булыр.

– Булыр! – Мәхмүт тагын тамагын кырды. – Әһе-әһе... Баргач күрерсең.

...Капка алдында зур мәйдан. Менә шунда рота-рота тезелгән мәхбүсләрнең кайсыберсе җилкәсенә биштәр аскан, кайсы чемодан, әрҗә күтәргән – юлга әзерләнәләр. Бөтен мәйдан лык тулган. Бер буш урын калмаган. Әйтерсең походка әзерләнгән гаскәр. Тик киемнәр генә чуар – кайсы пальтодан, кайсы костюмнан, кайсы күлмәкчән. Ара-тирә хәрби кием кигәннәр дә күренә. Тик якаларындагы петлицалар гына сүтеп алынган – урыннары яшәреп, гимнастёркаларның элекке төсләрен әйтеп торалар. Хәзер инде алар уңган, билгесез төскә кергән.

Башка төрмә-лагерьларда колонна дип атыйлар иде. Монда, Владивосток озату пунктында, нигәдер хәрби бүленеш – рота, отряд. Паёк өләшер өчен җайлангандыр, бәлки. Ротада – ике йөз, отрядта – мең тоткын. Ә монда хәзер ничә отряд?! Хода үзе белсен, һәр көн алмашыну бара – берничә отряд төньякка китсә, эчке Россиядән яңалары өстәлеп тора.

Ә бүген ниндидер бихисап зур кәрван җыйнала. Лагерьның яртысыннан артыгы кузгалгандыр, мөгаен.

Шак-шок! Нәрсә шакылдый дип борылсам, Мәхмүт чакма белән ут «эзли» икән – шак-шок!

– Булды... кулга ут кабынды, көйрәт.

Мин дә бушлат кесәсенә үк яшерелгән «кәҗә сыйрагы»н иплəп алып, төзәтеп көйрәттем, суырдым. Нигәдер чәчәдем – йөткерә башладым.

– Мә.

Мәхмүт әйтеп бетергәнне дә көтмәде – «кәҗә сыйрагын» ашыгып авызына капты. Башкалар түземсезлек белән аңа үрелделәр – тәмәке төтенен исни башладылар.

Өстәлләр дә җитәрлек иде, өстәл артындагы түрәләр дә аз түгел иде, әмма меңләгән тоткынны чишендереп,

аның сәләмәләрен капшап, формулярын дөресләп, тикшереп лагерьдан конвойга тапшырганчы, кояш түбәгә күтәрелде.

Инде август ахыры иде. Кояш сүрәнләнер вакыт. Әмма монда, Ерак Көнчыгышта, кояш якын икән. Нәкъ бездәге җәй кояшы төсле кыздыра, пешерә. Башта без моңа сөенгән идек, чөнки төн салкынча булып, яхшы ук калтыратты. Беренче нурларда рәхәтләнеп җылындык. Ә соңрак... Өстәвенә тагын бер җәфа.

Лагерь администрациясе безне – юлга чыгучы мәхбүсләрне тукланудан төшергән. Ә яңа түрә – конвой башлыгы, бер урынга алып барып япканчы, тоткыннарның ашау-эчүе белән кызыксынмый. Ә соң без кая барабыз? Безне кая дыңгычлап тутырырлар? Әйтмиләр.

Шулай да тоткын төпченә, иснәнә һәм ахырында ни дә булса сизә. Менә безнең арада да хәбәр таралды.

– Имеш, портта «Джурма» исемле бик зур океан корабы тора, ди. Безне шул корабка төяп алып китәчәкләр. Кая? Берәүләр, Сахалинга, ди. Икенчеләр әйтүенчә – Камчаткага. Димәк, ни булса да, диңгезгә, океанга. Ичмасам, бер рәхәтләнеп дөнья гизәбез икән. Минем бит әле океан корабларында йөзгәнем юк. Нинди икән ул бөек Тын океан?

Ә шулай да ашыйсы килә, эч борып-борып ала, кычкырып куя.

2

Лагерь үзенең вышкалары, чәнечкеле тимерчыбыкка уралган биек коймалары белән артта калды. Колонна – ун мең тоткын – эреле-ваклы сопкалар арасындагы тар юлдан портка таба агыла – очы-кырые юк.

Тирә-якта җәяүле, атлы конвой, этләр. Алда һәм колоннаның артында, ачык йөк машиналарында пулемётлар.

– Таралмагыз!

– Сөйләшмәгез!

– Тизрәк, тизрәк атла, йолкыш!

Ак сакаллы, күзлекле, бик зыялы чырайлы бер карт чемодан күтәргән, үзе аксый. Ул башта бездән алда иде. Инде кала-кала артка чыкты. Элеккегә караганда да ныграк аксый башлады.

– Тизрәк бул, кемгә әйтәм, картлач!

Конвоир, арттан килеп, мылтыгының прикладады белән төртеп кычкырды:

– Атла, контр!

Карт абынып барып егылды. Кулыннан чемоданы ычкынып тәгәрәде, ачылды – китаплар чәчелде...

– Тиз-тиз!

Без үрдән түбән төшеп киттек.

Кояш кыздыра. Шабыр тиргә баттык. Ярый әле бездә чемодан, авыр капчыклар юк. Юкса...

– Ибраһим, кара әле.

– Нәрсәне?

– Әнә юл читенә кара, – ди Ардалион, – әрәм калган дөнья.

Чыннан да, юл кырые чуп-чуар: чемоданнар, капчыклар, әрҗәләр, кием-салым, одеял, кружка-чәйнекләр. Ташлыйлар...

Кояш кыздырганнан-кыздыра бара. Бөркү. Тузан. Эчәсе килә. Тел авызга сыймый. Иреннәр чатнаган. Ичмасам, төкерек тә җыелмый. Эчәсе килә.

Инде юл читендә, чемоданнар арасында егылып калган тоткыннар да очрый башлады. Аларны этләр сөйри...

Әле менеп, әле төшеп сопкалар арасыннан бара торгач, кинәт бер урамга килеп чыктык.

Агачтан салынган бер катлы өйләр. Белмим, әллә инде бу Владивостокның бер бистәсе, әллә шәһәргә якын бер посёлок. Хәзер бөтен халык, карты-яше урамда, капка төбенә, ачык өйалдына чыгып басканнар. Бала-чагалар койма өстендә, кайбер «батырраклары» өй түбәсенә, морҗа янына урнашканнар. Безне күзәтәләр. Тып-тын, бер тавыш юк. Яшьләр – кызыксынып, картраклар борчылып – жәлләп карый.

Урамга килеп керүгә, конвой атлары безне ике яклап кысрыклый башлады. Җәяүле конвойлар, атарга әзерләнеп, мылтыкларын кулга алды.

Кояш инде ерак сопкалар артына тәгәри башласа да, кызу кимеми. Урамга кергәч, тузан тагын да артты. Бигрәк тә атлы конвой бертуктаусыз әле алга, әле артка чаба. Тынчу. Сулыш алып булмый. Инде тәндә тирләрлек тир дә калмады, ахрысы. Аркада ап-ак тоз. Авызда, иреннәрдә тоз. Аяклар көчкә-көчкә генә атлый.

– Тиз-тиз!

Һау-һау өреп, этләр өскә ташлана.

Капка төпләрендә җыелган халык колонна якынлашуга хәрәкәткә килде – кайсы күмәч, кайсы колбаса, кайсы алма ташлый. Сафлар бозылды. Кемдер алга чыкты. Кемдер иелеп аста калды.

– Бух-бух!

Бер-ике тапкыр мылтыктан аттылар, мөгаен, халыкны куркытыр өчен, һавага.

Атлы конвой шашынып чаба башлады. Кемнедер кагып-егып, кемнедер таптап уздылар.

Тагын бах-бух!

Ә мин төштәге кебек кенә киләм – күрәм дә, күрмим дә, ишетәм дә, ишетмим дә. Күз алдымдагы су йә елга булып ташый, йә күл булып чайкала. Мин шуларга омтылам... Якынлашуга, алар юк була. Су! Бер генә йотым су! Иреннәрне генә чылатсаң да хәл керер иде...

Күпме килдек? Тагын күпме барасы бар? Кайда ул шомлы «Джурма»? Беркем белми.

– Тиз-тиз! Сузылмагыз!

– Һау-һау!

Мин саф кырыенда барам. Конвой нигәдер арттарак калды. Алда, мин барган якта, почмакта, ике катлы йорт. Өйалды сарыга буялган. Аның баскычында кызыл кыекча бөркәнгән бер хатын басып тора – узучыларны бик җентекләп карый. Кемнедер эзләгән сыман. Менә аның карашы миңа төште. Күзләребез очрашты. Мин, соңгы көчемне җыеп, башымны күтәрдем, авызымны ачтым һәм, кулым белән ишарәләп, ишетелер-ишетелмәс эндәштем:

– Су, су...

Хатын башын иде дә өйалдының ачык ишегеннән йөгереп эчкә кереп китте. Без инде бу өйне узып барабыз. Бу хатын чыкмас, чыкса да өлгермәс дип пошынган идем, нәкъ өйалды турысыннан атлаганда, теге хатын, йөгереп чыгып, миңа бер чүмеч мөлдер тулы су сузды...

Салкын су! Мөлдер су! Бөтен тәнем рәхәтләнеп китте – егәрләнеп, кулымны суздым. Бер чүмеч су минем кулымда. Туйганчы, туйганчы...

Чүмечне авызыма китерергә дә өлгермәдем, аркама приклад белән китереп тондырдылар. Теге хатын, акырып елап, ишектән кереп югалды. Чүмеч кулымнан очып китте.

Мин баскыч төбендәге ташка барып мәтәлдем...

ТЫН ОКЕАНДА

1

Ниһаять, Владивосток портыннан кузгалуның икенче тәүлегендә, Лаперуза бугазын үтеп, безнең «Джурма» корабы Тын океан киңлегенә чыкты. Япон утраулары, күгелҗем томанга төренеп, артта калды. Курс – Магадан.

Гаҗәп икән ул океан – очы да юк, кырые да юк. Әллә кая офыкка барып тоташа да юк була. Аерып та булмый: әллә күк ишелеп океан өстенә төшкән, әллә инде океан үзе җиде кат күккә күтәрелгән. Җәйрәп яткан күм-күк мохит – шылт та итми, тып-тын. Кичкә авышып барган кызгылт кояш, үзе шушы мохит кочагына ташланып, аның яшькелт күкрәгендә чайкала. Салкынча, тоз төсле һава. Трюмның сасы, тынчу һавасыннан соң без йотлыгып сулыйбыз.

– Әй, сасыклар, нәрсә шаккаттыгыз? – Борт буенча арлы-бирле йөргән сакчы солдат, әллә тик торудан ирегеп, әллә инде түрәләр алдында яхшатланып кычкыра һәм кулындагы мылтыгының затворын ачып-ябып, безне куркыта башлады: – Тизрәк! Парашагызны аударыгыз да марш трюмга!

Николай белән мин юри, Тын океанны күрик дип, чираттан тыш параша чыгарырга алынган идек. Ике колагыннан каен таяк уздырылган, кара май белән майланган зур мичкә параша белән лыкма тулы, трюмның биек баскычыннан көч-хәл күтәреп мендек. Авыр, сасы. Уңайсыз. Баскыч тар һәм текә. Трюмның авызына җитеп, инде чыгарабыз дигәндә генә, мичкә, тайчанып китеп, өстемә төшә язды, ярый әле аякны терәп калдым – уң аяк кысылды, параша, чайкалып, өстемә түгелде.

Хәзер, шул хәтәрдән соң, аз гына ял итә – тирә-якны тамаша кыла идек. Конвоир ялны бүлде:

– Тиз! Тиз!

Кая тиз – акрынлап та көчкә илтәбез. Борт әйләнәсе чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган. Койрык якта бер мәйданчык эшләнгән. Шунда күтәрелеп, тимерчыбык аша парашаны аударырга кирәк.

Бая парашаның сасы сыекчасы өстемә генә түгел, хәтта битемә чәчрәгән булган – юынып алырга иде. Мо-

хит хәтле мохит өстендә барабыз – бит юарлык су юк.

Җил исте – тоз исе сасы параша исен алып китте...

Без парашаны площадкага күтәреп аудардык...

2

Менә без Тын океан уртасында. Кызык та, куркыныч та... Бортның теге ягында балыклар, китлар, акулалар һәм башка диңгез җанварлары мыж килгән тозлы су, төпсез су, чиксез су... Ә бортның бу ягында тоткыннар мыж килә.

«Джурма»ның бихисап зур «карынында» – ун секция, һәр секциядә – бер отряд. Безнең секция – җиденче. Ул миңа Казандагы чиркәү-төрмәне хәтерләтә. Монда да нәкъ теге чиркәүдәге сыман биш катлы сәндерәләр. Монда да алар ике бүлектән: бер бүлектәге сәндерәләр борт буена тезелгән, икенче бүлек – уртада, юан терәүләргә калын-калын такталар түшәп эшләнгән. Бу уртадагы сәндерәләр дүрт яктан ачык – һава йөреп тора. Лампочкалар да алар каршысында – якты. Аларны «люкс» дип атадык. Ә безнеке– «тоз рәте». Чөнки безнең башлар бортка терәлгән. Анда һәрвакыт дымлы, тоз исе һәм якорь чинавы нервыга тия. Баш чатный. Йөрәк дерт-дерт итеп китә. Без – «Казан бишлеге» – урыннан уңмадык. Ә «люкс»та көн дә уен, көн дә туй.

Менә хәзер дә «люкс»чылар пыр тузалар. Әнә бер Кызыл сакал аякларын бөкләп утырган да бер төркем ачык авызларга мәзәкләр, әкиятләр сөйли. Хәзерге темасы – каз. Мөгаен, карны ачкан – корсагын тынычландырырга тырыша.

– Их, егетләр, каз ботының тәмлелекләре...

– Үзеңнең ашаганың бармы соң?

– Юк, минем бабай күргән, бай ашап бетергән.

– Ха-ха! Менә сиңа калҗа!

– Их, мин хәзер берүзем бер казны йотар идем...

– Тукта! Ашыкма, үтен сытарсың да косарсың...

– Ха-ха-ха...

– Инде балык ашы турында сөйлә, аны сездә ничек әзерлиләр?

– Өчле итеп. Андый ашны бер кашык капсаң, телеңне йотарсың. Ә ул, егетләр, менә ничек әзерләнә...

Өстә, нәкъ лампочка астында, карта сугалар. Алда булачак атналык лайкалар, баландалар «оча». Түбәндә бер төркем украин җыр суза:

3

Каядыр түбәнгә очтым, кинәт күтәрелдем – авып киттем. Бу нинди яман төш? Йокы аралаш уйлап-рәнҗеп тә өлгермәдем, башым белән бортка килеп сугылдым – күземнән утлар чәчелде.

Уяндым. Әмма һични төшенмим – бу ни хәл? Нигә мәтәлчек атам? Әйтерсең лә мине зур бер брезентка салганнар да арлы-бирле бәргәлиләр. Ашказаным бугазыма килә – укшыйм.

Тагын тәгәрәттеләр. Тагын башым белән бортка килеп терәлдем, башым чатнап, ярылып киткәндәй булды – аңымны югалттым. Тагын каядыр этеп җибәрделәр. Көч-хәл белән күзләремне ачтым. Бернәрсә күрмим, әллә үзе дөм караңгы, әллә күзләрем күрми...

Буылып-буылып укшый башладым, косасы килә. Инде косам дигәндә генә әллә кая тәгәрәп китәм дә хәлсезләнәм.

Нәрсәләрдер чиный, шыгырдый, үкерә, шыңшый. Акыру. Бакыру. Кычкыру. Сүгенү. Җан тетрәткеч тавышлар. Үксү. Елау. Тагын чайкалып тәгәрәп китәм.

Чинап якорь чылбыры тартыла, күтәрелә, аннан кинәт нервыларны өзеп, чинап төшеп китә.

Бөтен дөнья әйләнә – асты өскә килә. Әнә трюм түшәменә эленгән, кызарып кына янган лампочка авып, түбән төшеп китә, аннан тагын күтәрелеп, утлы камчы булып чайкала.

Тагын укшыйм. Тәгәрим. Каршыдагы «люкс» шыгырдап безнең өскә килә – балкаларга терәлә. Аннан, кинәт чайкалып, икенче якка авыша. Сәндерәдәге тоткыннар терәүләргә ябышалар, бер-берсенә тотыналар, аннан таралып-тәгәрәп китәләр.

Терәүләр шыгырдый. Такталар бер алга үреләләр, бер шуышып артка чигенәләр. «Люкс» таган шикелле чайкала.

Кораб, чайкалып, тагын кырын ятты. Параша мичкәләре тәгәрәде. Кемнәрдер сәкеләрдән егылып төште.

Кораб турайды, аннан тагын бер гәүдәсе белән ниндидер упкынга төшеп китте.

Нәрсәдер чатнады, шартлады һәм күк күкрәгәндәй гөрселдәп ауды. Коточкыч тавышлар колакны ярды.

4

Ниһаять, күзләремне ачтым. Бөтен тән ут яна. Баш чатный. Авызда тәмсез тәм. Кузгалырга тырышам, булмый. Әйтерсең лә әгъзалар таралган – җыеп ала алмыйм.

Кайда соң мин? Капшанам. Астымда – су, пычрак су. Мөгаен, параша түгелгән... Ыңгырашкан, ләгънәтле сүгенгән тавышлар.

Шулай да мин кайда ятам соң? Капшанам. Тимер идән. Тимер стена. Кораб чайкалмый. Нигә чайкалмый ул?

Кинәт югарыдан якты төште. Мөгаен, люкны ачтылар. Баскычтан кемнәрдер төшә, сөйләшәләр.

– Барысын да, барысын да палубага.

– Кая?

– Балкаларны, такталарны котельняга.

– Ә үлеләрне?

– Борын ягына, берәмләп ташлагыз! Әүвәл формулярлар белән тикшерергә кирәк.

– Яралыларны?

– «Джурма» бит кызыл хач корабы түгел, ята бирсеннәр.

– Параша мичкәләре җимерелеп беткән.

– Трюмны чистарткач, складтан икенче мичкәләр алырсыз... Йә, әйдә, ауган терәүләрне күтәрә башлагыз.

– А... а... башымны... кыстыгыз...

– Әйдә, әйдә, тарт.

– Кулым, кулым...

Тагын акыру, бакыру, сүгенү, елау башланды. Палубадан төшүчеләр терәүләрне, такталарны суыра, каера, күтәрә башладылар.

– А... аякны сындырдыгыз...

– Кабахәтләр...

– Тиз! Тиз!

Яңа төшендем, мин сәке астында, идәндә – трюм төбендә ятам икән. Шторм тынган. Ә «люкс»? Яңа күрдем – «люкс» юк. Андагы тоткыннар да юк. «Люкс» урынында аркылы-торкылы өелгән-ишелгән терәүләр, такталар; изелгән, кысылган, асылынып калган мәетләр... Ыңгырашу. Акыру. Сүгенү. Һәм команда:

– Әйдә, әйдә, такталарны палубага!

Көч-хәл белән кузгалып, сәке кырыена хәтле шуышып килдем. Кемдер торырга булышты.

– Ә, син тереме?.. Бир кулыңны. – Кемдер сәке өстенә

тартып алды.

Кичкә таба без тагын Мәхмүт белән, бу юлы инде чират буенча, палубага параша алып чыктык. Тик инде яңа мичкә – карамай белән майланырга да өлгермәгән, колаклары да юк. Төбеннән сүс бау белән элмәкләнгән. Күтәрергә җайсыз. Әле бер, әле икенче якка авыша, түгелә. Хәл дә юк. Баскычка куя-куя, көчкә алып чыктык.

Тып-тын. Бөек океан җәйрәп ята, йокымсырый. Әйтерсең лә өч көн, өч төн шашынып тузынган шторм, унар метр биеклеккә күтәрелгән, корабны йомычка итеп кагып йөрткән тау-тау дулкыннар булмаган да. Әмма... үзүзебезне капшап-чеметеп карыйбыз – бу безме, чыннан да исәнме?

– Әй, сасыклар, тиз әйләнегез!

Парашаны, көч-хәл күтәреп, борт кырыена таба алып киттек.

Кояш, кып-кызыл кояш, Тын океан эченә төшеп бара. Ә безнең «Джурма», үз артыннан ак күбекле койрык калдырып, төньякка ашыга, курс – Магадан.

ЛИНКОЛЬН ПРИИСКАСЫНДА

1

1940 елның көзендә, улакларда су туңып, алтын юу тукталгач, безнең колоннаны Линкольн приискасына күчерделәр. Колымада совет заманында Америка президенты исемендәге приискамы? Гаҗәп шул. Үзем дә төшенә алмыйм. Ул вакытта, билгеле инде, безнең башта прииска исемен төпченү кайгысы юк иде.

Колонна Томанлыдан төнлә ай яктысында кузгалса да, Линкольнга җиткәнче күз бәйләнә, караңгы төшә башлады. Ул арада кар да яварга тотынды. Без, бер-беребезгә кысылып, бушлатларның булыр-булмас якаларын күтәрдек. Суык.

Ниһаять, алда, сопка итәгендә, манаралар күренде. Күңелгә җылы булып китте – тиздән барак, бәлкем, кичке баланда да бирерләр...

Алдан җибәрелгән бригада безгә инде ышанычлы урын – ике рәт чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган, озынлыгы биш йөз, киңлеге ике йөз метр чамасындагы лагерь

да эшләп куйган. Дүрт почмакта һәм ике як урталыкта манаралары да бар. Анда инде зур ак толыпларга уранып, мылтыкларын безгә таба төбәгән сакчылар да басып тора. Лагерь эчендә бер-берсенә каршы салынган дүрт барак. Әмма нигәдер аларның кабыргаларына кар өеп куйганнар. Менә шул инде торагыбыз, без шунда кышларга тиешбез.

Ләкин анда җитү әле бик мөшкел хәл. Безнең колоннада ничәмә йөз тоткын. Җитмәсә, барысы да илле сигезенче статья белән. Җәзалары да, ким дигәндә, ун ел яки артыграк каты режим. Өстәвенә һәр мәхбүснең формуляры өстенә кызыл кара белән «Аеруча хәтәр!» дип язып куелган. Менә шуларның берсен генә югалтып кара – конвой әһеленең башы югалачак.

Машиналар зона алдына килеп туктауга, алдагысыннан беренче булып конвой башлыгы сикереп төште. Ачулы әмер. Сүгенү. Чинап эт өрү, ыгы-зыгы. Машиналарда берәр генә конвоир калдырып, башкаларын камарга җибәрделәр. Ул арада манара һәм капка өсләрендәге прожекторлар кабынды. Конвой башлыгының тавышы яңгырады:

– Тыңлагыз! Машиналардан төшеп, унардан сафка тезелеп, тезләнергә боерам! Бер адым читкә атлаучылар качарга омтылучы исәпләнеп атылачак! Тиз-тиз төшегез!

Кузгалдык. Көн буенча кысылып, кузгалмый утырудан, суыктан аяклар агач булып каткан. Капылт кузгалып, алга омтылуга, атлый алмыйча, бер-беребез өстенә аудык. Машиналарның бортларын ачтылар – карга мәтәлдек.

– У-уф! Аягым...

Минем кырыйда гына берәү җан тавышы белән кычкырып җибәрде. Борылдым. Скульптор карт Алексей Николаевич икән. Кар өстендә мүкәли, тора алмый. Күтәрим дип бөгелгән идем, җиргә сеңеп китә яздым – аркага приклад төште.

– Урыныңа бар!

Гадәттәге процедура башланды:

– «А» хәрефләре, өстәл янына!

Тоткыннар машиналарга фамилияләренең баш хәрефе буенча төркемләп утыртылган иде. Беренче машинадагылар, торып, өстәлгә якынлаштылар да тагын тезләнделәр.

– Беренче номер, өстәл янына кил! Тиз!

Алдагы рәтнең сул як кырында тезләнгән беренче аре-

стант күтәрелде – озын, ябык, әйтерсең лә колга. Аркасында нәни генә биштәр. Ул, абына-сөртенә өстәлгә җитеп, үзенең «пароле»н кычкыра башлады:

– Александров Александр Андреевич. 1917 елда туган... Унбиш ел төрмә.

Конвой башлыгы кулындагы формулярны лагерь вәкиленә бирде. Капка төбендә тоткынны ике конвоир көтә. Тентү.

– Бушат биштәреңне!

Капчык чишелә. Кар өстенә үзе эшләгән агач кашык, консерв банкасы – котелок, иске-москы чүпрәкләр чәчелә. Бер конвоир шулар өстенә ташлана – актара, һәрбер җөйне капшый.

– Чишен тизрәк! – дип акыра икенче конвоир. – Мыштырдама!

Җил. Ярма булып кар сибелә. Суык. Тоткын шыр ялангач килеш кар өстендә сикеренә...

Сигез йөз арестант менә шулай сират күперен кичә.

Ниһаять, төн уртасы узгач кына, алыш-биреш мәшәкате очланды. Аннан вахтёрлар безне, икешәр йөздән бүлеп, баракларга камадылар. Инде, ичмасам, бераз җылынырбыз дип атылып-бәрелеп керсәк, ис китте.

Барак дигәнебез киндер чатыр булып чыкты. Тышкы як стеналарга кар өеп чыгуның хикмәтенә дә менә шунда гына төшендек. Җылы булсын өчен икән... Әмма бу чатырда җылы дигәннең торуы чамалы иде. Идән – җир. Стеналар, түшәм-түбә – киндер. Ике як стена буенда икешәр катлы сәкеләр (такта урынына урталай ярылган каен бүрәнәләр түшәлгән). Сәкеләр арасында, урталыкта – ишек каршында һәм түрдә – таш өстенә куелган ике тимер мичкә. Алар мич хезмәтен башкарачак икән: өстә – морҗасы, алда утын тыга торган тишеге бар.

Вахтёр һәрбер мичкә берәр кочак утын бирде. Ягып җибәрдек. Озакламый мичләр пешерелгән кысла кебек кызарды. Менә кайда ул дөньяның рәхәте – җылынып туя алмыйбыз. Әле ал, әле арт белән әйләнәбез. Бияләйләрдән, бүрекләрдән көек исе чыга башлады. Яныннан һич китәсе килми...

Ләкин бу рәхәт озакка сузылмады – өстән тамчы тама башлады. Мичләр чыж-пыж итә. Каралып-каралып китә. Бу күтәрелә. Әйтерсең лә беренче тапкыр ягылган кышкы

кара мунча. Мич кызган саен, палатка түбәсе өстендәге кар күбрәк эри. Тамчы шыбырдый гына. Өске сәкеләрдән түбәндәгеләргә күчтек, ләкин анда да ышыкланыр урын юк. Тышта буран, ә палатка эчендә яңгыр – тып-тып тама.

2

Бөтен тирә-як ап-ак томан эчендә. Кояш та, таулар да, кәрлә агачлыклар да – берсе дә күренми. Әйтерсең лә Колыма ак кәфенгә уралган. Шылт иткән тавыш та юк. Сулыш алып булмый – тын кысыла. Суык ут кебек көйдерә. Бармаклар бияләй белән бергә катканнар, лом тотарга бөгеп булмый. Баскан җирдә тыпырдыйбыз, юкса аяклар, ЧТЗга (Чиләбе заводы тракторының көпчәгеннән укмаштырылган резин ботинкаларга) ябышып катып калачак.

Борынга төтен исе килә. Ара-тирә томан арасыннан кызыл ялкыннар күренеп кала. Анда – учак. Учак янында – конвой. Борын кытыклана. Нинди тәмле ис, көйгән ботка исе! Бер генә кашык шул боткадан авыз итеп, учак янында утырсаң... Кинәт томан ярылып китте, нәрсәдер дөп итте.

– Александр! Саша! Нәрсә булды?! – Янымда гына шурф казып торган озын егет Александров, ломын кочаклаган килеш, үзе чокый башлаган шурф өстендә ята. Иелдем, йөзе күм-күк. Күзләре калайланган. Тарткалыйм: – Саша, Саша! – Эндәшми. Нишләргә? Учак янган якка карап кычкырам: – Гражданин начальник, кеше үлә!

– Хөрәсәннәр! Контрлар, ата-бабагызны... – Конвой башлыгы сүгенә-сүгенә килде. – Монда да корткычлык эшлиләр, кабахәтләр. Менә бит, эшләмәс өчен кырык хәйлә табалар. Ә син аның артыннан сөйрәл. – Ул Александрны пимасы белән тибеп этәреп карады. – Каткан, үләксә. Менә, халык дошманы үлгәндә дә халыкка зыян итмичә үлми бит ул, сволочь! – Түрә, ачуланып, арлы-бирле йөри башлады. Мин, юл биреп, арткарак чигендем. – Хәзер менә теләсәң нишлә. Калдырсаң, кичкә хәтле таш булып катачак, җавап бир. Зонага озатсаң, сакчыларның икесен алырга туры килә. Ә монда күзгә төртсәң күренмәслек томан: контрларның көткәне дә шул гына. Ә син нәрсә бәбәкләреңне миңа терәп каттың?! – Ул, Александрны ташлап, миңа ябышты. – Сиңа әйтәм түгелме? Шурфны кем казый? Пушкинмы? Яле!

Ул сугарга дип кизәнгән иде, таеп китте, мин, тиз генә

ломны алып, шурфны чокый башладым.

– Гражданин начальник! – Эш кораллары ташый торган чананы өстерәп, бригадирыбыз Имәнкулов килеп чыкты. – Менә чана китердем.

– Ярар. Салыгыз! Зонага!

Александрны чанага сузып салдык. Бригадир ике тоткынны чакырып алды. Алар чанага җигелделәр.

– Кузгалыгыз!

Бер конвоир – алдан, икенчесе – арттан. Егерме өч яшьлек студент Александр Андреевич Александров китте. Томанга күмелде. Мәңгелеккә...

Конвой башлыгына, чыннан да, мәшәкать өстәлде. Ул бригаданы бер түгәрәккә җыйды. Шурфларны участок буена түгел, бoҗра-бoҗра торып казырга боерды. Камау сызыгы тагын да якынлашты. Учак җылысыннан аерылганга, этләр чинап, улап өрергә тотынды. Кызык холыклы кеше бу конвой башлыгы. Әле генә ул мине теләгәнчә сүгеп, сугып егарга омтылган иде, хәзер инде учакларны күчерергә кушты. Бу эш ярый калды. Кисәүләрне күчергәндә, арлыбирле йөренеп, учак кабызып, шактый җылынып алдык. Җитмәсә, учак тирәсендә бер-ике икмәк сыныгы да табылды. Билгеле инде, аны йөгергән арада кисәүдә җылытыпэретеп ашап бетердем. Хәл керде.

Учаклар тагын ялкынланып яна башлады. Этләр хуҗалары белән бергәләп ут янына кызынырга утырды. Мин тагын шурф казырга тотындым. Норманы тутырырга кирәк бит. Бер караганда, нормасы әллә ни дә түгел – диаметры утыз сантиметр, тирәнлеге бер метрлы шурф казу. Башта мин үзем дә пүчтәк эш дип тотынган идем, юк икән.

Менә бүген иртәдән бирле газапланам, ә шурфның тирәнлеге кырык сантиметрга да җитми. Җир корыч булып каткан. Суккан саен, лом зыңлап сикереп китә. Бар көч белән тагын бәрәсең, тагын сикерә. Шулай азаплана торгач кына, бер кыйпылчык кителә. Тагын, тагын сугам.

– Йа Ходa, ни өчен мине болай газаплыйлар?! Ни өчен?!

3

Белмим, әллә инде түрәләрнең рәхиме килде, әллә инде кеше җитешмәү – мине «ипподром»га күчерделәр. Монда да кинәнерлек әллә ни юк, шулай да, шурф ка-

зыгандагы кебек, смена буена бер җирдә кадалып тормыйсың. Ә Колыма шартларында бу инде ярыйсы ук җиңеллек.

Грунт никадәр генә каты булмасын, тоткын шурфны тиешле тирәнлеккә җиткерергә мәҗбүр. Карцер, паёктан мәхрүм итү, ору-сугу, һәрхәлдә, тәэсирсез калмый – мәхбүс йә үлә, егыла, йә шурфны бер метр тирәнлеккә төшерә. Шуннан соң бу бригаданы башка участокка, тагын шурф-чокыр казырга күчерәләр. Тегендә шартлатучылар килә.

Җир калтыранып китә. Күк күкрәгән сыман гөрселдәү ишетелә. Аннан җир, чайкалып, челпәрәмә килеп, күккә атыла.

Менә шушы тар-мар ителгән грунтны, бер кыйпылчыгын да калдырмыйча җыеп, читкә илтеп өяргә кирәк. Шунда гына бу участок алтын юу сезонына тулаем әзерләнгән булачак.

Грунтны ташыр өчен махсус чаналар эшләнә. Аларның табаннары бүрәнә. Аркылы агачлар да шул табанлыктан кисеп куелган һәм болтлар белән беркетелгән. Чана өстенә өч-дүрт кубометр җир сыешлы әрҗә куела. Ул да калын каен такталарыннан җыелган һәм кыршаулар белән тарттырылып ныгытылган. Менә шушы әрҗәле чана «колымашка» дип атала.

Грунт шартлатылган участоктан өемгә хәтле – боз юл. Аның озынлыгы ике-өч чакрымга җитә. Бу – үзәк юл. Аңа төрле яктагы участоклардан казылып, чокырланып беткән кушма юллар килә. Безнең участок исә – бу үзәк юлның урта бер җирендә. Шулай булгач, безгә колымашканы ике-өч чакрымга түгел, аның яртысына гына илтергә туры килә. Бу да ярыйсы ук отыш.

Һәр колымашкада биш тоткын. Өчәү, аркалыкларга җигелеп, алдан тарта, икәү арттан этеп бара. Менә шулай колымашкага җигелеп җир ташу «ипподром»да эшләү була инде.

Бүген көн аяз, болытсыз, томансыз. Тәбәнәк соргылт күктә – өч кояш. Өчесе дә кызгылт боҗралар эчендә. Бу кояшлар гадәттәге кояш кебек балкып нур чәчми, бик сүрән кызарып кына торалар. Шунлыктан, көн әле иртә булуга да карамастан, әйләнә-тирә эңгер-меңгер, кояш тотылгандагы кебек шомлы. Үзе болай чатнама суык түгел, кырык-кырык биш градуслар тирәсендә генә булыр. Колы-

ма өчен бу күпмени!

Безнең «бишлек»тә гел яшьләр, кулга алынганчы комсомолның җитәкче оешмаларында эшләгән егетләр. Шуның өчен безне кайберәүләр «комсомоллар звеносы» дип тә атый.

Звено башлыгы – Әбҗәлимов Мәхмүт. Аның ярдәмчесе – Николай Васильевич Акимов. Ул Мәхмүткә караганда шактый таза, имән төбе сыман юантык. Лагерьда аны Поддубный дип йөртәләр. Әйтерлеге дә бар. Берничә тапкыр егетләр көрәшеп карады, ләкин Николайны егучы булмады. Бу бит әле ачлы-туклы йөргән хәлендә. Әгәр туйганчы ашатсаң! Звеноның өченче әгъзасы – Ардалион Михайлович Нижегородцев. Буе-сыны белән Николайга капма-каршы. Озын. Ябык. Коры сөяк. Сөякләренең таралып китмичә укмашып йөрүенә ис китә. Дүртенчебез – Гений Измайлович Республиканец. Гәүдәгә тәбәнәк, юантык булса да, йөзгә чибәр. Киң маңгай. Тирән утырган зур соргылт күзләр. Туры борын. Юка иреннәр. Түгәрәк матур ияк.

Мөгаен, сезне аның исем-фамилиясе гаҗәпләндерәдер. Чыннан да, артык яңгыраулы бит. Юри үзләштерелгән тагылма исемдер яки кушаматтыр дип уйлый күрмәгез. Юк, тегесе дә түгел, бусы да.

Аның ата-анасы бик иртә ачлыктан үлә. Өч яшьлек малай Казан урамында бер кешесез ялгыз кала. Кемдер аны балалар йортына алып барып бирә. Исеме ничек? Атасы кем? Фамилиясе ничек? Беркем белми. Малай – хәл эчендә. Менә шунда, Казан балалар йортында, коллективның гомуми җыелышында табылдык балага исем кушыла. Җыелыш күпчелек тавыш белән карар чыгара: «Малайның исеме – Гений, фамилиясе Республиканец булсын. Татар баласы булуы күренеп торсын өчен, атасы исемен Измайлович дип куярга».

Озакламый бу балалар йорты ни сәбәптәндер таратыла. Гений Республиканецны Беренче укчы татар полкы үзенә балалыкка ала. Ул шунда тәрбияләнә, үсә, мәктәпкә укырга йөри башлый. Ниһаять, полк улы Гений, югары белем алып, зур тормышка аяк баса. Башта ул Татар академия театрының директоры булып билгеләнә. Анда берничә ел эшләгәч, Гений Измайловичны Татарстан культура идарәсе башлыгы итеп тәгаенлиләр.

1936 елда Казанда Владимир Ильич Ленинның мемо-

риаль музееен оештыру мәсьәләсе күтәрелә. Бу аеруча җаваплы һәм әһәмиятле эшне – музей оештыруны – кемгә тапшырырга соң? Шобага Республиканецка төшә. Чөнки ул инде башка оешмаларда да үзен оештыру эшләренә сәләтле, армый-талмый эшли белүе белән таныткан була. Гений Мәскәүгә Надежда Константиновна янына китә. Владимир Ильичның гомер юлдашы Республиканец кандидатурасына бик риза булуын белдерә һәм мөмкин булган кадәр ярдәм күрсәтергә вәгъдә итә. Республиканец, зур дәрт, куаныч белән юлбашчыбызның Казанда торган елларын, беренче революцион адымнарын җанландырып, яңа буын күз алдына бастыру эшенә бирелә. Музейда яңаданяңа экспонатлар, документлар барлыкка килә. Ләкин бу әле аз, бик аз. Ульяновлар гаиләсе торган йортны нәкъ 1884 елгы хәлгә китерү, шул вакыттагыча җиһазлау сорала. Ә вакыт аз. Октябрьнең егерме еллыгына өлгертергә кирәк. Шул көнне музейның ишекләре ачылырга тиеш! Гений көне-төне йөгерә, эзли, ашыга.

1937 елның җәй уртасында Республиканец Мәскәүдән, Крупскаядан телеграмма ала. «Музей оештыру эшләре буенча тиз арада миңа килүегезне үтенәм. Н. Крупская». Гений шул көнне үк вокзалга йөгерә – билет алып, вагонга кереп утыра. Поезд кузгалыр алдыннан гына купега НКВД вәкиле кереп, Республиканецны «бер генә минутка» комендатурага кереп чыгарга чакыра...[1]

Беренче колымашканы тырышып, түбәсеннән өеп

---

[1] 1957 елны, реабилитациядән соң, мин Казанда Республиканецның хатыны – атаклы җырчы Зифа Басыйрова белән очраштым. Гений Измайловичның соңгы көннәре турында Зифа ханым миңа менә нәрсәләр сөйләде: «1942 елның көзендә мине Эчке эшләр халык комиссариатына чакырдылар. Котым очты. Нишлисең, бардым. Җаным уч төбендә. Мине чакырган кеше, ишектән керүгә, исәнләшеп-нитеп тормады, бик коры гына: «Сез Гений Измайлович Республиканецны беләсезме?» – диде. «Ничек белмәскә, ул минем ирем. Ул кайда, биш ел аның турында бернәрсә дә белмим», – дидем. «Ярый, хәзер күрешерсез», – диде. Өнемме? Төшемме? Аптырап калдым. Мине, машинага утыртып, Арча кырындагы психбольницага алып килделәр. Бер палатаның ишеген ачып, эчкә керергә куштылар. Янымдагы кешеләр белән бергә кердем. Бер генә караватъ. Анда баштанаяк одеялга уранган бер кеше ята. Врач килеп одеялны ачты:

– Гений, торыгыз, хатыныгыз килде.

төядек. «Ипподром»да норма – участок. Менә шушындагы тар-мар ителгән грунтны җыеп, тазартып, өемгә ташып бетерергә кирәк. Алданрак эшне бетерсәң, учак ягып, ут янында җылынырга рөхсәт ителә. Мондый рәхәткә кем өметләнми соң?

Мин, звенога яңа килгән кеше булганга, гадәт буенча урта аркалыкка җигелдем. Уңда – Мәхмүт, сулда – Николай. Арттан колымашканы Ардалион белән Гений этә.

– Бер, ике, өч, киттек!

– Яле, тагын бер!

Ә колымашка урынында. Биш арестантның җан-фәрман тырышуына, этүенә ул эһ тә итми, кузгалмый.

– Болай булмый, егетләр, – Мәхмүт аркалыктан чыга, – табаннар бозга каткан. Ломнарны алып, кырыйдан, астан күтәрегез әле. Әйдәгез бергәләп, взяли!

Менә бит бәла, колымашканы боздан һич кубарып алып булмый. Өстерәп килгәндә табаннар кызган, туктагач, бозга ябышып катканнар. Хәзер лом белән дә каерабыз, бишәүләп җилкәләрне куеп этәбез. Кузгалмый бит, ләгънәт төшкере! Ахырда, бик озак азаплана торгач кына чана кузгалды. Аркалыкларга җигелеп тартып киттек... Колымашка чинап, сыкрап, көчкә-көчкә генә бара. Иң читене – менә шушы тыкрыктан чыгу, ә төп юлга эләксәң, боздан җиңелрәк шуа.

Чыктык. Ыгы-зыгы шәһәр урамындагы сыман. Уң яктан грунт төялгән колымашкаларны өемгә этеп-тартып баралар. Сул яктан буш колымашкалар кире кайта. Кычкыру. Сүгенү. Мәхшәр.

Үзәк боз юл, барган саен, сөзәкләнеп, үргә күтәрелә. Очына барып җиткәндә син инде биек, ясалма тау өстендә буласың. Аста – яр. Менә шунда җиткәч, колымашканы кырые белән борып, йөкне аударасың. Тотып калмасаң, чана үзеңне дә өстерәп алып төшеп китәчәк. Ә инде түбәндә – җәһәннәм чокыры! Юл туктаусыз үргә менә, шуның өчен монда гел арттан этеп, сакланып барырга кирәк. Югыйсә, колымашка ычкынса, туктатам дип уйлама. Ул, үз авырлыгы белән басып, түбән очачак.

Безнең аяктагы ЧТЗлар бозланып каткан, тимераяк кебек шуа, бер урында басып торып булмый. Без алга омтылабыз, аяклар артка китә. Бер урында таптанабыз шулай. Аптырагач, бүтәннәргә юл биреп, колымаш-

каны читкә чыгарып туктаттык. ЧТЗларны лом белән суккалап, бозларын ватып, җиңеләйтеп алдык. Тагын юлга төштек. Аяклар инде таймый, бар көч белән тартабыз. Бара. Тизрәк! Ашыгабыз. Участокны тазартып бетерергә кирәк бит. Учак янында җылынуы нинди рәхәт!

Кинәт өем янында шау-шу күтәрелде. Кычкырулар! Сүгенү! Нәрсә булган? Күтәрелеп карарга өлгермәдек, алдыбыздан барган колымашка, бар грунты белән чигенеп килеп, безнең колымашкага бәрелде...

4

Кайбер кешеләрне бәхет дигәнең үзе эзләп таба. Менә архитектор Алексей Николаевичны алыйк. Линкольнга килгән көнне ул, машинадан егылып, аягын сындырган иде. Шуның аркасында кышның иң зәһәр суыгында өч ай рәхәтләнеп авырулар чатырында ятты. Инде аннан гына чыккан иде, безнең палаткага кизү итеп куйдылар. Моңа кадәр Колымада ишетелмәгән, булмаган хәл бит, илле сигезенче статьялы кизү булсын, имеш. Иң шәп вазифа ич бу лагерьда. Аны бары чын җинаятьчеләр генә башкара. Бүтәнчә булуы да мөмкин түгел. Кизү торучы тәүлегенә өч тапкыр конвойсыз гына гомуми зонага чыга. Мәсәлән, иртә белән ул чатырдагы тоткыннар саны буенча паёк алып кайта. Ничек кенә әйтмә, икмәк тураган җирдә сынык-санык төшмичә, валчык коелмыйча калмый. Кизү менә шуларны җыеп ашый ала. Төш вакытында ул ашханәгә баландага бара. Боларны безгә караганда яхшырак ашаталар. Аларның өстәлендә балык башлары, эчеп бетерелмәгән баланда да кала. Аларны да җыеп ашарга була бит. Кич белән тагын ашханәгә...

Кизүнең эше дә оҗмах рәхәте. Тышта илле-алтмыш градус суык, ә ул чатырда, мич янында, без җилкәгә салып ташыган утынны яга. Төнлә инде аяк киемнәрен, чолгауларны киптерә. Көндезен иске-москыны ямый, пима, ЧТЗны төпли яки, чүпрәк тапса, бияләй тегә. Бияләйне сатып, өстәмә бер паёк яки бер-ике төрем тәмәке алырга була. Тоткынга тагын нәрсә кирәк?

Дөрес, бу урында Алексей Николаевич түгел, башка берәү булса, аны почмакка кысып яки аерым бүлеккә чагып, күздән җуярлар иде. Ә Алексей Николаевичка һичбер арестант үчекми. Аны барысы да ярата.

Ул үзе болай буе-сыны белән әллә ни күзгә ташланырлык кеше түгел. Тәбәнәк. Ябык. Җитмәсә, аз гына бөкресе дә бар. Бите озынча. Аны тагын да озынайта төшеп, ап-ак кәҗә сакал сузылып төшкән. Яше җитмешләр тирәсендә булыр. Әмма шуңа карамастан бик хәрәкәтчән, тынгысыз карт.

Ул һич тик тормый, һәрвакыт үзенә бер эш таба. Чатырда берәр тоткын авырый икән, аның янында, һичшиксез, Алексей Николаевич. Компресс куя, яфраклар кайнатып, чәй эчерә. Берәү өметсезлеккә бирелеп баш күтәрми ята башласа, безнең карт аңа да җитешә – көлә-көлә эчең катарлык мәзәкләр сөйли яки утыз ел төрмәдә-коеда утырган атаклы испан язучысы Сервантес һәм бүтәннәр турында гәп башлый. Мәхбүс үзе дә сизмичә күтәрелә, тернәкләнеп китә.

Күптән түгел ул бөтен баракны шаккатырды. Хәйран калдык. Эштән кайтсак, аш өстәлендә ак һәм кара шахмат фигуралары парадтагы сыман кара-каршы тезелеп торалар. Менә кызык. Буш вакытларда чиратлашып уйный башладык. Күңелле. Уен кызыгына бирелеп, кайда икәнеңне дә онытасың. Ара-тирә бригадалар арасында, аннан чатырлар арасында турнир да оештырырга керештек. Әмма бу күңел ачу озакка бармады. Чираттагы тентүләрнең берсендә шахматларны табып мичкә актылар. Безнең чатыр өч тәүлек карцер режимына куелды.

Тик Алексей Николаевич бирешми. Тагын да кызыграк яңалыклар уйлап таба. Шуларның берсе тагын бөтен лагерьны куандырды, әмма аның да соңы фаҗигале булды.

5

Сезнең йолдызлар тавышын ишеткәнегез бармы? Мөгаен, юктыр, чөнки аларның сөйләшкән тавышлары бары төньякта гына ишетелә бит. Тыңлап карагыз әле, алар хәзер менә минем янда сөйләшәләр.

– Тып-тып! Тып-тып!

Ишеттегезме, ә бит минем янда беркем юк. Күктә калтырап торган йолдызлар һәм ярты ай. Ай сөйләшми. Ул ялгыз. Ә йолдызлар, күрәсезме, алар никадәр! Әйтерсең лә күк йөзенә алмаз кыйпылчыклары сипкәннәр. Менә шул куштаннар кызлар кебек пыш-пыш киләләр, серләрен бүлешәләр:

– Пып-пып! Пып-пып!

Бер урында басып торып булмый, суык. Авыз-борыннан чыккан сулыш – пар бөртекләре, һавага таралып китә алмыйча, зәһәр суыктан шартлыйлар: «пып-пып». Шушы тавышны якутлар «йолдызлар тавышы» диләр. Менә бүген дә шундый, йолдызлар сөйләшә торган суык кичләрнең берсе. Эш бетте. Ә зонага һаман кайтармыйлар. Торган саен суык көчәя. Әллә инде зәмһәрир учакларына утын өстиләр. Ялкыннары бөтен тәнне ялап, көйдереп ала. Бер урында сикерәбез. Ниһаять, тилмереп көткән боерык: «Тезелегез!» Зонага йөгерәбез. Янъяктан этләр дә юырта. Өрмиләр. Колаклары салынып төшкән. Баскан саен, кар шыгырдап китә. Сулыш тыгыла. Тын алып булмый. Яндыра. Керфекләрдә – боз. Борын агара. Авыз корышкан. Атлаган саен абынабыз. Конвой сүгенә, акыра, егылганнарның аркасына – приклад. Йөгерәбез.

Көчкә генә зонага килеп җиттек. Ярый әле яхшы дежурный туры килде. Тентеп маташмады, тиз генә санады да капканы ачты.

Үзебезнең палаткага якынлашкач, гаҗәпләнеп туктап калдык. Бу ни бу? Кайдан килеп чыккан соң монда Төньяк шаһзадәсе! Туңуыбызны онытып, аның тирәсендә әйләнә башладык. Гаҗәп! Зона эчендә, безнең чатыр алдында, тармаклы мөгезләрен артка ташлап, башын югары күтәреп, һава иснәп, мәһабәт болан басып тора.

– Карагыз әле, иптәшләр, – диде Алексей Николаевич, кичке баланданы чөмереп бетереп, шау-шу басыла төшкәч, – әгәр дә вахта капкасыннан чатырларга килә торган юлга аллея эшләсәк, ничек булыр?

– Нинди аллея тагын? – Аптырашып калдык. Әллә инде карт саташа башладымы?

Палатка эчендә, бомба шартлаган төсле, ха-ха-халап көлү күтәрелде.

– Туктагыз! Туктагыз әле! – Карт, кулларын селкеп, ачулы кыяфәт белән кычкыра башлады: – Нигә көләсез, мин сезнең белән киңәшергә телим бит.

– Иң яхшысы: бер чүмеч баланданы ничегрәк артык чәлү турында киңәшик.

– Баланда! Баланданың җитмәгәнен мин үзем дә беләм. Ул – корсакка. Күңелгә дә азык кирәк бит...

– Баш катырма әле, корсак буш булгач, күңел күзе дә сукырая.

– Әйдә, Алексей Николаевич, сөйлә әле.

– Мин кардан, су сибеп катырып, төньяк хайваннарының сыннарын эшләп куярга уйлыйм.

– Әйбәт ич, нигә эшләмәскә?

– Әйе, әйбәт булыр иде. Ләкин... – Мин икеләнеп калдым. – Аларны эшләргә байтак кар кирәк булыр. Аны кайдан алабыз? Зонадагы карны инде эчеп бетереп киләбез ич.

– Менә шуның өчен дә сезгә эндәшүем.

– Булмаса, болай итик, – диде бригадирыбыз Зариф Имәнкулов. – Ягарга ботак-санак алып кайтабыз бит. Икенче култыкка кар-боз кантары кыстырыйк.

Бу эшкә күрше чатыр тоткыннары да кушылды. Зона бер, урам бер. Аллея да бер булачак бит. Имәнкулов бу турыда лагерь һәм конвой башлыкларына әйтеп рөхсәт алды. Алар өчен дә кызык бит, зонада – җанварлар аллеясы.

Шулай итеп, кич белән эштән кайтканда, җилкәгә ботак-санак күтәрсәк, култык астына кар яки боз йомарламын кыстыра торган булдык. Ил төкерсә, күл була, диләр бит, аз-азлап ташысак та, чатырыбыз алдында кар-боз өеме көннән-көн үсә башлады. Алексей Николаевич эшкә тотынды. Төнлә ул кизү вазифасын башкара: мичкә яга, аяк киемнәрен, чолгауларны, бияләйләрне киптерә,

---

Караваттагы кеше тиз генә одеялын тартып алып тагын уранды.

– Торыгыз!

– Комачауламагыз, зинһар, мин Владимир Ильич белән сөйләшәм...

Тавыш таныш, Гений тавышы... Йөгереп барып, одеялны тартып алып кочакламакчы идем, ул мине этеп җибәрде. Егылдым. Мин аягүрә басканда, алдымда коточкыч бер кеше басып тора иде. Бөтен йөзен кара сакал баскан. Күзләре, акаеп, әле бер, әле икенче якка ташланалар.

– Кем сез? Нигә рөхсәтсез кердегез?! Әйттем бит, мин Ильич белән сөйләшәм. Китегез! Китегез!

Ул безне куып чыгарды. Мин аннан соң бу палатага берничә тапкыр килдем. Ләкин ул: «Ильич белән сөйләшәм, вакытым юк», – дип, палатага керттермәде. Берничә елдан соң мин аның үлүе турында хәбәр ишеттем».

ә көндезен палатканы тиз генә себереп-тазартып чыга да сын эшләргә керешә. Баланда, паёк алып кайтып өләшкәч, тагын шул эшкә.

Башта Алексей Николаевич карны, палаткага кертеп, тагаракка сала да су коеп изә. Аннан ул бу измәне өстәлгә алып, камыр әвәләгән кебек әвәли, өя. Кар өеме акрынлап сын рәвешенә керә башлый. Баш, койрык, аяклар барлыкка килә. Бәйләүче, ныгытучы материал итеп таяк, чыбык-чабык, чүпрәк-чапракны да файдалана. Менә шушы хәлендә сын чатыр алдына чыгарыла. Ул анда шыкырдап ката. Шуннан соң инде скульпторның төп эше башлана. Җанварга «кием» киендерергә, күзләрен ачарга һәм тик аңа гына хас бер хәрәкәттә – позада туктатып калдырырга кирәк.

Төньяк җанварлары, кошлары күбрәк ак төстә – буяу кирәкми. Ә менә боланнар, пингвиннар һәм башкалар өчен соргылт, кара төсләр кирәк ич. Оста аптырамый. Аллага шөкер, корым бар, көл бар...

Алексей Николаевич, консерв банкасына борын куеп, комган сыман бер савыт эшләп алган. Менә шушы «тылсымлы» комган бөтен сыннарга җан иңдерә. Комган эчендәге су кирәк икән кара, кирәк икән соры була. Менә шул хикмәтле су сын өстенә бөркелә. Көн суык. Сын өстенә сибелүгә, су бөрчекләнеп катып кала. Менә шул рәвешле тире-йон, каурый барлыкка килә. Барлыкка килә дип әйтергә ансат. Ә чынында – михнәт.

Сыннарны «терелтү» эше, иң нечкә хезмәт, тышта эшләнә. Ә суык кырык биш-илле градустан да ким түгел. Менә шунда су белән, кар белән сәнгать әсәре тудырып кара! Берничә көн ул, кулына кашык та тота алмыйча, баланданы савыт читеннән чөмереп кенә йөрде – бармакларын өшетте. Ләкин аңа карап карт эшен ташламады. Каяндыр балык мае табып, бармакларын майлап, чүпрәк белән урап, тагын үзенең «остаханә»сенә чыкты.

Бу эш ике айдан артык барды, һәм, ниһаять, Яңа елга – 1940 елның утыз беренче декабренә – «мәрмәр сыннар аллеясы» әзер булды.

Бәйрәм бәйрәм инде ул, әзерлек кирәк. Тоткын да аңа әзерләнә. Бер-ике көн кала гына түгел, бер ай алдан.

Безнең тәүлеклек рацион: биш йөз грамм икмәк. Иртә-

кичен берәр чүмеч (ярты литр) баланда. Төшкегә баланда һәм ярты чүмеч арыш камырыннан чумар. Чумары әләксә бик яхшы, күбрәк чумар суы гына була. Менә шушы ризыктан соң илле-алтмыш градус суыкта унике сәгать буе лом белән чуер җирне чокырга яки колымашкага җигелеп грунт ташырга – норманы тутырырга кирәк. Паёкны тилмереп көтәсең, инде кулыңа тигәч, ашаганыңны тоймый да каласың – әллә булды, әллә юк. Корсак һаман буш, һаман сорый... Тагын көт!

Менә шушы паёктан бәйрәм өлешен дә чыгарырга кирәк. Кирәк! Бәйрәмдә, Яңа елны каршылаганда, ичмасам, бер туйганчы ашарга. Ә ничек? Ничек булса да! Декабрь башлану белән, без, авызыбыздан өзеп, берәр кыйпылчыкны үзебездән үзебез яшерә башладык. Кая яшерергә? Ул икмәк кыйпылчыкларын чатырда калдыру һич мөмкин түгел, аны шундук «сугалар». Кая? Кечкенә янчыкка саласың да, күзне йомып, бушлат кесәсенең иң төбенә төшереп җибәрәсең. Юкса кул калтырый, күз йотып алырга тора. Шулай итеп, янчык иң ышанычлы җирдә – кесәдә. Йөргәндә, утырганда, бөгелгәндә ул тәнгә бәрелеп кытыклый. Авызга су килә. «Бер генә бөртек, бер генә валчыкны алып кап инде! Рәхәтләнеп китәрсең. Хәл керер!» – ди шайтан нәфес, вәсвәсәли. Кайвакытта үз кулыңны үзең кесәдә бурлыкта тотасың. Кулны тартып аласың да, ачудан сикереп торып, колымашкага җигеләсең.

Яңа елга әзерлектә мин башкалардан уздыра төштем. Әйтмәгәнем булсын: конвой башлыгы ничектер миңа рәхимлерәк карый. Анда-монда йөгерергә, чыбык-чабык җыярга, учак ягарга булса, миңа куша. Мин инде хәл кадәренчә җитез, йөгереп эшлим. Учак та тиз кабына, утын да ярыйсы була. Менә шул чыбык җыйган арада куаклыкта яфраклар очрый. Мин аларны кесәгә, кесәгә. Палаткага кайткач киптерәм. Менә дигән чәй.

Утыз беренче декабрьдә, эштән кайту белән, безнең чатырларның ишегенә йозак салдылар. Этләрне зона эченә җибәрделәр. Саклык. Кем белә, монда гел «илле сигезләр» ич. Яңа ел алдыннан аларның әллә нинди усаллык эшләүләре дә мөмкин.

Төн. Барак тирән тынлыкка чумды. Һәр тоткын сәкедә – үз урынында. Кайсы яткан, кайсы ярым кыйшайган, кайсы сәкедән аякларын төшереп, башын иеп утырган. Тып-тын.

Йоклыйлар. Юк. Мондый төндә йокларга мөмкинме соң? Алда – 1941 ел... Ул мәхбүсләргә нәрсә алып киләчәк? Амнистия? Яңа срок? Ирек? Кабер?

Тоткын уйлана. Башы чатный, ярыла яза. Уйлана.

...Төрле ашамлыклар, эчемлекләр белән тулы өстәл. Шат күңелле, якты чырайлы дуслар. Балалар. Ата-аналар. Хатының...

– Даң-доң!

Сәгать уникене суга. Өстәл янындагы кешеләр барысы да аягүрә басалар. Шешәләр ачыла. Бокалларда янып торган шәраб.

– Яңа бәхет, яңа шатлык өчен...

– Шак-шок!

Тоткын сискәнеп айнып китә, тәмле уйларыннан аерыла.

Ишектә конвой.

– Ятыгыз, үләксәләр, нәрсә көтәсез? Отбой!

6

Иртәгесен, Яңа ел көнне, каравыл башлыгы үзе килеп, ишектәге йозакны ачып, иртәнге тикшерү-барлауны үткәргәч, лагерьга чыгып йөрергә рөхсәт итте.

Әкият кебек матур көн. Ашыкмыйча, калгып кына тәңкә кар ява, әйтерсең лә күктән йолдызлар коела... Алар күзләрне чагылдырып җем-җем итәләр.

Караңгы тынчу палаткадан чыгуга, күз чагылып, баш әйләнеп киткән иде... Хәзер инде сулап туеп булмый – салкынча хуш ис! Гаҗәп икән ул яңа явып торган тәңкә кар исе – шәраб эчкән кебек тәмле исертә, тәнгә егәр, дәрт өсти. Бар кайгы-хәсрәтең онытыла.

Барыбыз да аллеяга атладык. Юлның ике ягында метр биеклегендәге мәрмәр нигезләр... Алар өстендә тундраның гүзәл җанварлары, кошлары. Каядыр ашыгып барган-очкан җирдән алар монда бик азга кына ял итәргә туктаганнар, кунганнар.

Вахта капкасыннан килгәндә, сезне беренче булып болан каршылый. Ул чабып барган мизгелдә кинәт сагаеп туктап калган. Зур, тармаклы мөгезләр артка ташланган, колак шәм булып торган. Аның каршында арт аякларына басып, тундрага хәйран калып карап торган ак аю. Аннан төлке, бүре, шакал, куян, пингвин, акчарлак, морж...

Һәрберсе үзенә генә хас рәвеш алып тукталган-

нар. Безнең белән танышырга килгәннәр, хәзер-хәзер күтәрелеп юк булырлар кебек... Һәммәсе дә үз зурлыгында, үз төсендә.

Кар һаман ява. Йолдызлар коела. Ул йолдызлар постаментлар өстенә, аларга басып торган сыннарның иңенә куналар һәм тылсымлы бер нур белән балкыйлар. Гаҗәеп матурлык.

Арестантлар аллея буенча акрын гына әле вахтага, әле палаткаларга таба атлый, сыннар алдында туктап кала. Нинди матур, нинди гүзәл бу дөнья!

7

Бу аллея лагеребызны җылытып, яктыртып җибәрде. Җанварлар, кошлар иртә белән безне эшкә озатып кала, ә кичен алар, ерактан үрелеп карап, безне каршы ала. Без ашыгабыз, әйтерсең лә анда безне туганнарыбыз көтә. Аена бер була торган ял – мунча керү көнендә лагерьдагы барлык тоткын шушы аллеяда була.

Берәүләр кайчандыр, кайдадыр күргән зоопаркны искә ала, икенчеләр, үзләренең ау маҗараларын хәтерләп-сөйләп, тыңлаучыларны көлдерә, ә өченчеләр, сынга табынучылар кебек тукталып, башларын иеп торалар.

Мин үзем дә, аз гына буш вакытым булды исә, аллеяга чыгам. Озак, бик озак карап торам бу салкын, әмма күңелгә бик җылы сыннарга. Еракта, Тын океан артында, тайга артында, казах далаларында калган туган Күкчәтавым күз алдыма килә минем. Дөнья нинди зур, нинди гүзәл! Анда хайваннарга, кошларга урын бар. Ә кешеләргә? Ә кешеләргә нигә тар бу киң дөнья?

Мин үзем ешрак болан алдына килеп туктыйм. Нигәдер ул миңа бик якын. Аның белән сөйләшәм, иң яшерен, изге серләремне бүлешәм. Уйга, хыялга батам... Менә шушы боланга атланып, иреккә, туган җирләргә очсаң иде. Анда барып җитәр өчен, ничәмә-ничә диңгезне, ничәмә-ничә тауны, караңгы урманнарны кичәргә кирәк бит. Озын юл. Авыр юл. Куркыныч юл. Син абынмассыңмы? Син арымассыңмы, толпарым? Юк! Юк! Син бит бар җанварлардан түзем, бар йөгерекләрдән йөгерек. Мин ышанам синә, җанварым. Оч, алып оч мине, толпарым, туган якларга!

8

Март башында Магаданнан өлкән бер түрә килә икән дигән хәбәр таралды. Чатырларның ертык-тишекләрен ямарга куштылар. Чираттан тыш мунчага алып барып, чәч-сакалны кырыктылар, юылган күлмәк-ыштан бирделәр. Ике төн рәттән бaрактан куып чыгарып, зур тентү ясадылар – без-пычак ясарга ихтимал булган тимер кисәкләрен берсен дә калдырмый сыпырып алдылар һәм чатырыбызны ике көнгә карцер режимына куйдылар – кичке аштан соң ишеккә йозак элделәр.

Бу өлкән түрәне каршы алу әзерлегенә Алексей Николаевич та катнашмыйча булдыра алмады. Постаментларны төзәтте, алар өстендәге сыннарның кителгән, кырылган җирләрен ямады-сылады, сыйпады. Ничек кенә әйтмә, бу аллея – сәнгать, иҗат җимеше. Олы түрә, һичшиксез, сәнгатьне белә һәм хөрмәтли торган зәвыклы кеше булырга тиеш.

«...Тиздән зур амнистия була, имеш. «Илле сигез»ләрнең барысын да азат итәләр икән. Монда килә торган түрә, тоткыннарның хәлен, тормышын үз күзе белән күреп, Мәскәүгә барачак һәм бу турыда иптәш Сталинның үзенә доклад ясаячак икән. Паёк инде алты йөз граммга җиткереләчәк икән. Умач урынына ботка бирәчәкләр, ди...»

Менә шундый имеш-мимеш белән бөтен лагерь гөж килә. Кемне тыңларга, кемгә ышанырга белмисең. Ә шулай да күңелгә рәхәт. Кем белә бит. Бәлкем? Бәлкем, чыннан да, хаклык өстенлек алыр. Бәлкем, безгә дә ирек килер. Өметсез – шайтан, диләр бит...

Ниһаять, унөченче март көнне иртән, эшкә чыгармыйча, вахтадан кире бордылар. Аврал башланды. Сәке такталарын, дөресрәге, бүрәнә яргакларын ком белән ышкып юдык. Чатыр тирәсен себереп, тап төшкән җирләргә кар сибеп чыктык. Алексей Николаевич үзенең аллеясы белән азапланды. Себерде, сөртте, су бөркеп яңартып маташты.

Зонада ыгы-зыгы. Вахтёрлар, бригадирлар йөгерә. Кычкыру, сүгенү – барысы бергә буталган. Кинәт даң-доң, даң-доң!

Вахта янындагы баганага асып куелган рельска суга башладылар. Бу инде һәр мәхбүс өчен аңлаешлы – таныш әмер: «Вахта янына килеп, рота-рота булып (һәр палатка

– бер рота) тезелергә!»

Тезелдек. Без – беренче рота. Шуның өчен вахтада беренче булып торабыз. Мин – алгы рәттә. Бөтен хәрәкәт күз алдында. Көтәбез. Җитәкчеләр юк. Көтәбез. Аяклар өши башлады. Кузгалырга боерык юк. Көтәргә!

Менә бервакыт вахта ишеге ачылды. Бер төркем хәрби киемдәге кешеләр безгә таба атлады. Алда – озын буйлы, тулы гәүдәле кеше атлый. Аның өстендә гәүдәсенә сыланып торган өр-яңа шинель. Башында елкылдап торган, алтын төсендәге каракүл папаха. Аллеяга якынлашуга, түрә кинәт туктап калды – төбәлеп боланга карады. Муенын аз гына уңга борды – ак аюга карады. Сулга борды... барлык сыннарга күз йөртеп чыкты.

– Начальник! – диде ул акрын гына калын бас белән. Лагерь башлыгы Иван Иванович, урта буйлы, юантык кеше, аның янына килеп үрә катты. Папахалы кунак кузгалмыйча, ияген кагып кына сыннарга ишарә итте: – Бу нәрсә, Петергоф?!

– Иптәш генерал... – Безнең түрә каушап, тотлыгып калды. – Монда лагерьда бер скульптор бар...

– Яле, кайда ул скульптор? Күрим әле.

Алексей Николаевич, чакырганны да көтмичә, генерал алдына килеп басты:

– Гражданин генерал!

– Гаҗәп, мин сине Пётр I кебек мәһабәт гәүдәле кешедер дип уйлаган идем.

Тынлык. Аптырап калдык. Нәрсә турында сүз бара соң?

– Гафу итегез, – диде карт. – Мин сезне төшенмәдем, гражданин генерал.

– Менә мин дә төшенмим, – диде генерал һаман әле акрын тавыш белән. Тынлык. Кинәт ниндидер бер ерткыч тешләгәндәй, генерал кычкырып җибәрде: – Нәрсә?! Сине монда Колымага яңа Петергоф салырга җибәрделәрме? Әллә алтын казыргамы?

Яшен суккандай булды. Сискәнеп, калтыранып киттек. Генерал муенын безнең лагерь башлыгына таба борды.

– Яле, ныграк бер күсәк китерегез әле!

Лагерь башлыгы үзе вахтага йөгереп керде дә кисәү агачы күтәреп чыкты. Барыбыз да катып калдык. Тын алу киселде. Нәрсә була? Безнең түрә, генерал янына килеп, бер – кулындагы таякка, бер – генералга күз йөртеп, ап-

тырап карады.

– Бу... ничек?..

– Скульпторга бир! – диде генерал ачулы тавыш белән.

Алексей Николаевич кисәү агачы сабын кулына алды да, нишләргә белмичә каушап, генералга карады:

– Гражданин генерал...

– Җитәр! – Калтыранган тавышны калын бас таш булып басты. – Монда нәрсә, тоткыннар лагеремы, әллә ял йортымы?! – Тавыш күтәрелеп, нечкәреп китте. Генерал кызарды: – Яле, син, скульптор булмыш... Хәзер үк бу чучкаларны күздән югалт!

Башыбызга тукмак белән суктылармыни – иелеп төштек. Мескен Алексей Николаевич хәлсезләнеп бөгелде, кулындагы таягы төшеп китте.

– Вахтёр! – диде генерал ачулы тавыш белән. – Монда кил!

Вахтёр – озын буйлы, таза уголовник егет — йөгереп килеп, генерал каршына басты. Кунак, инде тынычлана төшкән сыман, акрын гына эндәште:

– Әнә җирдәге таякны алыгыз да бу хайваннарны күздән югалтыгыз. Лагерь кешеләр өчен, хайваннар өчен түгел. Башлагыз!

Күзләремне йомдым.

Шарт-шорт, шарт-шорт. Әйтерсең лә башыма сугалар, иелеп-иелеп китәм.

Күзләремне ачканда, аллея урынында инде челпәрәмә китерелгән, ватылган боз кисәкләре генә ята иде...

МАДРИД

1

Моннан бик күп еллар элек тундрада Калым исемле батыр яшәгән. Аның бөтен гәүдәсе саф алтыннан гына торган. Ул вакытта кояш тундра күгеннән китмәгән, көне-төне нурын сипкән. Шуның өчен дә монда кар яумаган, диңгез туңмаган. Тундра ел тәүлегенә ямь-яшел гөлбакча булып, чәчәк атып торган. Диңгез буенда калын кара урманнар шаулаган. Андагы агачлар тәмле җимешләренең салмагыннан иелгәннәр. Болыннарда кызарып пешкән җиләкләрдән аяк атлар урын калмаган. Урманнарда – кошлар, болыннарда – көтү-көтү хайваннар, өер-өер җәнлекләр, куркуны, ачлыкны татымыйча, рәхәт

җәйләгәннәр. Мондагы кешеләр дә, кием-салымны, суыкны, кайгы-хәсрәтне белмичә, оҗмахтагы кебек ваемсыз яшәгәннәр. Шуның өчен дә ул вакытта бу җирләр Тундра дип түгел, Гүзәл Якут дип аталган икән.

Әмма бу рәхәт озакка сузылмаган. Көннәрнең берендә диңгез артыннан явыз гыйфритләр чыгып, кояшны, урлап, котыпка алып киткәннәр, Якут җире дөм караңгы булып калган. Агачлар корыган. Үсемлекләр сулган. Диңгез калын боз катламы белән капланган. Кошлар, хайваннар, җәнлекләр, кешеләр, суыктан туңып, ашарга азык таба алмыйча ачыгып, кая барырга белмичә аптырап, зар елаганнар. Гүзәл Якут иле кара кайгыга баткан.

Менә шул шомлы вакытта Калым батыр аягүрә баскан. Аның алтын гәүдәсе, балкып, тирә-якка нур чәчкән. Якут җире яңадан яктырып киткән. Ләкин бу нур кояш нуры кебек җылы түгел, салкын нур булган. Алтын нуры кешеләрне, табигатьне җылыта алмавын күргәч, Калым батыр, кояшны гыйфритләрдән тартып алырга дип, котыпка киткән.

Гүзәл Якут тагын дөм караңгылыкка чумган. Ә аның халкы, өметләнеп, хәвефләнеп, үзенең батыры Калымны көткән. Якут күгенә унике тапкыр ай күтәрелгән, җирне яктыртырга тырышкан, ләкин үзе дә, суыкка чыдый алмыйча, өшеп-күшегеп диңгезгә чумган. Унике тапкыр чумган. Калым батыр һаман кайтмаган. Халык өметен югалтып, хәле бетеп егылган. Нәкъ менә шушы фаҗигале мизгелдә, ниһаять, ерак котыптан кояш балкып чыккан. Якут җире яңадан яшәреп, матураеп киткән. Халык, җыр җырлап, кубыз уйнап, барабаннар сугып, үзенең батырын каршылаган. Якут илендә моңарчы һич күрелмәгән, ишетелмәгән бәйрәм – туй башланган. Иң куәтле шәраблар, иң симез итләр, иң тәмле тәгамнәр өстәлгә куелган. Җыр, бию, уен-көлке чиген белмәгән. Халык үзенең батырын хөрмәтләгән, сыйлаган...

Әмма арада Калым батырның данын көнләүче хаин бер җан да булган. Ул, гыйфритләргә сатылып, Калым батыр эчә торган Якут кәсәдәге шәрабка агу салган. Уникеай буена гыйфритләр белән сугышып арыган-талган Калым агулы шәрабны эчүгә йоклап киткән. Шуны гына көтеп йөргән гыйфритләр, чатырга кереп, йоклап яткан Калымны суйганнар.

Батыр, уянып китеп, аягына баскан. Гыйфритләр кояшны диңгез ярына ташлап качканнар. Әмма батыр озак басып тора алмаган, киселгән башы аны җиргә тарткан. Калым хәлсезләнеп егылган. Аның башы – Аляскага, гәүдәсе – Якут җиренә, аяклары Алданга төшкән.

Һәр язны, үзен гыйфритләр суйган көнне, Калым батыр егылган җиреннән күтәрелеп баса, туган Якутстанына – тундрасына карый, сокланып, яратып карый һәм... хәле бетеп егыла икән. Менә шул вакытта, Калым батыр аягүрә басып торганда, аның мәһабәт алтын гәүдәсе тирә-якка нур сибеп балкый. Бу могҗизаны белмәгән соңгы заман кешеләре Калым батырның нурлы шәүләсен ялгышып «Төньяк балкышы» дип атыйлар икән.

Бу легенданы миңа үзебезнең бригададагы карт якут сөйләгән иде. Әйтүенә караганда, ул, кулга алынганчы, Якутск шәһәрендә укытучы булып эшләгән һәм Төньяк халыкларының фольклорын җыю белән шөгыльләнгән. Бу легенданың нигезендә, һичшиксез, чынбарлыкка ишарә ята. Дөрестән дә, Төньяктагы алтын тамырлары Аляскадан башланып, бөтен Колыма мәйданы буенча тармакланып, Алданга чыга бит. Моны инде ишетеп түгел, үз күзләрем белән күреп беләм, үз кулларым белән казып беләм. Җиде кат тирең түгелә, җиде тапкыр җаның чыга ул алтын оясын казыганда.

Ниһаять, Калым батыр җирләренә дә яз килде. Кар эреде. Елгаларда бозлар кузгалды. Сопкалар ашыгып яшәрә башладылар. Ә кояш, йокысын онытып, туктаусыз әйләнә. Әнә ул боз диңгезләре артына төшеп байый. Әмма шәфәкъ нурлары сүнәргә дә өлгерми, капма-каршы яктан, котыптан, шул ук кояш яңадан күтәрелә башлый. Ул үзе кинәндереп кыздырмый да, бөтенләй үк сүнми дә – сүрән, саран.

Менә шушы соры көннәр башлануга, бөтен Колыманың асты өстенә килә, туздырылган кырмыска оясы кебек мыж итә. Тоткыннар, түрәләр, солдатлар, этләр – барысы да зиндан-забойларга чыга. Вахта капкалары янындагы баганаларга асылган чулак рельсларга да тынгылык бетә.

– Даң-доң! Даң-доң!

2

Бу нинди музыка? Кем уйный болай матур итеп?

– Тор, үләксә!

Билем киселеп киткәндәй булды, сикереп тордым. Каршымда – кулына резина таяк тоткан вахтёр. Ә барак ишегеннән, һау-һау итеп, тешләрен ыржайтып, бозау хәтле овчаркалар килә.

Абына-сөртенә йөгереп барып, вахта алдына тезләндек.

– Бүген илебезнең валюта цехы эшли башлый. Сез монда үзегезнең кара җинаятьләрегезне хезмәт белән юар өчен сөрелгән явызлар, халык дошманнары. Алдыгызда тачка, кәйлә, көрәк, забой, норма! Норманы тутырмау – аңлы рәвештә контрреволюцион корткычлыкны дәвам итү. Экономик диверсия! Ә мондый саботаж өчен халык сезгә икенче тапкыр шәфкать күрсәтмәс. Төшендегезме, контрлар!

Колонна башлыгы – озын, ябык, әз генә бөкрәеп, түбән карап йөри торган капитан – бүген өр-яңа формадан, төптөз басып, калын бас белән әмер бирде:

– Бригадаларны забойга төшерергә! Эшкә!

Менә шулай Колымада алтын бизгәге башлана. Билгеле инде, бу күренеш миңа яңалык түгел. Мин бу 1941 елның язында инде өченче тапкыр алтын юарга чыгам. Әүвәле бер сезон Линкольн приискасында эшләдем. Аннан монда – Сусуманга күчерделәр.

Безнең бүгенге забой Колыма елгасы белән сопка арасында. Бу сопка тундра ягыннан болан мөгезе кебек тармакланып килә дә, Колыма ярларына ике-өч километр калганда, кинәт көньякка борыла. Менә шул аралык – безнең забой. Кыш көне шурфлар казып, шартлатып, забойның өске кат грунтын алып, ачып куйган идек. Радиусы ике-өч чакрымга сузылган бу забойның урта бер җирендә биек эстакада – бункер урнаштырылган. Бункер астыннан елга ярыннан ук корылган зур улак үтә. Яр буендагы насос станциясе Колыма суын шул тирән улакка – бутарага коя. Су көчле этем белән туктаусыз ага. Һәрбер забойдан бункерга берничә трап-басма сузылган. Алтын комлы грунтны тачкага тутырабыз да трап буенча бункерга ашыгабыз. Норма – йөз тачка. Өлгер! Шул такта трап буенча сыңар тәгәрмәчле «самоходка»ны бар көчкә әйдибез. Забой эчендә әле бик үк тыгыз түгел, берберебезгә юл да бирәбез. Ә менә бункерга якынлашкан-

да, югары күтәрелгәндә, кыямәт. Һәркем ашыга – тизрәк менеп җитәргә тырыша. Эстакадага күтәрелә барган саен, тачка авырлыгы артка этә. Ә арттагы тачкалар синең тез астыңа сугып-куалап киләләр. Аз гына йөрешеңне акрынайттыңмы, артыңдагы тачка тез астына килеп керә дә, син тачкаң, грунтың белән түбән мәтәләсең. Ярый әле тачка бер якка, син икенче якка тәгәрәсәң... Әнә безнең бригадада өч кеше, эстакададан авып, тачкалары астында да калдылар. Берсе, башы изелеп, шунда ук үлде. Икесе, аяк-куллары сынып, больницада ята.

Эстакада янында зур мәйдан – забой. Андагы эскәмиядә участок башлыгы утыра. Ул – биектә. Бөтен забой аның күз алдында. Ул һәрбер тоткынның ничек эшләгәнен күреп, күзәтеп тора. Әгәр берәр мәхбүс ял итәргә утыра икән, эстакададагы рупор хәзер аны кузгата.

– Фәлән бригада! Штраф!

Димәк, бу бригада нормасына өстәмә рәвештә бункерга тагын ун тачка грунт җиткерергә тиеш! Шуның өчен бригада үзен үзе куалый, берәүгә дә эш вакытында, арыса да, авырса да, туктап торырга бирми – артык ун тачканы кемнең эсткадага күтәрәсе килә, бигрәк тә смена соңыннан.

Бөкрәеп, авыр тачканы көчкә-көчкә эстакадага менгереп килгән тоткыннарны участок башлыгы туктаусыз куалый:

– Әйдәгез, әйдәгез! Тизрәк!

Бу каһәр төшкән «әйдәгез!» йоклаганда да колагымда зыңлап тора торган иде. Әле хәзер дә, берәр кеше ул сүзне кычкырып әйтсә, тетрәнеп китәм. Җан куркып калган, күрәсең.

Бункер астында улак-бутара. Аның ике ягында зур агач көрәкләр белән коралланган бутарачылар. Алар агым су белән этелеп-юылып алга китеп барган ком, балчык, таш кисәкләрен бертуктаусыз арлы-бирле бутап, туктатмыйча агызып торалар. Бункердан төшкән грунт су белән улак буенча агып, чайкалып, юылып бара да бутара очындагы чүплеккә төшә, тау булып өелә бара.

Тәүлегенә ике тапкыр, көндезге һәм төнге уникедә, бирегә аерым бүлек вәкилләре килә. Бу безнең өчен иң кадерле минутлар. Вәкилләр бутаралар төбенә утырган алтынны бушата, ә без үлеп забойларга сузылабыз...

Сезонның беренче көннәре безнең бригада өчен ярыйсы ук уңышлы булды. Йомшак комга туры килдек. Һәрберебез норманы арттырып тутыра бардык. Төп алты йөз граммлы икмәк паёгы өстенә өстәмә рәвештә Стаханов паёгы – өч тапкыр ботка, йөзәр грамм ипи кыерчыгы һәм берәр әчмуха хуш исле махорка бирә башладылар.

Ләкин бу рәхәт көннәр озакка сузылмады. Инде икенче удар декаданы да югары күрсәткечләр белән төгәллибез – Стаханов бригадасы исемен алабыз, беренче категория тәэминатка күчәбез дип куанып йөргәндә генә, безнең забой «яшел бака»га килеп терәлде.

Менә минем забой яшькелт бака кебек кабарып, күзәнәкләнеп ята. Бар көч белән басып көрәкне батырам да, кыйшайтып, яшькелт балчыкны көрәп алмакчы булам. Ә ул күәс чиләгендәге камыр төсле сузылып күтәрелә, өзелми. Аптырагач, «бака»ның күзәнәкле күзләренә ике аяклап басып, көрәкне суыра башлыйм – аяклар бата.

– Мадрид! – дип, ярдәмгә чакырам.

Күрше забойда эшләүче бригадир килеп, кулдан тарта башлый.

– Йә, йә, бер кулың белән көрәккә таян.

– Хәзер... Әй, атаңа нәләт төшкере, ЧТЗлар кала бит...

– Калмагае тагын... Әйдә, атла!

Забойдан көч-хәл белән чыгып, тачка артына ышыкка утырабыз. Минем забой чокырда, эстакададагы «рупор»ның күзе төшәрлек түгел.

– Карале, синдә берәр урарлык юкмы? Миндә кичә үк бетте бит... эч поша. Бу «бака» безнең актык канны суыра инде, – ди авыр сулап Мадрид.

Бушлат кесәләремне кайтарып, кагып-сугып, чүп-чары белән ике «кәҗә сыйрагы» урыйбыз.

Забой нәкъ кырмыска оясы – берәүләр бөкрәеп казый, икенчеләр, ашыгып, казылган грунтны тачкага тутыра, өченчеләр өеп тутырылган авыр тачка белән трапка – такта өстенә чыга, йөгерә. Ләкин бераз баруга, тачка тәгәрмәче, тактадан шуып, забойга төшеп китә. Ул тачкасын күтәреп куя алмыйча азаплана. Әнә ике тоткын тачкаларын ташлап сугышырга тотынды, мөгаен, узып китәм дигәндә, тачкалары эләгешкән. Шау-шу. Сүгеш. Кычкырыш... Бу тавышларның барысын басып, эстакададан

«рупор» акыра:

– Тизрәк кыймылдагыз! Тизрәк!

Забой өстендә күгелҗем эңгер, көтү-көтү булып мыжылдап торган сукыр чебен. Ә кояш сопка артына төшеп бара. Бөтен офык кызыл ялкын эчендә. Ниндидер бер куе кызыллык белән, шомлы бер шәүлә ташлап яна ул хәзер.

– Да... Испаниядә дә менә шулай янды... – ди күршем Мадрид, баеп барган офыкка карап.

Мин дә шул офыкка текәлеп уйланып утыра идем, сискәнеп борылдым.

Ул битлеген фуражкасына күтәргән дә, «кәҗә сыйрагы»н авызына капкан килеш, офыкка төбәлеп хәрәкәтсез калган, һәрвакыт мин аңа сокланып карыйм – матур кеше. Озынча буй, атлет гәүдә. Менә хәзер ул миңа кырын утыра. Аның профиле аеруча күзгә ташлана – туры борын, нык кысылган юка иреннәр. Түгәрәкләнеп чак кына алга чыккан ияк. Озынча битне ак төкләр баскан. Фуражка астыннан чал чәчләр күренә. Ә Мадрид миннән нибары биш яшькә генә олы бит. Аның чын исем-фамилиясе – Максим Петрович Жаворонков. Максим Петрович – очучы. 1936 елда генерал Франко республикага каршы фетнә күтәргәч, ул үз теләге белән Испаниягә китә һәм интербригада составында сугыша. Максим башка совет очучылары белән берлектә Мадрид күген саклый. Ул бик күп тапкыр Долорес Ибаррури белән очрашкан, һава сугышындагы батырлыклары өчен Испания Республикасы ордены һәм медальләре белән бүләкләнгән. Гвадалахара операциясендә фашист зениткасы аның самолётын яндыра. Максим Петрович парашаут белән ташланып котыла. Әмма җиргә төшкәндә аягын сындыра, шуңа ул хәзер дә бераз аксап йөри. Испаниядән яраланып кайтып бер ел торгач, аны шпион дип гаепләп кулга алалар. Хәрби трибунал Максим Петровичны үлем җәзасына хөкем итә – ул бер ай үлем камерасында һәр минут саен үлем көтеп утыра. Верховный Совет Президиумы бу җәзаны унбиш ел төрмәгә алыштыра. Менә шул үлем камерасыннан чыкканда, Максим Петровичның чәчләре ап-ак булып агарган була.

Максим Петровичның холкы салмак, һичбер вакыт кызып китми – сабырлыгы, акылы белән җиңә. Кайда булуын белеп алгач, аңа Мадрид кушаматы биргәннәр. Бөтен ла-

герь – тоткыннар да, иреклеләр дә аны Мадрид дип йөртә, чын исем-фамилиясен белүче, мөгаен, бик сирәктер.

Линкольннан бу Сусуман приискасына китергәч, мине өченче бригада чокырына урнаштырдылар да:

– Менә бригадир Мадрид, – дип таныштырдылар.

Шул көннән без бер-беребезгә иялəшеп киттек.

«Кәҗә тәпиләребез»не рәхәтләнеп суырып та бетерә алмадык, «рупор» (күреп өлгергән бит, җаһил):

– Өченче бригада бригадиры Мадрид, эстакадага! – дип акырды.

Озакламый Мадрид забойга кайтты. Без барыбыз аның янына җыелып, тынып калдык.

– Иптәшләр, – диде ул акрын гына... Битен сырып алган черкиләрне сыпырды, битлеген төшерде. Аннан, борчылып, башын күтәрде: – Безне «крутушка»га күчерделәр.

Сопка артына төшеп кояш баеды. Шунда ук көньяк кызарды. Таң ата башлады. Этләр өрә. Сүгенгән, боерык биргән тавышлар яңгырый. Нормасын тутырган бригадаларны зонага – ялга алып китәргә әзерләнәләр. Ә без, норманы тутырмаган бригада, «крутушка»да тәүлек буе – норманы тутырганчы – забойда калырга тиеш.

3

Менә инде өченче тәүлек «крутушка»да әйләнәбез. Көне-төне эшләсәк тә, көнлек норманы тутыра алмыйбыз. Куллар кабарып, канап бетте. Паёк алты йөз граммнан дүрт йөзгә төште. Баланда да сыекланды. Менә бит ул каһәр төшкән «яшел бака» ничек канны суыра.

Кояш тагын гадәтенчә сопка артына төшеп, кызарып баеды. Көньякта инде алсуланып таң беленә. Нормасын тутырган бригадалар зонага ял итәргә йокларга барырга җыена, ә без... Кинәт эстакададан тавыш:

– Өченче бригада, зонага!

Үз колагыма үзем ышанмыйм, саташаммы әллә дип, бригадирга йөгердем:

– Карале, Мадрид, син дә ишеттеңме? Безне дә зонага җибәрәләрме? Чынмы?

Мадрид, гадәттәгечә елмаеп, забоеннан чыкты:

– Бригада, зонага! Җыелыгыз.

Зонага кайткач, безне ашханәгә алып бардылар. Стаханов сые белән сыйладылар, баракка кайткач, берәр әчмуха махорка да бирделәр.

– Бу ни бу? Төшенмим, – дип, Мадрид янынарак авыша төштем. Без аның белән бер сәкедә янәшә ятабыз.

– Шаулама! – ди ул, пышылдап, аннан үрелеп колагыма гына әйтә: – Мәмәт углы ике самородок тапкан, өч йөз граммнар чамасында. Шуны акрын гына участок башлыгына төрткән.

Без шунда ук үлеп йоклап китәбез.

Дүртенче кичне зонага чакырмадылар. Тагын «крутушка» башланды.

– Тагын төпчек эзләргә кирәк, – ди Мадрид.

Аны табып кара! «Яшел бака», ләгънәт төшкере, аны тиз генә ычкындырмый. Тирән яшергән. Ә безнең куллар карарга чирканыч: кып-кызыл кан, чеп-чи яра.

Иллә мәзәк тә инде бу тоткын дигән халык. Үзе ач, үзе ялангач булуга карамастан, әллә нинди мәзәкләр уйлап таба, әллә нинди кызыклы кушаматлар уйлап чыгара. Хикәянең башында әйтеп узган, Колымага җиттем дигәндә икенче якка борылып сопка башыннан күтәрелгән кыяны «Бәхет төенчеге» дип атаганнар. Яхшы төенчек, казах халкының киез өе кебек күтәрелгән тау! Менә шушы «төенчек» эчендә мин дә бәхет эзлим, аз-азлап ул бәхетне таба да барам, ахрысы. «Бәхет» төшенчәсе төрле шартларда төрлечә үзгәрәдер, күрәсең. Мәсәлән, менә бүген иң зур бәхет – туйганчы ашау һәм кесәдә хуш исле махорка булу. Ә алар миндә бар. Миңа Стаханов сые бирәләр. Каян ул дисезме? Аны миңа менә шушы «Бәхет төенчеге» биреп тора әле. Монда ничек килеп эләктемме? Теге «яшел бака»да инде бер атнадан артык азапланабыз – норма да юк, самородок та күренми. Бригада хәлдән тайды, көчкә йөрибез. Эстакададан «рупор» бертуктаусыз камчылый:

– Өченче бригада, тизрәк кыймылда!

Арысам да, соңгы көчемне җыеп, забой кырыен кырып, тачканы тутырып, трапка чыктым. Мин алга омтылам, хәлсез аякларым артка китә, ә арттан тез астымны сөзеп, бастырып киләләр. Тагын «рупор»:

– Өченче бригада! Өченче бригада, кыймылда!

Ниһаять, эстакадага якынлаштым, инде соңгы борылышка күтәреләм дигәндә, әллә таеп киттем, әллә этеп җибәрделәр, тачкам тәгәрмәче траптан чыкты, кыйшайды. Авып киттем.

Күземне ачсам, ниндидер ташландык бер забой. Торып китим дип кузгалган идем, җаным чыгып киткәндәй кычкырып җибәрдем, сул янбашым кузгалырга бирми, хәлсезләнеп тагын яттым. Бит-күзне сукыр черки сырып алды. Кычытынуга, әрнегәнгә чыдап булмый. Өстерәлеп булса да, үргә, җил якка чыктым. Черки таралды. Янбаш та әүвәлге кебек сызламый. Утырдым. Кайда мин? Артымда тау күтәрелгән. Бу бит «Бәхет төенчеге». Аны инде барлык ягыннан кимергәннәр, хәтта әнә кояш чыгыш ягыннан эченә тишеп кергәннәр, әйтерсең лә Әбүгалисина яшәгән мәгарә. «Бу да бик җайлы забой. Әмма җимерелү куркынычы бар дип япканнар. Эшләтмиләр», – дигән иде бит Мадрид миңа беркөнне.

– Ах син, үләксә, инде монда постыңмы?

Башымны күтәрүгә коелып төштем – түрә!

– Бас аягыңа!

– Гражданин начальник, – көч-хәл белән тордым, – мин эстакададан егылдым.

– Анысын күрдем. Бәлки, син юри егылгансыңдыр?

– Тачка тәгәрмәче...

– Җитәр! Марш забойга!

– Гражданин начальник, – әллә кайдан телемә бу сорау төште, – монда, менә бу забойда эшләргә рөхсәт итегезче?!

Участок башлыгы, болай карауга усал күренсә дә, вакыт-вакыт йомшап китә торган гадәте бар иде. Минем соравым фәрештәнең «Амин!» дигән мизгеленә туры килде, ахры. Ул сүгенмәде, аз гына бөкрәя төшеп, күзләремә текәлде:

– Курыкмыйсыңмы?

– Башны югалткач, чәч өчен елау файдасыз.

– Молодец! – диде начальник кинәт, көлгән сыман итеп авызын ерып. Мөгаен, бераз спирт төшереп алган. – Туры әйткән кешене яратам. Тик менә нәрсә, үз кулың белән гариза язып, баш инженерга илт. Алай-болай булса, безгә җавап бирерлек булмасын! Төшендеңме?

Икенче көнне баш инженер минем гаризаның кырыена кызыл карандаш белән: «Үз үтенече буенча «Бәхет төенчеге»ндә эшләргә рөхсәт итәм», – дип сырлап бирде. Мин шул көнне үк бу забойга күчтем.

Эстакададан егылгач, ничек «Бәхет төенчеге» яны-

на килеп әләгүемне бары тик икенче көнне генә белдем. Траптан егылганда өстемә тачка төшкән. Мин аңымны югалтканмын. Артымнан килгән безнең бригада тоткыннары Мәмәт углы белән Василь Петренко мине култыклап тау итәгенә алып барып салганнар. Анда бит, эстакада астындагы кебек, су эчендә ятмыйсың, коры җир.

Миңа, казах илендә туып үскән кешегә, бу яңа забой ошап китте. Ул киез өй кебек гөмбәзләнеп утыра. Эче дә киез өй кебек киң. Нәкъ түбәдә төнлек кебек, якты төшеп тора торган тишеге дә бар. Иң рәхәте – кәйлә белән бер суксаң, бер тачка грунт ишелә дә төшә. Ташып кына өлгер. Бу сопка – тулаем боз булып каткан ком тавы. Түбәдәге төнлекне япсаң, ком эчендә ялт-йолт килеп алтын ясмылары яна.

Эшләрем майлаган арба кебек тәгәри. Казуы да җиңел. Бункер да якында гына. Төшкә хәтле норманы – йөз тачканы чыгарам да ашап алам. Ял иткәннән соң, тагын утыз-кырык тачка стахановча ташыйм. Башкалар исә әле һаман «яшел бака»дан чыга алмый. Иптәшләремә анда-санда, үземнән арттырып, икмәк, балык һәм махорка биреп торам.

Әле дә хәтеремдә: Колымада сирәк була торган кояшлы, җылы көннәрнең берсе иде. Мондый аяз көннәрдә үзеңне ничектер җиңел хис итәсең, эш тә әллә ни арытмый. Кояш күтәрелгәнче ярты норманы эшләп ташладым. Инде тагын бер рейс илтәм дә тәмәке тартырга утырам дип, тачканы куыштан ук йөгертеп чыгып килә идем – бригадир. Чак кына үзен бәреп екмадым. Ярый әле ул тачканы ике кулы белән тотып терәп калды.

– Тукта! – Үзе башын чайкап көлә. – Кара бу ударникны, әллә инде мотор куйганнар үзеңә.

– Ә ничек уйлыйсың? – Тачкадан кулларымны ычкындырдым. – Стаханов паёгы! Әйдә, югары чыгыйк. Нишләп болай бик иртә?

– Беләсеңме, – Мадрид тачка яныннан кысылып үтеп яныма килде дә кулын җилкәмә салды: – Беләсеңме, бездә сөенеч.

– Ничек? Нәрсә булды?

Аптырап калдым. Мадрид балкып тора. Күзләре зур булып ачылган – зәңгәр чаткылар. Гадәттә тонык йөзендә хәзер алсулык. Сакал-мыек кырылган. Иреннәрендә – ел-

маю. Бу ни булган? Беренче тапкыр мин аны шундый шат күрәм...

– Нинди сөенеч? Ни булды, әйт әле?!

– Хәзер... – Максим Петрович, аксый төшеп, куышка таба борылды, мине кулдан тартты. – Әйдә, мәгарәңә керик. Монда нәкъ «карга»ның күз алдында.

Мин тачканы кире куышка тартып керттем – күренеп тормасын. Берәрсе килеп тә җитәр.

– Кара, монда салкынча икән, рәхәт.

– Йә, сөйлә инде, нинди сөенеч китердең?

Ул тачка өстенә утырды. Мин аның каршына, ком өстенә, кырын яттым. Бу кадәр сузуына эчем поша башлады.

– Йә, сузма инде.

– Беләсеңме нәрсә, миндә бүген ике сөенеч. Беренчесе – бер сәгать эчендә өч «төпчек» таптык.

– Шулаймы?! – Мин торып утырдым. – Кемнәр тапты? Үлчәдегезме?

– Мәмәт углы, Петренко, соңгысын, иң зурысын, яңа килгән комиссар Габдрахманов тапты. Бизмәнгә аскан идек, биш йөз граммлы паёкны басып китте.

– Менә шәп... Димәк, ярты килодан артык. Инде кая куясыз аларны?

– Бригадны җыеп шыпырт кына киңәштек. Мин дәүләт фондына бирергә тәкъдим иттем.

– Шуннан?

– Шуннан киңәштек. Гомумән, бригада самородокларын дәүләт фондына бирергә каршы түгел. Ни әйтсәң дә, бригадада барысы да элекке коммунистлар. Ләкин куркалар.

– Кемнән?

– Кемнән булсын, участок башлыгыннан. Мәмәт углы әйтә, әгәр без яхшы забойда булып, норманы тутырып барсак, бер хәл иде. Ә бу «бака»да инде ике декада норма тутыра алмыйбыз, әлегә теге вакыттагы «төпчек» саклап килә. Әгәр мондый зур калҗаны дәүләткә бирсәк, башлыкның җаны чыгачак. Шул көнне үк ул, үч итеп, алтынны аңа бирмәгән өчен, бригаданы трибуналга тапшырачак, ди. Үзең беләсең ич, былтыр беренче бригада ике йөз грамм булыр-булмас самородокны конвой командирына биргән өчен, «рупор» аларны, норманы тутыра бару-

ларына карамастан, айдан артык штраф паёгында тотты.

– Әй-йе... Ул андыйны булдырыр.

– Мәмәт углын башлыкка җибәрдек. Миңа барырга кушканнар иде, – Максим Петровичның йөзе караңгыланып, сул кабагы дерелдәп китте, – баш тарттым. Мин андый шкурниклар белән сөйләшә алмыйм. Алар дәүләтне түгел, үзләрен кайгырта.

– Анысы шулай инде. Йә, ә бригада нинди «калым» сорый?

– Нинди булсын, «бака»дан коткаруны.

Башка забойга күчерсә, анда без үз көнебезне үзебез күрә алабыз.

– Алтын күрсә, фәрештә аза, диләр бездә.

– Ә безнең начальник күптән азган... Бәлкем, бригаданың күзе ачылыр. Ә икенче сөенеч?

Максим Петрович җавап бирмәде – тачка өстеннән торып, куыш буенча арлы-бирле йөри башлады.

Гадәттә, болытлы көннәрдә бу куышта караңгы, күз ияләнгәнче тачканы да күреп булмый иде. Ә бүген төнлектән әйтерсең лә алтын багана сузганнар. Тирә-як япякты булып тора. Ә янып торган багана эчендә тузан, черки, чебен... Максим Петрович арлы-бирле үткәндә, багана сүнә, аннан тагын кабынып китә...

– Икенчесе нинди сөенеч дисеңме? – Ул гаҗәеп бер ихлас күңеллелек белән елмайды, каршыма утырды: – Зур сөенеч. Бүген кызым Дилорис төшемә керде. Муенымнан кочаклаган да, әти, нигә мине тәбрикләмисез, миңа бит бүген дүрт яшь тулды, ди. Уянып киттем. Чыннан да, бүген аның туган көне бит, – ул авыр итеп көрсенде. Аның әле генә яктырып-сөенеп янган күзләрендә яшь тамчылары. Авыр көрсенү. – Мине кулга алганда аңа әле бер ай да юк иде... – Тынлык һәм кинәт сызланып чыккан йөрәк тавышы: – Йа Алла, кайда ул хаклык?!

Мин, сискәнеп, артка чигендем. Максим Петрович, акылдан язган кеше кебек сикереп торып, забойның почмагына барып капланды да үксеп елый башлады.

Мин нишләргә белми аптырап калдым.

Бераздан ул аңына килгәндәй булды, куллары белән күзләрен уды, акрын атлап, аксап, тачка өстенә килеп утырды.

– Гафу ит, үз гомеремдә беренче тапкыр... – Ул

почмакка текәлеп уйга калды. Фуражкасы җирдә ауный. Утыз биш яшьтәге ирнең чал чәчләре җем-җем итә. – Яздым, – кинәт Максим Петрович миңа таба борылды: күзләре кызарган, ачу-нәфрәт белән тулган, – Верховный Советка яздым. Сталинга яздым, тикшерегез: мин дошманмы-юкмы? Мин – шахтёр баласы. Атам каторгада үлгән. Үзем үз теләгем белән Испаниягә киттем, Республика өчен сугыштым, чак кына үлемнән калдым. Йә әйт әле, син дә совет кешесе, язучы бит. Мин совет халкының дошманы була аламмы соң?

Нәрсә диим? Мин үзем дә шундыйларның берсе. Икебез дә башларыбызны идек.

– Беләсеңме нәрсә, дус, – Максим Петрович минем янга, забойга күчеп утырды, инде ашыкмыйча, үз-үзенә әйткән сыман салмак кына сөйли башлады: – Верховный Совет та, Сталин да минем гаризаларга җавап бирмәде. Белмим, бәлкем, аларга барып җитмәгәндер хатларым. Инде беләсеңме кемгә язарга уйлыйм? Дугласка!

– Дугласка? – Мин аптырап калдым. – Ничек? Америка киноартисты Фербенксскамы?

– Кара әле, мин сиңа генерал Дуглас турында сөйләмәдеммени?

– Юк, беренче тапкыр ишетәм андый генерал турында. Кем соң ул, американмы?

– Юк ла, үзебезнең совет кешесе. Дуглас – кушамат, чыны – Яков Владимирович Смушкевич[1]. Авиация генерал-лейтенанты, ике мәртәбә Советлар Союзы Герое.

– Һаман төшенмим, нигә Дуглас?

– 1936 елда генерал Франко Испания Республикасына каршы фетнә күтәргәч, бик күп совет кешеләре, үз теләкләре белән Испаниягә барып, интербригада оештырдылар. Ә генерал Смушкевич анда Хәрби авиация министрлыгында баш киңәшче була. Үзе турыдан-туры сугышларда катнаша һәм җитәкчелек итә. Мин дә аның кул астында, интербригада составында сугыштым. Мадрид янында без Муссолининың атаклы «Кара ялкын», «Алла көче» һәм «Кара каурыйлар» дивизияләрен тар-мар ит-

---

[1] Нәкъ менә шушы көннәрдә, Бөек Ватан сугышы башланудан ике атна гына элек, СССР Хәрби һава көчләре башлыгы Яков Владимирович Смушкевич кулга алына һәм «халык дошманы» дигән яла белән атып үтерелә.

тек. Бу операциядәге батырлыгым өчен генерал Дуглас үзе саф алдында мине алтын сәгать белән бүләкләгән иде... – Ул, сүзен бүлеп, почмакка таба атлады һәм борылып килде. – Кара әле, тәмәкең бармы? Миндә бетте, күп тарттым, ахрысы, бүген.

Мин тәмәке янчыгымны чыгарып тачка өстенә куйдым. Ул кесәсеннән бик пөхтә итеп өчпочмаклап киселгән кәгазь чыгарды. Икебез дә сүзсез генә «кәҗә сыйраклары» урадык.

– Йә, ярый, мин учакка барып кабызып килим. (Тоткынга шырпы йөртү рөхсәт ителми.)

– Мадрид! – дидем мин. – Беренчедән, синең аягың авырта. Икенчедән, син – минем кунак, өченчедән – мин яшьрәк... Үзем генә йөгерим...

Ул елмайды.

– Алайса, бар, йөгер... Мин чынлап та арып торам... Аннан соң бригадир кешегә учактан учакка йөгерү килешмәс.

Мин куышның ишегенә – тишеккә таба атладым.

– Тизрәк, үлеп тартасым килә. Аннан Гвадалахара операциясе турында, Дугласның батырлыклары турында сөйләрмен.

– Хәзер.

Куыштан чыгып, Колыма яры буенда төтенләп торган учакка таба йөгердем. Кинәт артымнан нәрсәдер кыштырдаган, төшкән төсле булды. Туктап борылдым. Эчем жу итеп китте. Йөрәгем тибүдән туктады кебек. Катып калдым. «Бәхет төенчеге» ярылып, ишелеп төшеп килә.

– Мад-рид!..

Җан тавышым белән кычкырып җибәрдем. Ләкин, минем тавыш барып җиткәнче, куышның ишеге ишелеп ябылды.

БӘЙРӘМ БҮГЕН

1

– Гыйлемдар абый, нәрсә анда пыш-пыш киләсең, әллә дога укыйсыңмы?

– И туганым, догадан да изгерәк – Габдулла әфәнде Тукаевның шигырьләрен укыйм. – Күршем, бушлатын башына ук тарта-ябына төшеп, миңа якынрак шуышты. – Гаҗәби хәл, туганым. Эчем пошканда аның шигырьләрен

укысам, күңелем яктыра да китә. Хафаларым тарала. Менә, туганым, тыңла әле, нинди изге, шифалы сүзләр:

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бу шигырьне мин үзем дә яттан беләм. Мәктәптә укыган чакта, Октябрь бәйрәме көннәрендә бу шигырьне сәхнәгә чыгып сөйләгәнем дә бар иде әле. Мин үзем нигәдер ашыгып, сүзне сүзгә чәкәштереп сөйлим. Шуңа, ахры, шигырьнең тәме, нуры китә. Ә менә Гыйлемдар абый ашыкмый – һәр сүзне туп-тулы итеп, тәмләп әйтә, әйтерсең кызарып пешкән хуш исле алмалар өләшә:

Бер мөкаддәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген...

Гыйлемдар абыйны әйтәм, үзе болай әллә ни күзгә ташланып тора торган дәү кеше түгел – вак сөякле, чандыр. Һәрвакыт пөхтә итеп түгәрәкләп кырылган ап-ак сакал аның яхшы ук шадра битенә ямь биреп тора. Инде алтмыш яшькә җитеп килүенә карамастан, хәрәкәтчән, җитез, терекөмеш сыман тәгәрәп кенә тора. Шуның өчен начальниклар да үзенә яхшы карый – кулайрак эш бирә. Хәзер ул – конвойның утагасы, ягъни Прометее. Ул конвойга учак яга, чәй кайната. Алтмыш градус суыктан шыңлап торган Колыма забойларында моннан да «блатной» эш булуы мөмкинме соң? Җитмәсә, конвой өстәленнән әз-мәз сынык-санык кала.

– Күрше, менә бүген дә тегеләрнең чәйнекләрен бераз кыстым. – Ул чүпрәккә төргән чәй-төпчекләр суза. – Берәр төшкә яшереп куй. Бәйрәм көнне, Алла язса, тәмләп чәй эчәрбез. Мин инде сынык-саныкны киптерә башладым...

– И Гыйлемдар абый, безгә нинди бәйрәм инде. Без бит халык дошманнары...

– Юк-юк, туганым, бер дә алай дип күңелеңне төшермә, хаклык җирдә ятмый. Бер көн килер, сизми дә калырсың.

2

– Мин бүген бытовикларга ял бирдем. Аларга бәйрәм. Октябрьнең егерме өч еллыгы. Иң зур бәйрәм. Ә сез?! –

Начальник колоннаның алдыннан бер уңга, бер сулга ашыгып атлап узды да уртада туктап калды. Башын күтәрде. Чекерәйгән зәһәр күзләре белән бораулап карады. Аның өстендә биле бөрмәле озын кара тун. Башын-

да – кама бүрек, аякларда – киез итекләр. Үзе кысла төсле кызарган, мөгаен, бәйрәмне «котлап», иртә белән үк бераз «төшереп» чыккан.

Ә без?

Кичә кичен конвой барак ишегенә йозак салгач, инде иртәгә дә ачмаслар дип куанган идек. Өметебез акланмады – бүген чаңны көндәгегә караганда да иртәрәк актылар. Урыннарыбыздан торып өлгермәдек, баракка, һауһаулап, этләр атылып керде. Сәкедә калганнарны тешли, талый, өстери башладылар.

– Бүген иртәнге аш юк сезгә. Туры вахтага! – диде конвой начальнигы, суганлап-борычлап сүгенгәч. – Сезнең аркада безгә дә ял юк. Контрлар, үләксәләр, хәшәрәтләр, тизрәк селкенегез!

Вахта алдына килеп тезелдек.

Чатнама суык. Тын алып булмый, салкын һава бугазны кыса. Без генә түгел, йолдызлар да калтырана кебек. Баскан урында түзеп тора алмыйбыз – тыпырдыйбыз. Мөгаен, алтмыш градус бар бу зәмһәрир суыгы. Калтыранмаслык та түгел бит. Өстә – иске, таланып беткән бушлат, шундый ук эт талаган чалбар. Башта чүпрәк бүрек. Аякта ЧТЗлар.

– Ә сез – халык дошманнары, – начальник, тамагын кырып, тагын бер-ике адым алга атлады, туктады, – сез – Октябрьнең дошманнары. Менә ни өчен сезгә бәйрәм юк. Үзегезнең кара җинаятегезне аз гына булса да аклар өчен, сез бүген забойда ике норма бирергә тиешсез. Бу приказны үтәмәгән контр кичен зонага кертелми. Туптуры карцерга! Төшендегезме?!

Колонна үлгән төсле эндәшми. Бары шыгыр-шыгыр иткән аяк тавышлары гына ишетелә. Начальник арлы-бирле атлый. Колонна өстендә өшегән йолдызлар калтырый, салкын һава шарт-шорт итә.

– Конвой! – Һава шыңлап китте. – Халык дошманнарын эшкә!

Этләр өрә башлады.

Шыгырдап, зонаның тимер капкасы ачылды.

– Беренче рәт, алга!

– Беренче рәт, тезлән!

Зона капкасыннан чыгып, бер ун адым атладык та шыгырдап торган карга тезләндек.

– Икенче рәт, алга!

Икенче рәт безнең артка килеп тезләнә.

Тик торудан иреккән-туңган этләр, һау-һаулап, зонадан чыккан һәрбер тоткынга ташланып күңел ачалар. Конвоирларга да юаныч. Бозау хәтле берәр эт көчкә атлап килгән берәр тоткынны төртеп екса, талый башласа, рәхәтләнеп көләләр. «Самородок, әйдә, бир контрларның кирәген!»

– Аягүрә басыгыз!

Ниһаять, өч рота чыгып бетте бугай. Конвой башлыгы колоннаның алдына чыкты:

– Кем алга чыга, кем артка кала, кем колоннадан читкә чыга – качарга җыену дигән сүз. Атачакбыз. Аңлашылдымы?

Тынлык.

– Марш, халык дошманнары, забойга!

3

Суык көчәйгәннән-көчәя бара, ташлар шартлап ярыла, һава калтырый. Сулыш киселә, тын алып булмый. Ә авыздан чыккан пар шундук шартлап ярыла. Гаҗәп! Колымага беренче килгән көннәрдә мин, бу хәлгә аптырап, тирә-якка карана-эзләнә идем – кем соң анда шулай шарт-шорт итә? Хәзер инде күнектем. Юк, суыкка түгел, йолдызлар «пышылдавы»на. Ә суык үзәккә үтә – көйдерә. Аз гына кузгалмый хәрәкәтсез торсаң, хәзер сын булып катып каласың... Бу зәмһәрир суыгы – җылы яктан монда эләккән иптәшләргә: үзбәкләргә, таҗикларга, азәрбайҗаннарга һәлакәт. Алар ломнарын тоткан килеш басып торалар-торалар да кинәт авалар... Кич белән сменадан кайтканда аларны чанага салып алып кайтабыз да зона каршындагы тәрәзәсез, ишексез баракка – үләт җыя торган урынга кертеп ташлыйбыз.

Мин – балта остасы малае. Кече яшьтән эшләп үстем. Өстәвенә мин бит Себер кешесе, суыкларга күнеккән, «кояш баласы» түгел. Шулай да бу суыкка, Колыма суыгына күнегеп-түзеп булмый, үрле-кырлы сикерәм. Ломны кулга алып җиргә суккалыйм.

Мин суккан саен, корыч лом, зыңлап, җирдән сикереп китә. Шурф әле ярты тирәнлегенә дә җитмәгән. Ә аны бер метр тирәнлектә казырга кирәк. Ә бүген бәйрәм хөрмәтенә ике шурф казырга.

Җир корыч кебек каты, кителеп-кителеп кенә кала. Иске-москы чүпрәкләрдән ялгаштырып теккән бияләйләрем шакырдап каткан. Кул өшегән, бармаклар тырпайган. Аяктагы ЧТЗлар да, чын трактор табаннары сыман катып, борыннарын күтәргәннәр, кузгалган саен шак-шок киләләр. Лом, зыңлап, кулны, иңбашларын яңгыратып төшеп китте. Мин бер урында тыпырдыйм. Кулларымны үземә шап-шоп сугып җылынырга тырышам. Ә суык аның саен каныгып өтә генә.

– Туганым, менә бераз табыш алып килдем...

Карасам, яр астыннан, кар-бозны чукып эшләнгән баскычтан, Гыйлемдар ага күтәрелеп килә. ЧТЗларын көчкә-көчкә авыштыра.

– Уф, кулыңны бир әле...

Мин, йөгереп барып, кулымны суздым. Бармаклар тырпайган, бөгелмиләр. Гыйлемдар аганың куллары алай ук бирешмәгән икән, тотып алды. Тартып чыгардым.

– Мә, мә, туганым, теге газраилләр күргәнче яшер. – Гыйлемдар ага, учак янында җылынып, чәй эчеп утырган конвоирларга карый-карый, чүпрәккә төргән төргәкләр суза. Бусы – икмәк калдыклары, бусы – төпчекләр, бусы... – ул нигәдер аз гына елмаеп алды, – чәйнекләрен сыктым, чәй чамасы, кичен кайткач, бергәләп бәйрәм чәе эчәрбез, яме, туганым...

Гыйлемдар ага сүзен әйтеп тә бетерә алмады, учак ягыннан кычкыра да башладылар:

– Әй, су ташучы! Кая олактың, чәйнек бушады?!

– Нәләт төшкерләре, бугазларына көйдерге чыккыры. – Гыйлемдар ага ачулана-сүгенә, ашыгып төргәкләрен миңа ыргытты да, тиз генә чүгеп, кар өстеннән шуышып, ярдан түбән төшеп тә китте.

Ул арада төньяктан җил күтәрелде. Ак өермәләр өерелә башлады...

4

Буран бөтен забойны урап алды. Ажгырып суга. Аягүрә басып торып булмый.

– Беренче рота, уңга! Тукта!

– Икенче рота!..

– Өченче рота!..

Конвой башлыгы, ютәлли-ютәлли, соңгы боерыгын бирде:

– Колонна, утырырга! Кем дә кем кузгалса, качарга омтылу хисаплана, кисәтүсез атыла... Конвой! Колоннаны чылбырлап урарга! Этләрне бушатырга! Марш!

Тезген җебенең бушавын сизүгә, этләр кырыйда утырган тоткыннарга ташландылар – йолыккалый башладылар. Кемдер, эт тешләвенә чыдый алмыйча, ахры, сикереп торды.

Шундук мылтык шартлады.

Әле генә күтәрелгән озын буйлы егет авып төште.

Җил көчәйде.

Без инде көрткә күмелә башладык...

Кичкә таба буран басылды. Безгә инде кузгалырга, аягүрә басарга рөхсәт иттеләр. Әмма күпләр тора алмады. Кайсы аягын, кайсы кулын өшеткән, ә кайберәүләр бөтенләй таш булып каткан. Минем дә сул аяк өши язган иде. ЧТЗ эчендә көч-хәл кыбырдата-кыбырдата җан керттем. Гыйлемдар ага алып килгән сынык-санык та эләккәч, кан йөреше көчәйде, ахры. Бастым.

Кайтырга җыена башлаганда, конвой башлыгы безнең бригадирны чакырып нидер әйтте дә яр астына – Колымага таба кулы белән төртеп күрсәтте. Бригадир, ике тоткынны алып, шунда төшеп китте.

Озакламый алар боз булып каткан берәүне, күтәреп алып килеп, колонна алдына салдылар. Үрелеп карауга тетрәнеп киттем: анда... минем Гыйлемдар абый ята иде...

Колонна акрын гына зонага таба атлый. Туң кар атлаган саен шыгыр-шыгыр килә. Артта өч чанада мәетләр. Бишесе – төрле роталардан туңып үлгәннәр. Ә алтынчысы – су ташучы Гыйлемдар абый. Ул калын тимер кыршаулар белән тарттырылган агач чиләк белән су күтәреп ярдан менгәндә аягы таеп китеп егылган да, башына теге авыр агач чиләк төшкән икән.

Мин чана өстерим. Анда Гыйлемдар ага. Ул үзенең зур яшькелт күзләре белән күккә караган да, пышылдап, «Бәйрәм бүген!» ди сыман...

КАРА САКАЛЛЫ КЕШЕ

1

– Ха-ха-ха!

– Ха-ха-ха!

Сискәнеп, куркып уяндым. Бу нинди тавыш? Чыннан да көләләрме? Әллә! Әллә инде акылдан шашалар? Колыма лагерьларенда инде дүрт ел йөреп, беркайчан да болай тавышланып көлүне ишеткәнем булмады ич. Җитмәсә, бу бит әле санбаракта – җыен авырулар арасында! Гаҗәп! Күзләрем ачылыр-ачылмас шул сәер тавыш килгән якка борыла башлаган идем, сыным катты – әле генә (инде ике тапкыр) киселгән сул аягым тагын да чатнап сынгандай булды, аңымны югалттым.

– Ха-ха-ха!

Колакта һаман шул ук сәер тавыш. Ниһаять, тагын күзләремне ачтым. Маңгайда бөрчек-бөрчек салкын тир! Инде чүпрәк белән уралган, сулкылдап-чәнчеп бәгырьне телгәләп торган сул аякны кузгатмыйча гына, башымны тавыш килгән якка борып, барак эченә күз ташладым. Чыпта түшәлгән ике катлы сәке-сәндерәләр. Ярым караңгы озын барак. Каршы як стенадагы ике тәрәзәнең рамнары да күренми, бозланып каткан, хәтта тәрәзә яңакларын кар сарган. Күрәсең, тышта тагын буран-җил ыжгыра. Барак вакыт-вакыт селкенеп куя, менә-менә очып китәр сыман. Уртадагы тимер мич сүнгән, санитарлар бүген утынга бармаган. Суык. Җил тәрәзәгә килеп сугылуга, рамнар дерелдәп, болай да күшеккән тәнне сискәндерде. Менә шушы инде ул Линкольн алтын приискасындагы тоткыннарның җан саклау урыны – санбарак. Суык һәм шомлы. Әмма нигә соң авырулар барысы торып утырганнар да миңа таба караганнар? Барысының да авызы ерылган, әйтерсең бер чүмеч өстәмә ботка чәпегәннәр.

Тагын сискәнеп, калтыранып киттем – зур бер куык шартлагандай булды.

– Ха-ха-ха!

Нәкъ минем каршыдагы сәкедә яткан башкорт егете Фәнун торып утырган да бөгелә-бөгелә көлә, терсәктән киселгән чулак куллары, бер күтәрелеп, бер төшеп, буш калган күлмәк җиңнәрен арлы-бирле җилфердәтә, әйтерсең лә ак әтәч киртәгә менеп канатларын кага. Уң ягымдагы ике аягы да бот төбеннән киселгән белорус Гриша – бригадир – мендәренә капланып ук яткан, җилкәсе сикереп-сикереп китә. Бу ни хәл? Нәрсә булган соң боларга?

Ул арада шау-шу, пырхылдау акрынлап басыла төште.

– Әйе... шуннан, – Фәнун, чулак куллары белән күзләрен уып, яшьләрен сөрткәләп, кемгәдер сорау бирде: – Теге егет нишли?

– Җитәр, каркылдашмагыз! – Өстән берәү җикеренеп куйды. – Кешегә сөйләргә бирегез, каргалар!

Кемгә эндәшә соң ул? Кемне сөйләргә чакыра? Башымны сул якка бордым да имәнеп киттем – бу кем тагын? Күршем Герман кайда? Аның урынында бөтен битен кара сакал баскан, тузган кара чәчле таныш түгел ниндидер бер ят кеше ята. Өстенә одеял да ябынмаган, күлмәкыштаннан гына. Ачык күлмәк изүеннән кара йон белән капланган киң-калку күкрәк күренә. Гәүдәсе тулы, гадәти тоткынга охшамый, кипкән балык түгел. Үзе, Көнчыгыш халыкларына хас иркенлек белән аякларын бөкләп, одеял өстенә утырган. Куллары исән-сау. Аяклары исән-сау! Гаҗәп! Җыен гарип арасына нишләп килеп кергән? Эчем жу итеп китте – мөгаен, «стукач»! Юри, ни сөйләрләр икән дип, безнең арага ташлаганнардыр. Телне теш артында тотарга кирәк бу хаин янында! Кара, мәлгунь, мәхбүсләрне сатып ничек симергән!

– Шуннан... – теге Карасакал, алдында яткан мендәрне изеп-бөкләп терсәк астына салды да, ярым кыйшаеп ятып, миңа аркасы белән әйләнеп, сүзен ялгады. Тавыш көр, яңгырау. Ниндидер чит милләт акценты ишетелеп кала. Ашыкмый, белеп, вәкарь белән, һәрбер сүзен әйтеп бетереп, мавыгып сөйли, – шуннан... Шаһзадә камыш арасыннан үрмәләп, күренмичә генә яр читенә килә дә, күлдә коенып йөргән теге пәри кызларының күлмәкләрен урлап алып, кире камыш арасына яшеренә.

– Вот егет! – Гриша, мендәреннән күтәрелеп, шуышып, сәке кырыенарак килеп утырды, – булдырган, шулай кирәк.

– Бүлдермә әле, нәкъ кызык җирендә!

– Шуннан... – Карасакал, бу шау-шуга, сүз атышуга бөтенләй игътибар бирмичә, хикәясен дәвам итте: – Коенып, су чәчрәтеп уйнап арыгач, пәри кызлары, күлдән чыгып, күлмәкләрен калдырган җиргә – камышлык янына йөгерәләр.

– Ә күлмәкләрдән җилләр искән, ә?

– Гриша, бүлдермә әле!

– Их, – Гриша бөтенләй сабырлыгын югалта, – их, күңел түзми, егетләр, кызлар искә төшкәч... Ярый, бетте, сөйләгез.

Тукта, мондый әкиятне кайда ишеттем соң мин? Юк, ишетмәдем, укыдым. Бу мәшһүр «Әлфе ләйлә вә ләйлә» («Мең дә бер кичә») китабындагы гүзәл әкиятләрнең берсе түгелме? Әйе, нәкъ үзе. Кара бу шомны, үзе «чагучы» булса да, кызыктырып сөйли. Тыңларга кирәк. Мин дә Карасакалга таба шуыштым. Аяк сызласа да, баягыдай чатнамый әле.

– Шуннан кызлар, чыр-чу килеп, шаулашып, күлмәкләрен эзли башлыйлар. Анда йөгерәләр – юк. Монда йөгерәләр – юк. Гриша әйтмешли, күлмәкләрдән җилләр искән.

– Менә минем сүз дә ярап куйды...

– Әй, бер кыстыбый инде син, Григорий, – Фәнун чынлап рәнҗеде. – Сөйләргә бир әле...

– Ә, мин нәрсә?..

– Шуннан, – теге көр тавыш шау-шуны җиңде, – күлмәкләр табылмагач, кызларның кайберләре елый да башлый. «Җитәр, эзләмәгез дә, еламагыз да!» – ди пәри патшасы кызы Шәмсебану һәм үзе, йөгереп, кире күлгә керә. Башка кызлар да аңа ияреләр. Шәмсебану, су эченә кереп, башын гына өстә калдыра да кисәтә: «Тәнегезне күрсәтмәгез, судан чыкмагыз, монда адәм исе килә. Сак булыгыз!» Кызлар үзе янына җыелып беткәч, Шәмсебану, ярга таба борылып, ачулы тавыш белән кычкыра: «Әй син, кызлар күлмәген урлаучы оятсыз адәм, чык монда! Күрен! Йә, күрик үзеңне, тагын нәрсәгә хәлең җитә икән, мескен адәм баласы!» Оятыннан җиргә сеңеп китәрдәй булган Шаһзадә, яшеренгән җиреннән чыгып, яр читендәге таш өстенә күлмәкләрне куя һәм Шәмсебануны баш иеп сәламли дә сөйли башлый: «Җиһанның гөле, галәмнең тулган ае, еллар буенча илдән ил гизеп эзләгән бәхетем, гүзәл Шәмсебану! Мин һич карак түгел. Мин – Бишек чүлендә ялгыз калып, әлсерәгән бичара гашыйк. Коткар мине бу җәфалардан, ханым-солтаным!»

Айның ундүртенче кичәсе кебек балкыган Шаһзадәнең йөзен күргәч, кызлар телсез кала. Шәмсебану да горур-тәкәббер башын түбән ия һәм: «Мин җиңелдем, – ди. Аннан кыюсыз гына: – Сез – ир кеше, шәрә

тәнле кызларның киенүләрен карап тормагыз, алар ояла», – ди. Шаһзадә кире камыш арасына кереп китә. Биш кыз, үз күлмәкләрен киеп, аккошка әверелә. Ә алтынчысы – Шәмсебану – күлмәксез. Таш өстендә аның гына күлмәге юк. Шәмсебану: «Күлмәгемне бирегезче», – дип елыйелый ялварса да, Шаһзадә аның күлмәген бирми.

– Дөрес эшли егет, – ди түземе беткән Гриша.

Ишек шыгырдап, чинап ачылды, ургылып кар бураны керде. Бераздан томан эчендә сырган бушлат өстеннән ак халат кигән санитар Тимка-Кадак күренде һәм, гадәтенчә, шундук кычкыра-җикеренә башлады:

– Бу нинди башбаштаклык?! Ятыгыз! Обход! – Ул өч-дүрт катлы лагерь сүгенүләре белән үзенең каралар өереннән булуын исбат итеп, түбәнге сәкедә утырган әле бер, әле икенче авыруны этеп-төртеп, кызганнан-кыза барды: – Контрлар, әле монда да корткычлык эшлисезме? М-мин, – ачуыннан тотлыга да башлады, – м-м-мин с-с-с-езне акылга өйрәтермен... Карцерга!

Әмма ул ахырынача җикеренеп, авыруларның котын алып өлгермәде, ишек шыгырдады. Барак тагын ак томанга тулды. Тимка, кемгәдер йодрыгы белән янап, «Тизрәк!» дип акырды да үзе шунда ук сәке кырыена басып үрә катты.

Ишектән, өс-башларын кага-суга, тирә-якка кар-боз чәчрәтеп, ике кеше керде. Алдагысы ак якалы, билле озын туннан, үзе мичкә сыман юан. Ул колакчын бүреген салып, селеккәләп, буранда кунган карны авырулар өстенә чәчте дә кире киде, кесәсеннән яулык чыгарып, битен сөртә башлады. Үзе кып-кызыл, әйтерсең яңа гына мунчадан чыккан. Аның артындагы кара бәрән тиресеннән тегелгән папаха кигән, йонлач постау пальтолы, озын чандыр ир күзлеген салып сөртергә кереште. Калын кара кашлар астында ачуташ күзләр, зур борын, кабарып торган кара мыеклар.

– Гражданин начальник, санбаракта җитмеш сигез авыру. Барысы да ята. Бүген өч мәет чыкты! Мин...

– Юләр! – Түрә аның рапорт биреп бетерүен дә көтмәде, ачулы тавыш белән бүлде һәм артында торган күзлеклегә җилкә аша гына эндәште: – Өч тәүлек карцер. Яз! Рапорт та бирә белми.

Әле генә бөтен баракның котын алып йөргән Тимка

изрәп төште.

Түрә, аңа игътибар да бирмичә, башын югары күтәреп, күкрәген булдыра алганчы калкытып, акайган хәрәкәтсез күзләре белән авыруларны чәнчеп, баракны әйләнеп чыкты да теге сыны катып басып торган санитар Тимка янына якынлашып туктады, күзлеклегә борылды.

– Бу әрәмтамаклар монда күпме хөкүмәт акчасын ашап ята инде? Забойда эш тукталып тора, доктор, ә?

– Гражданин начальник, болар бит авариядән соң... Аяк-кулсызлар...

– Алай булгач, алардан ни файда?

Врач, аптырап, җавапсыз калды. Начальник һаман шул ачулы кыяфәт белән арлы-бирле атлады да кинәт минем яндагы теге кара сакаллы кешегә текәлде, кычкырып җибәрде:

– Ә, Стоянов әфәнде! Нәрсә, син дә монда аунарга килдеңме?

– Юк, гражданин начальник. – Күршем торып утырды. – Аягыма агач төшеп яраланган идем.

– Менә... Ходай сине каргаган. – Начальник, бөтен баракны гаҗәпләндереп кычкырып көлде: – Син саран... саран... шуның өчен Алла аягыңа суккан, шулаймы, доктор?

– Бик дөрес, – диде артта торган врач, нигәдер иелә төшеп.

– Менә... менә... Ишеттеңме, Стоянов?! Инде аягыңа баскач алай саранланма.

Күршем Стоянов калтыранып китте. Түрә, кинәт башын күтәреп, өске сәкегә күз йөртте дә әле һаман катып басып торган Тимкага борылды:

– Ә бу ябалак нигә башыннан уранган? Башлыкларны яратмыймы?

Тимка-Кадак, сикертмәгә баскандай, сикереп өске сәкегә күтәрелде дә теге авыруның одеялын йолкып алды.

– Тор! – Шундук ап-ак булып, кире сикереп төште. – Гражданин начальник, ул инде «каткан».

– Юләр, хәзер үк моргка алып барыгыз. Начальник килмәсә, мәетләрне күрүче дә юк. Бу юләргә тагын ике тәүлек карцер өстә. Калганнарның паёгын кыскартырга кирәк. Тизрәк забойга чыгарлар.

2

Колонна башлыгының санбаракка обход ясау мис-

сиясе икенче көнне ук үзен сиздерде: гадәттә, авыруларга бирелә торган биш йөз граммлы паёк дүрт йөз граммга калды. Болай да тамак туймый иде. Ә хәзер? Менә кеп-кечкенә, чиле-пешле арыш ипиен кош тоткан сыман кысып торам, кулымны җәйсәм, очып китәр сыман. Чыннан да, бу кыерчыкны авызга якын гына китереп кара, хәзер юк булачак – ачлык түземне белми. Ә аннан егерме дүрт сәгать авызыңны шүрлектә тот.

Ул арада шыгырдап-чинап ишек ачылды да, Тимка һәм тагын бер санитар носилка күтәреп керде. Тимканың сөмсере коелган, күтәрелеп тә карамый, кичәгедәй җикеренеп кычкырмый да, мөгаен, карцерда йоклап чыккан. Хәзер менә мәетләрне алырга килгән. Тагын кемгә чират? Ишектән кергән суык белән әүвәле бернәрсә дә күренмәде. Бераздан томан таралды, югары сәндерәдән берәүне, өстерәп төшереп, носилкага салдылар. Ике ел бер забойда, алмаш-тилмәш бер перфораторда эшләгән дус – Морозны алып киттеләр.

Ул минем кордаш иде. Кулга алынганчы, Минскида республика комсомол газетасында әдәби хезмәткәр булып эшләгән. Шигырьләр язган... Икебез дә бер забойда ишелгән җир астында калдык. Икебезгә дә бер көнне ампутация ясадылар – минем сул аякны тубыктан кистеләр. Морозның ун аягын – балтырдан. Әмма икенче көнне үк икебездә дә гангрена башланды. Өченче көнне Морозга яңадан ампутация ясап, аягын бот төбеннән кискәннәр иде... Ә мине нинди язмыш көтә? Нәкъ шушы шомлы уйлар белән газапланганда, киселгән бот төбем сикереп-сикереп китә. Гүя аякка берьюлы йөзләгән энә кадыйлар.

Гадәттә, Колымада алтын ачык җирдә – приискаларда казыла, шахталар бик сирәк. Кырыгынчы елларда анда нибары ике-өч шахтада гына алтын казыйлар иде.

Гомумән, Колыма шартларында шахтада эшләү тоткын өчен ярты бәхет. Чөнки анда яз башлану белән кара болыт булып сарылып мәхбүснең җанын өтә торган, соңгы канын эчеп-агулап күбендерә торган комсыз чебен-черки юк! Кышын сөякләрне өшетә торган зәмһәрир суыклар тирән забойга хәтле барып җитә алмый. Монда – ышык! Өстәвенә, канга тоз салып, миеңне әйләндереп, туктаусыз «Әйдә, селкен!» дип кычкырып торучылар да юк!

Миңа менә шул бәхет көтмәгәндә насыйп булды. Бер

төнне йоклап яткан җирдән торгыздылар да безнең бригаданы, тулаем машинага утыртып, Линкольн приискасыннан Индигарка буйлап алып киттеләр. Кая? Белмибез. Ниһаять, иртә белән машинабыз бер тау итәгенә килеп туктады.

Бу шахта тыштан борын заманда кыргый кешеләр яшәгән мәгарәләргә охшый. Монда, гомумән, материктагы кебек вертикаль түгел, ә горизонталь шахталар. Артык биек булмаган ялангач-соры сопкалар итәгеннән эчкә таба тишеп-казып кергәннәр дә, бераз баргач, уңга-сулга борылганнар. Штреклар. Штрекның туктаган җирендә – лава. Димәк, нәкъ менә шушында инде алтын тамырлары.

Лава – ындыр табагы. Монда көне-төне перфораторлар гөрелдәве, кәйләләр чыңы, вагонеткалар чинавы, сүгенү, тузан-туфрак һәм ара-тирә җыр. Туган илне, еракта калган мәхәббәтне сагыну җырлары яңгырый монда. Өстә – забойда җырлап кара, хәзер карцерга юл тотарсың. Ә монда кем ишетә моңаюыңны?!

Билгеле, монда өстәге эштән җиңел түгел, киресенчә, авыр, уңайсыз. Лавалар биек түгел, алтын «тамырлары»ның катламына карап бер күтәрелә, бер төшә. Гомумән, басып түгел, бөкрәеп йөрергә, бөкрәеп эшләргә туры килә.

Һәр лавада – егерме-утыз кешелек бер бригада. Аның бер төркеме перфораторлар белән катламнарны тишә. Шурф ясый. Шартлатучылар килеп, ул шурфларга запал-аммонал сала һәм бикфорд шнурлары белән тоташтырып шартлата. Икенче төркем шушы ишелгән токымны – алтын комын – вагонеткаларга тутыра, өченче төркем, вагонеткаларга җигелеп, комны өскә чыгара, бутаралардагы бункерларга аудара. Менә шулай унҗиде-унсигез сәгать һәр көн – ай буенча, ел буенча, җәза вакытың тулганчы.

Колымада агачка кытлык! Шуның өчен монда штрекларда да, лавада да терәүләр сирәк, «түшәм»нәр, менә-менә ишелеп төшәм дип, калтыранып кына тора. Ләкин аңа игътибар иткән кеше юк...

Мороз безнең бригадага былтыр, көзге юл белән Магаданнан килде. Озын буйлы, чандыр, аксыл чырайлы егет. Ялкауланмый, кайда эш авыр, шунда үрелә. Ял вакытында сузып, онытылып белорус җырларын җырлый. Тавышы көр, моңлы. Менә шул сыйфатлары белән ул тиз арада бри-

гадада «үз кеше» булып китте. Ә миңа бигрәк тә. Чөнки ул да минем кебек, шигырьләр ярата, укый, яза. Мин атаклы украин шагыйре Тарас Шевченконың шигырьләрен бары тик русча тәрҗемәләре аша гына белә идем. Ә үз телендә ул бигрәк тә көчле, аһәңле яңгырый икән. Морозның әнисе – украин хатыны, шунлыктан егет ике телне дә яхшы белә. Минемчә, ул Шевченко шигырьләрен укымый, шагыйрьнең үзе булып ялкынланып яна иде. Ул да, минем кебек үк, өйләнергә өлгермәгән. Сөйгән кызы Люба Минскида калган – университетта укый. «Их... бер генә тапкыр аның төпсез зәңгәр күзләрен күрсәм, алсу иреннәреннән үпсәм, үлсәм дә үкенмәс идем», – ди торган иде ул, без икәү калганда уфтанып.

Менә хәзер шул дус егетне салкын алачыкка чыгарып ташладылар. Ә ерак Минскида студентка Люба һаман әле Мороз Петяны көтә булыр.

Гадәттә, күрше лаваларда шартлаулар башланыр алдыннан, шахтадан берәүне дә калдырмый чыгаралар иде. Каты шартлау-селкенүдән башка лаваларның да ишелүе мөмкин.

Ә менә теге фаҗигале иртәдә, шахта башлыгы үзе килеп, инде шартлау алдыннан тышка чыгарылган бригадаларны кире лавага куды.

– План тулмый, алар монда бот күтәреп яталар. Хәзер үк лавага! Бүген эшне тикшерергә комиссия киләчәк.

Без, үзебезнең лавага төшеп, эшкә тотындык. Мороз перфоратор белән шурф тишә. Мин лавада яткан токымны вагонеткага тутырам. Башкалар кәйлә, көрәк белән казый, көри, тишәләр. Мин вагонеткамны тау токымы белән тутырып бетереп, инде этеп тышка чыгарырга гына керешкән идем, күрше лавадагы шурфлар шартлый башлады. Лава селкенде, ком коелды, һәм баш өстендә асылынып торган лампочка лып итеп сүнде. Шунда ук аркама, аягыма ниндидер авыр нәрсә ишелергә тотынды, мин, егылып, аңымны югалттым.

Күзләремне ачуга сискәнеп киттем: яп-якты. Ниндидер сәке өстендә ятам. Кайда мин? Кем китергән? Торып карыйм әле дип кузгала гына башлаган идем, сул аягым, ток суккандай, дерелдәп тартылды, авыртуга чыдый алмый ыңгырашып, күзләремне йомдым.

Яңагыма суккалаганга уянып киттем, каршымда ак ха-

лат кигән ике таныш түгел кеше басып тора.

– Бусы әле тере, – диде күзлеклесе, һәм шунда ук икесе дә каядыр юк булдылар.

Ыңгырашкан, кычкырган тавышлар. Ак халатлы кешеләр носилка күтәреп үттеләр. Менә шунда гына үземнең кайда ятканымны төшендем.

Минем хәл артык хәвефле түгел икән, сул аягымның бармаклары изелгән һәм уң кулым бераз яраланган.

Бригада егерме җиде кешедән иде, баракка нибары тугыз кешене китергәннәр. Башкалар ишелгән җир астында күмелеп калган. Әле казыйлар, ди. Бәлкем, тере калганнар да бардыр, кем белә. Була күрсен.

3

– Күрше, күрше, хәлең ничек? Нигә башыңны күтәрмисең?

Янымдагы Карасакал телемне ачарга маташа. Минем хәл белән кызыксына! Беләм мин сезнең халыкны, лагерьда беренче ел түгел. Сез шулай йомшак җәеп, катыга утыртасыз. Чагучылар барысы да менә шулай пышылдый, елан булып яныңа үрелә. Тукта, менә аягым гына язылсын, синең хаин җаныңны борыныңнан чыгарырмын. Мәхбүсләрне сатып ничек симергән, бакамыни, рәтләп борыла да алмый. Әнә бит, кичә түрә үзен әллә кайдан таныды. Әле фамилиясен дә белә. Стоянов, ди. Мөгаен, Болгариядән җибәрелгән шпион, инде безнең хисапка тиресен саклап калырга тырыша.

– Сезнең ашыйсыгыз килмиме?

Кара, адәм актыгы, кай яктан суга. Күрәсең, паёкны әйләндереп-әйләндереп каравымны күзәтеп торган. Ачуыма чыдый алмадым. «Юк!» – дидем дә борылып яттым. Ачу ташудан аякның авыртуын онытып сузып җибәргәнмен – балта белән чаптылармыни. Сыным катты – тешләремне шыгырдатып-сызланып ыңгыраштым.

– Сезгә кайчан ампутация ясадылар?

Менә бит, һаман канга тоз сала – минем аякта аның ни эше бар?

– Нәрсә, мәетләр әрдәнәсенә өяргә ашыгасыңмы?

– Киресенчә, – диде теге, тигәнәк булып кадалып, – гангрена башланмаганмы дип хафаланам.

– Булса? Синең ни эшең? Әнә Морозны алып чыгып киттеләр ич, нигә туктатмадың?

– Әйе... – ул авыр итеп көрсенде, – соңга калдым. Булыша алмадым... Ягез әле, аягыгызны күрсәтегез. Карыйм әле.

– Сез кем, врачмы?

– Хирург.

Күрше үзе миңа шуышып килеп утырып, культяны чорнаган бинтны сүтә башлаган иде, авыр ис борынга сукты. Ә аягым киселгән җиреннән кара янган.

– Гангрена!

– Нишләргә соң?

– Хәзер үк ампутация ясарга! Хәзер үк! Булмаса, гангрена бик тиз күтәреләчәк.

– Инде бит ике тапкыр ампутация эшләделәр.

– Наркоз беләнме?

– Хлороформ юк, диде баш врач. Наркозсыз гына кистеләр.

– Кабахәт! – Күршем кызарып-бүртенеп китте, чынлап ачуланган сыман кылана. – Менә ике көндә алты кешене моргка чыгардылар. Барысы да ампутациядән соң гангрена белән.

Үз аягымнан килгән искә үзем чыдый алмыйм, күңелем болгана. Җитмәсә, сулкылдап сызлый.

Менә сиңа кирәк булса. Инде нишләргә? Бер кистеләр, ике кистеләр. Инде өченче киссәләр? Аннан – бот төбеннән. Ә аннан соң? Тәнем чымырдап китте... Күршем Георгий (Карасакалның исеме шулай икән) үзен врач дигәч, бераз йомшара төштем. Кем белә, өметсез – шайтан, ди бит борынгылар. Барак очындагы фанера белән бүленгән бүлмәдән – медпункттан – бер аяк белән сикергәләп барып, йод, марля алып килде, киселгән урынны йод белән майлап, чиста марля белән яңадан урады. Кара, үзенең кулы йомшак. Марля уравы да теләсә ничек түгел – беренче тапкыр бәйләмәве күренеп тора. Әллә чыннан да врач микән бу Карасакал, ә?

4

Без төн буе йокламыйча сөйләшеп чыктык. Шул әңгәмәдән мин күршем турында менә нәрсәләр белдем.

Кара сакаллы тоткын – Георгий Стоянов – Болгариянең Казанлы өязендә туып үскән икән. Софиядәге медицина институтының хирургия факультетын бетереп, төрле шәһәрләрдә, больницаларда врач булып эшли һәм шул

елларда Георгий Димитров оештырган яшерен оешмага – коммунистлар партиясе сафларына керә һәм яшьләр арасында монархиягә каршы көрәш алып бара, берничә тапкыр кулга алына, төрмәләрдә дә утыра һәм ахырында Болгариядән китәргә мәҗбүр була – Германиягә чыга.

Белгәнебезчә, 1934 елда хөкүмәт башына Гитлер килгәч, коммунистларга террор уздыру нияте белән, рейхстаг бинасына ут төрттерә, янгын чыгуны коммунистларга сылтый, Георгий Димитровны һәм аның юлдашларын гаепли. Шушы эш буенча Стоянов та кулга алынган була. Георгий Димитровның ныклыгы, батырлыгы, эзлеклелеге, оста оратор булуы җиңү китерә. Димитровчылар азат ителә һәм Советлар Союзына чыгарып җибәрелә.

Стоянов соңгы елларда Мәскәү больницаларының берсендә хирург булып хезмәт итә. Ә менә 1937 елның башында аны кулга алалар һәм, шпионлык итүдә гаепләп, ун ел төрмәгә хөкем итәләр.

– Менә шулай итеп, мин Колымага килеп чыктым һәм Томанлы приискасында больницада баш врач булып эшләдем.

– Ә монда, Линкольн больницасына ничек килеп эләктегез соң?

– Ишеттегезме, кичә колонна башлыгы мине түрәләргә хөрмәт күрсәтмәүдә, саранлыкта гаепләде.

– Әйе-әйе. Үзем дә сездән сорыйм дигән идем әле. Ул сезне нинди саранлыкта гаепләде соң?

– Спирт аз биргән өчен.

– Спирт? Төшенмим. Нинди спирт?

– Иң таза, туксан алты градуслыны.

– Төшенмим.

– Нигә төшенмәскә, бер генә операция дә, укол да спиртсыз-дезинфекциясез башкарылмый. Шуның өчен больницада һәрвакыт таза спирт була. Томанлы түрәләре дә кичләрен миңа «авыз чылатырга» килә башлады. Башта мин, яңа кеше буларак, тешне кысып, аз-маз койгаладым. Тора-бара алар һәр көн һәм күбәүләп керә башладылар. Ләкин спиртны миңа Магадан больницасыннан норма белән генә җибәрәләр. Бигрәк тә теңкәгә тигәне каравыл башлыгы Волков булды. Ул, хәтта төнлә уятып, авырулар алдында спирт даулый башлады. «Гражданин начальник, спирт инде операциягә дә калмады. Бирә алмыйм»,

– дим. Ә ул җикеренә: «Ах, шпион, син әле башлыклар белән шулай сөйләшәсеңме? Мин сине хәзер үк карцерга озатырмын. Бир дигәч бир. Колымада су җитәрлек. Бер чиләк кушсаң, бер айга җитәр». Мин, кызып китеп, аны куып чыгардым.

– Шуннан?

– Шуннан ни булсын. Волков әйткәнчә инде. Мине икенче көнне үк, врачлыктан алып, кара эшкә – утын ташырга кудылар. Ике айдан соң бу приискага җибәрделәр. Өченче участокта колымашка белән җир ташыдым. Үткән көнне, колымашка астында калып, сул аягымның тубыгын чыгардым.

Билгеле ки, Болгария бик күп еллар Госманлы төрек империясенең колониясе була.

– Безнең хуш исләр аңкып торган мәшһүр розалар аланы Казанлыкта да төрекләр күп, – диде Стоянов. – Без төрек балалары белән бергә мәктәпкә йөрдек.

– Алайса, сез төрекчә дә беләсездер?

– Мин төрек мәктәбендә өч ел укыдым. Менә шунда гарәп әдәбияты белән таныштым. «Мең дә бер кичә», «Кырык вәзир», «Тутыйнамә»ләрне төннәр йокламый укып, хыялланып йөрдем. Беләсезме, авыруны дару белән дәвалау гына аз, һәм хәтта ул әле тиешле нәтиҗәне дә бирә алмый.

– Төшенмәдем.

– Борынгы юнаннар «сәламәт тәндә – сәламәт рух» дигәннәр. Ә мин аны «сәламәт күңелленең тәне дә сәламәт» дип үзгәртеп әйтер идем.

– Ничек?

– Авыру үз эченә йомылып, сөйләшмичә, көлмичә ятса, үзен үзе кимерә, хәлен авырайта гына. Аны чире турында уйлаудан коткарырга кирәк. Сөйләшсен, көлсен... Әйе-әйе, көлсен. Көлү ул – сәламәтлекне күтәрүче иң тылсымлы дару. Шифалы.

– Әйтәм кичә бөтен барак гөр килә иде.

– Монда бит барысы да диярлек «илле сигезләр», нахакка гаепләнгән кешеләр. Җитмәсә, шундый фаҗигагә дучарлар: кайсы аксак, кайсы чулак. Шуңа күрә мин аларның эчке газаплануларын, фаҗигале хәлләрен онытырырга тырыштым...

Менә бит ул кеше ничек. Халык азатлыгы өчен көрәшә.

Сөрелә. Аннары, ниһаять, иркен, азат тормыш башлыйм дигәндә, тагын нахак бәлагә дучар була. Шулай да кешелеген югалтмый.

Ә мин шикләндем, шөбһәләндем һәм Георгий Стояновны «чагучы» дип каһәрләдем.

5

Иртәнге обходтан соң күршем, бер аксактан култык таяклары сорап алып, баш врач хозурына китте. Уф Алла, ни генә булыр икән инде? Рөхсәт итәрме? Итсә генә ярар иде! Ә аягым, үч иткән кебек, әллә инде тынычсызланганга, сулык-сулык итеп сызлый, чәнчә. Тышта исә күз ачкысыз буран. Баш очындагы тәрәзәдән суык өрә, дер-дер киләм. Көтәм. Ишек ачылмый. Ичмасам, агач аяк белән булса да, туган илгә, Күкчәтау далаларына кайтырга, ялгыз атамны, дус-ишләрне күрергә насыйп булсын иде. Ниһаять, ишек ачылды – әүвәле култык таяклары, аннан Карасакал күренде... Нинди хәбәр алып килә икән күршем? Йөрәк дөп-дөп итә. Аяк сикереп-сикереп китә, әйтерсең лә кыздырылган энә чәнчәләр. Так-ток! Так-ток! Таяклар якынлаша... Күршемнең йөзе караңгы. Күзләре миңа карамый.

Димәк, баш врач күршемә минем аякны ампутацияләргә рөхсәт итмәгән... Бу өмет тә челпәрәмә килеп ватылды.

Икенче көнне Магаданнан ике хәрби кеше – мөгаен, ГУЛАГ (лагерьларның Баш идарәсе) вәкилләре килеп, безнең санбаракны карап, шахтадагы авария турында сорашып йөрделәр. Алар Георгий Стоянов янында тукталып озак кына сөйләштеләр. Күрәсең, аны электән беләләр.

Менә шушы комиссия рөхсәте белән Георгий миңа ампутация ясарга әзерләнә башлады.

Георгий санитар Тимка белән дә уртак тел тапты. Ул үзенең ярдәмчесен чакырып килде.

Иң элек алар операция бүлмәсендәге барлык әйберне: өстәл, урындык, шкаф, кушеткаларны чыгарып, бүлмәне кайнар су белән юып, стеналарын пешекләп чыктылар. Ә Георгий үзе ашханәдән зур бер бак алдырып, барак уртасындагы плитә өстенә куйды да, су салып, операция вакытында кия торган киемнәрен, җәймә-салфеткаларны кайната башлады. Гаҗәп! Безнең баш

врач андый эш белән мәшәкатьләнеп маташмый, бер урынга дүрт-биш авыруны яткырып тураклый бирә иде. Ә бу! Ул гынамы? Иң әһәмиятлесе – шкафны тазарткан вакытта аскы шүрлектән ике шешә хлороформ да таптылар. Этикеткалары гына төшкән булган. Ә бит «хлороформ юк» дип, уяу килеш, тере тәнне пычак белән тунап, пычкы белән кисте, мәлгунь. Икенче тапкыр аягымны кискәндә, авызыма капкан чүпрәкне чәйнәп, үземне кушеткага бәйләгән каешларны өзеп, һуштан язган идем ич... Ә хлороформ шунда шкаф эчендә генә аунап яткан булган.

Бак төне буе бытыр-бытыр кайнады. Георгий плитә белән ике арада әйләнде – эш коралларын кайнатты, урын-җиргә дезинфекция ясады.

Өченче көнне иртәнге баландадан соң Тимка белән Петро мине култыклап операция бүлмәсенә китерделәр. Шаккаттым, бүлмә яктырып, киңәеп киткән, һавасы да бүтән, җиңел.

– Бәхетең бар икән, – дип, Георгий мине көлеп каршылады. – Менә берүзеңә туп-тулы шешә. Ипләп кенә ят әле. Менә шулай. Аяк-кулыңны бәйләп маташмыйбыз. Бу масканы борыныңа салыйк... Иснә, иснә, башыңны боргалама! Сана: бер, ике...

Борынга йөзләгән кырмыска керәмени. Кычыттыра, тончыктыра...

– Сана, сана! Өч, дүрт...

– Өч... дүрт... алты... – башым әйләнә, каядыр китеп барам, – ун... егерме... егерме... – Артык саный алмадым, онытылдым.

Ниндидер тирән диңгездә йөзәм. Яр ерак. Мин хәлсезләнәм. Кулларым күтәрелми. Чумып-чумып китәм. Батам. Батам! Коткарыгыз!

Көч-хәл белән күзләремне ачтым, бөтен нәрсә әйләнә.

– Уян! Уян! Операция бетте инде. Озак йокларга ярамый. – Авырттырмыйча гына, шап-шап итеп яңакларыма сугалар.

Ниһаять, күзләремне ачтым. Бүлмә, каршымда торган ак халатлы Георгий Стоянов әйләнеп китте, кушеткага ябыштым.

– Мә, аз гына ром йот.

Кушетка кырында, идәндәге ләгәндә, ярты сыйрагым

ята.

– Ярар, борчылмагыз. Мин тездән унбиш сантиметр калдырдым. Озын да түгел, кыска да түгел, һәрбер протезга ятышлы. Стандарт протез сезгә нәкъ булачак. Әле йөгереп йөрерсез.

Санитарлар мине култыклап урыныма алып барып салдылар. Изрәп йоклап киткәнмен. Ул көнне Георгий тагын өч тоткынга ампутация ясаган.

Бер атнада аягымның ярасы бөтәйде. Мине гомуми баракка чыгардылар. Георгий баракның ишек төбенә хәтле аксый-аксый озата килде. Хушлашканда, кулларымны каты кысып:

– Кайгырма! Хаклык беркөнне килер, – дип, соңгы тапкыр кочагына алды.

Менә инде ничә дистә ел бер сыйрагым Колыма җирендә, мәңгелек туңда ята. Ничә дистә ел протезда йөрим. Киселгән урында бер шеш, яра юк! Һәр көнне иртән торып протез кия башлагач:

– Мең рәхмәт сиңа, ерактагы дус! – дип, мин Георгий Стояновны искә алам.

Аны – кара сакаллы күршемне күрәсе, кочаклыйсы, рәхмәт, мең рәхмәт әйтәсе иде. Берничә тапкыр Болгариягә, Софиягә хат язып, аны эзләргә дә җилкенгән идем. Әмма булмый. Артык четерекле, уңайсыз җирдә очраштык шул без аның белән...

Әмма Георгий Стоянов мәңге минем күңел түремнән китмәс.

ИКЕ ОЧРАШУ

Ике мичне дә тоткыннар, сукыр чебен төсле, өерелепсырып алган. Кайсысы күшеккән, өшегән бармакларын тырпайтып, пешә язып мичкә үреләә. Кайсысы пимасын, чолгауларын киптерә. Кайберәүләре, шыр ялангач калып, күлмәк-ыштанын кыздыра – «куйларын» коя. Алар мич өстендә шытыр-шытыр килеп шартлый, көек исе тарала. Шунда ук эреле-ваклы консерв банкалары быгырдый – чәй кайный. Берсе куя, икенчесе ала. Берсе кулын пешерә – түгә. Пар оча, сүгенү, шау-шу тарала.

– Яле, контрлар, юл бирегез!

Ванька-Козгын! Колга буй. Тузган кара бөдрә чәч. Кар-

чыга күзләр. Баракның старостасы. Чегән. Яшь. Бәлки, теге Корольнең улыдыр? Ул мичкә якынлашканда юл бирергә өлгермәгәннәрне шундук тибеп очырды. Козгын, гөнаһ шомлыгы, мич янында күлмәген кыздырып торган ап-ак сакаллы картка – рус әдәбияты профессоры Переверзевка бәрелеп, болай да дерелдәп кенә торган гәүдәне аударды. Көйгән ит исе аңкыды. Ярый әле профессорны шундук тартып алдылар... Мескен карт кычкыра да алмый, ыңгыраша гына. Сәкегә сузып салып, көйгән җиренә боз куйдылар.

Ванька-Козгын мич өстендәге барлык банкаларны арлы-бирле этеп төшерде дә үзенең өч литрлы кәстрүлен куйды. Өстәмә баланда, ботка! Аңа ашханәдән махсус рәвештә җибәрәләр – түрә!

Чатырның аргы очындагы түбән сәкедә (тамчы тама торган өстәге сәндерәдә – политиклар) бер төркем блатной, өсләренә одеял ябынып, карта суга – паёкка, баландага, тоткын «мундир»ына. Уен – изге. Отылучы вәгъдәләшкән вакытта бурычын түләргә тиеш. Юкса!

Кичә әнә шул карта уйнаучылар рәтендәге түбән сәкегә кыйшайган идем. Мин – баракта «штатный» әкиятче. Блатнойлар әкият тыңларга ярата. Шуның өчен миңа аеруча хөрмәт, өстәмә бер чүмеч баланда – әкият сөйләгән кичләрдә анда-санда түбән сәкедә йокларга да рөхсәт. Казан төрмәсендәге карцер онытылды – тамак тәмугка кертә. Бервакыт, кемдер бик каты төртеп-этеп җибәргәнгә уянып, җиргә барып төштем. Чатырда идән юк, тоткынга такта әрәм итәләрме соң, ул әле прииска кирәкярагына да җитми. Аңгы-миңге ятам. Шунда нәрсәдер шак итте. Гырылдый башлады. Көч-хәл белән аягүрә бастым. Карауга, чәчләрем үрә торды. Сулыш алудан туктадым. Сәкедә – киселгән баш! Муенынннан ургылып кан ага. Калай күзләр миңа кадалган. Гришка-Чыпчык бит бу!

Оттырган унбиш паёгын вакытында китермәгән.

Ә Ванька-Козгын, бернәрсә дә булмаган сыман, кан тамып торган беләк озынлыгы пычагын Гришка-Чыпчыкның бушлатына сөртте-сөртте дә, итек кунычына кыстырып, ниндидер табор көен сызгыра-сызгыра, баракның икенче башына китте.

Бүген мин Гриша яткан җирдә ятам – урын киңәйде... Төшкә кермәсә ярар иде. Инде керсә дә, кермәсә дә –

керфекләр йомыла, арылган, аяк-кулны җыеп алып булмый. Иртә караңгыдан кара кичкә хәтле забойда, чатнап торган суыкта-челләдә, алтын юу сезонына участоклар әзерлибез бит.

Көнозын туңган тән хәзер мич кызуында да җылына алмый. Бушлатны баштан ук уранып, калач булып бөкләндем.

Йокы аралаш ниндидер шау-шу колакка керде. Әүвәле колагымны яба төшеп икенче якка әйләндем – шау-шу тынмый. Тагын борылдым.

– Магаданнан этап килде!

Безнең Линкольн приискасы Магаданнан мең чакрым ераклыкта. Этап безнең өчен зур сөенеч – яңа тоткыннар өстәлә. Этап килгәндә нинди генә мәхбүс йоклап ята ала! Мин дә йокылы-уяулы күзләремне ачтым. Чатыр ишегеннән ишелеп суык керә. Томан. Шау-шу. Бернәрсә дә күренми – йокы баса, тагын күзләрне йомдым, яңа гына җылына башладым бит. «Ярар, иртәгә дә күрермен әле». Әмма тавышлары колакта. Сөйләшәләр. Кычкыралар. Әле өске, әле түбәнге сәкедән урын эзләп тыкшыналар – егылып төшәләр. Сүгенүләр. Кычкырулар. Димәк, контрлар өстәлгән, уголовниклар килсә, урын сорап тормый, үзләре «хуҗалар»ны өстерәп төшерә.

Менә минем яныма да берсе килеп тыкшынды. Озын коры сөяк – шалдыр-гөлдер. Үзе суык, әйтерсең лә чатыр артындагы шыплап каткан каен яргагын китереп салдылар. Аягым белән этеп җибәрдем, чигенде, тавышланмады, кысылыбрак ятты. Мин йоклап киттем.

Тагын күзәтченең карлыккан тавышы:

– Этапныкылар, тышка чыгыгыз!

Тагын ыгы-зыгы. Эт өргән тавышлар. Сүгенү. Тагын ишелеп кергән суык! Каһәр генә төшсен, яңа гына җылынып йоклап киткән идем, тагын бүлделәр.

Ә ишек төбендә инде конвой башлыгы барактан чыгар алдыннан этапчыларның «гамәл дәфтәрләре»н укый.

– Петров Иван Иванович – илле сигез, унынчы.

– Пятница Миколь Кузьмич – илле сигез, унҗиденче.

Димәк, аларны яңа конвой санап-тикшереп ала.

– Тизрәк кыймылдагыз, тизрәк!

– Петров!..

– Мутин Мохтар!..

Күршем ишетелер-ишетелмәс кенә җавап бирде:

– Мин!

– Тизрәк! Авызыңны фәлән итим, йокыңны ачармын, күтәрел!

Янымдагы тоткын сикереп торды, ыңгырашты. Сәкедән шуып төште.

– Тизрәк! Формуляр!

– Мутин Мохтар, илле сигезенче статья, ... пункт, ун ел төрмә...

– Чык әйдә!

«Мохтар! Мутин!» Яшен суккандай, аңгы-миңге булып киттем. Аннан, сикереп торып, ишеккә таба йөгердем.

– Син кая кузгалдың, үләксә?!

Кемдер яңагыма сугып җибәрде – йокым ачылды. Алдымда – конвой башлыгы, кулында бер кочак формуляр. Ул ачулы карады да чыгып китте.

Ишек ябылды. Йозак шалтырады.

...Мең тугыз йөз утызынчы еллар. Казан педагогия техникумында укып йөргән студент чагым: стипендия унбиш сум. Шуңа ашыйбыз, шуңа киенәбез, шуңа күңел ачабыз, газета-журналлар яздырабыз, комсомолга, МОПРга[1], «Бетсен наданлык!» җәмгыятенә һәм башкаларга взнослар түлибез. Дөресен әйткәндә, тамак хәле әллә ни артык түгел иде.

Ә кәеф һәрвакыт күтәренке!

Борынны төшермибез – көн дә уен, көн дә туй. Кайсыдыр «булачак шагыйрь» үз шигырьләрен әле язарга өлгермәгәнлектән, Тукайныкын җайлаштырган, без, карын ачса, күмәкләшеп шуны җырлыйбыз:

Фәгыйләтен, фәгыйләтен, фәгыйләт,
Әй, бу студент халкының күңле шат!

Лекцияләрне тыңлау җәфасыннан котылу белән, без – егет-җилкенчәк – кышын Печән базарына, «Көфер почмагы»на барабыз да утын кисәргә-ярырга ялланабыз, җәен, пристаньга төшеп, баржалар бушатабыз. Кавын-карбыз килгәндә бигрәк күңелле – корсак шартларга җитешә. Менә шул «өстәмә керем» походыннан арып-

[1] МОПР – международная организация помощи борцам революции.

талып, өстерәлеп тулай торакка кайтып егылганда гына сөенечле хәбәр:

– Академия театрында – «Отелло»!

– Отелло ролендә – Мохтар ага Мутин!

Әфсен өрделәрме – арулар, йокылар әллә кая кача. Икмәк алырга дип саклап йөргән соңгы тиеннәрне җыябыз да (кызлар-шефлар да безнең җилкәдә, ярлы булсак та – егет) галеркага билет алабыз. Әгәр инде бөтен курска җитәрлек акча җыелмаса да, кайгы юк, хәйләсен табабыз. Бер өлешебез, күбесенчә кызлар, алдан билет белән кереп, беренче пәрдәләрне карый, аннары тәнәфестә контрамаркаларны безгә – көтеп торучыларга чыгарып бирәләр. Без инде соңгы пәрдәләрне карыйбыз. Теләк – Мохтар ага Мутинның Отеллоны уйнавын күрү. Без генәме? Бөтен Казан шулай ашкына. Мохтар ага исеме афишаларда күренү белән, театр кассасында билет калмый.

Залда ут сүнә. Авыр бәрхет чаршаулар акрын гына ачыла.

Замок. Йокы бүлмәсе. Көмеш шәмдәлләрдә берничә генә шәм яна. Ярым караңгылык. Түрдә атлас чыбылдыклар белән капланган караваткә. Анда, күпереп торган мамык түшәк-мендәрләргә күмелеп, ак ефәк юрган ябынып, гүзәл Дездемона йоклый.

Кинәт шәмнәр калтыранып, кызгылт телләре сузылып-тибрәнеп китә. Бүлмә эче тагын да караңгылана төшә. Ишек ачыла. Бүлмәгә, ашыгып, Отелло – Мутин керә. Көч һәм гайрәт ташып торган мәһабәт гәүдә. Сокланырлык килеш-килбәт. Ул – Флоренция дәүләтенең дан һәм шөһрәткә күмелгән атаклы генералы.

Иң авыр, куркыныч сугышларда да каушауны белмәгән менә шушы кеше хәзер үзенә үзе урын таба алмый газаплана. Ул бөек һәм мескен хәзер үзенең мөкатдәс гыйшкы алдында. Генерал акыллы һәм кызу канлы мавр-хыянәтче Ягоның мәкерле хәйләсе белән агуланган. Ул яна! Анда – бөек саф мәхәббәт һәм дәһшәтле нәфрәт! Өермә! Давыл! Тайфун! Ә Дездемона сабыйлар гамьсезлеге белән рәхәтләнеп, һичбер хәвеф-хәтәр сизмичә, онытылып йоклый.

– Син нинди пакь һәм гүзәл... (Отелло, иелеп, Дездемонаны үбә.) Әмма... өзелгән роза кебек суларга-шиңәргә

тиешсең хәзер.

– Отелло, бу синме? – Нинди ышанулы, назлы тавыш.

Отелло сискәнеп китә, гүя аны кара елан чага.

– Әйе, кадерлем... – тавыш калтырана. Отелло иңрәп күтәрелә. Аның йөрәгендә хәзер ике ут – мәхәббәт һәм нәфрәт. Отелло үз-үзе белән көрәшә. Кем кемне?! Мәхәббәтме? Нәфрәтме?

– Минем бердәнбер гөнаһым – сиңа булган керсез мәхәббәтем...

– О, юк! Юк!

Мәкер белән агуланган, күзләре тонган Отелло, бу илаһи тавышка чыдый алмый, тулып-ташып, Дездемонага ташлана һәм үзенең саф, изге мәхәббәтенә кул суза...

Зал сулыш алудан туктап тетрәнә.

Ә инде явыз хыянәтче Ягоның җинаяте фаш булгач, Дездемонаның илаһи мәхәббәте үзенең бар сафлыгы белән яңадан ачылгач, Отелло соңгы көчен югалтып егыла.

Ул әле исән. Әмма Дездемонаның самими мәхәббәтеннән башка яшәү аңа нигә? Нигә?!

Йөрәкләр тибүдән туктый... Һәм, бары озак вакыт үтеп акылын җыйгач кына, тамашачылар шашынып, тыела алмыйча Мохтар ага Мутинны алкышлыйлар...

Менә шушы бөек артист, гали җан, татар халкының даны һәм сөенече – бүген арестант. Колыманың җан тетрәткеч зәмһәрир суыгында этап белән куылып, бер приискадан икенчесенә сөрелә. Ни өчен?

Мин, үксеп елап, урыныма килеп егылдым. Вахта алдында һаман әле шау-шу – конвоирларның ачулы әмерләре, сүгенүләре һәм өстерелгән этләрнең абалап өрүе.

Ә мин һаман әле тыела алмыйм, үземне үзем тиргим, үкенеп өзгәләнәм. Ул бит минем янымда гына ятты. Нигә инде сикереп торып исәнләшмәдем, кулларын кысмадым? Кайдан килә? Кая бара? Авырмыймы? Ул, мөгаен, шушы араларда гына материктан килгәндер. Казанда нинди яңалык бар икән? Минем Казаннан китүемә-аерылуыма инде дүртенче ел бара бит – их, сорашасы, сөйләшәсе иде...

Урыннан-сәкедән сикереп торып йөгерәсе – Мохтар аганы куып җитеп кочаклыйсы килә. Мескен күңел, юкка

гына талпынасың бит! Чатыр ишегендә ат башы хәтле йозак. Аннан ары чәнечкеле тимерчыбыклар, манаралар, мылтыклар, пулемётлар, этләр. Ә шулай да... Син кайда, Мохтар ага? Кайда син?

Бу очрашылмаган очрашудан соң ике елга якын вакыт үтте. Колыма һәм Индигирка елгалары инде ике тапкыр, аз гына вакытка булса да – июнь, июль, август айларында өсләрендәге калын боз катламнарын салып, ачылып, ниһаять, башка елгалар кебек тулып, ташып агып, улакларда алтын юдылар, «соргылт-кызыл тараканнар» – самородокларны чайкадылар. Ә тоткыннар һәр көн, һәр ай берсеннән-берсе өметлерәк хәбәрләр тыңлады. Тиздән моңа хәтле ишетелмәгән бик зур амнистия була икән, илле сигезләрнең барысын да азат итәләр икән...

Әмма һәр көн таң караңгысыннан вахта каршындагы өрлеккә эленгән чаңга сугалар:

– Даң-доң! Даң-доң!

Уяну. Вахта. Конвой. Тентү. Карцер һәм... тагын этап. Өмет. Ышану. Көтү. Мәхбүс шулар белән яши дә, мескен.

Менә шулай михнәт чиккәндә, ниһаять, мин, агач аякка калып, инвалидлар колоннасына килеп эләктем.

Инвалидлар колонна-лагере Магаданнан егерме өч чакрымда. Шуның өчен «Егерме өченче колонна» дип йөртәләр икән аны.

Бу лагерьда ике зона. Берсе – эшче зона, анда аз-маз кузгала, әле ни дә булса майтара ала торган инвалидлар тупланган. Икенчесе – гарип-горабалар, сукырлар, аяккулсызлар.

Мине турыдан-туры беренче зонага керттеләр. Монысы да бәхет – эшләсәң үлмисең. Мин кәрзин үрүчеләр бригадасында эшли башладым.

Бу зона зур, монда ширпотреб цехлары – мебель, савыт-саба, уенчык, карават ясыйлар. Талчыбыктан кәнәфи, урындык, чемодан, тартмалар һәм кәрзиннәр үрәләр. Бу соңгысы миңа бигрәк тә ошады – төрле төстәге бизәкләр төшереп үрелгән кәрзиннәр: түгәрәк, озынча, капкачлы, капкачсыз – уенчык диярсең, шундый матурлар.

Беренче бригада – уголовниклар, Аллага шөкер, аларның аяк-куллары исән-сау, конвойсыз да зонадан чыгып йөри алалар. Аларга ышаныч зур – Колыма буеннан

талчыбык кисеп, аркалап алып кайталар.

Без бу талчыбыкның кабыгын сыдырабыз, каезлыйбыз. Аннан аны зур казаннарга салып кайнатабыз. Ул ныгый, үргәндә дә чатнамый, йомшый, сыгылмалы була. Талчыбыклар «пешеп» өлгергәч, алып бераз саркытабыз да төрле төстәге буяу изелгән казаннарга төшереп манабыз. Кайсы кызыл, кайсы яшел, кайсы күк төскә керә. Буялган талчыбыклар цехта бераз киптерелә. Менә шуннан соң гына алар эшкә файдаланыла – салават күпере төсләре белән балкыган нәфис кәрзиннәргә әверелә.

Мин килеп кушылган кәрзинчеләр бригадасында илле тоткын-инвалид. Барысы да «илле сигезләр». Бригадир Максим Максимович минем төсле үк агач аяк. Инде чәчләре агарган, түгәрәк йөзле, ягымлы кеше. Ачуланмый. Сүгенми. Сабыр. Лагерьда андый кеше бик сирәк очрый. Кулга алынганчы, ул Киев хәрби округында дивизия комиссары булып хезмәт иткән, Гражданнар сугышында Ковпак белән бергә сугышкан карт командир, большевик диләр үзен.

– Кәрзин үрү төбеннән башлана. Без дә шуннан башлап өйрәник, яле, әнә теге нечкәрәк талчыбыкларны бир әле, – дип, Максим Максимович мине, үз янына утыртып, һөнәренә өйрәтә башлады.

Ниһаять, монда эшли башлауның беренче якшәмбесендә, Колымага килгәннән бирле өч елда, беренче тапкыр ял иттем, төшке баландага хәтле йокладым. Үземә үзем ышанмыйм, көпә-көндез сәкедә аунап ятам. Кызык.

Төшке аштан соң мин дә, башкалар кебек, палатка артына кояшта кызынырга чыктым.

Май. Кояш ярыйсы ук югары күтәрелгән, кыш көннәрендәге кебек офык тирәсендә генә әйләнми. Дөрес, монда әле, материктагы кебек, агачлар яфрак ярып, сиреньнәр шау чәчәктә утырмый. Кар көртләре яңа гына челтәрләнә. Юл читләрендә, тау итәкләрендә әле беренче гөрләвекләр генә... Шулай да яз! Күңелдә – яз!

Зона ике кат чәнечкеле тимерчыбык белән уратылып алынган. Һәр почмакта манара. Анда кулына мылтык тоткан солдат ялт-йолт каранып-күзәтеп тора. Әгәр инде алай-болай берәр тоткын тимерчыбыкка якынлаша башласа, хәзер затворын арлы-бирле йөртеп кычкыра:

– Якын килмә! Атам!

Сул якта – эштән чыкканнар зонасы. Арада чәнечкеле тимерчыбык койма һәм манара. Арырак – вахта. Анда бер төркем конвойчылар капка төбендәге өстәлдә домино уйный.

– Ой, карагыз әле, – дип кычкырып җибәрде кемдер, – әнә кыр казлары килә.

Аптырап, тавыш килгән якка борылдым. Колымага нинди кыр казлары килсен ди. Зона аръягындагы үрдән, бер-бер артлы нәкъ кыр казлары төсле тезелешеп, бер төркем гарип-гораба төшеп килә: бөкрәйгәннәр, көчкә-көчкә атлыйлар, җилкәләрендә коры-сары каен ботаклары. Нишлисең, Колымада май аенда да мич ягарга кирәк!

Бу инде гарип-тоткыннарның әле бераз кыймылдый ала торганнары – зонаны утын белән тәэмин итүче бригада.

«Кыр казлары»ның алды инде зонага җитте. Озын шинель кигән колга буйлы вахтёр уголовник кулындагы наряд кенәгәсенә карандаш белән билге ясап кычкыра, вахта капкасыннан кертә:

– Иванов, уз!

– Базарбаев, уз!

– Пятница, уз!

Алпан-тилпән килеп, үз аякларына үзләре сөртенеп, утынчылар уза. Төркемнең иң соңында ава-түнә килгән озын, ябык бер инвалид вахта капкасына да җитә алмыйча абынып егылды. Артта тартылып-уйнаклап килгән овчарка, бәе бушауга, бер генә сикереп, җирдә яткан теге утынчының өстенә ыргылды һәм талый башлады.

– Ха-ха! Ха-ха!

– Шайтан, әйдә каезла шул контрны.

– Ха-ха, хи-хи-хи! – Арттан килгән конвойчылар, туктап калып, бу тамашаны карап көлә башладылар.

Бушлаттан мамык оча, әйтерсең лә кар ява.

Теге мескен, бөгелеп, башын яшерә. Овчарка, шуны сизгәндәй, утынчының башындагы иске бүреген йолкып алды. Овчарка бүрекне йолыккалап ертканда, бер конвойчы килеп, теге мескенне тибә-тибә тарткалады:

– Тор, тор, контр! Зонага кергәч иркәләнерсең.

– Әй, Мутин! – Бу яктан вахтёр кычкыра-сүгенә башлады, – ... фәлән итим, тагын комедия башлыйсыңмы?

Мин сиңа хәзер театрны күрсәтермен. Тиз йөгер, бригаданы көттермә!

«Мутин! Мохтар ага!» Мин чәчрәп урынымнан тордым – агач аяк төртелеп, авып киттем. Тагын тордым. Җан тавышыма кычкыра башладым:

– Мутин! Мохтар ага!

Ашыгып вахтага таба атладым (каһәр төшкере, агач аяк атлаган саен сөртенә).

Мохтар ага инде үз зоналарының капкасыннан узган, утынын ташлаган иде.

– Мохтар ага!

Ул минем тавышны ишетте, ахрысы, борылды, калтыраулы зәгыйфь тавыш:

– Сез кем? Кайдан? – дип инәлде.

– Мин... Мин... Казаннан.

– Зона яныннан кит!

Мохтар ага зонага кергән иде инде, тагын теге овчарка аның өстенә ташланды. Манарада мылтык шартлады. Минем сул җилкәм көеп китте.

Ун көн карцерда утырганнан соң, мине, качарга әзерләнүдә гаепләп, тикшерүгә хәтле бөтенләй гарипләр зонасына күчерделәр. Ә теге көнне манарадан атылган пуля җилкәмне тырнап кына үткән иде, ярам ун көндә төзәлде.

Зонага керүгә, вахтёрдан: «Мутин Мохтар кайда?» – дип сорадым.

Ул кулын селтәде.

– Ишетмәдеңмени, ул артистка инде әллә кайчан «агач бушлат» кигезделәр ләбаса.

САНДУГАЧ

1

Берәр җирдә Алябьевның «Сандугач» көен җырлауларын ишетсәм, һәрвакыт туктап уйга чумам. Бик еракта калган, әрәм үткән гомер һәм якын бер дустым искә төшә. Бу тылсымлы көйне ишеткәндә ничек аны сагынмаска?! Мин бит аны тар юл, тайгак кичүдә – лагерьда очраткан идем. Киң күңелле, юмарт, кулыннан гөл түгелеп тора торган гаҗәп кеше иде ул. Ә тавышы? Үзе көр, үзе моңлы. Ул җырлаганда Фёдор Иванович Шаляпин җырлый

диярсеӊ.

Соңыннан, төрмәдән котылгач эзләп карадым. Ул ике елдан соң азат ителергә тиеш иде. Әйтүенә караганда, Новгород шәһәренә, карт анасы янына кайтырга тиеш иде. Шәһәр милиция бүлегенә яздым. «Андый кеше бездә исәптә юк» дигән җавап килде.

Аннары Мәскәү радио студиясенә «Фәлән кеше Алябьевның «Сандугач» көен бик яратып җырлый иде. Менә шул дустыма музыкаль сәлам рәвешендә «Сандугач» көен берәр күренекле җырчы башкаруында тапшырсагыз иде» дип хат язган идем. Бүген эштән кайткач, радиоалгычны куюга исем китте. Үтенечемә җавап рәвешендә «Сандугач» җыры. Бүлмәдә аның яраткан көе-җыры яңгырый!

...1945 елның октябрь ахыры иде. Трасса төзү колонналарындагы тоткыннарны ашыгыч рәвештә каядыр күчерә, алып китә башладылар. Чират безгә – инвалидлар колоннасына да җитте. Җыен аяксыз-кулсызларны, вагоннарга төяп, башта Тайшет шәһәренә, станциядә өч көн торгканнан соң, аннары Маршинск озату төрмәсенә китереп тутырдылар. Шуннан Марлаг бүлекләренә бүлеп-бүлеп җибәрү башланды. Мин бүтән «илле сигез»ләр белән «Антибес»ка барып эләктем.

Антибес! Кызык! Шайтаннарга, җеннәргә каршы дигән сүз буладыр инде.

Юкка гына гаҗәпләнмәгәнмен икән бу сәер исемгә. Дөрестән дә, бу исем җисеменә бик тә муафыйк икән. Моңа без Антибеска килеп кергән беренче төндә үк ышандык.

Маршинскидан иртә чыксак та, лагерьга кичкә таба гына килеп җиттек.

Беренче күбек кар – тездән батып атлыйбыз. Өстәвенә, лагерьга якынлаша башлагач, җил кузгалды. Буран. Көчкә килеп җиттек. Чәнечкеле тимерчыбык белән ике кат уратылган зур лагерь. Манаралар. Вахта, агачтан салынган кечкенә алачык. Тимер морҗадан төтен күтәрелә. Димәк, анда җылы. Без вахта янына килеп туктауга, куыштан лагерь түрәләре килеп чыкты:

– Беренче саф, алга! Киемнәрегезне салыгыз!

Суык. Җил. Ә монда чишенергә кирәк. Зонага куркыныч

әйбер алып кермәсеннәр, янәсе. Чишенү, киенү, формулярларны тикшерү, санау – бер генә түгел, берничә тапкыр. Чөнки тапшыручы конвой башлыгы да, алучы лагерь башлыгы да бер-берсенә ышанмыйлар. Һәрберсе үз бармагы белән тоткыннарның күкрәгенә төртә-төртә саный.

Ниһаять, зонага, баракка кердек. Монда инде җылынырбыз дигән идек, кайда ул, зәмһәрир суыгы. Баракта бер генә бөтен тәрәзә юк. Барысын ватып-җимереп бетергәннәр. Аптырагач, тәрәзәне юк-бар белән томалап, кар белән күмдек.

Бу эш безне бераз җылытты. Шул җылыны югалтмыйк дип, баракка кергәч, барыбыз да түбәнге сәкеләргә бер-беребезгә тыгызланып яттык. Арылган, йоклап та киткәнбез.

Кемдер иягемә сукты, сискәнеп уяндым.

– Акчаң кайда?

– Нинди акча?

– Менә нинди акча! – Борын төбендә генә пычак ялтырады. – Тизрәк!

Аңгы-миңге килеп башымны күтәрүем булды, сугып ектылар.

– Бушлатын ал!

– Полундра!

Барак, ут кабынгандай, дерт итеп кузгалды.

– Уголовниклар!

Ул арада ишектән кулларына таяк, төрле тимер кисәкләре, ясалма пычаклар, кистәннәр тоткан тагын бер төркем акырып килеп керде.

– Полундра!

– Контрларны из!

Ыгы-зыгы. Шау-шу. Сүгенү. Шатыр-шотыр сәке такталары кубарыла башлады.

– Син нишләп торасың?! – Кемдер арттан килеп төртеп алды. – Әйдә, мичне җимер!

Ул, шундук иелеп, мичнең капкачын суырып алды да якынлашып килгән пычаклы бер уголовникның башына сукты. Теге акырып егылды. Мин мичне сүтә башладым. Тузан, көл, корым. Кирпечләрне биреп торам, арттан килгәннәр аны алып, ишек төбенә өелгән уголовникларга ыргыталар. Беренче һөҗүм кире кагылды – барак уртасына үтә алмадылар, кире чигенделәр. Әмма безнең көч тә

кими бара, мич сүтелеп, кирпечләре атылып бетте. Сәке такталары да җитәрлек түгел. Күпләр буш кул белән калды. Ә тегеләр яшьләр, тазалар. Өстәвенә, алдан ук сугышырга әзерләнеп, коралланып кергәннәр.

Икенче һөҗүм башланды. Без, сәке такталарыннан баррикада ясап, бер почмакка өелдек. Уголовниклар тагын да ныграк котырды, күзләрен кан баскан.

– Контрларны сыт!

Тагын пычаклар, кистәннәр ялтырады. Без ташлаган кирпечләр кире үзебезнең башка төшә башлады. Берничә уголовник инде, баррикада өстенә үрмәләп, пычакларын янарга тотынды. Без хәлдән таябыз. Күпләр яраланган... Нишләргә? Әгәр алар өстенлек алса, барыбызны да суеп чыгачаклар. Нишләргә, көч-хәл белән такталарны тотабыз.

– Иптәшләр! – Калын көчле бас, барлык шау-шуны, акыруны басып, баракны дер селкетте. – Курыкмагыз, алга!

Баррикада алдына калын каен такта күтәргән берәү тезләнеп йөреп килеп чыкты да тактасы белән, печән чапкандагы кебек, арлы-бирле селти-суга башлады. Никадәр гайрәт! Никадәр көч! Тактага туры килгән уголовникның берсе дә басып кала алмый, мәтәлеп, тәгәрәп китә. Ә теге, тезе белән йөргән ике аяксыз кеше, бер куркусыз алга бара. Моны күреп, без дә күтәрелдек. Тагын акыру-бакыру, сүгенү, пычак, кистән, такта уйный башлады. Җәһәннәм!

2

Сугыш иртәнгә хәтле барды. Әле без уголовникларны кудык, әле алар безне кысрыклады. Әгәр бу сугыш тагын беразга сузылса, без инде җиңеләчәк һәм бандитлар башбаштаклыгына дучар булачак идек. Бәхеткә, таң тынар-тынмас, баракка бер отделение солдат белән конвой башлыгы килеп керде.

Солдатлар, приклад белән сугып егып, ике якны аерып, унлап тоткынның кулларына богау салып, типкәләп, өстерәп алып чыгып киттеләр.

Барак тынды.

Безнең яктан дүрт мәхбүс үлгән икән, аларны санитарлар, носилкага салып, моргка алып китте. Җиңел яралы-

лар үзләре медпунктка өстерәлде. Авыр яралылар калды: кайсы җирдә, кайсы сәкедә. Алар белән маташырга вакыт та, мөмкинлек тә юк иде. Мин, Аллага шөкер, җиңел котылдым, сул күз күгәргән, уң кулда пычак ярасы. Күлмәк җиңен ертып кысып бәйләгән идем, сызлавы басылгандай булды.

Уголовникларның югалтуы нихәтле булгандыр, билгесез. Алар үлекләрен дә, яралыларын да чыгарып, үз баракларына алып китәргә өлгергәннәр. Менә шулай итеп, без Антибес лагере белән таныштык.

Өч-дүрт көн баракны төзәтү, сәкеләрне җәю, тәрәзәләрне кую, ишекләрне рәтләү, тазарту, юу белән үтте. Баракка бераз торак төсе керде. Әмма мичне яңадан сала алмадык, ичмасам, бер бөтен кирпеч калсачы. Колосниклар, ишекләр, япкычлар берсе бер калмаган, ватылып, кыйралып беткән.

Вахтадан ике тимер мичкә бирделәр. Аларны алып килеп, баракның ике башына урынлаштырдык та морҗалар куйдык. Мичкәләрнең бер як төпләрен тиштек.

Мич әзер!

Утын да җитәрлек, теге сугышта кыйралып, эштән чыккан сәке такталарын, ишек яңакларын арлы-бирле ярып, кисеп, мичкә тутырдык. Мич дөрләп янып китте. Беренче тапкыр баракка җылы төште.

– Яле, яшьти, миңа да урын калдыр, – дип, калын бас гөрелдәде.

Карасам, берәү, мүкәләп, сәкегә менеп маташа. Бер аягы балтырдан киселгән, икенчесенә иске тун җиңе кидерелгән, өстерәлеп килә. Башы иске бер чүпрәк белән уралган, кан сирпеп тора. Күзләр күм-күк. Авыз ерылган...

– Әй, кызык та булды соң сабан туе, ә?

Бу кем? Абайлабрак карасам, теге баррикадада такта белән селтәнеп уголовникларны пыр туздырган батыр. Почмаккарак кысылып, урын бирдем.

– Әйдә, менә монда сузыл, кысылып ятсак, җылырак булыр.

3

Яңа күршем миңа әллә ни кысынкылык күрсәтми, комачауламый, киресенчә, файдасы тия.

– Мин – Маслов Валентин Валентинович. Илле сигезенче статья, ... пункт, ун ел төрмә, – дип таныштырды

ул үзен.

– Ул унлыкны кайда элəктердең? – дим.

Авызы тагын ерыла... Əллə нинди җилбəзəк сыман. Əллə инде шөрепләре тулы түгел...

– Котелоктан, – ди.

Мин гаҗəплəнəм.

– Ничек «котелоктан»? Ул чумар түгел бит.

– Нəкъ менə өстенə бастың... Чумар эченнəн килеп чыкты.

– Тукта əле, Валентин, сөйлəсəң рəтлəп сөйлə, башны катырма! Чумар белəн ун ел арасында байтак аерма бар.

– Алайса, тыңла, – ул, койрыгы белəн шуышып, минем янга елышты. – Волхов юнəлешендə, бер һөҗүмдə мине яхшы ук теттелəр, дүрт ярчык берьюлы килеп утырды. Өчесе – аякка, берсе – кулга. Кулныкы зарарсыз, санбатта ук алып ташладылар. Ə менə аяктагылар яхшы ук алама булды. Сул аякны чəлтердəн кисəргə туры килде. Ə уң аяктагысы əллə кая эчкə кереп киткəн, табанда, бастырмый.

– Син бит госпитальдə булырга тиеш.

– Ə мине кайдан дисең – госпитальдəн.

– Ə нигə монда?

– Əйттем бит. – Ул тагын авызын киң ерып елмайды.

Бу үзе эре бəдəнле адəм, баш зур, колаклар салынып тора. Утыргач, аның янында мин – бүкəн янындагы түмгəк төсле генə. Əмма, шундый баһадир гəүдəле булуына карамастан, сабый балалардай беркатлы, ачык. Ак күңелле, ачуланмый. Ə инде бер кузгалса, теге көндəге сыман, аны инде бер кеше тыя алмый.

– Озын сүзнең кыскасы, госпитальдə бик начар ашата башладылар. Иң ачу килгəне – санитарларның комсызлыгы... Дежурныйлар күрə бит... Безгə дигəн итмайны кухняда үзлəре бүлеп ашыйлар. Ə безгə чумар урынына коры су, баланда. Беркөнне иртəнге обходта госпиталь башлыгына əйтеп салмыйммы: «Лев Абрамович, безне эттəн яман ашаталар. Санитарларыгыз урлый». Иптəш кара көеп китте, бер сүз əйтмəде. Икенче көнне мине трибунал хөкем итте, контрреволюцион үгет өчен ун ел төрмə. Ярар! – Ул, койрыгы белəн шуышып, сəкедəн төшə дə башлады. Озын, табагач кулларына култык таякларына таянган сыман таянып, бер күтəрелеп, бер төшеп, барактан чыгып та китте.

Һәр көн шулай, иртәнге тикшерүдән соң, кайвакытта баланданы да көтмичә, шуып төшеп китә дә суга баткандай югала. Аннан бары кичке тикшерү вакытында гына кайта. Кая олага ул – Ходай үзе белә. Әллә урлашып йөри инде?

4

– Яле, күрше, колагың шешкән идеме, мә, тот, – ул, әле сәкегә менмәс борын ук, бияләй хәтле зур күн янчыгын ыргытты. – Рәхәтлән, кәгазе дә бар.

Янчыкның җебен тартып авызын ачуга, төчкереп җибәрдем.

– Әп-течи...

– Менә-менә, андый-мондый гына махорка түгел, марҗа чылатып үстергән әче җимеш.

Менә «кәҗә сыйрагы» төреп өлгермәдем, янчык кулдан кулга сәке, барак буенча китте. Валентин ике табагач кулларына таянды да сикереп сәкегә утырды.

– Ничек, тәмлеме марҗа җиләге?

– Тфү... – Мин чәчәлим, күзләрдән яшь ага.

Янчык кире кайтты. Буп-буш, күзгә кырып салырлык бөртеге дә калмаган тәмәкенең...

Тәмәке белән генә түгел, ара-тирә икмәк паёклары алып кайтып та сыйлый Валентин. Ә бүген, сәкегә утыруга, куеныннан бер пар менә диген өр-яңа хром итекләр чыгарды.

– Ничек, ошыймы?

Шаккаттым, телем бәйләнде.

Һичшиксез, карак. Лагерьда мондый итекне кайдан алмак кирәк. Тентү килеп, мине дә алып китмәсәләр ярый, «кәҗә сыйраклары»н, паёкларны борыныңнан чыгарырлар.

Ул итекләрен киредән куенына салды да бөгәрләнеп ятып гырлап та китте. Ә мин әле бер, әле икенче якка әйләнәм, һич йокы керми күзгә. Хәтәр кеше булып чыкты бит әле бу күрше, юкка үзенә урын бирдем.

5

– Менә шулай, безнең ыру гомер-гомергә Гатчинада тора. «Алтын аяклар» дип йөртәләр безнең нәсел кешеләрен.

– Ха-ха! Менә ябыштырдың, Валя, уйлап та тор-

мыйсың... Синең аякларны да алтынга манганнармы?

– Тукта, нәрсә авызыңны ерасың?! Мин дөресеннән барам. Россиянең барлык патшалары безнең башмакларны киеп йөргән.

– Ха-ха! Алтын башмак аркасында Антибеска килдең, ә?

– Җитәр, бүлдермәгез! Сөйләсен, эчеңне тишәме? Валя, әйт әле, мондый курчак шикелле итекләрне тегәргә материалны, хромны кайдан аласың?

– Җүләр, лагерьда әйбер беткәнме? Иске тун, иске бүрек, ташланган куныч. Менә шуларны җыям, тазартам, кыркам, буйыйм.

– Тукта, тукта, каты киттең. Буяу кайдан? Шурум-бурум түгел, әнә нинди лак. Янып тора.

Безнең сәкегә җыелган халык Валентин теккән шыгырдап торган хром итекләрне кызыксынып, сокланып карый. Кунычларын әйләндерәләр, олтаннарына, үкчәләренә чиртеп-чиртеп карыйлар.

– Фабричный...

– Тукта әле, әйтсен, лак кайдан, ә?

– Кайдан булсын, морҗадан. Анда сине лакларга да җитәрлек корым бар.

– Әйе, бу – булыр-булмас башмакчының эше түгел. Патша киярлек башмак тегү, дим.

– Ә-ә, Антибеска ничек эләккәнеңне яңа төшендем. Романовлар династиясе белән бәйләнештә булган өчен!

– Юләр, итекче белән патша арасында нинди бәйләнеш?

– Даң-доң! Даң-доң!

– Барлау!

6

Валентин лагерьның итек тегү цехында эшли. Антибестагы барлык түрәләр, бигрәк тә аларның хатыннары, кызлары, аны сырып алып, чиратлы-чиратсыз итек, боты, туфли тектерә башладылар. Хәтта Маршинск түрәләре дә Валентинны белеп алганнар.

– Заказ ун елга җитәрлек! – ди ул, кичен кайтып сәкегә күтәрелгәч. Әле һаман шаяра. Әмма элекке кебек озак-озак әңгәмәләр корып, патша итекләре турында хикәяләр сөйләми. – Мә, күрше, йөрәк ялга, – дип, миңа үзенең паёгын, анда-санда колбаса кисәген төртә дә бушлатын

ябынып гырлый башлый. Арый, бик арый башмакчы.

Ничек кенә булмасын, ул миңа зур терәк. Югыйсә эшләрем көннән-көн хөртиләнә башлаган иде. Валентин аркасында гына бераз хәл алдым.

Бу арада лагерь түрәләре безгә дә эш тапты – ике цех ачты. Берсе – эрләү, икенчесе – туку-бәйләү цехы. Беренче цехта сыңар аяклылар. Алар шул аяклары белән орчык әйләндерә, мамыктан җеп эрли. Икенче цехта бөтенләй аяксызлар, койрыкларына утырып, ыргак белән мамык җептән оек, бияләй бәйлиләр.

Мин беренче цехка эләктем. Башта орчыкны әйләндерү тансык-кызык булса да, иртәдән кичкә кадәр ялгыз аяк белән берөзлексез эшләү ярыйсы ук арыта башлады. Өстәвенә эрләвемнең юне юк, йә юан, төерле була, йә нечкә – өзелеп теңкәгә тия. Кичен эшне тапшырганда, йомгагымны бракка чыгардылар. Нәтиҗәдә паёгым өч йөз граммга төште, төшке ашта баландадан соң бирелә торган ярты чүмеч чумардан да колак кактым.

– Иртәгә дә брак бирсәң – карцер! – диде цех башлыгы, минем йомгакны сул яктагы кәрзингә ташлап.

Сүзендә торды, икенче кичне мин үз сәкемә кайта алмадым, карцерда йокладым... Валентин цех башлыгына итек тегеп биреп мине бәладән коткармаса, белмим, карцерда ничә көн булыр идем. Алай гына түгел, фырт эшкә күчерде.

– Син цехта мич ягып утырырсың, – диде цех башлыгы, мине эрләүдән алып. Көнозын җылыда, җитмәсә, ашханәдән бәрәңге урлап китерәләр. Пешереп бирәм, «өресе» үземә дә кала.

7

Бервакыт төнозын кар яуды. Иртә белән җил чыкты, күз ачкысыз буран күтәрелде. Ул көнне безне эшкә чыгармадылар, ишеккә йозак салдылар. Зонага тимерчыбык сузып, берничә эт җибәрделәр.

Һич көтмәгәндә бәйрәм. Бөтен барак дерт итеп кузгалды, төрле ярыкларга, тишекләргә, идән асларына яшерелгән карталар, шашкалар, шахматлар, ашыклар калкып чыкты. Ыгы-зыгы. Шау-шу! Уен. Сәке өстендә, сәке астында, идәндә өер-өер булып утырган, яткан, аягүрә баскан, азарт белән шашкан төркемнәр.

– Буби валет!

– Банкада унбиш паёк.

– Яп туз белән!

– Тукта, чү, хәрәмләшмә!

– Менә сиңа мат!

Төтен, пар. Сүгенү. Кычкырышу, сугышу. Тагын валетлар, корольләр шапылдый. Барак артында җил, давыл. Тәрәзәләрне кар баскан. Упкын-упкын җил сукканда, стеналар дерт-дерт итеп китә. Ә баракта бәйрәм. Кем ничек булдыра ала – шулай күңел ача, көлә, кычкыра, сикерә. Гаҗәп, һәрвакыт шат күңелле, кайгыра белми торган күршем Валентин гына күңелсез, бот башларын бушлат белән төргән дә түшәмгә текәлгән. Әүвәле куркып киттем, әллә инде җан тәслим кылган. Үрелеп карыйм – авыравыр итеп сулый. Озын сары керфекләре йомылып-йомылып куя.

– Валентин, әллә авырыйсыңмы?

Җавап юк. Җавап бирми.

– Валентин...

– Эч поша, күрше... Эч поша, – сул як бите тартылып, сикереп-сикереп китә. – Контузиядән... Борчылсам, һәрвакыт бит алмаларым сикерә башлый.

Үземнең сөйләшәсе дә килә. Әмма тагын сүз катарга базмыйм, нигә комачауларга, ичмасам, бер көн тынычланып сагынсын...

Ә сагынырлыгы, пошынырлыгы бар аның.

1941 елның беренче маенда өйләнә ул, туе була. Ә егерме икенче июньдә сугыш башлана. Валентин фронтта. Разведчик. Кыю һәм батыр хәрәкәт итеп, «кирәкле тел»не алып килгән өчен, аны Кызыл Байрак ордены белән бүләклиләр. Аннан соң һөҗүм, контузия, ике аяктан аерылу. Госпиталь. Инде өйгә кайтам дигәндә (дөресен әйткәндә, өй юк. Гатчина немецлар кулында. Кая да булса тылга китү мөмкинлеге генә бар...) кинәт хәрби трибунал. Ун ел төрмә. Антибес.

Менә бит кеше язмышы нинди чокыр-чакырлы. Сагына ул. Сары сагыш.

– Со-ло-вей...

Кинәт барак калтырап, яңгырап китте. Мин торып утырдым. Бу ни? Бу нинди көчле, моңлы, яңгырау тавыш? Барактагы барлык шау-шу, сүгенү, кычкыру тынды.

Җыр үсте, көчәйде, сандугач булып өзгәләнде. Тышта буран, өермә, җил сызгыра, ыңгыраша. Җил, саташып, баракка ташлана, аны дер селкетә. Ә монда, барак эчендә, моңа кадәр һич күренмәгән тынлык, изге тынлык. Карталар, паёклар, сүгенүләр, якага-яка килешүләр – барысы да онытылган. Бөтен барак сихерләнгән, тылсымлы җырны тыңлый. Монда җәй. Монда иртәнге кояшлы, җофар исле урман. Монда өзелеп-өзелеп, очынып-очынып сандугач сайрый:

Соловей мой, соловей,
Голосистый соловей!
Ты куда, куда летишь,
Где всю ночку пропоёшь?

Валентин урыныннан торып тезләнгән, башын артка ташлаган. Ярты гәүдәсе белән дә ул башкалардан биек булып, мәһабәт булып күренә. Ул, бар күкрәгенә, бар мәһабәт тавышына ирек биреп, йөрәген бушата.

Йөрәк! Кеше йөрәге, син нинди бөек һәм илаһи! Ул менә хәзер җыр булып, өмет булып, еРактагы якты азат көн булып ташый:

Соловей мой, соловей,
Голосистый соловей!..

Валентин Маслов безнең баракның гына түгел, барлык колоннаның – Антибесның юанычы, сөенече булды. Кичләрен эшкә чыкмаган яңгырлы, буранлы көннәрдә аның җырлавын үтенәләр. Ул кыстатмый, дөресрәге, үзе теләп җырлый, моңая. «Вниз по Волге матушке-реке», «Вдоль по Питерской»...

Нинди генә җыр җырламасын, ахырында ул нигәдер Алябьевның «Сандугач»ын кабатлый... Гаҗәп бер көй, моңлы тавыш белән сандугач булып өзгәләнә ул.

– Бу көйне Дусям ярата иде... Гел шушы җырны җырла әле дип үтенә иде, – диде Валентин миңа бервакыт, ачылып китеп.

Теге беренче төн сугышыннан соң каршыдагы баракта торучы уголовниклар белән пычакка-пычак яши идек. Хәтта безне баланда алырга, паёк алырга ашханәгә үткәрмиләр, талыйлар, кыйныйлар иде. Бары тик конвой белән генә йөрибез. Бигрәк тә алар Валентинга үчле, аны үтерергә җыеналар иде.

Гаҗәп. «Сандугач»ны ишеткәч, алар бөтенләй үзгәрде.

– Валюша, безнең баракка да килеп бер җырла әле, – дип үтенә, чакыра башладылар.

Ике барак арасында дуслык урнашты. Ул гынамы?

Валентин җырлый башласа, аны тыңларга вахтадагы түрәләр килә. Манарада сакта торган солдатлар, автоматларын куеп, таң калып тыңлыйлар иде. Ул җырлаганда бөтен лагерь дерелди. Көчле, көр, музыкаль иде аның тавышы.

Ә куллары?

Куллары, чыннан да, алтын булып чыкты. Валентин теккән итекләр, туфлиләр, иң соңгы фасон, модага әверелеп, лагерь түрәләре хатыннары арасында көнчелек-ызгыш тудырды, һәрберсе Маслов теккән туфлине генә кияргә тели. Ул хәзер, күпме тырышмасын, тегеп өлгертә алмый. Ә түрәләр көтәргә яратмый. Ахырында шушы чибәр осталык – алтын куллар – аның башына җитте.

Бу вакыйга менә ничек була. Беркөнне конвой командирының хатыны Валентинга итек тегәргә заказ бирә һәм тиз арада тегеп бетерергә куша – кунакка барырга кирәк. Ә икенче көнне колонна башлыгы Валентинны кабинетына чакыра да:

– Берсекөнгә кызыма туфли тегеп өлгерт. Туй, – ди.

– Гражданин начальник, миндә әле конвой командирының ашыгыч заказы бар бит, – ди Валентин, аптырап.

– Өмерне үтә! – дип, түрә аны куып чыгара.

Валентин бу ике көнне йокларга да кайтмады, эштә булды.

– Уф Алла! – дип, икенче көнне көчкә кайтып егылды. – Бер убырдан котылдым. Туфли кызга ошады. Менә бүләк итеп бер пачка «Казбек» та бирде.

Без папиросны тартып та өлгермәдек, вахтёр йөгереп килде, мышнаган.

– Командир чакыра.

– Капут! – диде күршем миңа карап, рәнҗүле елмаеп.

– Ярар, телеңә салынма, тиз!

Валентин зур бияләй кулы белән минем кулны кысты да, койрыгында шуып, сәкедән төшеп китте.

Әйтерсең лә суга батты. Шул китүдән без Валентинны күрмәдек. Вахтёрларның әйтүенә караганда, конвой командиры Валентин Масловны, лагерь режимын бозуда

гаеплəп (мастерскойда кунган өчен), əүвəле карцерга япкан, аннан штраф зонасына җибəргəн.

...Бүлмəмдə Алябьевның «Сандугач» җыры яңгырый.Ниндидер җырчы, фамилиясен ишетə алмый калдым, көчле бас белəн җырлый, тавыш бер үсə, күтəрелə-очына, бер кинəт төшеп китə.

Йөрəк өзгəлəнə.

Дустым Валентин да ишетəме икəн хəзер бу җырны – бу бит минем аңа сəламем, сагыну тавышым.

ЮЛНЫҢ СОҢЫ

1

...Ниһаять, ирек!

Вахта ишегеннəн чыгып, əле яңа гына явып үткəн күбек кар өстеннəн агач аяк белəн бата-чума бер-ике адым атладым да туктап калдым. Өнемме, төшемме? Мин хəзер чыннан да иректəме? Хəвефлəнеп, шиклəнеп кенə артыма əйлəнеп карадым. Бу ни хəл? Күлəгə булып артымнан калмый «тиз-тиз!» дип этəрмəлəп, сүгеп йөргəн автоматлы сакчылар да, «һау-һау» килеп өскə ыргылып торган овчарка этлəр дə күренми. Сəер! Чыннан да, алар инде юкмы? Əллə теге тар ишекле, рəшəткə тəрəзəле вахтада яшеренеп, бу нишлəр икəн дип сагалап кына торалармы юкса? Ун ел буе канга, тəнгə, сөяккə сеңеп калган бу явыз иярченнəр-тагылмаларның кинəт юк булуына күңел дə, күз дə ышанып бетə алмый. Аптырап, сагаеп, куркып-дерелдəп тирə-якка карыйм. Ат башы хəтле йозак белəн биклəнгəн тимер капка. Ике кат чəнечкеле тимерчыбык белəн уратылып алынган зона.

Тырпайган чəнечкеле тимерчыбыклар артындагы тəбəнəк баракларга карыйм – күзлəремне ала алмыйм... «Их! Син бəхетле... Ə без? Без ул көнне, азатлыкны күрə алырбызмы, əллə монда «такта бушлат» киярбезме... Ирекка сəлам!» – дип, анда калган дусларның көрсенеп, еламсырап əйткəн сүзлəре, тавышлары колагымда чыңлый.

– Нəрсə катып калдың, аксак?! Əллə лагерьдан китəсең килмиме, контр?!

Вышкадагы сакчының кычкыруына сискəнеп-каушап, ашыгып кузгалган идем, агач аяк таеп китте, мəтəлеп барып, юл читендəге көрткə егылдым.

– Ха-ха! Ха-ха! Әй, ни таптың, аксак? Яртысын миңа да бир... Ха-ха! – Тик торудан иреккән яшь кенә егет эче катып көлә. – Әй, контр кисәге, ирек тәмлеме? Нәрсә, Аллаңа сәҗдә кыласыңмы? Ха-ха!

Көч-хәл белән агач аякны шудырып барып, көрткә терәп күтәрелдем, тәнем – шабыр тир. Җилкәдәге капчык әйләнеп килеп күкрәккә төшкән, муенны кысып буып тора. «Биштәр»не аркага этеп ташлап, юлга чыктым.

Нинди матур тирә-як! Җем-җем итә, гүя энҗе сипкәннәр. Хуш ис, беренче кар исе! Беренче яңгыр – ләйсән яңгыр! Шифалы яңгыр. Балачакта «үсәбез, үсәбез!» дип, шул яңгырда коена идек ич. Ә беренче карны ничек атыйлар соң? Минемчә ул да ләйсән – пакь, йомшак, җирне ничек итеп агарткан – ак җәймә җәеп чыккан. Мөгаен, минем бүген ирекккә – азатлыкка чыгуымны хөрмәтләп, табигать дөньяны алмаз кыйпылчыклар сибеп бизәгәндер. Яңа күтәрелеп килгән кояш нурларында алар күзләремне чагылдыра, салават күпере төсләре белән балкыйлар.

Хуш ис! Беренче кар исе нинди рәхәт, сулап туя алмыйм! Үзем ашыгам – Мариинск вокзалына җитеп, Күкчәтауга билет алырга кирәк! Әле һаман болай конвойсыз баруыма, тимер юл поездына үзбаш билет алырга ашыгуыма ышанып җитә алмыйм. Бу ашкынулар барысы да төш кенәдер дип куркам, үземне үзем чеметеп карыйм. Үч иткәндәй, ашыккан саен, агач аяк таеп-таеп китә яки юл читендәге көртләргә төртелә. Аякны күтәреп алып, урап атларга туры килә. Әле һаман агач аякка күнегә алмыйм. Их, бу бүкән башы урынына үз аягым булса, ничек йөгереп китәр идем мин...

Моннан ун ел элек – 1937 елның егерме бишенче октябре иртәсендә – нәкъ менә бүгенге кебек ашыгып атлый идем түгелме? Юк! Юк, кызганыч ки, бүгенгедәй түгел шул.

...Казан. Көз. Томанлы иртә. Урам буендагы агачларның яфраклары әле яңа гына саргая башлаган. Алтын көз. Мин егерме алты яшьлек, таза, типсәм тимер өзәрлек егет, – Казан педагогия институтының дүртенче курсы студенты. Әмма читтән караганда мин әле хәрби. Өстә – хаки төсендәге постау гимнастёрка, күгелҗем галифе. Башта – өр-яңа фуражка, йолдызы гына алынган. Аякларда – кунычлары ялт-йолт итеп торган

хром итекләр. Һәрхәлдә, өч еллык хезмәттә полк мәктәбен бетереп, кече командир дәрәҗәсенә күтәрелгән егет идем ич мин! Институтка килгәч тә, мин бу хәрби киемнәрнең кайберсен гади пиджак, чалбарга алыштырмадым. Ошый иде миңа хәрби кием, килешә дә иде. Курсташ кызлар да: «Ибраһим, хәрби кием бик килешә сиңа», – диләр иде...

Биек, киң ишектән кереп, инде менә бу иләмсез тәбәнәк вахтаның тар капкасыннан кысылып чыкканчы бары тик ун ел гомер узган. Ун ел! Егерме алты белән утыз алты арасындагы алтын еллар!

Яшьлегемнең иң гүзәл, иң шаулы, иң мөкатдәс көннәре! Алар шушы ике ишек арасында калды... Нигә?

Юлдан атылып килгән бер «Москвич» чак кына үземне таптап китмәде, көч-хәл белән көрткә авып калдым.

– Ачык авыз! Йолкыш! Юньсез аксак! Нәрсә комачаулап йөрисең?! Читтән барырга ярамыймы әллә? Синең аркада яхшы кешеләр бәлагә юлыгыр! – Машина эчендәге адәм, тәрәзәсеннән башын сузып, әнә шулай тиргәп-сүгеп китте.

Ә мин көрткә бата-чума көчкә күтәрелдем.

Тукта, нигә рәнҗедем соң әле мин – дөресен әйтте ич. Сул аяк урынына чыпта белән бәйләнгән бүкән башы. Өстә ертылып-таланып беткән токкын бушлаты һәм шул ук сорттагы ертык балаклы чалбар. Ялгыз аякта ямалыр урыны калмаган ЧТЗ. Башта – бер колагы йолкынган бүрек кисәге. Иреккә чыгасымны ишеткәч, барактагы иптәшләрнең берсе посылка белән алган чалбарын, икенчесе өстендәге яңа бушлатын салып биргән иде. «Безгә ярар, ә син инде – иреккә! Артык мескен күренмә», – дип сөендергәннәр иде. Бүген вахтадан узганда, сакчы: «Лагерьдан яңа кием белән чыгарга рөхсәт юк! Яле, хәзер үк сал», – дип, шундук чишендерде дә, яңаларны үзенә алып, почмакта яткан ертык-портыкны миңа ташлады. «Мә, йолкыш, мыштырдамый тизрәк эл дә сыздыр. Юкса хәзер, лагерь милкен урлаган өчен, икенче срок бирдерермен».

Мондыйлардан булыр да. Каушавымнан, киенер-киенмәс, вахтадан атылып чыктым.

Ә шулай да нигә соң мин аксак? Нигә мин йолкыш? Ун ел элек мин аксак та, йолкыш та түгел идем ич. Нигә?

– Әй, бабай, Мариинскигамы? – Бер йөк машина-

сы шып итеп минем янга туктады. – Әйдә, утыр. Ирекккә ашыгасыңмы, батя?

Кабина ачылды. Мин агач аякны этә-төртә көчкә күтәрелдем.

2

Тык-тык. Тык-тык. Вагон бертуктаусыз тыкылдый, чайкала, буферлар сугылып, зыңлап китә. Поезд Себер урманнары, Себер сопкалары аша Көнбатышка ашыга.

Инде, мөгаен, төн уртасы. Вагон уртасындагы «буржуйка» каршында карта суккан бер төркем «фырт»лар да, югары сәкегә менеп, калайланып уралганнар. «Буржуйка» инде сүнгән. Мариинскига минем кебек лагерьдан азат ителгән байтак тоткын җыелган икән, күбесе – уголовниклар. Барыбызны бергә җыеп, җимерелеп беткән бер товар вагонына тутырдылар да Аллага тапшырдылар.

Лагерьда вакытта «Ни булыр, азат итәрләрме, юкмы?» дип тәшвишләнеп, өч-дүрт төн йоклый алмаган идем. «Инде вагонга эләксәм, аю йокысы белән йоклармын», – дип уйлаган идем. Менә хәзер мин вагон эчендә, күзләргә йокы гына кунмый. Күңел ашыга, ул инде әллә кайчан Кукчәтауда...

Кем каршы алыр икән? Билгеле инде, әти, үги булса да әни, сеңлем Разия. Әй, куанырлар! Ул арада тирә-күрше, дус-иш килеп җитәр. Иптәшләр күп иде дә күбен, сугыштан кемнәр генә исән-сау кайта алды икән? Бардыр, бардыр әле бергә ат-ат уйнап үскән малайлар. Их, сагындым үзләрен!

Тик менә өс-баш бик хөрти. Җитмәсә, бет сырып алган. Әле монда, вагонда, суыкта да йә бер, йә икенче җирне тешләп, кычыттырып теңкәгә тияләр, каһәр төшкерләре. Әй, оныта да язганмын, әти: «Хәзер без Сафаларда торабыз. Аңа өй салып бирергә сөйләштем. Кайтсаң, туп-туры шуларга төш», – дигән иде бит бер хатында. Ә Сафа җизниләрдә борын-борыннан мунча бар. Әни, һичшиксез, мин кайтуга мунча ягып җибәрер. Күлмәк-ыштанны шартлаганчы бер кыздырырмын инде, барып җитсәм.

Их, рәхәтләнеп бер чабынырга! Юк, бер чабыну белән генә ун ел каешланган арка бирешмәс. Аны өч-дүрт тапкыр каезларга туры килер, һичшиксез.

Әти өс-башка берәр кием алып куйса ярар иде, ха-

тымда язган идем язуын. Хәзер сугыштан соң кием-салымы да юктыр, солдат иске-москысы булмаса. Булса, анысы да ярап торыр иде. Нәләт, теге вахтадагы сакчы өр-яңа бушлат белән чалбарны тартып алып калды бит... Аны инде бер «ярты»га әллә кайчан шуыткандыр.

Әгәр аз-маз рәтле кием табылса, шунда ук эш эзләргә китәм, алтмышка җиткән атаның җилкәсен кимереп ятып булмас. Нинди эш булыр икән? Билгеле инде, мәктәпкә укытучы итеп алмаслар алуын. Илле сигезенче статьядан соң биш ел мәхрүмлек тә бар ич әле. Бәлкем, редакциягә урнашырмын, хәбәрче кебек йөремсәк эш уңайсыз булыр булуын. Тик нишлисең, кайда да йөрергә кирәк. Әй, ярар, нәрсәгә монда бүрәнә аша бүре куып ятам. Кайткач күз күрер. Туган җиргә кайтам бит. Туганнар да, дус-ишләр дә җитәрлек ич анда.

– Ту-у-уу!

Паровоз бөтен тирә-якны шыңлатып кычкыртты. Мөгаен, берәр станциягә якынлашабыз булыр. Ашыйсы да килә... өч көнгә бирелгән коры паёкны вокзалда ук ашап бетердем бит. Яхшы эшләгәнмен. Булмаса, мондагы уголовниклар хәзер талап алырлар иде. Әнә теге аскы сәкедә яткан картның сумкасын күз алдында «шуыттылар». Мескен акырып-акырып елады: «Соңгы паёгым иде. Тагын дүрт көн кайтырга кирәк», – ди.

– Ту-уу...

Паровоз тагын кычкыртып, ухылдап, станциядә туктамыйча гына алга омтылды. Әйдә, әйдә, корыч атым, ашык, тизрәк йөгер! Алда минем туган Күкчәтавым...

3

Йөрәк дөп-дөп итә. Бу ни – каушаумы, әллә куанумы?

Ай болытлар арасыннан йөзеп килеп чыкты: тирә-як яктырып китте. Менә каршымда инде җиргә сеңеп барган, кыйшайган кәс түбәле өй – Сафа җизниләрнең йорты. Безнең өй әнә теге каршыдагы мәчетнең аръягында, почмакта иде. Утызынчы елларда, калада тормыш авырайгач, әти, ул өйне сатып, алтын приискаларына киткән булган. Хәзер тагын Күкчәтауга күчеп кайткан да, әнә вакытлыча, үзенә яңаны салып алганчы, Сафа җизниләрдә тора икән.

Бу ике бүлмәле иске өй миңа кечкенәдән таныш. Мин бит ялгыз гына бала идем, уйнарга абыем да, энем дә булмады. Ә монда, җизниләрдә (әтинең бертуганы

Әшрәф апаларда), бер көтү бала-чага. Җизни Күкчәтау – Акмулла – Кызылъяр арасында йөк ташый, ә апа йомшак табигатьле, безне орышмый. Тирә-күрше балалары белән бергә өйне ду китереп уйныйбыз. Төннәрен апаның өлкән улы Хәсән, без сыер астын, ат абзарын тазарткан, көрәгән өчен, «Алтынчәч»не сөйли, һәр төнне шул бер үк әкият, әмма кызык!..

– Сөйлә, сөйлә инде, Хәсән абый.

– Иртәгә өлкән кураны тазартып, тиресне түгәсезме?

– Түгәбез.

Мондый кызык әкиятне тыңлар өчен тирес түгү түгел, утын ярырсың.

Ләкин бу йорт миңа кызыклы әкиятләр белән генә түгел, ә фаҗигале бер хәл белән дә истә. Бу йортның бусагасы төбендә минем кадерле әнием Маһиҗамал фаҗигале рәвештә вафат булды.

Безнең әти белән әни Татарстанның Балтач ягыннан, әүвәле бабай, аның артыннан әти Себергә эш эзләп килгәннәр дә Күкчәтауда төпләнеп калганнар. Әти, солдатка каралырга кайткан вакытында өйләнеп, әнине дә Күкчәтауга алып килә. Башта алар үзләренә оя табу нияте белән көне-төне эшлиләр, авылга кунакка кайту турында уйларга вакыт та булмый. Инде өйне салып бетереп, «уф Алла» дип тынычланганда гына Герман сугышы башлана. Әти фронтка китә. Аннан революция. Аннан Колчак, атаман Анненков баскыннары, кулаклар фетнәсе һәм, ниһаять, дәһшәтле ачлык. Егерме беренче елда ваба авыруы белән бергә Идел буе халыкларын кырып салган коточкыч ачлык.

Менә шулай итеп, әнием, килен булып төшкәннән бирле, ун елга якын, туган бусагасына атлап керә алмый, атаана, туганнарын күрә алмый.

Ниһаять, 1922 елда дөнья бераз тынычлангандай була, игеннәр уңа. Безнең күршедәге Бану әби (ул Түнтәрдән икән) авылына кунакка кайтырга җыена. Моны ишетеп, әнием дә җилкенә. «Сиңа әйтәм, әти-әнине бик сагындым. Бану әбигә ияреп барып кайтыймчы. Улымны да алып барыйм», – ди. «Сала башлаган өем бар, эшне ташлап китә алмыйм, алайса, Ибрай белән үзең генә барып кил. Өйнең акчасын алданрак сорарлар, юллык сәмән генә бирермен», – дип, әти бу сәфәргә каршылык күрсәтми.

Әни юлга әзерләнә башлый. Күчтәнәчләр ала, аш-су пешерергә тотына. Ә мин инде урамда, дусларым Галәү, Фәйзи, Гомәрханнарга мактанам:

– Беләсезме, мин Казанга китәм бит.

– Шартлатасың, андый еракка сине кем алып барсын?

– Валлаһи, – дим.

– Борчак сибәсең, – диләр.

– Барам дигәч барам, әни белән барам.

Бу хәбәргә безнең урамдагы барлык балалар шаккатты.

Чыннан да, ышанырлык хәбәрмени, балтачы Низаминың улы Казанга барсын, имеш.

Ә әни инде авылдашларга күчтәнәчкә дип чәкчәк, кош теле, бавырсак, тагын әллә ниләр, әллә ниләр пешерә. Үзе: «Аш-суым бик уңа, юлыбыз, иншалла, уң булыр!» – дип сөенә, очып-кунып йөри. Ару-талуны белми, көтү куганнан алып караңгы төнгә хәтле йөгерә, һаман юлга әзерләнә. Бану әби, кереп:

– Ходай боерса, җомга көн Кызыл Ярга кузгалырбыз, килен, иншалла, – дип, юлга кузгалу көнен дә билгеләп чыкты.

Нәкъ шул көнне әти эштән гадәттәгегә караганда соңга калып кайтты. Әни, аны капка төбендә үк каршылап:

– Сиңа әйтәм, нигә болай озакладың? Самавырымны өч тапкыр яңарттым, – диде.

– Яман хәбәр ишетелеп тора әле, – диде әти салкын гына, капка төбендәге бүрәнә өстенә утыра калып, балтасын бүкәнгә чапты. – Ревкомга барган идем.

– И... Раббым, – әнием коелып төште, – әллә тагын сугышмы?

– Казаклар тагын фетнә күтәргәннәр. Күкчәтаудан пропускысыз берәүне дә чыгармыйлар, ди.

Ул төнне әни йокламады, намазлыгын җәйде дә бик озак намаз укыды, елады, пышылдап, ниндидер догалар укыды.

Ул вакытта әле Күкчәтауга тимер юл килеп җитмәгән иде. Казанга барыр өчен әүвәле йөз сиксән чакрымдагы Кызыл Яр каласына барырга, шунда поездга утырырга кирәк иде. Ә менә хәзер анда барыр өчен ВЧКдан пропуск кирәк. Аны ничек алырга? Менә бит, инде кузгалам дигәндә генә...

Бер төндә әнием танымаслык булып суырылды, ап-ак булып калды. Күзләре эчкә баткан, иреннәре күгәргән.

Мин дә аптырадым. Әгәр алай-болай Казанга бара алмый калсак, малайлар күзне ачырмаслар, «буш куык» дип кенә йөртерләр.

Әти иртәнге чәйдән соң, гадәттәгечә, алъяпкычын киеп, пычкы-балтасын алмады.

– Булмаса, Сафага барыйм әле. Ул түрәләр белән таныш. Может пропуск алып бирер.

– Әти, мин дә барам.

Өчебез дә Сафа җизниләргә киттек.

Әни нигәдер бик акрын, туктап-туктап кына барды. Җизниләргә килеп җиткәч тә: «Тыным кыса. Менә шушында гына утырыйм әле», – дип, ул баскыч төбендә утырып калды. Әти белән мин эчкә, өйгә кердек. Пропуск турында әйткәч үк, җизни торып җиләнен киде: «Әйдә, түрә андамонда китканче барыйк. Фетнә булгач, алар өйдә утырмаслар», – дип кабаланып чыгып та китте. Олы кызы Рабига «Мин дә барам» дип, әтисенә иярде. Мин, урамда бер малайны очратып, кичен далага ат багарга бару турында сөйләшә, киңәшә калдым.

Мин инде әтиләр турында оныткан да идем. Рабига йөгереп килә, бөтен урамны яңгыратып кычкыра:

– Сөенче! Сөенче!

– Нинди сөенче?

Ул арада Рабига баскыч төбендә утырган әни янына килеп тә җитте, баягыдан да катырак кычкырып тезеп китте:

– Апа, апа, сөенче! Начальник пропуск бирәм диде!

– Ә... ә! – Әни сискәнеп күтәрелеп карады, пышылдап кына тагын: – Ә... ә, – диде дә ике кулы белән күкрәген кысып авып китте...

Икенче көнне, җомгадан соң, безнең урамнан күл якка ике олау кузгалды. Алда әни, аның артында Бану апа. Ул – Казанга, әни – зиратка. Зират күл буенда, Кызыл Ярга бара торган олы юл каршында иде.

Әле менә хәзер дә әнием бу өйнең баскычы төбендә хәл җыеп утыра кебек...

Чымырдап өшеп киттем, вокзалдан җәяү килеп тирләгән идем инде, кузгалмый басып торгач, тир каткан. Күкчәтауда әле кар төшмәгән икән, шулай да суык, көзге кара суык. Болыт арасына кереп качкан ай тагын күренде.

Тузган, кыйшайган иске өй, кинәт яктырып: «Нихәл, исән-сау кайттыңмы? Сине күрмәгәнгә байтак булды бит...» – дип, минем белән исәнләшкәндәй булды.

Кайттым, кайттым, ага-йорт! Үзем дә сизмичә, калын, карт бүрәнәләрне капшый-сыйпый башладым; сагынып кайттым сезне, сабый чак бишегем.

Йорт кинәт юк булды. Дөм караңгыда калдым. Әллә куркынып, әллә инде туңып дерелди башладым. Нишләп торам соң, шакырга, уятырга кирәк. Тәрәзәгә якынлаштым. Йөрәгем ярсып китте, кулымны күтәрәм дә, дерелдәп, шакый алмыйча кире төшерәм. Кемнәр тора икән хәзер бу өйдә? Танырлар микән? Ашыгып, каушап, тәрәзәне шакырга үрелгән идем, агач аяк нигездән таеп китте дә, тәрәзә яңагына барып сугылдым.

– Әй, кем анда?

Әти тавышы.

– Мин... бер мосафир... кунып чыгарга рөхсәт булмасмы?

Өй эче яктырып китте, кысып куйган лампаның филтәсен күтәрделәр. Өстәл янында озын чандыр бер кеше, ак күлмәк-ыштаннан. Әти! Сәкегә иелде, мөгаен, өстенә кияргә эзли. Йөрәк дөп-дөп итә. Чыннан да, бу минем туган әтиемме?

– Хуҗа...

– Ибрай! – Әти кычкырып, тәрәзәдән атылып чыгардай булып, йөгерә-аксый, мин торган тәрәзә ягына килде: – Ибрай... син кайттыңмы?.. – Ул үксеп елап җибәрде.

4

Ирек ул иркенлек-тиңлек түгел икән әле. Минем өметләр, язгы гөрләвекләр өстендәге иртәнге юка боз кебек, атлаган саен чатный, челпәрәмә килеп ватыла бара.

Күкчәтауда рус телендә өлкә газетасы чыга икән. Беркөнне редакторга кердем, үземнең Казанда республика газеталары редакциясендә эшләвемне, шигырьләр язуымны, инде басылып чыккан өч китабым булуын сөйләдем. Редактор, урта яшьләрдәге күзлекле кеше, өстәленә иелеп, минем сүзләрне «алай икән» дип җөпләп, дикъкать белән тыңлады да, мин сөйләп бетергәч, кинәт тураеп, кашларын җыерды:

– Гафу итегез, бездә сезгә лаеклы эш табылмас, – диде һәм, телефон трубкасын алып, кемгәдер шалтырата башлады. Бу инде сүз бетте, китәргә мөмкин дигән ишарә.

Шәһәр мәгариф бүлегенә барып, үземнең педтехникум тәмамлавымны, пединститутның дүртенче курсыннан китүемне әйтеп, башлангыч мәктәптә урын табылмасмы дигән идем. Сап-сары бөдрә чәчле мөлаем ханым, сөрмәле кашларын җыерып:

– Балаларыбыз язмышын без халык дошманнары кулына тапшыра алмыйбыз, – диде.

Бала вакытта бергә ат-ат уйнап, аннан мәктәптә бергә укып үскән Нигъмәтулла исемле иптәшем бар иде. Ул хәзер Күкчәтауда заготскотның өлкә конторасында директор булып эшли икән. Бу хәбәрне ишетүгә, күңелем яктырып китте, менә кем миңа бер эш табып бирер. Тизрәк барып күрешергә, сөйләшергә кирәк. Ул әле минем кайтканымны ишетмәгәндер, югыйсә әллә кайчан йөгереп килеп җиткән булыр иде бит.

Иркенләбрәк сөйләшеп утырырбыз дип, конторасына бармадым, кичне көттем. Аның атасы Фәсхетдин абый да (мин читтә йөргәндә, үпкә авыруыннан вафат булган икән) балтачы иде, әти белән бергә эшли иде. Өйләрен дә бергә салганнар иде. Шуның өчен мин аларның өйләрен беләм, Кызыл урамында, чат башында ике бүлмәле, алтыпочмаклы өй.

Бала вакытта Нигъмәтулланы «черки» дип атый идек, тәбәнәк, ябык, авырудан чыкмый иде. Хәзер, өйләрендә каршыма килеп баскач, имәнеп киттем: миннән калку, таза, хәтта аз гына корсагы да бүлтәеп тора. Әллә ул, әллә башка...

– Ә, кайттыңмы? Яхшы булган, – диде ул салкын гына, теләр-теләмәс кенә кулын биреп.

Күрештек. Утырдык. Ул нигәдер тиз генә аш бүлмәсенә чыгып керде. Мөгаен, хатынына самавыр куеп җибәрергә кушкандыр. Тәмәке тарттык. Инде йомышым турында сүз башлыйм гына дигән идем, аш бүлмәсеннән хатын-кыз тавышы ишетелде:

– Әй, Нигъмәт, без инде кинога соңга калабыз ич. Нигъмәт сул кулын күтәрде, карады – алтын сәгате ялтырап китте.

– Әйе, әйе, Бибиҗан, – ул, торып, шифоньердан ко-

стюмын алып кия башлады. – Ибраһим, син инде гафу ит, без билет алып куйган идек. Бик кызык картина, ди, бүген.

Капка алдына чыктык. Нигъмәтулла нигәдер ялт-йолт тирә-якка карады, миңа тиз генә кулын сузды, хушлашты һәм пышылдап кына эндәште:

– Син инде, Ибраһим, безгә килеп йөрмә, күршеләр бик алама. Мин, наверное, вакыт булса, үзем сезгә барып чыгармын. Сафа абзыйларда торасызмы? Ярый, хуш.

Ул ашыгып кире өенә кереп китте.

Үги әнинең йөзе көннән-көн караңгылана башлады. Үземә турыдан-туры әйтмәсә дә, күршеләргә кереп: «Кайтканына өченче ай китте. Эш турында уйламый да, һаман атасының җилкәсен кимерә», – дип зарлануын ишетә башладым.

Нишләргә? Кая, кемгә барырга? Аптыраган. Яңа ел, 1948 ел якынлаша, ә мин һаман эшсез.

Кая гына барып гозеремне әйтмим, паспортымны карыйлар да йөзләрен чыталар.

Нигъмәтулланы көтеп өметләнгән идем, ул да күренми. Бүтән иптәшләр дә бар иде, берсе-бер килеп хәлне белсәче.

Әтинең йөзенә карарга оялам. Әни болай да күтәрелеп карамый, кабаклары төшкән. Без җизниләрнең мунчасында торабыз.

Тик Әшрәф апа гына анда-санда чәйгә чакыра, искемоскыны рәтләп мине киендерә – чалбар, пиджак рәтләп бирде, иске тунны кыскартып, «москвичка» ясады, рәхмәт төшкере.

Ә мин һаман әле иртә торам да, кайвакытта чәй дә эчмичә, әтидән оялып, урамга чыгам. Буран. Суык. Кая барырга икән бүген?

Аяклар сау булса, берәр складка йөк ташырга-бушатырга керер идем. Бүкән башы белән үз-үземне дә әле көчкә йөртәм – атлаган саен, көрткә батып, чыгып китә алмыйча җәфаланам бит, коргыры. Кайвакытта бер ишектән икенче ишеккә кагылып, «Сезгә лаеклы эш юк!» җавабыннан җан өшегәч, өйгә ничек тә соңрак кайтыйм дип, Күкчәтауны урап алган, бала вакытта уйнап йөргән калкулыклар артына чыгам, берәр таш куышына ышыкланам, уйланам... Нигәдер Тукайның һаман бер шигырен

кабатлыйм:

Шат яратса да, җиһанга ят яраткан Раббысы...

Үксеп елыйм. Туйганчы елыйм. Монда, таш куышында, суык булса да, аулак – берәү дә күрми.

Кай көннәрдә зиратка барып, әнием кабере янына утырам да күңелемне бушатам.

Бар күңелләрдән җылы, йомшак синең кабрең ташы, –
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Шулай Яңа ел алдыннан беркөнне әти кичке чәйдән соң: «Әйдә, тәмәке тартып керик», – дип, мине ишегалдына алып чыкты. Анда Сафа җизниләрнең үрәчәле чанасы тора иде, шунда утырдык. Әти, янчыгын чыгарып, тәмәке төрә башлады. Сизәм, нидер әйтергә тели. Күрәсең, яшь хатыны алдында күңел серен ачасы килми.

Әти яшь вакытында бик таза булган, көрәшләрдә дә, кабак сугышларында да бирешмәгән. Үзе мәчет салышып йөрсә дә, мәчет ишеген елына ике тапкыр, Корбан гаете белән Ураза гаетендә генә ачкан. Шуңа, ахры, аны, кыерсытып, «Урыс Низами» дип атаганнар. Әмма Күкчәтауда аннан оста балтачы-столяр булмаган. Күкчәтаудагы иң матур, челтәр кәрнизле, өлге тәрәзә капкачлы өйләр – аның эше... Менә шул атаклы оста хәзер тәмәке кабыза. Тәрәзәдән төшкән җиделе лампа яктысында ул бигрәк тә мескен күренә, ябык, арка бөкресе чыккан. Заманында аның мыегы, нәкъ маршал Будённыйныкы сыман кабарып, колакларына уралып, йөзенә ниндидер бер мәһабәтлек сирпеп тора иде. Хәзер инде әнә ул мыек та сәлперәйгән, юкарып, сыланып тора.

– Улым! – диде әти, нигәдер авыр сулап. – Мин менә гомер буена балта чаптым. Әле менә үземә дигән өй дә юк. Син минем ялгыз улым. Сине укытып, балтадан котылырмын дигән идем – булмады, – ул сүнеп барган «кәҗә сыйрагы»н чытырдатып суырды. Очкыннар чәчрәде. – Булмады! – Тагын көрсенү. – Ходай шулай язгандыр инде. Син дә кулыңа балта алмасаң булмас. Мин бүген Сафа белән килештем. Без аңа яңа өй салабыз, ә ул безгә өеннән артып калган бүрәнәләрне, такталарны бирә. Шулай тырышып, үзебезгә бер куыш рәтләмәсәк булмас.

Әти сүнгән төпчеген кар өстенә ташлап таптады. Яшь кар шыгыр-шыгыр килде.

Якында гына эт өрде.

5

Калын карагай бүрәнәләр. Көч-хәл күтәрәбез, үзләре сөяк сыман каты, карандаш очлый торган үткер балта чапкан саен сикереп-сикереп китә, бигрәк тә туң вакытта. Менә шушы бүрәнәләрне әүвәле тап-таза итеп кырырга, чистартырга, аннан өч ягын такта кебек итеп тигезләп чабып чыгарга һәм шоп-шома итеп ышкыларга кирәк.

Шуннан соң гына бура бурый башлыйбыз. Почмакларны «француз йозагына» бикләп, әти үзе чаба, кисә. Ул кадәресенә әле минем кул ятмый. Мин күбрәк иртәдән кичкә хәтле бүрәнә чабам, уем алам, тырнак куяр өчен тишекләр бораулыйм.

Бура үскән саен, бүрәнәләрне югарырак күтәреп салырга туры килә, бер генә тапкыр түгел – берничә тапкыр.

– Шулай, шулай... – ди әти, күзләрен кысып бер алга, бер артка атлый, әле яңа гына куйган бүрәнәнең ятышын, уемның дөрес булуын карый. Аннан бүрәнәне тимер сызгыч белән сызып чыга. – Әйдә әле!

Әле генә көчкә-көчкә күтәреп куйган бүрәнәне тагын көч-хәл күтәреп җиргә салабыз. Әти бүрәнәнең сызылган җиреннән тагын балтасын ялатып, кәгазь калынлыгы юнып ала...

Агач аяк кирәк җирдә бөгелми, кирәкмәгән җирдә таеп китә, авыр күтәргәндә, җирне тишеп керә, суырып та ала алмыйсың.

Кичен чәй эчәр-эчмәс егылам, ә иртән... Иртән кузгала алмыйм, бөтен тәнем ватылган, аксак аягымның тезе каҗалып, чи яра булып кансылый. Торырга кирәк.

Ниһаять, яз башына өйне салып бетердек. Сафа җизниләр дүрт бүлмәле матур өйгә күчтеләр. Безгә – иске өй һәм артып калган бераз бүрәнә, такталар. Әтинең әле моңа хәтле дә җыеп килгән матчалыклары, ишек-тәрәзә яңаклары бар икән. Менә шуларның барысын караштырып, инде үзебезгә өй салырга җыенабыз.

– Өйгә тотынсак, ашарга юк, – диде беркөнне әти, такта ышкылаганда. – Мин торгта эшләүче Хафизга өй салырга килештем. Көндез анда эшләрбез, ә иртә-кичен үзебезнең өйне сипләрбез.

Менә шулай итә-итә, ниһаять, үзебезнеке дигән куыш та булды. Казах әйтмешли, үз башыбызга төтен чы-

гара башладык. Минем чулак аяк та, өстерәлә торгач, барыбер бүтәнчә булмас инде дип, ахрысы, сөялләнеп тупасланды, элеккечә үк атлаган саен кырылып чиләнми. Куллар да балтага ятышланды. Әти инде миңа бура почмакларын «француз йозак»ка бикләүне, ишек-тәрәзә яңакларын утыртуны да тапшыра башлады. Билгеле инде, үзе һәрвакыт күзәтеп-өйрәтеп тора.

Ә менә үги ана белән ара һаман да җылына алмый. Ул, җае килгән саен, «үтмәс товар» дип кадап ала, кырыкка җиткән сакаллы сабыйның ыштырларын юар хәлем юк дип, керләремне атып бәрә башлады. Ахырда, әти белән киңәшеп, өйләнергә булдым. Маһинур исемле бер тол хатынны алып кайттым.

Менә шунда исем китте. Тагын чәпчер инде дисәм, әни һич тә шау-шу күтәрмәде, хәтта коймак коеп, никах урынына бер мәҗлес ясап, күрше хатыннарын чәйгә дә чакырды.

Мин дә куандым. «Әллә кайчан өйләнәсем калган икән, әни май булды», – дип мактанып та алдым.

Маһинур беренче көннән үк өйдәге бар эшне: кер уу, идән юу, сыер саву, сыер куу, аш-су пешерүне үз кулына алды һәм җитез-пөхтә булуын күрсәтте.

Сүзгә саран әти дә беркөнне аштан соң:

– Ярады, киленнән уңдык, – диде.

Минем дә күңел күтәрелеп китте. Ниһаять, сукмак юлга алып бара. Эш тә җитәрлек. Сугыш вакытында кыйралган дөньяны халык төзәтергә ашыга. Шуның өчен бер эш бетәр-бетмәс икенчесенә димләп киләләр.

Менә шулай яхшы гына эшләп, торып ятканда, беркөнне сеңлем Разия яшь баласы белән иреннән аерылып кайтты. Башта мин аның кайтуына сөенгән дә идем. Билгеле инде, иреннән аерылуга түгел, үзебезнең гаиләгә кушылуына. Ничек кенә әйтмә, үги анадан туган булса да, бердәнбер кардәш, сөйләшсәң дә, киңәшсәң дә дигәндәй. Ул бит инде акылга утырган, унъеллыкны тәмамлап, өлкә судында секретарь булып эшли.

Әмма бу юравым белән ашыкканмын икән...

Гаҗәп, Разия бусагадан атлап керүгә, әтинең миңа булган карашы үзгәрде – суынды. Ул инде элеккедәй минем белән ачылып сөйләшми, киңәшми. Кашлары салынган, йөзе һәрвакыт чытык. Ә беркөнне эштән кайтканда турыдан-туры әйтә салды, йөрәккә хәнҗәр кадады:

– Син инде үзеңә лаеклы эш тап та үзеңә куыш эзлә. Өй тыгызланды, – диде ул ачулы тавыш белән, кырыс кына.

Коелып төштем. Мондый сүзне ишетермен дип уйламаган идем. Әти бит кечкенәдән мине ярата – аркасына асып йөри иде. Ә инде Казанга китеп кулга алынуымны ишеткәч, ул көне-төне елаган, хәтта асылына башлаган. Кайткач, күкрәгенә кысып, балалар төсле үкереп елады, «күрә алмам дигән идем... өнме, төшме...» дип кочаклап йоклады ул мине беренче төндә. Ә хәзер? Ни булды аңа? Нигә кырысланды?

Әтинең бу көтелмәгән сүзләрен мин, билгеле инде, Мәһинурга әйтмәдем, әмма үзем төнозын керфек какмадым, борчылып чыктым. Нишләргә? Кая барырга? Хәзер бит мин ялгыз башым гына түгел, икәү, бәлкем, өчәү дә...

Әтинең бу кырыс сүзләренең серен күршеләр чишеп бирделәр. Әни инде әллә кайчан аларга әйтеп йөри икән:

– Үзенә генә түгел, кешегә дә кәсафәте тия. Менә шул ристан аркасында кызым югарырак эшкә күчә алмый. «Агаң – халык дошманы» дип юлын кисәләр мескеннең, көн дә елый. Кайчан гына күздән югалыр, җан көеге.

Ә икенче көнне Разия әти алдында әйтә салды:

– Син миңа туган түгел, син – халык дошманы! Синең аркаңда мине эштә күтәрмиләр. Кит бездән!

Шул кичне мин өйдән чыгып киттем. Кая? Үзем дә белмим...

6

Диңгез кешеләрнең кайгысын юа, диләр. Ә мин «урман кешенең хәсрәтен тарата» дияр идем. Әнә бит! Берсеннән-берсе биек, төз, кара-кучкыл чуклы таҗ кигән егет-карагайлар юл буйлап басканнар да мине тын гына озата баралар. Алар арасында яшь каеннар, гөләп, тубылгы куаклары һәм чәчәкләр... Әчкелтем карагай сагызы белән чәчәкләр исе борынны кытыклый. Сулап туя алмыйсың!

Юлның сул ягында күгелҗемләнеп күл күренеп кала. Борылышта ул бөтен хозурлыгы белән күренә. Ярында – аркылы-торкылы гранит ташлар. Кайсы кит балыгын хәтерләтә, кайсы дөя, кайсы кызыл сыер булып тездән су эченә кереп баскан.

– Чыпылт, чыпылт...

Вак дулкыннар яр читендәге гранит ташларга акрын

гына сугылалар да кире чигенәләр. Аннан тагын пышылдашалар: «чыпылт-чыпылт». Әйтерсең лә серле әкият сөйлиләр.

Түгәрәк күлне калын кара карагайлар белән капланган тау урап алган. Таулар хәзер күксел томан эчендә. Тып-тын. Күл өстендә бер җыерчык юк. Таулар, урманнар, күл төбендә шәүләләнеп, әкияти бер күренештә балкыйлар. Гүя бу зәбәрҗәт кәсәдә әбелхәят суы...

Тирләгән идем, чишенеп коендым, тән рәхәтләнеп, җиңеләеп китте. Урман уртасыннан сузылган борма юлга кабат чыктым, инде сәфәрем ерак калмады. Урман эчендә урнашкан Боровой урман техникумында минем иске дус Харис директор икән. Кичә моны Сафа җизни әйтте.

– Безнең Харис кияү – техникумда директор. Нинди эш кирәк, хәзер табып бирә. Хәлимә дә шунда. Үзеңне күргәч куанырлар, – диде.

Төнлә, товар поездына утырып, Шучы каласына килдем. Аннан инде таныш юлдан җәяүләп техникумга.

Чү! Кинәт сискәнеп туктап калдым. Нәкъ минем аяк астыннан гына юлны бүлеп, тиен сикерде, мөгаен, юлым уңар болай булгач...

– Син инде мине гафу ит, – диде Хәлимә иртәнге чәй янында, ничектер әрнүле тавыш белән. Үзе калтыранып китте. – Үпкәләмә... – Сүзе бүленеп, кинәт туктап калды.

Кыз вакытында Хәлимәнең йөзе түгәрәк, бит алмалары кызарып пешеп тора иде. Без аны, үчекләп, «Алмапа» дип йөртә идек. Алай үчекләгәч, ул бигрәк тә кызара, матурая төшә иде. Хәзер Хәлимә нигәдер сулган гөл төсле кипкән, юкарган, яңак сөякләре калкып, бите озынаеп киткән.

– Нигә алай дисең? Нәрсәгә үпкәлим ди. Яхшы каршы алдыгыз, сыйладыгыз. Рәхмәт. Мин инде танымассыз да дип уйлаган идем. Юк, онытмагансыз. Без бит балачактан ук дуслар.

– Менә шул эшне боза да инде...

Аптырап калдым.

– Ничек? Мин бит сагынып килдем.

– Тсс! – Хәлимә миңа бармак янады да сикереп торды, йөгереп барып, ишекне тартыбрак япты, кире урынына килеп утырды, авыр көрсенде. – Уф Алла... Кара, авызыңнан андый сүз чыгарасы булма!

– Нинди сүз?

– Сагындым дип әйтә күрмә, дим.

– Нигә?

– Нигә булсын, болай да Харис төне буе миемне игәп чыкты. Ул синең иске ярың, сине эзләп килгән. Арагызда бер нәрсә бар, – ди.

– Их, Хәлимә, Хәлимә, миндә хәзер хатын-кыз кайгысымы? Үземнең йөкле хатынымны кая куярга белмим. Әле ялгыз башыма да урын юк. Кичә кич Хариска барысын да сөйләдем ләбаса. Мин монда хатын эзләп түгел, эш эзләп килдем. Харис мине яхшы белә бит. Булышыр дип өметләнгән идем.

– Их!.. – Хәлимә тагын көрсенде. – Барысын да төшенәм, әмма... – Күзеннән яшь бөртекләре тәгәрәде. – Кулымнан килсә, мин синең өчен әллә нәрсәләр эшләр идем. Хәзер, үзең күрәсең, ике бала. Харис шундый көнче. Бер адым атларга бирми. Менә бүген, син булгач, иртәнге чәйне дә эчмичә җенләнеп чыгып китте.

– Менә сиңа кирәк булса... Ә мин Харисны үз күреп, берәр эшкә урнаштырыр дип килгән идем.

– Тсс! – Хәлимә энә кадалгандай сикереп торды. – Әнә үзе кайтып килә. Син тизрәк кузгал инде...

Станциягә кире килдем. Вокзалда, гадәттәгечә, ыгызыгы, шау-шу, ашыгу, кабалану. Берәүләр Күкчәтау ягына китә. Берәүләр – Акмоллага. Ә миңа кая барырга? Кемгә таянырга? Нишләргә? Баш чатный. Җавап таба алмыйм.

Аптырагач, вокзалдан бераз читкәрәк китеп, чирәм өстенә пальтомны җәйдем дә яттым. Көн болытлы. Ярты аяк сикереп-сикереп китә. Һава бозылыр алдыннан шулай кылана ул, хәерсез.

Кесәдә нибары унбиш сум акча (яңача бер сум илле тиен). Аның белән нинди билет аласың. Бер тамак ялгарга да җитми бит ул. Нишләргә соң?

Менә сиңа ирек! Менә сиңа туган ата! Менә сиңа әни, сеңлең... Көткәннәр! Йоклап киткәнмен икән, паровоз кычкыртканга сискәнеп уяндым. Күкчәтау ягыннан ниндидер бер поезд килеп туктады – пассажир поезды. Берәүләр төшә. Берәүләр менә. Кочаклашалар. Үбешәләр. Көлешәләр... Бәхетле җаннар! Әнә каршыдагы вагон тәрәзәсендә өстәлгә тезеп куйган шешәләр. Сөт, кефир.

Авызыма сулар килеп китте...

– Ибраһим, бу синме?! Нишләп торасың?

Егылып китә яздым. Алдымда – Галәү Маннапов. Бергә уйнап үскән малай. Хәзер инде агай булган. Тулы гәүдәле. Өстендә яхшы костюм. Аптырап калдым, ни әйтергә дә белмим.

– Исәнме!.. Кая барасың?

– Алма-Атага киңәшмәгә... Төсең юк, әллә авырыйсыңмы?

– Әйе, башым чатный. Кара әле, Галәү, мин акчамны алдырдым, инде билетка да юк.

Ул арада кызыл фуражкалы дежурный вокзал ишеге алдында эленеп торган җиз кыңгырауны какты.

– Менә кесәдә бер утыз сум бар...

Галәү костюм кесәсеннән бер уч акча чыгарып миңа тоттырды да поездга таба йөгерде.

Кесәгә акча кергәч, хәтерем дә яктырды. Тукта, Акмоллада минем бер дус бар бит. «Антибес»та бергә яттык. Ул – бытовик, срогы да тулырга тиеш. «Әгәр Күкчәтауда рәтле эш табылмаса, үземә кил. Урнаштырам», – дигән иде.

Кассага йөгердем...

7

Төнлә аз гына яңгыр явып узган иде, ә монда, Акмолла урамнарында, аяк атлашсыз саз, бигрәк тә минем ише агач аякларга. Атлаган саен, тездән батып китәм, агач аякны ике куллап суырам. Көч-хәл белән аны тартып икенче адым ясыйммы, тагын батам. Кай җәһәннәмдә тора бу Алтай? Кайда соң аның Шанхай дигәне? Шәһәрнең көньягындагы иске бараклар, саман өйләр белән тыгызланган «нахалка»лар бистәсен Шанхай дип атыйлар икән. Әйтүенә караганда, Алтай шул Шанхайның урта бер җирендә, базарга каршы, чат башындагы өйдә торырга тиеш.

Ниһаять, җан тиргә төшеп, былчыракка батып, сораша-сораша, Алтай торган өйгә килеп җиттем. Эчем жу итеп китте, яртылаш җиргә сеңгән сыман йорт, түбәсе кыйшайган, ишек каерылган. Түшәме җимерелеп төшкән бер бүлмәне үтеп, икенчесенә кердем. Кап-караңгы, бернәрсә дә күренми. Бары тик колак тондыргыч чебен мыжлавы.

– Өйдә кеше бармы?!

Нәрсәдер кыштырдады, каршыдагы сәкедән мияулап песи сикереп төште, карлыккан тавыш гырылдады:

– И... коргыры, тагын кем җөри, җокы бирмәй?

– Чичәй, Алтай дигән адәм шушында торамы?

Әйтерсең камчы белән сукты:

– Китче, Алтай-балтаеңды белмәймен, ни дигән каңгырган җансың?!

– Мин, чичәй, Күкчәтаудан.

– И... әнә бакзал башында Торсын кассапчы торады. Алтай-балтаеңды шуннан сора!

Тагын саз ерып, кирегә, вокзал якка, итче Торсынны эзләп киттем.

Капка төбендә мине көрәк белән су ерып, кура тазалап йөргән бер карт каршылады, озын, чандыр, чөй сакал. Өстендә – иске чапан, башында – кыркылып беткән бүрек.

– Әссәламегаләйкем, ага!

Әллә саңгырау, сәламемне алмады, шикле бер караш белән озак карап торды, аннан кырыс кына эндәште:

– И... көннең кашы каралганда ни кылып җөрисең?

– Ата, сез Алтай дигән адәмне белмисезме?

Карт, сискәнеп, артка чигенде:

– Ул кем, җулдасыңмы?

Мин куанып киттем: төпченеп сораша, – мөгаен, монда тора.

– Ие... якын юлдашым иде.

– И... җаксы адәм икәнсең... жулдасың төрмәдә утыра. Талаган кичә төндә.

Бусында инде башыма чукмар белән суктылар, аңгыминңге килдем.

– И җаксы килдең, – чал ачулы тавыш белән мыгырдады, – милиция ул сукбайның жулдасларын эзләп җөри иде... Искәртү кирәк.

Бу чал сакаллы дорфа карт яныннан ничек ычкынганымны да белми, алдыма-артыма карамый йөгерәм. Кая? Үзем дә белмим. Ниндидер бер тыкрыкка килеп кысылдым. Әллә кайдан бер кәрлә эт чыгып, абалап өрә башлады.

Артта кемнәрнеңдер ашыгып килүләре, сөйләшүләре ишетелде. Бар көчемә йөгерә-атлый, тыкрыкның очына чыктым. Күмер өеме. Вагоннар. Ниндидер тупик. Мин

күмер өеме янына барып егылдым. Якыннан гына уф-уф килеп паровоз үтте.

Төн буенча яңгыр яуды.

Мин тупиктагы бер товар вагоны астында утырып чыктым. Арыган, алҗыган булуыма карамастан, күзләремә йокы кунмады. Бердән, вагон басарга йөргән карак дип тотып ябарлармы дип хәвефләнсәм, икенчедән, эч, быгыр-быгыр килеп, һич тынычлык бирми. Бичара, нишләсен, инде икенче тәүлек авызга бер валчык төшкән юк. Алтайга җиткәч тамагымны бер туйдырырмын дигән идем, ярый әле үземне эләктермәделәр. Теге дорфа картның карашы яман иде, вакытында ычкындым...

Алсу нур бөркеп, кояш күтәрелә башлады. Тирә-як яктырып, матураеп китте. Яңгырдан соң монда күмер өемнәре, төтен сеңгән иске, җимерек вагоннар арасында да иртәнге тәмле хуш ис!

Ә шулай да ашыйсы килә.

Вокзал артындагы базарда, озыннан-озынга сузылып киткән өстәлләрдә сөт, эремчек, катык, ара-тирә бөтен тәбикмәкләр дә күренә. Нинди тәмле ис!

Вокзалдагы пассажирлар килеп әле бер, әле икенче өстәлгә туктыйлар, сөт, катык белән тәбикмәк ашыйлар. Аларга карап авызыма су килә.

Читкәрәк китеп, өстемдәге күлмәгемне салдым, төрмәдән кайткач, әти үзе «Мә, улым, үзең киеп туздыр» дип бүләк иткән иде бит...

Вокзалдан читтә аулак бер җиргә – ташландык шпаллар өстенә килеп утырдым да ике тәбикмәкне бер шешә сөт белән ашадым да бетердем... Сизми дә калдым. Үз гомеремдә, хәтта Колымада да, мондый тәмле ризык ашаганым юк иде.

Корсак тулгач, тынычланып, шпал өстенә сузылып яттым.

Күзем эленеп киткән.

– Ту-ту-ту!

Сискәнеп уяндым.

Каршыдагы биек өелгән тимер юлдан поезд килә. Алтын билбаулы яшел вагоннар. Алда кызыл түшле мәһабәт тепловоз. Поезд якынлаша. Вагоннарның тәрәзәләре ачык. Аннан пассажирлар карый. Менә вагон-ресторан. Өстәлләрдә шешәләр. Әнә ике пассажир кулларындагы

стаканнарны чәкештерә. Ишеге ачык тамбурда хәрби киемдәге бер егет белән күк күлмәкле бер кыз басып тора. Алар, бер-берсенең кулларыннан тотышып, далага карап көлешә-көлешә, ни турындадыр сөйләшәләр. Поезд шпаллар өеменә якынлашты. Аларның күзләре миңа төште. Кыз, елмаеп, миңа кул болгады – «хушыгыз!». Аңа ияреп, теге хәрби егет тә кул болгады.

Кара, дөнья нинди матур! Кара, дөньяда әле нинди әйбәт кешеләр яши. Түзмәдем, сикереп торып, үзем дә теге кыз белән егеткә яулыгымны болгадым.

– Хушыгыз! Хушыгыз!

– Ту-ту-ту!

Поезд китте. Ерактагы чәчәкле Алма-Атага, карлы түбәләре күкләргә үрелгән Алатау ягына китте. Бүгенге беренче һәм соңгы сөенчем дә шул поезд белән офыкка китеп югалды. Мин тагын үземнең авыр, чәнечкеле уйларым белән калдым.

Кояш инде баеп бара икән. Әле яңа гына күтәрелеп килә иде түгелме? Тагын төн якынлаша. Кайда йокларга? Нигә йокларга? Аннан кая барырга – уңгамы, сулгамы? Юл юк! Өстемдәге соңгы күлмәкне сатып ашадым. Кесәдә бер тиен акча юк.

Нигә соң болай?

Әнә берәүләр нинди пөхтә, матур итеп киенәләр, нәфселәре ни тели, шуны ашыйлар, кая барасылары килсә, шунда китәләр. Ә мин? Мин – бүре! Мине куалар, эзәрлеклиләр. Кешеләр минем белән сөйләшергә курка. Мин алардан куркам. Нигә?! Мин дә бит алар төсле үк кеше. Миңа бит әле утыз сигез генә яшь. Мин бөтен яктан камилләшкән, дөньяда үз урынын тапкан ир булырга тиеш бит! Ә хәзергә – сәләмә киемнәргә төренгән агач аяклы гарип. Нигә мин гарип? Анадан шулай гарип булып тудыммы? Сугыш мәйданында илемне саклап гарипләндемме? Ни өчен мине тере гарип ясадылар һәм хәзер чирканып яннарыннан куалар?

Җир тетрәнеп китте. Сискәнеп, аягүрә бастым. Поезд килә. Кызыл вагоннар! Әйтерсең лә берәү җилкәмнән төртеп торгызды. Кызыл вагоннарга таба атладым. Тизрәк! Тизрәк! Ашыккан саен, агач аяк төртелә, сөртенә. Әнә инде вагоннар гөрелтесе. Якынлаша! Якынлаша! Тизрәк! Пальто чабуы аякка уралып, йөгерергә бирми.

Аны салып ыргытып, өемгә йөгердем. Җир дер-дер итә. Менә уф-уф итеп, пар бөркеп, тирә-якка төтен таратып килүче паровоз күренде. Тизрәк! Соңгы көчемне җыеп, тырмашып, өемгә үрмәлим. Төнге яңгырдан соң балчык йомшарган, шуа, бата. Нәрсәдер дерт-дерт итә. Әллә җир, әллә минем йөрәк. Җитә алсам гына ярар иде... Әмма... мин инде рельска ятам дигәндә генә, соңгы чуен тәгәрмәч дыңгырдап, тәгәрәп узды. Мин хәлсезләнеп, ачынып шпаллар өстенә аудым.

– Булмады...

8

Нәрсә соң ул фактура? Нәрсә соң ул нетто? Брутто? Тара? Унлы үлчәүдә ничек үлчиләр? Контора счётында ничек исәплиләр? Ходай белсен, төшкә дә кермәгән нәрсәләр. Ә шулай да мин менә Кызыл Яр авылындагы кооперация ашханәсендә буфетчы – товар алам, товар сатам, хисап бирәм.

Мондый җаваплы эшкә ничек алдылар дисезме? Билгеле инде, кызганып түгел, чыгырыннан чыккан мохтаҗлыктан гына. Бу ашханәдә буфетчы, гадәттә, бишалты айдан артык эшләми, судланып, төрмәгә китә икән. Шуның өчен авылда инде бу буфетка керүче табылмаган. Ә ашханә-буфет эшләргә тиеш. Мин, Ходайга тапшырып, тәвәккәл кылдым. Нишлисең, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума, диләр бит...

Вакыты җитмәсә, үләм дисәң дә үлә алмыйсың икән. Бу талпыну да барып чыкмагач, бераз суындым. Икенче көнне өстемдәге пальтомны саттым да Күкчәтауга кайтып киттем. Төн уртасында ишекне шакыдым. Йоклыйлар. Бераз икеләнеп, кыймыйча торгач, тагын тәвәккәлләдем.

– Кем анда җиде төн уртасында?

– Мин, әни.

– Ә, үтмәс товар, тагын кайттыңмы?!

Үги әни өйалды ишеген ачты, әмма үзе уртага басты – тәбәнәк, юан, ак күлмәк-ыштаннан. Ачулы. Кулында җиделе лампа.

– Маһинур өйдәме?

– Булыр өйдә, – әни нигәдер җилкәләрен сикертте, лампа пылт-пылт итеп китте, – уйнаштан бала тапты. Әле менә кичә Разиянең итәген урлап качып киткән.

– Кайда инде ул хәзер?

– Чёртым беләме? Милиция белән эзләп таба алмадык. Бик кирәк булса табарсың әле. Ярар, әтиеңә иртәгә эшкә барырга кирәк.

Ишек шап итеп ябылды. Лампа сүнде.

Дөньяда әле мәрхәмәтле кешеләр дә бар икән. Бер иптәшем паспортымны алыштырып бирде. Икенче иптәшем «ун ел хисапчы булып эшләде» дигән язуга кул куеп, мөһер сугарга җөрьәт итте. Нәкъ менә шул документларны юллап йөргәндә, Кызыл Яр авылындагы ашханәгә

буфетчы кирәк дигән хәбәрне ишеттем.

Сельпо председателе, урта буйлы, аз гына шадра битле казах, документларны күргәч көлеп җибәрде:

– Уйбай, нәкъ үзе, ун җыл хисапчы булып эшләгән, – дип, документларны бухгалтер кызга сузды.

Тәрҗемәи хәлне хезмәт кенәгәсенә ятыштырып язып бирдем. Председатель Мостафин миңа бер ташландык йортны күрсәтте.

– Шушында катын-балаңны алып кил. Алда күз күрер.

Шул көнне үк келәттән аракы, шәраб, конфет, шикәр кебек товар алып, фактурага кул куеп, буфетны ачып җибәрдем.

Икенче көне, Күкчәтауга барып, Мәһинур белән улым Шамилне алып килдем. Мәһинур өйнең эчен-тышын сылап, агарта, юа башлады.

Кызыл Ярдагы беренче көн үзе бик кызыклы башланып китте. Ул кичне безгә Хозыр килде. Чын, һич ялган юк, ышанмасагыз, менә үзегез хөкем йөртегез.

Кич белән, ашханә ябылгач, мин буфеттан бер бөтен икмәк, ярты кило шикәр, бер әчмуха чәй алып кайттым. Ә Мәһинур, башындагы дебет шәлен сатып, чиләк, чәйнек, табак-савыт, кашык һәм бер кило ит алган булган. Мин кайтканда өй ялт иткән, анда тәмле аш исе аңкый иде.

Ниһаять, беренче тапкыр Мәһинур белән үз куышыбызда, күршедәге казах карчыгы бүләк иткән тәбәнәк түгәрәк өстәлебездә үзебез пешергән ашны ашарга утырдык. Күптәннән инде итле аш ашаган юк иде, хуш исе борынны кытыклый.

– Йә, карчык, – дидем мин, көлеп, – өстәл байларча, музыкасы гына юк!

Сүземне очлый да алмадым, ишек ачылды.

– Әссәламегаләйкем!

Аптырап калдым. Ишек төбендә ап-ак сакаллы бер казах карты басып тора, култык астында ак яулыкка төрелгән зур гына төргәк.

– Вәгаләйкемәссәлам, ата, югары чыгыгыз, – дидем, әле һаман гаҗәпләнеп.

Карт кыстатып тормады, төенчеген тәрәзә төбенә куйды да, кулын юып, өстәл янына утырды.

Аштан соң чәй эчтек.

– Хәерле булсын, – дип, карт бер аять укып дога кылды

да, тагын миңа карап: – Инде бер сырылай тартсам, ничек булыр? – диде.

Шаккаттык! Бу ни дигән сүз?! Ап-ак сакаллы карт! Дога. Инде...

Ул арада карт, урыныннан җитез генә торып, тәрәзә төбендәге төенчекне чиште һәм тальян гармун чыгарды.

Бармаклары бик җитез генә әле өскә, әле аска йөгерә, гармун телләре ашыгып аваз чыгара. Менә Себер татарларының иң яраткан көйләре «Бишкүл». Карт яхшы ук яңгырау тавыш белән җырлап та җибәрде:

> Бишкүл көе, Бишкүл көе, Бишкүл көен яратам.
> Бишкүл көенә җырласам, хәсрәтемне таратам...

Бераздан гармунга Маһинур да кушылды.

9

Бу ашханә Кызыл Яр авылының кырыенда – Чагалы елгасы борылышында – «Г» хәрефе шәкелендә салынган иске бер өйдә урнашкан иде. Иске булганда да шундый иске – исең китәрлек. Ул әле тумышында ук беләк юанлыгы карагай сайгаклардан гына әштер-өштер әмәлләнгән булган, нигезсез, җиргә түшәп кенә. Тора-тора ул тузган, утырган, нәкъ тавык тәпиендәге өйгә әверелгән.

Әнә тәрәзә төпләре астында, почмакларында баш сыярлык тишекләр. Алар иске-москы капчык, чүбек-чабык белән генә томаланган. Түбәдәге шиферларның күбесен җил куптарып алып ташлаган.

Эчке яктан ашханәнең стеналары кайчандыр фанер белән тышланып, ак буяу белән буялган да булган. Әмма хәзер инде ул фанерлар җыерчыкланып күпергәннәр, калкып чыкканнар. Буявы кубып, саргаеп шадраланган. «Г» хәрефенең ыргагында – аш пешерү бүлмәсе һәм кечерәк кенә буфет кисәге. Ә инде «Г»ның «ботында» – зал. Анда – дүртәр кешегә исәпләнгән җиде-сигез өстәл һәм җимерек урындыклар. Уртада – калай белән тышланган зур мич.

Кухняда – ике кеше. Баш повар, ул ук – ашханә мөдире. Аның ярдәмчесе, ул ук – официантка. Мин – буфетчы. Менә бар штат.

Баш повар – тәбәнәк, ябык, мескен генә бер ир. Ә исеме, мыскыллап куйган сыман, – Великанов Иван Иванович. Авызында һәрвакыт какланып беткән трубка пыскып тора. Иван Иванович сөйләшергә яратмый, әмма

һәрвакыт ниндидер бер көй шыңшып йөри.

Ярдәмчесе Вера Петровна шефның нәкъ киресе – мәһабәт гәүдәле, балтырлар, беләкләр сылык-сылык итеп торалар. Әгәр ул ачуланып бер кизәнсә, Великановның көле күккә очачак. Гөнаһларына керер хәлем юк – тавышланганнарын ишеткәнем булмады, һәр икесе үз эшендә: Вера Петровна бертуктаусыз сөйли, авылның иң соңгы яңалыкларын фаш итә, ә Иван Иванович, трубкасын пыскытып, бетмәс-төкәнмәс көен шыңшый.

Алар икесе дә мине яхшы каршы алды. Иван Иванович, зур гына җамаякны төбәсеннән тутырып, уртасына көнбагыш мае салып, тары боткасы бирде. Вера Петровна (ул вакытлыча буфетчы хезмәтен дә башкара икән) бер түтәрәм ипи дә китереп куйды һәм ашханәгә кемнәр килүен, нәрсә ашауларын сөйләп китте.

– Монда күбрәк авылныкылар килә бит, кайсы банктан акча ала, кайсы ревкомга, кайсы исполкомга... кайсы комендатурага... немецлар, поляклар, төрмәдән кайтканнар...

Эчем жу итеп китте. Әйтерсең лә минем төрмәдән кайтканны, ялган язулар белән йөргәнне белеп, сынап әйтә... Әмма Вера Петровна миңа игътибар да итми. Инде дөньядагы бүтән хәлләрне тезә башлады.

– Карагыз, сез бурычка бирмәгез. Бурычка эчеп теңкәгә тияләр. Әле миңа гына да дүрт-биш кеше бурычлы. Ала алсам ярар иде...

Дөресен әйткәндә, мин такылдавык хатынның бу сүзләренә әллә ни игътибар итмәгән идем. Әмма озакламый бу сүзләрнең алтын булуына шигем калмады. Инде кар төшкән иде. Буфетта җил уйнап тора. Аракы тезелгән киштәләрдә ап-ак кар чачаклары асылынып тора. Ашханәдә кунаклар юк. Мин өстәл-буфет артында утырдым-утырдым да, тәмам дерелди башлагач, кухняга Иван Иваныч янына тәмәке тартырга кердем – плитә янында җылырак. Вера Петровна утын ярырга чыгып киткән иде. Папиросымны тартып бетерергә дә өлгермәдем:

– Начальник килә! – дип, атылып-бәрелеп Вера Петровна керде. Кочагындагы ярты олау утынын плитә янына ташлады, мич селкенеп китте. Үзе һаман такылдый: – Менә бәла... Ә син, буфетчы, нәрсә шаккаттың? Чык тизрәк. Уф Алла, алъяпкычым кайда?! – Ул әле бер, әле

икенче почмакка йөгереп мәш килде. – Кайда гына куйдым?

– Вера Петровна, – диде Великанов артык ашыкмыйча, трубкасын плитә кырыена суга-суга, – алъяпкычың билеңдә ич.

Мин, чатанлап, буфетыма чыктым.

– Өч кешегә заказ.

Вера Петровна, залга чыгып, килүчеләрдән заказ ала. Мин талон язам. Повар шул талоннар белән үзенең ашсуын җибәрә. Кичен повар белән талоннарны барлап, санап, кухня ризыгының ничә сумлык сатылуын исәплибез.

Бер литр аракы, өч гуляш.

– Өч кешегә бер литрмы?

– Тиз дим. Ул көттергәнне яратмый.

Ике шешә аракы, стаканнар бирдем. Тагын яздым. Ул арада тагын берничә кеше килеп, тәмәке, шырпы сорады, талон яздырды. Мин бу котны алган башлыкның кем булуын да сораша алмый калдым. Бары заказ кәгазенә «Начальник» дип сырлап, счётта сумманы исәпләп төшерә башладым.

– Тагын бер бөтен, ике гуляш, – дип, Вера Петровна исәбемне ялгыштырды.

Аракыны бирдем. Гуляшка талон яздым. Сумманы исәпләп, заказга өстәдем.

Залда халык күбәйгәннән-күбәя бара, өстәлне өстәлгә кушалар, кухняга кереп, кыйшык аяклы эскәмияне дә алып чыктылар. Кунакларның барысы да диярлек кыпкызыллар, чиртсәң, битләреннән кан сирпер. Әллә суыктан, әллә аракыдан.

Озакламый залда күкле-яшелле тавыш белән җыр да күтәрелде, русча, казахча. Заказны язып биреп, исәпләп өлгерә алмыйм. Иван Ивановичның инде өч көн сатылмый туңып яткан гуляшлары да, җылытылып, «худ»ка китте. Туп-тулы бер ящик аракы бар иде, бушады. Ахырда шампан шәрабына күчтеләр.

– Минем инде аякларым йөрми, – дип, Вера Петровна еларга җитешеп зарлана башлады.

Бары тик төнге сәгать өчне сугып киткәч кенә көч-хәл белән өйләребезгә таралдык. Иртәгесен тагын буфетка. Буран, көрт. Култык таяклары көрткә бата да, мин мәтәлеп барып төшәм. Торам, тагын егылам. Ә буран котырганнан-

котыра бара. Көчкә генә ашханәгә килеп җитеп егылдым. Буфет шкафын ачып, үлчәүне өстәлгә куеп, шешәләрне тезәргә өлгермәдем, бер хатын килеп керде. Лампочка кызарып кына тора, караңгы. Өстәлгә килеп җитәр-җитмәс, сорап түгел, боерып:

– Бер литр аракы, – диде теге хатын. – Мин фәлән начальникның әйеле (хатыны).

Куанып киттем. Менә әйбәт булды дип, тиз генә кесәмнән кичәге түләнми калган заказ кәгазен чыгардым.

– Кичә ирегез бездә утырган иде... Заказны түләмәде... Тугыз йөз җитмеш сигез сум егерме өч тиен.

– Җала җапмагыз, – дип, хатын кырт кисте. – Менә бер литрга. – Ул ачу белән миңа илле сумлыкны ыргытты: – Минем җулдасым акча түләмәй заказ бирмәйде.

Аптырап ни әйтергә белми торганда, хатын ике шешәне сумкасына салды да ишеккә атлады һәм ачулы рәвештә:

– Җарайды, мин җулдасыма сезнең җалагызны айтаен, – дип ысылдады.

Ишек шап итеп ябылды.

Мин сылк итеп урындыгыма ишелдем. Менә сиңа кирәк булса! Нинди яла?

Төш авышкач, түрә абзый хәрби киемдәге бер кеше белән залга үтте. Бераздан Вера Петровна йөгереп килде:

– Начальник сине чакыра.

Мөгаен, исәпләшергәдер дип, заказ кәгазен кесәмә салып, счётны култык таякка кыстырып йөгердем.

– Сәламәтсезме?

– Рәхмәт. Яхшы.

Мөлаем гына кеше икән бу начальник. Йөзе матур. Елмаеп кына сөйләшә.

– Син җаңа буфетчымы?

– Әйе.

– Җаксы, җаксы, – ул тагын елмайды. Папирос кабызды, суырды. Иптәше – озын, таза гәүдәле кеше – нигәдер торып чыгып китте. Начальник авызыннан зәңгәр боҗралар чыгарып өрде дә миңа карады. – Бурычка товар бирергә ярыймы?

Аптырап калдым. Счётым кулымнан төшеп китә язды.

– Юк, ярамый, иптәш начальник.

– Алай булгач, нигә минем әйелемә «бурычыгыз бар» дидең?

– Мин бит... заказ буенча.

– Яле, яле... монда бир әле ул кәгазеңне.

Уф Алла. Ичмасам, хәтерләр... Мин халат кесәсеннән заказ кәгазен алып начальникка суздым.

– Рәхим итегез. Тикшерегез.

Кашлар җыерылды. Тавыш кинәт сикереп, ачулы тонга күчте:

– Бир, күп сөйләмә! – Ул минем тугыз йөз җитмеш сигез сумлык заказ кәгаземне кулымнан тартып алды да, ертып-ертып, идәнгә ташлады, үзе, шунда ук сикереп торып, ишеккә таба атлады. – Хөкүмәт малын тагын бурычка таратасы булсаң, мин сиңа урын табармын!

Култык таякларым төшеп китте. Мин мичкә сөялеп калдым.

Ишек шап итеп ябылды.

10

Буфеттан катып-туңып соң гына кайтып, йокларга гына яткан идем, кемдер тәрәзәне шакый башлады. Җимерер керәмени, бөтен өй селкенә. Бу дөбердәүгә бишектә йоклап яткан улым куркып уянды да елый башлады. Үзем дә сискәнеп кычкырып җибәрдем.

– Кем анда? Ни кирәк?

– Милиция! Ач!

Миңгерәүләнеп киттем – «килделәр!»

Мәһинур бишектән баланы ала башлаган иде, бу тавышка ул баланы төшереп җибәрде. Мин чалбар урынына гимнастёрканың җиңен кия башлаганмын. Аны атып бәрдем. Чалбар юк, таба алмыйм гына үзен.

– Әй, үлеп калдыңмы, ач җылдам?!

Тагын да катырак суга башладылар, әллә тәрәзәдән керәләр инде!

Бала акыра. Мәһинур елый. Мин, нәрсә эшләргә белми, чалбарсыз урын өстендә әйләнәм, үзем дер-дер киләм, әллә туңам, әллә куркудан.

Мөгаен, ялган язулар белән йөрүемне сизгәннәр. Их, нигә шул түрә белән бәйләндем.

Мин әле күптән түгел генә Казанга, Кави агага хат язып, «Акколак һәм Сакколак» исемле кечкенә поэмамны җибәреп, берәр редакциягә тәкъдим итүен үтенгән идем. Җавап тиз килде, әмма вафасыз. «Поэмаң балалар теле белән матур язылган, сюжеты да мавыктыргыч. Әмма

бер редакциягә дә тәкъдим итә алмыйм. Сәбәбен үзең беләсең. Әле күптән түгел генә, ун ел срогын тутырып, тәнкыйтьче-журналист Гомәр Гали кайткан иде. Өч-дүрт ай эш таба алмый аптырап йөрде. Кичә тагын кулга алганнар үзен. Шулай булгач, Казанга килергә җилкенмә!» дигән иде Кави ага хатында. Менә чират миңа да җитте.

– Ач, дим, җылдам!

– Үлеп калдыңмы, мур кыргыры...

Мәһинур, абына-сөртенә барып, ишекне ачты, өйгә ажгырып буран керде. Аның эченнән өсләрен ап-ак кар сарган ике милиционер күренде.

– Җыен, милиция башлыгы чакырды!

Күз ачкысыз буран. Алда, кар ерып, ике милиционер бара. Алар артыннан, култык таякларым белән көрткә бата-сөртенә, мин тырмашам. Артта бала күтәргән Мәһинур мине озата бара. Милиция конторасы авылның аргы башында. Үч иткәндәй, нәкъ шул яктан буран бурый.

Мин инде шабыр тиргә баттым, ә алда әллә никадәр барасы. Без әле ашханәгә генә якынлашабыз. Ул буран эченнән карачкы булып күренеп-күренеп кенә кала. Мөгаен, инде аны да, авылны да соңгы күрүем.

– Әй, буфетчы! – диде алда барган милиционерларның берсе, яшь казах егете, туктап: – Башлыкка Күкчәтаудан кунаклар килде, ике литр аракы сорады.

Әйтерсең лә өстемнән мең пот йөк төште, бушап, җиңеләеп киттем:

– Мә, Мәһинур, ачкычларны, күпме сорасалар, шулхәтле аракы бир үзләренә.

Мәһинур ачкычны алды да куана-куана ашханәгә йөгерде.

Мин буран эчендә күмелеп калдым.

– Уф Алла, өнемме, төшемме?

Чынлап еласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, диләр бит, мин дә, этләшә торгач, үлчәргә дә, санарга да, счёт тартырга да өйрәнә башладым. Әмма ничек итеп бурычка бирмәскә – акыл җитми. Кунакларым берсеннән-берсе өлкәнрәк түрә бит. Аларны кире кагып кара, бигрәк тә үзең «юеш»кә утыргач. Ә менә бер ай сәүдәдән соң алыш-бирешне исәпләп карасам: ике мең җиде йөз сиксән алты сум унҗиде тиен акча җитми! Нишләргә?..

Күкчәтауга барып, туган-тумача, дус-иштән бурычка

акча сорап карадык. Юк! Барысы да йөз дүндерде. Менә шунда гына миннән алда буфетта эшләгән бәндәләрнең ни өчен судланып китүләрен төшендем.

Әмма төшенүдән ни файда? Акча юк. Тагын төрмә дигән сүз.

– Булмаса, ашханәне ремонтларга алыныйк. Агач эшен син эшләрсең, буявын, агартуын мин, – диде Мәһинур.

Мин, сельпо председателе Мостафин белән сөйләшеп, өч мең сумга килешү төзедем дә Мәһинур белән ашханәне төзәтергә керештек. Эштән соң, кичләрен, ял-йокы исәбенә. Улыбызны аракы әрҗәсе өстенә яткызып торып. Ремонтны бетергәч, килешү буенча акчаны алып, «тишек»не ямадык. Уф Алла! Ләкин озаккамы?!

11

Кызыл Яр авылы янында кечкенә генә бер елга ага. Казахлар аны Чагала үзәне диләр. Чагала «Акчарлак» дигәнне аңлата. Авылга җитәр алдыннан елга ермакланып-тармакланып китә, ерактан, үрдән караганда, ул очарга әзерләнеп, канатларын җәеп җибәргән акчарлакка охшый. Бәлкем, аның исемен дә әнә шул күренеш тудыргандыр.

Эштән бушаган араларда, бигрәк тә кичкырын, мин, шушы елга буена килеп, уйланып утырырга яратам. Чагала үзе тар, үзе сай, ярлары да текә түгел, сөзәк! Анда вак-төяк куаклыклар. Ә мин утыра торган җирдә шомырт агачлары. Яз башында алар шау чәчәктә була. Әчкелтем хуш ис борынны кытыклый.

Әйткәнемчә, мин утыра торган җирдә дә үзән сай – үтәли күренә. Кызгылт, сары, саргылт, ак ком бөртекләре ногыт борчагы кебек чекерәеп яталар. Ара-тирә, аларны күләгәләп, вак чабаклар ялт-йолт үтә.

Мин утырган җирдән аз гына алда, су эчендә, зур гына бер чуерташ ята. Чагала агып барышлый шул ташка сугылып, чупылдап ала:

– Чупылт-чупылт, чупылт-чупылт...

Яратам мин шушы тонык пышылдаган тавышны тыңларга. Агып барышлый, теге таш янында бик аз гына тукталып, елга аңа үзенең ниндидер бик яшерен серен пышылдап кына әйтеп уза сыман:

– Чупылт-чупылт... чупылт-чупылт.

Нинди сер, нинди әкият сөйли икән бу көмеш канатлы

акчарлак? Әнә ишетәсезме, тагын:

– Чупылт-чупылт...

Чагала менә шулай, артык тавышланмыйча гына, сагышлы бер җыр көйләп оча-оча да, кылганлы далага чыккач, кинәт юк була. Җиргә сеңеп югала. Акчарлакның көмеш канатлары салына, җыры әйтелеп бетмәгән сер булып өзелә.

Гомер! Кеше гомере дә елга кебек ага бит. Берәүләрнең гомере Агыйдел төсле тулып ташый. Ул иксез-чиксез дәрьяларга барып чыга – зөбәрҗәт дулкыннарын чайкалдыра. Ә кайбер гомерләр менә шушы Чагала үзәне төсле акрын гына, чупылт-чупылт итеп кенә ага да иркен киңлеккә чыктым дигәндә генә эзсез югала.

Минем гомерем дә нәкъ менә шушы Чагала үзәне төсле саркып, тәшвишләнеп кенә ага. Кайчандыр мин, тау елгасы сыман, таштан ташка сикереп, тавышланып, чәчрәп ага идем бит. Нигә соң әле болай тып-тын, шыпырт булып калдым?

Күңелемдә әле һаман да яңа җырлар яңгырый. Мин һаман әле яңа шигырьләр, хикәяләр, романнар язу уты белән ялкынланам.

«Син инде яңа әсәрләр язып азапланма. Бер редакция дә аларны кабул итмәс» дигән Кави ага миңа җибәргән соңгы хатында.

– Чупылт-чупылт...

Сискәнеп, башымны күтәрәм. Уйлар очына җитә алмыйча өзелә. Мин, култык таякларымны алып, көчкә-көчкә генә аягүрә басам.

Акчарлак канатларында шәфәкъ яна. Әйтерсең лә канатларын җәйгән кызыл кош кичке күккә күтәрелергә җыена.

– Чупылт-чупылт...

Сагышлы җыр, зарлы пышылдау...

Ерак офыкта соңгы учаклар сүнә. Ел артыннан ел уза. Башлыклар алмашына. Үзгәрәләр. Бары тик аларның гадәтләре генә үзгәрми. Элеккеләре дә, соңгылары да, бер калыпка коелгандай, бурычка – бушка эчәргә, ашарга ярата. Ә мин, ике ревизия арасында ут йотып, янә көям, менә янам дип, кызган табага баскандай сикергәлим. Ашау-эчүне кысам. Мәһинур анда-монда кәнсәләргә йөреп идән юа, мич яга. Аның хезмәт хакын да

бурычлар түләү исәбенә җыеп куям.

Менә 1953 ел. Март. Радио. Сталин вафат...

Берәүләр елады. Берәүләр ләгънәт укыды. Берәүләр өметләнде. Әмма минем тормышка бернинди дә үзгәреш килмәде. Буфет. Башлыклар. Әҗәткә сораулар һәм тетрәнеп ревизия көтү.

Ниһаять, партиянең XX съезды. Ул шәхес культы җинаятьләрен каплап торган кара, шомлы пәрдәне күтәрде. Дөнья чирканып тетрәнде.

Күңел иләс-миләс. «Халык дошманы» дигән тамгадан, хурлыктан, җәбердән котылу өметләрем тагын кабынды...

Әмма минем гомер, Акчарлак үзәне төсле, һаман бер үзгәрешсез чупылт-чупылт килә...

Көтеп-көтеп аптырагач, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Климент Ефремович Ворошилов исеменә үземнең 1937 елда нахак гаепләнүем турында язып, бу кара таптан арындыруны үтендем.

Нинди генә җавап килер икән?

Ярсып, икеләнеп, өметләнеп, хәвефләнеп көтәм.

Көн дә көтәм.

Айлар үтте. Мәскәүдән җавап хаты әле һаман юк. Нинди озын, авыр, газаплы бу көннәр. Нинди генә җавап килер икән?

Этләнә торгач, кырык гариза биреп, авырыйм дип, буфеттан котылдым. Котылуын котылдым, әмма ике меңгә якын акчамны, чакырылмаган «кунак»ларымның түләнмәгән бурычларын түләп.

Кызыл Яр (Петропавловск) каласында алты айлык бухгалтерлар курсы ачыла икән, шунда укырга юнәлтмә алдым.

Көз җитте. Кар аралаш суык яңгырлар башланды. Мин инде, курсларны тәмамлап, райпотребсоюзда бухгалтер булып эшли башлаган идем. Беркөнне шулай лычма су булып, өшеп өйгә кайтып керүем булды:

– Менә сиңа хат, – дип, Маһинур конверт тоттырды.

Суыктан өйгә керүгә күзлек парланган, бернәрсә дә күрмим. Конвертны алам дигәндә, култык таякларым төшеп китте. Ярый әле сәкегә аудым.

Күзлекне алай-болай сөртеп, күшеккән-тырпайган бармаклар белән көч-хәл конвертны ачтым.

«Күкчәтау өлкә НКВД идарәсе сезгә фәлән көнне, фәлән сәгатьтә фәлән кабинетка килергә куша».

Утырып тәмәке тарттым. Теге кәгазьне тагын иҗекләп укып чыктым.

Йа Ходa, ни өчен чакыралар мине тагын ул шомлы йортка? Хәерлегәме? Хәерсезгәме?

– Дөп-дөп! Дөп-дөп! Нинди тавыш?

Чү, бу минем йөрәгем шулай ярсып, сызланып суга, тыпырчына түгелме? Йа Раббым, нишлим соң?!

САГЫНУ

Альбомымда күп вакыт узудан инде тоныклана башлаган бер фоторәсем бар. Ул минем өчен аеруча кадерле. Эчем пошканда, күңелсезләнгәндә альбомны алам, озак карыйм. Уйланам. Сагынам, өзелеп сагынам мин бу рәсемдәге җан дусларны.

Без анда өчәү. Өчәү... Хәзер мин берүзем генә. Япаялгыз. Икебез инде дөнья куйды – «дарелфанидан дарелбакыйга рәхләт әйләде». Тирән хәсрәт. Ул инде минем күңелдә мәңге бетәшмәс, кансырап торган чи җәрәхәт.

1956 ел. Көз. Казан. Кар аралаш яңгыр ява. Шыксыз көннәр. Әмма нәкъ менә шушы шыксыз, күңелсез вакыт безнең язмышта иң шатлыклы, якты көннәрнең берсе булды.

Без – өчәү. Ләкин без әле бер-беребезне күрмәгән, күрешмәгән. Алай гына да түгел, без әле бер-беребезнең ни хәлдә икәнен дә белмибез – исәнме? Әллә озын юлның ахырына хәтле барып җитә алмыйча берәр борылышта егылып калганмы? Белми идек әле ул вакытта, белми идек.

Без – өчәү.

Беребез – Котластан, беребез – Норильскидан, беребез – Колымадан.

Унтугыз елдан соң! Бер гомер бит үзе без аерылышканга! Кем уйлаган мондый бәхетле очрашу булыр дип.

Бауман урамы. Матбугат йорты. Якшәмбе саен өмәләр оештырып, унар-унбишәр кирпечне аркалап, һаман югарыга-югарыга ташып салган бина бит бу! Култык таякларыма абына-абына, ашыгып, баскычлардан күтәреләм, икенче катка. Язучылар союзы идарәсенә керәп

күрешер-күрешмәс, миңа чакыру билеты бирделәр. «Хөрмәтле иптәш, Сезне Татар опера һәм балет театры бинасы ачылу тантанасына чакырабыз». Имәнеп киттем.

Бусы да һич уйланмаган сөенечле очрак лабаса. Мин бит әле ул бинаның нигезен әзерләү өмәсенә катнашкан идем. Унтугыз ел элек...

Яз. Пединститут паркындагы мәһабәт юкәләр балга манылган нәни яфракларын әле яңа гына җәеп җибәргәннәр, һавада сулап туя алмаслык хуш ис. Бал исе. Без, әнә шул зифа юкә агачлары тирәсендәге ямь-яшел хәтфә түшәккә сузылып ятып, соңгы имтиханнарга әзерләнәбез. Шулай беркөн дөньяны онытып, китап-конспектларга мөкиббән китеп гыйлем эстәгәндә, институт комсомол комитеты секретаре Бәдигов йөгерә-атлый, мышнап килеп чыкты.

– Кай җәһәннәмгә таралдыгыз, үзегезне эзли-эзли арып беттем, – ди.

– Ни яна?

– Янмый. – Бәдигов юкә агачына терәлде, чыннан да арыган икән. – Райкомолдан шалтыраттылар, иртәгә сезнең факультет «бакыр бабай» бакчасына өмәгә барырга тиеш.

– Иртәгә? Иртәгә якшәмбе, аннан, үзең беләсең, зачётлар.

– Барысын да беләм. Бу бик ашыгыч эш икән. «Бакыр бабай» бакчасында зур бер бина салачаклар, ди. Менә шуның өчен андагы агачларны, казып алып, каядыр күчерергә, ди.

Аптырап калдым. Ничек инде Казанның нәкъ үзәгендәге гөлбакчаны туздырырга? Алай да икенче көнне, бөтен факультет белән көрәкләр, ломнар күтәреп, җырлый-җырлый, «бакыр бабай» бакчасына киттек.

Унтугыз елдан соң хәйраннар калдым – әкият. Кайчандыр бакыр бабай утырган бакча урынында мәһабәт, искиткеч гүзәл сарай. Бинаны әйләнәм – сокланып туялмыйм. Бинаның ике ягындагы куышта ике бөек шагыйрь басып тора. Аларга тәгъзим белән баш иеп сәлам бирдем.

Нәкышләп бизәлгән биек түшәмнәрдә бәллүр чәчәкләр булып кандилләр балкый. Аларның һәрберсендә күптин-күп шәмнәр яна – мәрмәр баскычларга, залларга, фойеларга нур түгелә. Бәйрәмчә матур, пөхтә

киенгән хатын-кызлар, ирләр, көлешә-сөйләшә, өске катка ашыгалар. Мин дә шул агымда. Әмма мин үземнең бу күркәм кавемгә ят булуымны күреп-тоеп гарьләнәм һәм каушыйм. Гарьләнәм, чөнки өстемдә таушалган иске кием-салым. Каушыйм, чөнки култык таякларым мәрмәр басмаларда шуып-шуып китә. Гүя алар: «Кара әле, хуҗа, без монда ялгыш килеп чыктык, ахры, бу без йөри торган төш түгел ич!» – дип, мине шелтәли һәм атлаган саен чайкалып кире чигенә.

Ниһаять, тирләп-пешеп, мең газап белән фойеның бихисап биек, ачык ишеге янына килеп терәлдем.

Зур, якты, матур зал. Сап-сары балавыз белән ялтыратылган паркет идән. Стена буйларында кызыл бәрхет белән тышланган аркасыз йомшак озынча урындыклар. Уртада шатлык белән балкыган халык чайкала – биек үкчәле нәфис туфлиләр, ялт-солты итекләр, ботиклар паркетка тияр-тимәс кенә шуа.

Мин, ишек кырыендагы йомшак урындыкларның берсенә елышып, кыяр-кыймас кына чүктем – култык таякларын аска яшердем. Үзем, сокланып, фойеда арлы-бирле йөргән шат, пөхтә кешеләргә карыйм. Казанлылар. Мин бит ун ел алар белән бергә кайнадым. Ә хәзер аларның берсен дә танымыйм, алар – мине... Кем танысын ди. Казаннан киткәнемә инде егерменче ел. Ә шулай да, кем белә, бәлки, бу күңелле төркемдә мине танучылар да бардыр. Ләкин алар, мине шәйләмәгән төсле, мөгаен, читкәрәк авышалардыр. «Халык дошманы» ярлыгы тагылган арестант белән кемнең күрешәсе килсен ди, бигрәк тә мондый тантанада, халык алдында. Гәрчә нәкъ менә кичә Казанда Союз Верховный судының минем эшне киредән карап, гаепсез дип табып, реабилитацияләнүем турында рәсми карарын алган булсам да...

Ул карарда «Салахов Ибраһим Низамовичны гаепләү буенча эш СССР Верховный суды Хәрби Коллегиясе тарафыннан 1956 елның 25 апрелендә яңадан каралды.

Хәрби Коллегиянең 1938 елның 12 маенда Салаховка чыгарылган хөкем карары кире кагыла һәм, гаебе булмау сәбәпле, эш туктатыла» дип язылган. СССР Верховный суды Хәрби Коллегиясенең суд составында председательлек итүче юстиция полковнигы Лихачёв кул куйган иде. Нәкъ менә шул кәгазь мине бу гүзәл сарайны ачылу тан-

танасына китерде бит. Әмма хәзер менә Штраус вальсы дулкыннарында рәхәт йөзүче шат казанлыларның миндә ни эше бар? Киресенчә, мин монда ак козгын ич. Сискәнеп киттем – кемдер артымнан килеп кочты.

– Таны, кем бу?

Каушап калдым, бик таныш тавыш шикелле. Үз гомеремдә ишеткән барлык дус-иш, таныш-белешләрнең тавыш төсмерләре колагымнан зыңлап узды. Ләкин бу йомшак, аз гына моңсу тавышның кемнеке булуын һич тәгаенли алмыйм.

– Йә инде, тизрәк әйт!

– Сөббух, – дип кычкырып җибәрдем. – Сөббух Рәфыйков!

Без кочаклаштык. Күзләргә кайнар яшь тыгылды.

Ниһаять, бу шатлыклы күрешүнең беренче давыллы хисләре акрынлап чигенде – без бер-беребезгә карап тын калдык.

Галимҗан Ибраһимовны тәбрикләү хатына кул куйганы өчен кулга алынып Норильскига сөрелгәндә, ул әле япь-яшь, коңгырт кара чәчле, зур соргылт күзле, аксыл йөзле, һаман елмаеп тора торган дәртле егет иде. Хәзер инде – ир уртасы. Киң маңгаенда – җыерчыклар, күзләрдә – тирән моң, чәчләр сирәгәя төшкән. Әмма аның йөзендә чытыклык, ачу яки ачыну ярсулыгы сизелми, иреннәрендә һаман әле самими елмаю.

– Ибраһим! – Кинәт аның иреннәре тетрәнеп китте, йөзенә күләгә төште. Күрәсең, минем артык текәлеп каравым аны борчыды, ул бу караштан котылырга ашыкты. Кулын иңемә салды һәм, кычкырып, аз гына шаярткан сыман, сүзгә чакырды. – Йә, Колыма аюы, сөйлә, нинди приискаларда булдың, күпме алтын казып алып кайттың?

– Җитәрлек. – Яртылаш бөкләнеп, бил каешыма эленгән чалбар балагыма ишарә ясадым. – Тик бер аякны...

Сүземне очлый алмадым, кемдер бүлдерде.

– Менә алар кайда посканнар, ә мин эзли-эзли арып беттем.

Күтәрелеп карадык та сөенечтән сикерешеп тордык. Мин бер аягым юклыгын да онытып җибәргәнмен, күтәрелүгә авып киттем. Хәсән ага Туфан мине кочып алды. Ул арада Сөббух та озын куллары белән безне урады – өчебез бер кочакка сыйдык, бер-беребезнең йөрәк тибе-

шен тыңлап, сүзсез калдык.

Җиз кыңгыраулар чыңлады.

Халык тамаша залына агыла башлады. Без дә аңыбызга килдек. Туфан ага, иелеп, урындык астыннан култык таякларымны алып бирде, бер үземә, бер култык таякларыма карады да нигәдер башын чайкады һәм рәнҗүле елмайды.

– Мөкяфәт...

ӨРӘҢГЕЛӘР ЯФРАК КОЙГАНДА

1

Мәскәүдән ерак түгел, электричка белән ярты сәгатьлек юлда, урман эчендә язучыларның Иҗат йорты урнашкан, һәр ел саен диярлек мин монда ял итәргә, язарга киләм. Языла. Илһамлы, шифалы почмак бу.

Язып, укып арысаң, әйдә, ял итәргә рәхим ит, каршыңда – кара урманга тиң парк. Мин аллеялар буенча йөреп, түтәлләр каршындагы урындыкларга утырып ял итәм.

Җил исеп китте, агачлар чайкалды, шаулаштылар. Каеннардагы соңгы яфраклар, кинәт нәрсәдәндер куркышып кузгалган саргылт күбәләкләр кебек, көтүләре белән күтәрелделәр дә ашыгып җиргә кундылар.

Ә икенче агачтагы яфраклар тиз бирешмәде, боргаланды, ботакларыннан аерылмаска тырышты. Ә шулай да әнә берсе өзелде, әмма җиргә ашыкмады, очты, хәтта туган өрәңгесеннән дә биегрәк күтәрелде һәм әле бер ягын, әле икенче ягын күрсәтеп чайкалды – әйтерсең лә канатларын ал, кызыл, алтын төсләргә манган тылсымлы ярканат. Җәйге төсеннән чагыштырмаслык дәрәҗәдә матур, сокландыргыч бу яфраклар – карт өрәңгенең көзге яфраклары.

Ниһаять, шул гүзәл «ярканат» минем алдымдагы урындыкка кунды. Түзмәдем, алыйм дип кулымны суздым... Һәм туктап калдым.

Нәкъ шул урындык артындагы сукмактан кемдер, ашыгып, аксаклап, миңа якынлаша иде. Кечерәк чандыр гәүдәле, дала халыкларына хас кысык күзле, яңак сөякләре аз гына калку. Узып китәр дигән идем, киресенчә, миңа таба омтылды һәм, урындыкны атлап чыгып, мине

кочаклады:

– Йа Алла, кемне күрәм, син теремени?..

– Санҗе! – Мин дә ашыгып аны кочтым. – Чыннан да, синме бу, дустым Санҗе? – Күзләремә кайнар яшь тыгылды.

Санҗе Кәләев белән мин беренче тапкыр моннан кырык еллар элек Топорок колониясендә очрашкан идем. Кырык ел узса да, күңелдән китмәслек хәлләрдә...

2

Иртәнге барлауны уздыргач, вахтёрларның берсе, яшьрәге, тагын атылып-бәрелеп баракка килеп керде. Бар тавышына кычкырды:

– Староста, барактагыларның барысын да вахтага! Тиз!

Югары сәкеләрдән барак уртасына идәнгә култык таяклары шалдыр-гөлдер коелды, гадәттәге сүгенү, кычкыру, ыгы-зыгы башланды.

Вахта алдындагы мәйданга дүртәр саф булып тезелдек. Алда койрыкларына утырган ике аяксызлар, алар артында агач аяклар, аннан сукырлар, саңгыраулар.

Тирә-якта ап-ак кар. Зона аръягында күгелҗемләнеп урман күренә. Тайга. Шул урман артыннан хәзер канкызыл булып кояш күтәрелә. Офык та, урман да, янгын кабынган кебек, кызарганнан-кызара бара. Җил юк, коры суык. Тайга «янган» саен, суык көчәя бара – «тешли».

Вахтёрлар колонна буенча арлы-бирле йөгерә, суганлап-борычлап сүгенә. Җирдә утырганнарны аяклары белән тибеп, басканнарны этеп-төртеп сафларны тигезләргә, колоннаны «тантаналы парад»ка – түрәне каршылар өчен әзерләргә тырышалар. Әмма инде күптәннән басып торганга, иске-москыларга гына уранган тоткыннар туңа, калтырыйлар. Шуның өчен булдыра алганнары тырыша, сафны бозалар. Бу хәл вахтёрларны бигрәк тә үчектерә.

Ниһаять, вахта будкасының ишеге ачылып, колонна башлыгы чыкты. Ак тун, ак бәрән бүрек, соры киез итекләр кигән озын буйлы, чандыр гәүдәле, чытык чырайлы, урта яшьләрдәге кеше. Ул, ашыкмыйча, гәүдәсен төз тотып, хәрби адымнар белән атлап, безгә өтеп карап, колоннаның бер башыннан икенче башына үтте. Ялт борылды һәм,

кире килеп, урта бер җирдә колоннага карап туктады:

– Контрлар, әрәмтамаклар! – Кинәт ул берәү җилкәсенә сугып җибәргәндәй аваз салды, без сискәнеп киттек. Әллә инде акылдан шаша? Юк, акылында икән, бер-ике адым алга атлады да сүгенде. Кемнедер эзләгәндәй, алдагыларны сөзеп үтте. Куркып киттек: әллә инде берәребезне карцерга ябарга җыена? Аллага шөкер, тукталмады, тагын эре-эре атлап, колоннаның аргы башына үтте, тагын борылды һәм вахта янында команда көтеп басып торган вахтёрлар янына килде. Шул ук ачулы тавыш белән боерды: – Хәзер үк барысын да утын әзерләргә куарга! Мин аларны бушка ашатып яткырмам.

– Ә... ә... аяксызларны, – диде алдарак торган бер вахтёр, тотлыгып. – Аларны кайда, иптәш начальник?

– Кайда? – Тагын гасаби тавыш, ачулы караш. – Кайда, зонада утын киссеннәр. Аяклары булмаса, телләре озын, барыбер халык дошманнары, аналарын... барысын да Мария-Магдалинага олактырырга! – Түрә, тагын ике катлап сүгенеп, безгә карап төкерде дә, ашыгып атлап, вахтага кереп югалды.

Вахта капкасы ачылды.

Ыгы-зыгы башланды. Вахтёрлар аяклыларны бер якка, аяксызларны икенчегә кудылар, тезделәр һәм утын командасын капкага таба алып киттеләр. Ул арада вахтадан автоматларын кулларына алып, этләрен җитәкләп конвой чыкты. Саңгыраулар сукырларны култыклады, алар артыннан үз-үзләрен көчкә йөртүче күтәрәмнәр кузгалды.

Алдагылар койрыкларында шуышып, без таякларга таянып, вахтёр артыннан иярдек, тау-тау итеп өелгән юан-юан нарат агачлары янына барып туктадык.

Һәр дүрт мәхбүскә бер пычкы, тукталмыйча алмаш-тилмәш кисәргә. Балта юк. Зона эченә балта кертү – хәтәр. Утынны зонадан чыгарып яралар, өяләр. Озакламый бөтен зонада пычкы тавышы яңгырады, чинады, чырлады. Безне эштән караңгы төшкәч, урманга утын әзерләргә киткән команда кайткач кына туктаттылар. Ике тоткын анда үлгән. Аларны чана белән тартып алып кайттылар.

Катып, туңып, арып чайкала башлаган идек – баракка кергәч рәхәтләнеп киттек. Кизүләр ике мичкә дә яккан, җылы. Озакламый кичке баланданы китерделәр. Баракта бердәнбер лампа ишек төбендәге баганага эленгән. Аның

да куыгы чатнаган, корымланган, булыр-булмас кына яктырта. Чират зур, ыгы-зыгы.

Әле генә умарта оясы кебек мыжлаган барак тынычлана башлады. Бүлә торган бернәрсә дә юк, мичкәне, чүмечне әллә кайчан алып чыгып киттеләр.

Мин итекне баш очына мендәр урынына салдым да йокларга әзерләндем. Итекне мич янына куеп киптерсәк нинди әйбәт булыр иде дә, ярамый. Хәзер урлап китәләр, аннан яланаяк каласың.

– Иптәшләр! – Тагын ни булган? Торып утырдым, староста эндәшә икән: – Иптәшләр, тыңларга әзерләнегез, тавышланмагыз. Хәзер Конан Дойльның Шерлок Холмс маҗаралары турында хикәяләр укуны башлыйбыз.

– Әйдә, әйдә, башла.

– Көтәбез.

– Әй, агач аяк, акрынрак йөр, шыгырдыйсың.

Мәхбүсләргә бердәнбер юаныч китергән, аларның монда, чәнечкеле тимер кыршау эчендә җәфалануларын оныттырган нәрсә – старостаның кичке укулары гына иде. Артур Конан Дойль хикәяләре – алардагы исәпсез күп серле, четерекле вакыйгалар һәм аларны фаш итүче атаклы Шерлок Холмс һәм доктор Уотсон безнең хыялыбызны биләде. Староста гаҗәеп мавыктыргыч һәм искиткеч катлаулы «Сары йөз», «Бөкре», «Буш йорт», «Алты Наполеон» кебек хикәяләрне укыды. Күбесен мин дә кызыксынып тыңладым. Тик әле мин һаман аның бу зәгыйфь янган лампа яктысында ничек укуын төшенә алмый идем. Ниһаять, бер буранлы, без эшкә чыкмаган көнне мин староста Полотай Николай Исидорович янына кердем. Баракның такта белән бүлеп алынган кечкенә бүлмәсендә тумбочка, озын бер эскәмия, топчан (анда киез, одеял, мендәр – начальникларча тора!).

Мин кергәндә, ул, култык таякларын топчанга терәп, мөгаен, чыгып китәргә ашыгып, тумбочка өстендә бер исемлек язып утыра иде. Миңа борылды:

– Сезгә ни кирәк? – Киң маңгай, зур борын, ябык йөз һәм эчкә баткан зур күзләр. Болай да кансыз ак бите чытылып китте: күрәсең, минем керү ошамады – эшен бүлдем.

– Сез һәр кичне Конан Дойль хикәяләрен укыйсыз, бүген көндез шул китапны миңа биреп тормассызмы?

Староста, карандашын кәгазь өстенә ташлап, миңа

гаҗәпләнеп карады.

– Аны мин каян алыйм?

Бу җавапка инде мин тагын да ныграк шаккаттым.

– Нигә, сез һәр кич аны укыйсыз бит?

– Ә-ә, менә нәрсә, – ул кычкырып көлеп җибәрде. – Мин бит аны бары тик күңелдән укыйм.

– Күңелдән?

– Әйе, күңелдән. Монда һичбер төрле китап бирмәгәннәрен белмисезмени?

– Беләм.

– Шулай булгач?

Ул борылып карандашын алды да янә язарга тотынды. Мин, култык таякларымны рәтләп, чыгарга җыендым.

– Сезнең,– диде ул, кинәт тагын миңа карап, – иректәге һөнәрегез нинди иде соң?

Мин үземнең язу-сызу белән шөгыльләнгәнемне әйттем.

– Менә шәп! – Ул инде, миңа таба шуышып килеп, кулымны кысты, елмайды. – Менә очрашу! Утырыгыз. Мин дә язучы. Шагыйрь. Украинадан.

Без сөйләшеп киттек. Полотай миңа бу лагерьда бер казах, бер калмык язучысы булуын, анда-санда аларның үзе янына килеп чыгуларын әйтте һәм алар белән таныштырырга вәгъдә бирде. Мин бу көтелмәгән очрашуга-танышуга куанып чыгып киттем.

Николай:

– Буш вакытта кереп утыр, сөйләшербез, хәзер миңа исемлекне начальникка алып барырга кирәк, – дип, култык таякларына үрелде.

Бу очрашудан соң озакламый мин тагын бер бәлагә очрадым: калган ялгыз аягымны да сындырдым.

Бәхеткә, аягым бөтенләй үк сынмаган – чатнаган гына булган һәм ул тиз төзәлде. Әмма мин санбарактан чыгарга ашыкмадым.

Санбарак шул ук зонада, шул ук күп санлы баракларның берсе. Ләкин монда өске сәкеләр юк. Аска салырга төрле үлән-яфрак тутырылган «киез», одеял, мендәр бирәләр. Бу инде менә ничә еллар күрмәгән рәхәтлек – комфорт!

Мине дә шундый урыннарның берсенә китереп салдылар. Инде менә, врач килеп карап, аягымны гипска салырлар дип көтеп ятам. Чөнки аяк чатный, сызлый, үз-үземне

кая куярга белмим. Ә врач юк та юк. Мин инде кычкыра, сүгенә башладым.

Ул арада бер санитар килеп, минем тавышны басты:

– Акырма, врач юк, аны Мариинскига җибәрделәр. Хәзер имче килә.

Баракта иллегә якын авыру мәхбүс ята иде. Күбрәге дизентерия – эч авыруы белән. Ләкин алар арасында да ятарга була: урын йомшак, эшкә кумыйлар, җылы. Аякның сызлавы басыла төшкәч, йокы да килеп җитте...

– Яле, күрсәт аягыңны, ни булган? – Кемдер одеялымны күтәрде.

Уянып киттем. Каршымда ак халат кигән берәү. Буйга яшүсмер егет кебек кенә. Ябык, йөзе ап-ак, ләкин чәче, кашлары чем-кара, күзләре кысык, бит сөякләре калкып чыккан. Дала халыкларыннан: әллә бурят, әллә якут. Имче дигәннәре шул, ахры, одеялны алып ташлап, аягымны карарга җыенды. Аякта кырык тапкыр ямалган, төпләнгән киез итек, аны күргәч, «врач» санитарга кычкырды.

– Иван, пычакны алып монда кил.

Санитар Иван – яшь кенә таза егет, килеп, пиманы кунычыннан башлап башына хәтле ярып җибәрде, чолгауларны сүтте.

– Кая, мондамы?

Әйтеп бетермәде, мин сикереп киттем. Гүя аягыма икенче тапкыр бүрәнә төште.

– Чыда, түз... Иван, тас белән су алып кил!

Мин, кычкырмас өчен, иреннәремне тешләп яттым. Имче аякны тотып, селкеп, капшап карады да яныма утырды.

– Сынып ук чыкмаган, чатнаган кебек. Кузгалмыйча ят, хәзер бинт салырбыз. Исемең, фамилияң?

Ул блокнотына исем-фамилиямне язды да кайдан икәнемне сорады. Анысын да әйттем. Кинәт аның йөзе яктырып китте:

– Кайсы шәһәрдән?

– Күкчәтаудан.

– Шулаймы? – Ул мине кочаклап ала язды, кулымны каты итеп кысты.

Без шундук казахча сөйләшеп киттек. Менә бу, хәзер янымда утырган ак халатлы имче (лекпом) теге көнне безнең баракның старостасы Николай Исидорович Поло-

тай әйткән казах язучысы Зәен Шашкин икән. Без ул көнне бик озак сөйләшеп утырдык.

– Туган җирне дә, туган телне дә үтә сагынып калган идем, сезнең белән очрашу көтелмәгән сөенеч булды,– диде ул, аякны юып, бинт белән бәйләп мендәргә салгач.

Моннан соң, буш вакыты булган саен, Зәен яныма килә башлады. Сөйләшеп туя алмыйбыз. Сөйләшә торгач, уртак танышлар, язучыларның хәлләрен белештек. Ул атаклы шагыйрь – казахның Есенины Мәгъҗән Җомабаевның шигырьләрен укыды. Үзе – прозаик. Алма-Атада берничә китабы басылып чыккан. Язучылар союзы әгъзасы, Мәскәүдә тарих, философия һәм әдәбият институтын тәмамлаган булган.

– Сиңа нинди гаеп тактылар соң? – дим сүз арасында.

– Нинди булсын, – ди Зәен, калын кашларын җыерып, йөзен чытып. – Милләтчелек. Мин – совет чорында пионерда, комсомолда тәрбияләнгән егет. Аннан мин – ярлы казах баласы. Байларга мал багучы булу урынына, Совет хөкүмәте аркасында, Мәскәүдә укыдым. Кайдан килсен миңа милләтчелек.

– Анысы алай, ул тамганы барыбызга да бастылар. Ә менә син ничек врач булып киттең? – дим, ярым җитди, ярым шаярып.

– Каян врач булыйм мин, – ди Зәен, башын чайкап. – Барысы да авырудан башланды. Үпкәм чирле. Өйдә вакытта кымыз эчеп, җылкы ите ашап, далада саф һавада йөреп саклана идем. Төрмәгә эләккәч, кан төкерә башладым. Хөкем чыгарылгач, мине төрмә больницасына салдылар. Анда озак ятарга туры килде. Чыгарып җибәрмәс өчен, врачлар мине санитар итеп калдырды. Югары белемле булгач, латин хәрефләрен яхшы беләм, даруларны, аларның составын, рецептларын өйрәнә башладым. Булыштылар, үзем дә тырыштым, шуның белән врачлар арасына кереп киттем.

– Имче... монда кил... дару, – ди баракның аргы башында яткан бер авыру.

Зәен, әңгәмәсен өзеп, шул авыруга таба китә...

Аяк тиз төзәлде. Әмма Зәен, «аягы сынган, һаман берекми» дип, аны гел бинтта тотып, язга хәтле чыгармыйча үзендә саклады. Больницаны тикшерергә комиссия килә дигәч кенә, санбарактан чыгарырга мәҗбүр булды.

3

Санбарактан чыккач, элекке иптәшләрем янына эләкмәдем. Монда да Зәен Шашкинның ярдәме тиде. Ул мине «савыгучылар барагы»на җибәргән. Анда чынлыкта савыкмаслар, инде тәмам бетерешкәннәр җыела. Алар, билгеле, бер төрле эш тә эшли алмыйлар. Әмма баландалары куерак, ятарга урын-җирләре дә бар.

Менә мин шул баракка урнаштым. Монда бер катлы сәкеләр. Алар шыгрым тулган. Күбрәге кузгалмаучылар. Мин зона врачы урынына калган Шашкинның күрсәтмәсе белән килсәм дә, «урын юк» дип, озак кына барак төбендә тоттылар. Носилка белән бер мәетне алып киткәч кенә, шуның урынына – баракның иң аргы почмагына барып яттым. Яхшы урын – тәрәзә янында.

Хәзер инде кояш күбрәк карый. Көндезләрен кар эри, түбәләрдән тамчы тама. Яз килә. Ичмасам, тәрәзәдән табигатьнең алышынуын карап хозурланырга була.

Яттым. Миңа каршы сәкедә берәү ауный. Одеялга төренгән, бите генә ачык. Менә шул йөзне күрүгә калтырап киттем. Әллә инде бусы да аяк сузганмы? Бит җәенке, үзе карындык төсле сап-сары, күзләр кысылган. Борын почык, иреннәр күм-күк. Хәрәкәтсез. Урынга утырып, култык таякларымны стенага терәп куйыйм дигән идем, алар шалтыр-шолтыр шуып төшеп китте. Бу тавышка теге күршем күзләрен ачты, кузгалып куйды. Юк, әле тере икән, үзалдыма тынычлана төштем.

– Кайдан? – диде күршем, ярыйсы ук ачык тавыш белән.

– Санбарактан.

– Шашкин ничек анда?

Кара, аны да белә, әллә казах инде? Сынап карар өчен, казахчалап дәштем:

– Хәлегез калай?

– Ә? – Ул ишетми калдым дип, ахры, башын суза төште. – Ни дидегез?

– Гафу итегез, мин сезне казах дип уйлап, казахча эндәшкән идем.

– Юк, – ул торып утырды. Шыр сөяк! – Юк, күрше, мин казах түгел, калмык.

Ничек авызымнан чыкканын да белми калдым:

– Санҗе Кәләев.

Күршемнең карындык бите яктырып киткәндәй булды, кысык күзләр зураеп, гаҗәпләнеп карады.

– Кайдан беләсез?

– Шашкин миңа сезнең турыда сөйләгән иде. Полотайдан да ишеттем исемегезне.

– Менә сөенеч... Әллә сез дә язучымы?

Ул арада ишек ачылып, берничә вахтёр килеп керде. Без дә, сүзләребезне бүлеп, урыннарыбызга сузылдык.

4

Ниһаять, тайгага да яз килде.

Кар, акрын гына эреп, җиргә сеңеп югалды, озакламый яшел үлән күтәрелде. Зона тышында гына түгел, хәтта зонада да, бигрәк тә икенче кат чәнечкеле тимерчыбык киртәләре тирәсендә. Тыелган зонага бармасак та, читтән карап хозурланабыз. Зона артындагы урманнар да инде яшәрә-яктыра төшкәннәр.

Озак-озак шул урманнарга карап торабыз. Кайвакыт чәнечкеле тимерчыбык белән уратылган зона, манаралар да, анда корулы автомат тотып торган сакчы да югала – без табигать кочагында йөгерәбез, яшел чирәмдә ауныйбыз, кедр агачларына үрмәләп менеп, тәмле, майлы чикләвекләр ашыйбыз. Хыялда!

– Әй, контрлар, нәрсә авызыгызны ачып катып торасыз, таралыгыз! Хәзер атам.

Тик торудан иреккән сакчы, автоматын шалтыр-шолтыр китереп, безгә төби башлый. «Кызык өчен» бер очередь бирүе дә мөмкин аның. Рәнҗү һәм нәфрәт белән баракларга таба таралабыз. Мәлгуньнәр, табигатькә читтән карап күңелне тынычландырырга да бирмиләр.

Әмма безнең икенче бер юаныч бар иде. Әдәби кичләр. Анда-санда без – Санҗе Кәләев, Зәен Шашкин, Николай Исидорович һәм мин – йә Полотай, йә Шашкин кабинасына җыелабыз – казах, калмык, татар, рус әдәбияты классикларын искә алабыз һәм үзебезнең шигырьләрне укыйбыз. Бу кичләр ничектер күңелгә ял бирә, кайгыларны оныттыра, яшәү көче өсти, сүнеп барган өметләрне кабыза иде. Кызганыч, бу сөенеч тә озакка бармады.

Беркөнне безнең дүртебезне дә ашыгыч рәвештә вахтага чакырдылар, аннары конвой белән станциягә алып бардылар. Монда инде поезд килеп туктаган икән, безне, вагонга утыртып, Тайшетка алып киттеләр. Анда карцер-

да йокысыз төн уздырдык. Нәрсәгә, нигә, яхшылыккамы? Яманлыккамы? Иртә белән безне берәмләп яшь кенә, әмма салкын йөзле, усал карашлы хәрби тикшерүчегә алып килделәр. Ул, ниндидер бер папканы актарып, бер кәгазьне алды да коры гына итеп:

– Сез лагерьда контрреволюцион төркем оештыруда һәм Совет дәүләтенә каршы агитация алып баруда гаепләнәсез. Менә гаепләү акты, – диде.

Мин аптырап, хәлсезләнеп киттем. Култык таякларым ычкынды, дык итеп урындыкка утырдым.

* * *

Әле генә парк өстендә куерып, тулганып, менә-менә салкын тамчылар белән коендырам дип куркыткан көзге, шыксыз кара болытлар кинәт таралды. Инде күптән зарыктырган кояш күренде. Шундый якты, шундый җылы, үзе дә безне күрүгә елмая кебек. Тирә-як балкып, матураеп китте.

Без Санҗе белән йомшак талир тәңкәләр түшәлгән сукмактан, наратлар, чыршылар арасыннан сөйләшеп барабыз, бер-беребезнең хәлләрен сорашып туя алмыйбыз.

Кинәт ул, нәрсәдер исенә төшкәндәй, капылт борылып, миңа карады:

– Ә Зәен Шашкин кайда хәзер?

– О, ул Казахстанның атаклы романчысына әверелде. Рус, казах телләрендә күп әсәрләре чыкты.

– Ә хәзер?

– Хәзер ул вафат шул инде.

Санҗе сискәнеп, борчылып туктады:

– Ничек?

– Шул, лагерьдагы чире – үпкәдән...

Без озак кына сүзсез атладык, тынып калып, уртак дустыбызны сагындык.

Асфальт сукмакка чыккач, Санҗе тагын сорау бирде:

– Николай Исидорович Полотайның да язмышын белмисеңме? Әйбәт мәсәлләр яза иде, чукынган.

– Ул инде күп еллар Ялтада тора. Сатирик шигырьләр яза. «Крокодил»ның төп терәге.

– Молодец! Мин шулай булыр дип уйлаган идем. Адресын бир әле, хат язармын.

– Санҗе, – корпус бакчасында торган бер язучы аны күреп калып кычкырды, – тизрәк, сине Элистадан теле-

фонга чакыралар.

Санҗе, ашыгып атлап, инде сизелерлек аксап, телефонга китте, мөгаен, өеннән шалтыраталар. Ул хәзер Калмыкстанның башкаласы Элистада тора. Бик күп шигырьләр җыентыгы һәм проза китаплары бастырып чыгарган. Калмык хөкүмәте аңа «халык шагыйре» дигән мактаулы исем биргән. Күкрәгендә Монголия хөкүмәте ордены балкый. Шигъри хезмәтен югары бәяләп, Улан-Батырга чакырып биргәннәр бүләкне.

Җил исте, агачлар чайкалып китте, җиргә сары яфраклар коелды. Менә минем каршыдагы өрәңгенең каралган ялангач ботакларының берсендә япа-ялгыз бер яфрак җилферди, чайкала. Җил аны йолкып алырга тырыша, ләкин ялгызак яфрак үз оясыннан, туган анасыннан – карт өрәңгедән аерылырга теләми. Әле бер, әле икенче якка иелә...

Ләкин рәхимсез көзге җил ялгыз яфракка үчекте, карт өрәңгене арлы-бирле селкетте һәм, ниһаять, теге мескен яфракны ботактан йолкып алып ыргытты.

Алсу-кызыл төсләргә манылган йолдыз – өрәңге яфрагы, өзелгәч тә, җиргә сыенырга ашыкмады, агачлар арасына очты, калгынды. Ниһаять, хәлсезләнеп, каршымдагы куак арасына төшеп югалды.

Кеше гомере дә нәкъ шулай, өрәңге яфраклары төсле сызланып, саргаеп, янып-көеп, теләмичә генә өзеләдер. Мөгаен, шулайдыр.

1957–1981

ЭЧТӘЛЕК

Җан авазы. Аяз Гыйләҗев 5

Юл башы 8
Кояшлы бүлмә 68
Алла йортында 76
Ана тавышы 100
Таныш түгел дус 107
Кояш баеганда 139
Бер йотым су 144
Тын океанда 149
Линкольн приискасында 154
Мадрид 174
Бәйрәм бүген 188
Кара сакаллы кеше 193
Ике очрашу 209
Сандугач 218
Юлның соңы 230
Сагыну 263
Өрәңгеләр яфрак койганда 267

Литературно-художественное издание

Салахов Ибрагим Низамович

РАССКАЗЫ КОЛЫМЫ

Казань. Татарское книжное издательство. 2017
На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Салахов Ибраһим Низам улы

КОЛЫМА ХИКӘЯЛӘРЕ

Мөхәррире Р. Н. Шакирова
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире М. Д. Вазиева
Техник мөхәррире һәм
компьютерда биткә салучысы Г. С. Нуретдинова
Корректоры Л. Р. Галимова

16 + Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 г. №436 – ФЗ

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 25.08.2017.
Форматы 84×108 $^{1}/_{32.}$ Шартлы басма табагы 14,7.
Тиражы 2200 д. Заказ

«Татарстан китап нәшрияты» ТР ДУП.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.
Тел./факс: (843) 519-45-22.
http://www.tatkniga.ru
e-mail: info@tatkniga.ru

Татарстан китап нәшриятының фирма кибетләре:
Казан, Бауман урамы, 19. Тел.: (843) 294-70-50.
Казан, Бауман урамы, 29/11. Тел.: (843) 292-03-18.
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-13.

Маркетинг бүлеге:
Казан, Декабристлар урамы, 2. Тел.: (843) 519-45-35.

Интернет-кибет:
http://www.tatkniga.ru

«Татмедиа» АҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.